ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.1996



## ХАЛКЫБЫЗ ИЛБАШЫН САЙЛАДЫ



## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ АНТЫ

**Татарстан Республикасы халкына тугрылыклы хезмәт итәргә, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын тәэмин итәргә, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә, Татарстан Республикасы Президентының үземә йөкләнгән югары вазифаларын намус белән үтәргә тантаналы төстә ант итәм.**

**МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ**

***1996, 3 апрель***

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**4**

**(882)**

**1996**

КАЗАН

## *Бу санда*

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Үлемсезлек символы ... 3
**Тукайга чәчәкләр:** С. ХӘКИМ, М. ЛЬВОВ, Х. ТУФАН, М. КӘРИМ, С. МӘҮЛЕНОВ, Ә. ФӘЙЗИ, Г. АФЗАЛ, Ш. ГАЛИЕВ, Р. ГАТАШ, М. ӘГЪЛӘМОВ шигырьләре ... 5
Ә. АЛИЕВА. Тукай гомереннең бер елы. 1912 ел. 122
З. РӘМИ. Тукайның ачык һәм яшерен имзалары. 139
Ә. НИЗАМЕТДИНОВ. Габдулла Тукайның мәхәббәте. ... 146

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ә. ГАЛИЕВ. Җимерелгән хыяллар. *Роман.* ... 12
Р. МИҢНУЛЛИН. Җәйне озату. *Шигырьләр.* ... 68
Р. ҖАМАЛ. Галәм очкыны. *Шигырьләр.* ... 86

ХИСАМ КАМАЛОВКА 70 ЯШЬ

Әҗәлне җиңгән әдип. ... 74
Х. КАМАЛОВ. Сугышта устав юк... *Фронт истәлеге.* ... 75

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

Бу халыкта — таулар горурлыгы. М. МАМАКАЕВ, Р. ӘХМӘТОВА, А. ДУДАЕВА, Х. ЗИБУКАЕВ шигырьләре. ... 81
С. К. АКСАЛ. Кичке эңгер. *Хикәя.* ... 90

ӘДӘБИ МИРАС

Рәшит ӘХМӘТҖАН. Соңгы шигырьләреннән. . 96

ПУБЛИЦИСТИКА

БАТУЛЛА. Американы мин ачтым. *Сәяхәтнамә.* ... 103

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Б. ХӘМИДУЛЛИН. Татарларның этник тарихы турында уйланулар ... 150

ХАЛЫК ИҖАТЫ

Р. ИСХАКОВА-ВАМБА. Мишәр татарларының халык җырлары. ... 162

МӘДӘНИ МИРАС

Т. ӘЙДИ. Муса Акъегет Төркиядә. ... 172

КИТАП КҮЗӘТҮ

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ. Татар тарихы буенча яңа дәреслек. ... 178
М. ВӘЛИ. Сатира батыры. ... 182
С. ПОВАРИСОВ. Ил йөрәгендә тамырлансын. . 185

Безнең календарь ... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ... 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шәһиева**
**Харрас Әюпов**

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«К 110-летию Габдуллы Тукая»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА «Символ бессмертия»; «Цветы Тукаю»: стихи С. ХАКИМА, М. ЛЬВОВА, Х. ТУФАНА, М. КАРИМА, С. МАВЛЕНОВА, А. ФАЙЗИ, Г. АФЗАЛА, Ш. ГАЛИЕВА, Р. ГАТАША, М. АГЪЛЯМОВА, статьи А. АЛИЕВОЙ «Один год из жизни Тукая»; З. РАМИ «Псевдонимы Тукая», А. НИЗАМУТДИНОВА «Любовь Габдуллы Тукая».
«Проза и поэзия»: начало романа А. ГАЛИЕВА «Разрушенные мечты»; стихи Р. МИННУЛЛИНА, Р. ДЖАМАЛА.
«К 70-летию Хисама Камалова»: фронтовые воспоминания Х. КАМАЛОВА.
«Из литературы братских народов»: стихи чеченских поэтов М. МАЛАКАЕВА, Р. АХМАТОВОЙ, А. ДУДАЕВОЙ, Х. ЗИБУКАЕВА; рассказ турецкого писателя С. К. АКСАЛ «Вечерние сумерки».
«Литературное наследие»: стихи Рашита АХМЕТЗЯНОВА.
«Публицистика»: статья БАТУЛЛЫ «Америку открыл я».
«Со страниц истории»: статья Б. ХАМИДУЛЛИНА «Этническая история татар Поволжья».
«Народное творчество»: статья Р. ИСХАКОВОЙ-ВАМБЫ «Народные песни мишар-татаров».
«Культурное наследие» статьи Т. АЙДИ «Муса Акъегет в Турции» и Х. З. ОЛКАН «Муса Акъегет».
«Книжное обозрение»: рецензии Марселя АХМЕТЗЯНОВА, М. ВАЛИ, С. ПОВАРИСОВА.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: скульптурный памятник Г. Тукаю в деревне Новый Кырлай; лауреат премии имени Габдуллы Тукая, народный поэт Республики Татарстан Гамил АФЗАЛ.

Б е з н е ң а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шәһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 5.03.96 ел. Басарга кул куелды 5.04.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 331. Заказ Е-141.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

# ҮЛЕМСЕЗЛЕК СИМВОЛЫ

(УЛ — МӨНБӘР ТӘРӘЗӘБЕЗ)

Безяшәгән гасырның башыннан ахырына кадәр (алга таба да бу хәл, һичшиксез, шулай дәвам итәчәк) халык Тукайны олылый, бөекли, инде әллә ничә буын аңа иман китереп күңелен түгә. Ни өчен? Хикмәт нәрсәдә?

Һәр милләт, һәр халык — кавеменең исәбе-санына, җиренең зурлыгы-киңлегенә, үткән юлының гомумтарихта ни дәрәҗәдә беркетелеп калуына карамастан, бу Кояш астында тулы хокуклы яшәвен расларга һәм киләчәктә дә Җир йөзендә лаек урыны барлыгына һәм булачагына дәгъва кыла. Шуны Тарих алдында, бүтән халык-илләр алдында раслар өчен Аңа (милләткә) таяныр ноктадар, инандыргыч дәлилләр, рухи генетик потенцияне күрсәтә алырлык шәхесләр, бөек затлар кирәк.

Заманында миңа байтак халыкларның бөек саналган шәхесләренә багышланган тантаналарда катнашырга туры килде. Русларның — Пушкин, казакъларның — Абай, латышларның — Райнис, украиннарның — Шевченко, әзәрләрнең — Физули, төрекләрнең — Юныс Әмрә, кыргызларның — Токтогул, чувашларның — Иванов бәйрәмнәре... Татар әдәбияты вәкиле булып бу юбилейларда чыгышлар да ясарга туры килде. Фейерверклы рәсми тантаналардан соң ялгыз калгач, күңелгә төрле уйлар да килгәли иде. Ни өчен бу шәхесләргә, пәйгамбәр күреп табыналар да, аларны илаһ күкләренә күтәрәләр соң әле? Ярый, гомер кичеп зур иҗат калдырганнар. Ләкин бит алар моннан фәлән йөз ел элек булган бисклекләр. Ни өчен алар безнең өчен, киләчәк өчен гел өлге булырга тиеш соң әле? Һәркемнең үз йолдызы дигәндәй, иң әүвәл, алар үз халыкларының газизләре, нигә аларга бөтен дөнья баш иярга тиеш? Өстәвенә, адәм заты булып яшәү рәвеше буенча, бер генә каләм иясенең дә Тукай йәки Шевченконың, Мәгарри йәки Достоевскийның шәхси тормыш-хаяттә кичергәннәрен кабатларга теләгәнен ишеткәнебез юк... Әмма... гомер кичкән саен, яфраклары коелган урманда ерактагы агач силуэтлары да ачыграк күренгән сыман, яшьлектәге өермәле уйлар тынып-утырып калгач, фикерләр дә үзгәрә төште. Кирәк икән, бик кирәк икән үткән заманның кабатланмас Затлары! Чөнки, алар — Бөек! Бусы — бер. Ә һәр Бөек шәхес ул — гомумкешелек хәзинәсе. Әгәр Бөек булсаң —

Нечкә җанлы, чын иманлы
булып туuың кирәк.
Шатлык-кайгыңны анларлык
җирлек булуы кирәк.

Шагыйрь булсаң, Дөнья өчен
давың, януың кирәк.
Януыңны күп халыклар
күмәк тануы кирәк.

Икенчедән, югарыда әйтелгәнчә, милләтне милләт итеп раслар өчен кирәк аларны олылау. Үзеңне үз милләтең баласы итеп, Кеше итеп тояр

өчен кирәк икән! Шулай булмаса, үзләрен зур милләт итеп дөньяга таныткан, тарихта тирән эз калдырган милләтләр, әйтик, алманнар үзләренең Гете, Шиллер; инглизләр — Шекспир, Байрон, испаннар — Сервантес, итальяннар — Дантеларын шулай планета масштабында күтәрмәсләр иде. Болары — Гареп цивилизациясеннән. Ә Шәрекъ дөньясыннан күпме бөек исемнәрне атап булыр иде!

Билгеле хакыйкать: күтәрердәйне генә, булганны гына күтәреп була. Максат куеп чөяр өчен мәгълүм масса-авырлык кирәк. Кош мамыгын ыргытып булмый. Аны җил кая тели, шулай өреп йөртәчәк. Рухи сабантуйда яңа буыннар киләчәккә алып барыр өчен Үлемсез Иҗат булу фарыз. Үлемсезлек турында уйланырга безнең өчен Тукай — иң кулай мисалларның берседер.

Үлемсезлек — бөек мәгънәгә ия сүз. Ул, мөгаен, Кешелек хыялының иң биек ноктасыдыр. Үлемсезлек юлын беркем тәгаен генә кистереп күрсәтә алмас. Юкса, әкиятләрдә Әбелхаят суын эзләмәсләр, Фаустлар алданмас, Ләйлә-Мәҗнүннәр харап булмас, Гайсә пәйгамбәрләр кадакланмас, фидакарьләр утларга ташланмас иде... Шулай да, без аңлаган асылында, Үлемсезлек юлына баруның кайбер төп нигез принциплары бар ул: ул — заманның чын мәгънәсендәге гадел һәм зирәк баласы була алудан, ягъни дәвереңнең төп проблемаларын чишү үзәгендә булудан, үз халкыңның мәнфәгатьләрен кайгыртудан (Вакыт галиҗәнапләре күзгесендә һәр халыкның үз хәлләре), киләчәкне анык күрә алудан гыйбарәт. Тукай — минемчә, бу принципларның һәммәсенә дә туры килгән шагыйрь.

Халык күңеленең тагын бер ягын онытмыйк: дөньялыктан пәйгамбәрләрчә яшьли янып китү — мәңгелеккә баруның тәгаен бер ышанычлы юлы. Безнең халык яшьли фаҗигале үлемгә дучар булган кызга яки егеткә тикмәгә генә җыр-бәетләр чыгармаган. Тукай бу яктан да Үлемсезлек кодексына бик туры килә.

Һәм, ниһаять, бер Бөек затны тану, аның олуглыгын бәяләү өчен, чорына лаек замандашлары булуы, илаһи рухны киләчәктә дә саклап, олылап бару өчен оныклары кирәк — яңа буыннарның тууы кирәк. Сандугач тавышын аерыр өчен бихисап кош сайравын тою-белү кирәк... Бу җәһәттән дә Тукай бәхетле шәхес. Чөнки аның иҗат чоры гаҗәеп дәвергә — халкыбызның гасыр башындагы олуг күтәрелеш-ренессанс чорына туры килә. Халык бөеклегенең рухи маякларын төгәл ачыклау, барлау заманы ул. Аннан соңрак дәвер буыннары рухи биеклекне тану, бәяләү буенча тагын да зирәгрәк булдылар — Тукайны бөек итеп танып, аны киләчәккә илттеләр. Ни генә димик, бу очракта бөеклекнең төп сәбәпчесе, әлбәттә, Тукай үзе, гаҗәеп иҗаты: XX йөз башында Россия киңлекләрендә шагыйрьләрдән бердәнбер диярлек уникаль шәхес бит ул! Ятим үсеп, дәүләт уку йортлары күрмичә тәрбияләнеп, бик аз гомер яшәп, ятимлек һәм ялгызлык кичереп, биш-алты томлык мәңгелек әсәрләр язган иҗатчы дип ул чорда тагын кемне атап була соң?

Хәер, үз бәһасен Тукай үзе дә яхшы белгән. Бу җәһәттән кечкенә генә лирик чигенеш. 1974 елның июлендә Михайловскоеда Пушкин бәйрәме үткән көннәрдә куен дәфтәремә мондый юллар язылган:

Йолдыз, Кояшларны күрми торып,
ничек белмәк кирәк бу Айны!
Мин, Пушкинның торган җирен күреп,
бөеклеген тойдым Тукайның.

Һәм, ниһаять, бу юлларны язган чакта, янә бер мәртәбә Тукай томлыкларын актарганда, аның «Пушкин вә мин» дигән шигырендәге мондый сүзләргә юлыктым.

...Шунда да күрмим үземне һич тә Пушкиннан түбән;
Тугъры күз салсаң эшенә — ул үзе миннән түбән!

Мин берәүне дә түбән йә югары санарга теләмим. Әмма — сүз әйтелгән!

Шагыйрьнең юбилее уңаеннан Татарстан китап нәшрияты берничә сувенир китап чыгарды. Шуларның берсе — төрле халык, төрле буын шагыйрьләренең бөек Тукай хөрмәтенә багышланган шигырьләр тупланмасы. Гомумән, Тукай хакында шигырь язмаган бер генә татар шагыйре бармы икән? Ул гына да түгел, башка халык шагыйрьләре, әдипләре дә аның турында үзләренең ихлас фикерләрен әйтеп калдырганнар, шигырьләр иҗат иткәннәр. Шуларны туплап 1976 елда, төзүче буларак, «Тукайга чәчәкләр» дигән бер җыентык чыгаруда катнашкан идем. Менә 20 еллап гомер үткәч янә бер китап. 20 ел эчендә Тукайга багышлап язылган шигырьләр никадәр ишәйгән! Аларда инде яңа төсмерләр, киләчәккә төбәлгән яңа мотивлар. Элек язылган әсәрләрдә «сүнде йолдыз», «калдырды үксез милләтен», «һәммәбезгә син әрәм» кебек тәгъбирләр өстенлек итсә, соңгы чорларда «Тукай безнең белән», «Син яшьтәш тә, замандаш та», «Тукай үлемсезлеген син озайтырга бурычлы», «Мин Тукайга барам» кебек күтәренке рухлы юллар хас.

Әйе, безнең халык та кояш астында үзенә урын даулый. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаганмы?» дигән сорау, шөкер, хәзер юк инде! «Уянып торып баскач нишләргә? Ничек хәрәкәт итәргә?» Менә төп тойгы — хис-уй! Тернәкләнеп, үз хакыңны даулау чорында — Тукай иҗаты үзе бер таяныч! Үзаңы уянган халык вәкилләре, бу очракта шагыйрьләре, Тукайга багышланган шигырьләре аша үзләренең иң мөкатдәс, иң изге идеалларын ачыклыйлар шикелле. Ул — югалган Дәүләтчелегебезне кайтару. Ул — Дөньяның иркле халыклары гаиләсендә булу. Бу хыял-максатка ирешү юлында Тукай үзе бер юлкүрсәткеч, үзе бер тәрәзә. Без шул мөнбәр тәрәзә аша, күзләребез яшьле булса да, кояш ягына таба карыйбыз.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*1995, декабрь.*

## ТУКАЙГА ЧӘЧӘКЛӘР

## Сибгат Хәким

* * *

Кирәк түгел төрле афишалар,
Кирәк түгел төрле игъланнар,
Бәйрәм икән, юбилее икән,
Тукай үзе йөри иң алдан.

Көе, моңы — бар да үзенеке,
Хәсрәтләнмә:— Каян җыр алыйк?
Тукай диден — хәрәкәткә килә
Халык үзе, үзе зур тарих.

*1976*

* * *

Бар татарда ничә йөзләп шагыйрь,
Һәр шагыйрьне истә тот аерым,
Кайта идем уйлап мин шуларга
Йогынтысын бөек Тукайның,

Яшен кырны яктыртты шул вакыт,
Күренеп китте юлда ат кабат,
Күренеп китте басу уртасында
Карт карама белән карт нарат.

Яшен кырны яктыртты берьюлы,
Менә, дидем, читен мәсьәлә,
Кайсына соң күбрәк төште якты?
Карамага? Атка? Нәрсәгә?

Яшен кырны яктыртты бертигез,
Бер кыр — бер чор кинәт гөлт итте,
Күз алдында җир яшәреп китте,
Берсен берсе узышып гөл китте.

*1978*

## Михаил Львов,

рус шагыйре

### Түбәтәй

Булдым мин Жаркентта,
Чимкентта, Ташкентта.
Утырдым идәндә,
Үләндә, брезентта.
Май ае кымызын
Киң дала түрендә
Эчтем мул мәҗлестә,
Казакълар җирендә.
Түбәтәй кигәнгә
Дусларны каратып,
Казакълар татарча
Сөйләште яратып.
Күрәсең түбәтәй
Аларга ошаган:
Син, диләр, кадерле
Тукайга охшаган,
Ә Абай токымы
Мактагач, бигрәк тә,
Май булып урнашты
Яхшы сүз йөрәккә.
Тукайга, Тукайга
Охшауны сөям мин,
Башыма таҗ итеп
Түбәтәй киям мин.

*Мөхәммәт САДРИ тәрҗемәсе*

## Хәсән Туфан

* * *

Һаман шулай, даһи егет хәлдә,
Олы юлда безнең сафларда,
Иң сыналган байракчыбыз сыман
Нурланасың алгы якларда.

Табыш та күп булды, югалту да
Күченгәндә иске доньядан.
Тик җуймадык, саклап калдык,
Безнең белән бергә син һаман.

«Халык гомере — мәңгелек»,— диләр,
Бу — сыналган, тугры сүз бугай.
Килер гасырларның аръягын да
Илең белән бергә уз, Тукай!

Алтын мирас итеп алдык сине,
Вәкил хәлдә татар иленнән.
Кул бирерсең килер гасырларга
Яңа чорга безнең исемнән.

## Мостай Кәрим,

Башкортстанның халык шагыйре

### Тукайга

Якты көнгә чыгып җитә алмый,
Күмелеп калган шахтер шикелле,
Сөйгән монологын сөйләп бетми,
Тынып калган актер шикелле,
Агуланган тынчу караңгыда
Янып бетми сүнгән шәм кебек,
Сахрадагы язгы елга кебек
Ташты да ул, тынды яшь егет.

Язгы кырау яфракларын бәргәч,
Кинәт кенә шиңгән гөл кебек,
Искелекнең тынчу һавасында
Тыны бетеп үлде яшь егет.

Без, давыллар булып, күгебезне
Кара болытлардан тазарттык,
Без — икенче туфан —
Җиребезне
Искелектән юып яңарттык.

Тукай җыры безнең белән килде,
Җыры ялкын аның бүген дә.
Тукай... Ул бит безнең якты йолдыз
Поэзиянең аяз күгендә.

## Сырбай Мәүленов,

казакъ шагыйре

### Тукай кабере янында

Киттең, Тукай,
Үттең, Тукай,
Йөрәкләрне яндырып,
Иңрәде ил,
Тетрәде җир,
Каплады кара болыт.

Кыска булды,
Иртә сүнде
Яшь гомерең, моңлы-зарлы.
Утка атып,
Кан елатып
Ташлап киттең Казанны.

Үтте еллар,
Үсте җырлар,
Син яңадан уяндың,—
Озын гомерең!
Кабат менден
Биегенә кыяның.

Тукай — яшь-яшь,
Абай — ак-чәч,
Үлмәс җаннар булдыгыз,
Берегез — монда,
Берегез — анда,
Йөрәкләрдә урыныгыз.

*Нури АРСЛАНОВ тәрҗемәсе*

## Әхмәт Фәйзи

### Габдулла Тукайга

Белмим, кайсы таулар күкрәгеннән
Һәйкәлеңнең ташы, тимере,—
Тик син үзең халык йөрәгеннән,
Халык мәхәббәте — синең исемең.
Халык гомерең — синең гомерең.

## Гамил Афзал,

Татарстанның халык шагыйре

### Йөрәгемдә йөртәм сине

*...Ял иткәндә, ятып укыйм кичтән сине,*
*Тору белән алып укыйм иртән сине.*
*Ак кәгазьдәй намусыма судья итеп,*
*Гомер буе йөрәгемдә йөртәм сине.*

Тукай — остаз, Тукай — шагыйрь, Тукай — ага,
Кызыл гөлләр башын игән сиңа таба:
Идел суы, синең яннан узган чакта,
Дулкыннарын әкрен генә ярга кага.

Җырларыңа хозурланып ил шатлана,
Бүрек салып керәбез без җыр бакчаңа:
Яшең белән сугарылган бу гөлләргә
Баккан саен сабыйлардай җан сафлана.

Күңелләрдә озак еллар, озак еллар
Янып торган, уйнап торган нурларың бар;
Туган илнең ташларына хисең белән
Ядкарь итеп уеп язган юлларың бар.

Тукай, халкым йөрәгенең ярасы син,
Ил алдында ил күзенең карасы син;
Токымнарның юлларында юлдаш булып,
Халык белән мәңгелеккә барасың син.

## Шәүкәт Галиев,

Татарстанның халык шагыйре

### Туры Тукай

Ул ятим дә, ул мескен дә диеп
Сөйләнелгән элек-электән,
Күз алдына аны боек итеп
Китерергә күпләр күнеккән.

Әйтерсең лә, Тукай бар гомерен
Арка туңып кына яшәгән?
Ләхәүләсен укытып Ишмиләрнең
Яшен булып шагыйрь яшьнәгән!

Әйткән сүзе — аткан угы һәрчак
Туры тигән, читкә китмәгән,
Зирәк халык аны юкка гына:
«Туры Тукаебыз» димәгән!

Мескен халык, мескен хаклык булмый,
Мескен шагыйрь була дисеңме?
Батыр дигән сүзгә рәттән куйыйк
Тукай дигән горур исемне!

Якты йолдыз булып атылган ул,
Зэгыйфь чэчэк булып сулмаган.
Туры Тукай, моңлы Тукай булган,—
Бөек булган, боек булмаган!

## Рәдиф Гаташ

* * *

Шигърият!
Тагын җаныңны
Барлый яз — чираттагы...
Нурланып яна биектә
Тукайның мирас тажы...

Уй житә алмас — шигъри тажң!
Бармы, әйт, сиңа лаек?!
«Мин!» — дигәннәрне, варис, дип
Танырмы, йә, ил-халык?!
Хакның тик исемен әйткәнгә
Әҗер без көтмибезме?!

Изге кәгъбәгә — пакьсезләр,
Исерекләр — үтмибезме?!
Көч-дәрәҗәбез бар, бәлки,
Йолдызга үрелергә?!
Ходай... аһ, Тукай каршында
Курку да булса бездә?!

Ә бармы моңсыз — шигърият?!
Әдәпсез — әдәбият?!
Үзең әйт, шигырь алласы,
Вөҗданны безнең уят?!

Мәңгелек җыр — Туган телне
Котлый яз — чираттагы...
Биектә һаман — кул җитмәс,
Сатылмый, вакланмый торган
Шигърият —
Тукай тажы!

## Мөдәррис Әгъләм

### Әйтте Тукай

*ТИҮ Ирек мәйданына кертелмәде,*
*Тукай һәйкәле янына җыелды.*
(Газета хәбәреннән.)


Халыкларның җиде юл чатында
Бәхәсләшеп торган чаклары...
Тукай сискәнер дип уйладым мин,
Ә ул...
Керфеген дә хәтта какмады.

Әйтте сыман: «Мине чит иттегез,
Тәгәрәшеп миннән көлдегез;
Мәйданыгыз ирек бирмәгәнгә,
Ирек сорап миңа килдегез!

Бишенче ел без уянганда да,
Әйе, андый хәллар бар иде...
Ул мин идем «Долой!» «Долой!» сүзен
Кычкырган бер татар шагыйре...»

Шулай әйтте Тукай иреннәре...
Һәм сөйлиләр:
Азмы малайлык!
Үткәнне һәм бүгенгене белми
Кычкырулар — шул ук «долойлык»!

Әйтте кинәт Тукай: «Митингка
Вакытыгыз бетте, барыгыз!
Хөр мәмләкәт, хөр Русия сезгә
Кирәк икән,
Яулап алыгыз!»



Әнәс
Галиев

# ҖИМЕРЕЛГӘН ХЫЯЛЛАР

РОМАН

## I

Февраль азаклары иде.

Галләм иртәнге поезд белән юлга чыкты. Шәһәр яны поезды көнгә өч мәртәбә: иртән, көндез, кичен йөри. Кайчан гына утырма, вагоннарда аяк басар урын да булмый, аркасына аллап-артлап капчык аскан халык кереп тула. Авыл шәһәрдән икмәк ташып тамак туйдыра. Авызыннан өзеп ит, май, йомырка алып килә дә, көче житкән кадәр икмәк күтәреп кайта. Галләмгә шулар белән эшләргә туры киләчәк. Уртак тел таба алырмы, әлегә әйтүе кыен.

...Сугыштан соң озак кына вакыт аның тормышы җайланмады. Фронттан марҗа ияртеп кайткан иде, килешә алмадылар, аерылырга туры килде. Хатыны куып чыгаргач, ничек янып-көеп йөргәнен үзе генә белә. Түзде...

Сабыр төбе сары алтын, ялгыз дүдәк булып озак йөрмәде, үзенә тиң хатын табылды. Бәхетенә күрә — татар хатыны. Менә дигән итеп тормыш корып җибәрделәр. Алма кебек ике балалары бар. Марҗа исенә төшсә, элеккеге җүләрлегенә ушлары китә.

Тик, гөрләп яши башлагач кына, тормышы үзгәрергә тора әле. Галләмне авылга эшкә җибәрәләр. Таптылар бер күндәм адәм, һаман аны җигәләр. Бу юлы калып торса да ярый иде югыйсә...

Бөтен илдә шау-шу куптарып утызмеңчеләр кампаниясе башланды. Шәһәрдән авылга кеше җибәреп, ахыр чиккә җиткән киеренкелекне тоткарларга исәплиләр. Имеш, җитәкчелеккә каты куллы кешеләр куялар да, тәртип нигыталар. Гадәттәгечә, бу эш тулысы белән коммунистларга йөкләнә. Кандидат сайлаганда, беренче чиратта аның партия стажына, партия сафында үзен ничек тотуына игътибар ителә. Дөресрәге, өстән бирелгән күрсәтмәне бернинди каршылыксыз үти торган кеше булырга тиеш. Авыл хуҗалыгы белән таныштмы, таныш түгелме — кызыксынып

тормыйлар. Бу сыйфатларны күз алдында тотканда Галләмгә тел-теш тидерә торган түгел. Шәһәр малае. Партиягә фронтта, һөҗүмгә барыр алдыннан керде. Орден-медальләре санап бетергесез. Запастагы совет офицеры — майор.

Шулай итеп, эш урынычдагы башлангыч партоешма тарафыннан утызмеңче итеп тәкъдим ителде. Тәкъдим хуҗа кушуы буенча эшләнде. Аңа көндәшеннән котылырга кирәк иде. Акылы бар җитәкче үзеннән өстен хезмәткәрне аппаратта тотамы соң? Хәер, ул вакытта Галләм мондый мәкерне аңларлык дәрәҗәдә түгел иде әле. Партия кушкан эшне изге санап, кая җибәрсәләр дә барды, карышмады, ә бу юлы беренче мәртәбә уйга калды. Авылда торып калган очракта, хатыны Шәфика анда барырга риза булачак түгел. Ирле-хатынлы бергә яшәмәгәч, нәрсә килеп чыкмас?

Җибәрмәүләрен үтенеп райком секретаре янына кереп караган иде, сүзне кыска тотты:

— Йә колхозга эшкә китәсең, йә партбилетыңны өстәлгә сал,— диде. Партбилетсыз яшәүне күз алдына да китерә алмый Галләм. Әллә, юкка гына аны күз алмасы кебек саклап, сул як куен кесәсендә, йөрәге турысында йөртәме?!

Ахыр чиктә хатыны Шәфиканы җигеп карады. Атна буе өлкә комитеты бусагасын таптап, ул да юньле эш майтара алмады.

Утызмеңче булып китүчеләрне беренче секретарь үзе кабул итеп, әңгәмә үткәрде. Ул аларны партиянең алтын фонды дип атады. Аннан егермебишмеңчеләрне искә алып, күмәкләшүнең беренче елларында алар башкарган эшне күккә чөеп мактады, шуларга тиң булырга өндәде.

— Сезгә каһәр суккан сугыш аркасында таркау хәлгә килгән колхозларны аякка бастыру бурычы йөкләнә,— диде.— Мондый җаваплы эшне ышанып тапшырган өчен һәркайсыгызда горурлык хисе уянырга тиеш.

Ул бер сәгатькә якын фәлсәфә сатып, сугыш елларында колхозларның илне, армияне азык белән тәэмин итүдә хәлиткеч роль уйнавын сөйләде.

— Сез авылга даими эшкә җибәреләсез, беренче көннән үк гаиләгез үзегез белән бергә булырга тиеш,— диде әңгәмәгә йомгак ясап. Сүз дә юк, эшлекле киңәш. Ләкин әле: киңәшне тыңла, үзеңчә эшлә, дигән сүз дә бар бит. Тормыш һаман бер урында тормый, кай чагында көне, сәгате белән үзгәрә. Галләм шуны уйлап шәһәр тирәсеннән ерак китмәскә тырышты. Теләгенә иреште дә. Аны шәһәр янындагы бер районга тәгаенләделәр. Андагы җитәкчеләр белән танышып килергә уйлап, бер-ике көнгә генә дип кайткан иде, райком секретаре кызу тотты. Чанасына утыртып, үзе эшләячәк колхозга ук алып китте.

Галләмгә кадәр бу колхозга рәислеккә ике кешене тәкъдим итеп карадылар — халык берсен дә кабул күрмәде. «Безгә үзебезнең авыл кешесе кирәк»,— дип, сүзендә нык торды. Лаеклы кандидатлары да бар иде. Әмма ул партия члены булмагач, райком аны рәис итеп куярга ризалык бирмәде. Ничек инде колхоз кадәр колхозга партиясез кешене хуҗа итеп тәгаеннәргә кирәк?!

Бу юлы алдан әзерлек алып барылды. Партбюро секретаре Фатыйма, берничә куштанны көйләп, җыелышта райком тәкъдим иткән кандидатны яклап чыгыш ясарга күндерде.

Җыелыш көздән бирле ягылмаган клубта уздырылды. Бик салкын көн иде. Халык аз җыелды. Салкыннан да бигрәк, мондый җыелышлардан тәмам гарык булганнар иде инде. Йорттан йортка йөреп җыелышка өндәүчеләр хәлдән таяр дәрәҗәгә җитте. Кайсы авыруга сабыша, кайсы качып кала. Ахыр чиктә райком секретаре кул селтәде:

— Бар булганы җитеп торыр, җыелышны үткәрәбез,— диде.

Тартып-сузып җыелыш законлаштырылды. Иң кирәге, беркетмә төзелде. Колхозда бу эшнең остасы, хисапчы Шакиров Таһир бар. Ул төзегән документка черки борын тыгарлык та булмый.

Шулай итеп, Галләм үзенең колхоз рәисе булып сайлануын сизми дә калды. Алдан әзерлеген күргәч, шома узды...

Җыелыштан соң Галләм райком секретаре рөхсәте белән шәһәргә — өенә кайткан иде. Менә бүген инде яңа билгеләнгән урынга эшкә бара. Гаиләсен калдырып китү авыр булды. Божыр кебек житез хәрәкәтле жиде яшьлек улы Фәрит «әти тиз кайт» дип кычкырып калды.

Галләм үзе белән артык бернәрсә дә алмады: өстендә бер кат кием — армиядә хезмәт иткәндә киеп йөргән тире тун, аякларында шул вакытта модага кергән күн аслы ак фетр итек. Тун астында погоннары алынган хәрби гимнастерка, галифи чалбар, биле солдат каешы белән буылган. Кулында кечкенә генә чемодан. Чемоданны алырга исәбе юк иде Шәфикасы көчләп дип әйтерлек кулына тоттырды. Анда бер пар күлмәкыштан, сөлге, сабын, тагын төрле вак-төяк әйбер салынган.

— Син нәрсә, кунакка барам дип беләсеңме әллә,— диде хатыны ярым шелтәләп. Вокзалга да озата төшмәкче иде, Галләм рөхсәт итмәде:

— Мин бит ерак китмим, көн саен булмаса да, атнага бер мәртәбә кайтмый калмам,— диде. Ә капкадан чыгу белән ничек итеп колхоздан котылу турында план кора башлады.

Ялга каршы көн булгангамы, бүген поездда халык аеруча күп иде. Галләмне бер кырыйга китереп кыстылар, кабыргалары сынамы дип тора. Ул арада сасы ис аңкып күңелне болгата башлады. Ярый әле, артык озак барасы түгел, ярты юлны үткәч, кечкенә бер станциядә төшеп калырга кирәк. Тик менә ничек төшеп калырга? Ишек янына узып булмый. Ничек итсә итте, иңбашлары белән төрткәләп шунда үрмәләде. Бер марҗаның җайсыз жиренә бәрелдеме, ул ачыйгланып кычкырып жибәрде һәм аның аркасын дөмбәсләргә тотынды. Галләм нишләгәнен белешмичә аны бер кырыйга этәрде, хатын ирләр кебек сүгенеп тагын да ныграк акыра башлады. Шулай маташа торгач, Галләм үзенә төшеп калырга кирәкле станциягә килеп житүләрен сизми дә калды. Ярый әле абайлап өлгерде, югыйсә, узып китүе дә бар иде. Бөтен көче белән ишеккә ыргылды һәм жиргә сикерде. Ул елларны юлда барганда хәзерге кебек вагон ишекләре бикләнми, поезд килеп тукталган урында менептөшеп йөрер өчен махсус эшләнгән платформалар да юк иде.

Поездлан бик күп халык төшеп калды. Барысы да янгын вакытындагы кебек ашыга, аркасына аскан йөге җиңелрәкләре хәтта йөгерә дә. Галләм салмак атлап шулар артыннан юнәлде. Аны алмага килергә тиешләр. Бер кырыйда чыпталы чанага жигелгән ат күреп, шунда китте. Барып житкәндә чананы капчык аскан хатыннар уратып алганнар иде инде. Һәркайсы иңенә аскан йөген чанага ыргытырга тырыша. Яшүсмер малай, чыбыркы белән селтәнеп, берсен дә якын жибәрми. Галләмнең үзе алмага килгән кеше икәнен сизеп булса кирәк, малай ук кебек атылып аның каршысына килеп басты:

— Абый! Сез безнең прсидәтелме? — Җавап көтеп тормады, кире ат янына йөгерде. Ул китеп торган арада чана капчыклар белән тулган иде. Малай әтәчләнеп аларны чанадан жиргә өстерәп төшерә башлады. Ике таза хатын тиз генә кулларын артка борып тотып, аңа кыймылдарга да ирек бирмәде. Житмәсә малай тагын калын киенгән: өстендә кырык ямаулы, сарык тиресеннән тегелгән иске тун, аякларында тула оек белән чабата. Башында иләмсез бүрек, колакчыннарын төшереп муен астыннан бәйләгән. Ике күзе генә ялтырап күренә.

Галләм хатыннар белән малай арасындагы таркалашны күргәч кенә поездлан төшкән халыкның ни өчен чабышуын аңлады. Монда ат жигеп заготзернога килүчеләр була икән. Барысы да алданрак барып, аркасына асып кайткан йөген атка салып жибәрергә ашыга. Салкын булгангамы, бүген Галләмне алмага килүче малайдан башка ат жигеп килүче күренми иде. Һава яхшы көнне исә юк йомышны бар итеп, ат жигеп килүчеләр дә очраштыргалый. Чөнки акмаса да, тама. Һәркайсы йөген атка салып кайткан өчен хәл кадәренчә түли.

Галләм чанага төялгән капчыкларга карап торды да:

— Боларның хуҗалары бар да сезнең авылларммы? — дип сорады.

— Син, иптәш прсидәтел, безне монда ташлап калдыра күрмә инде, — диде, сакалына ак кергән таза гәүдәле бер ир сүзгә кушылып. — Бөтенебез дә бер колхоздан, Ленин колхозыннан.

Тез тинентен гәүдәсе калын шәл белән уралган бер хатын тиз генә чана түрендәге капчыкларны алгарак күчереп, Галләмгә утырып кайтырга урын әзерләде:

— Менә монда сез сыясыз, — диде, арты белән басып торган Галләмнең иңбашына йомшак кына кулы белән төртеп. — Җилгә аркан утырыгыз...

Галләм атны күзәтеп, аның сүзләрен игътибарсыз калдырды. Аңа ат көчкә аягында басып тора кебек тоелды. Коры сөякка калган, кабыргалары санарлык.

— Әтүтән! Нәрсә шаккатып торасың, алып чык атны юлга! — дип әйткән сүзләрне ишеткәч, сискәнеп китте.

— Кем ул Әтүтән? — дип сорады янындагы хатыннан. Ул башта кычкырып көлде, аннан җитди сөйләшүгә күчеп:

— Ат җигеп килгән малайның кушаматы, — диде, кыскача гына аңлатма да бирде. Аның чын исеме Фәйзерахман икән, гел начальство янында чуалып, аларның йомыш-юлына йөргәнгә, иптәш малайлары аңа шушы кушаматны такканнар — «адъютант»ның татарчасы. Соңгы вакытта авылдашлары аны бары тик кушамат белән атап йөртәләр икән.

Менә ат капчыклар төялгән чананы өстерәп олы юлга чыкты. Капчык хуҗалары кыр казлары кебек аңа иярде. Галләм дә шулар янына барып баскан иде, аны көчләп дип әйтерлек чанага утырттылар.

Көн гадәттән тыш салкын. Каршыга җәяүле буран өрә. Галләм чанага утырып озак бара алмады. Иң элек аякларына «таракан керде». Ак фетр итек шакырдап катты. Аны киеп мондый салкында юлга чыгарга ярыймы соң? Күн итектән әлләни аермасы юк. Колаклары туңганга чыдар хәле калмагач, бүрек колакчыкларын төшереп ияк астыннан бәйләп куйды. Салкын эченә үтә башлагач, инде чанадан төшеп, ат артыннан тәпи-тәпи атлады. Урыны-урыны белән юлны кар көртләре каплаган, җырып йөри торган түгел. Галләм мондый буранлы көндә юлга чыгуына үкенеп куйды. Кичтән махсус радио тыңлап ятты. Синоптиклар яхшы һава вәгъдә иткән иде югыйсә... Хәзер беркемгә дә ышана торган түгел. Кем ничек булдыра ала, шулай алдый. Ярый, юлга чыксын да инде, чөнки райкомда тизрәк эшкә керешергә кушып, кисәтеп калдылар. Нигә соң әле аңа, яхшы атланган булып, үзен алырга җибәрелгән атка шәһәрдән кайтучыларның йөген төятергә иде? Әтүтән миннән акыллырак икән, дип уйлады ул. Катырак торып рөхсәт итмәсә, берсен дә чанага якын җибәрми иде.

Уйлар, уйлар... Очы-кырые юк! Җәяүле буран артыннан яшен тизлеге белән иген кыры буйлап йөгерәләр. Коры сөяккә калган булса да, ат җәһәт атлый, юлчылар шактый артта калды. Сакаллы ир аны куып житте һәм уйларын бүлдерде:

— Рәхмәт инде, энекәш! Егет икәнсең, яхшылык җирдә ятмый, онытмабыз. — Сакалына ак керсә дә, ул алай карт кешегә охшамаган — җиргә каты басып, туры атлап йөри; өс-баш киеме дә башкалардан аерылып тора. Күн тышлы бүрек кигән, аякларында кызыл кунычлы киез итек. Сугышка кадәр андый аяк киемен Кукмара ягыннан алып кайталар иде, соңгы елларда сатуда күренми. Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә дигәндәй, Галләм ирексездән аякларын күзеннән үткәрде дә:

— Аяк киемене асылын эләктергәнсез, — диде. — Каян алдыгыз мондый киез итекне?

— Әти мәрхүмнән калган мирас, кеше арасына чыкканда гына киям, югыйсә, күптән көле күккә очкан булыр иде. — Сүз уңаеннан аягындагы киез итекне мактап: «Элек әйберне жиренә җиткереп эшләгәннәр, —

диде,— хәзерге кебек миннән киткәнче, иясенә җиткәнче түгел»... Аннары кинәт туктап калды, Галләм аның тагын нәрсәдер әйтергә теләгәнен сизеп:

— Сөйләп бетер,— диде,— нәрсәдән шикләнәсең?

— Күп сөйләсәң, урыс алып китә, ди торган иде әткәй мәрхүм... Сугыш алдыннан үзе бер сүз өчен 10 елга хөкем ителде. Өч ел утыргач, үзе теләп фронтка китеп, төрмәдән котылды.

Галләм дә үткән заманны искә төшереп сүз куертмады, аның белән якынрак танышырга теләп:

— Исемегез ничек? — дип сорады.

— Мулла кушканча Шәрәфетдин, исемемә хыянәт иткәнем юк, тугры булып яшим. Хәзерге яшьләр әнә, ындыр артына чыгышка, урыска яраклашырга исәпләп, исемнәрен үзгәртәләр: Коля, Ваня, Саша, тагын әллә кемнәр...

Соңгы сүзләр Галләмнең авырткан җиренә тиде. Заманында ул да бу чир белән авырды. Армиядә хезмәт иткәндә иптәшләре аны Гриша дип атап йөрттеләр. Беренче хатыны Клава да аның чын исемен ишетергә теләмәде...

Галләм сүзгә мавыгып җылынып киткән төсле булды. Ләкин сүзне дәвам иттерергә туры килмәде. Казансуны чыгып тау менгәндә ат туктап калды.

— Арыды мескен,— диде Шәрәфи һәм булышырга теләп тәртәгә барып ябышты. Башкалар да аңа иярде, төрле яктан чананы сырып алдылар. Галләмгә тотынырга урын да калмады.

— Мине мыскыллар өчен җигеп килдегезме бу бәлане? — диде ул Әтүтәнгә мөрәҗәгать итеп.— Хәзер атның үзен салып, тартып кайтырга туры киләчәк.

— Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз — юк,— диде Әтүтән өзгәләнеп.— Иң яхшысы шушы, калган атлар бар да күтәрәмгә чыкты...

Уйлаштылар да, атны бераз ял иттереп тордылар. Шәрәфи капчыгыннан бер бөтен ипи чыгарып, аны тамак ялгатып алды. Бер хатын да атка ашатырга дип ипи чыгарган иде:

— Хәзергә җитеп торыр,— дип, кире капчыгына тыктырды.

Икмәк хәл кертте булса кирәк, ат үзе кузгалды. Берничә кеше алмаштилмәш булыша торгач, тау башына менеп тә җитте.

Буран көчәйгәннән-көчәйде. Кар көртләре юлны каплап, эз югалды. Ат тәҗрибәле икән, ул юл катысын сочлап атламаса, эш харап иде.

Тирә-юньдә бер нәрсә күренми. Киемгә кар сырышып, юлчылар ап-ак булдылар. Бер-береңә тотынып бармасаң, адашуыңны көт тә тор.

— Абый, абый, битең өшегән, кар белән ышкы,— диде Әтүтән Галләмгә.

Ул бик тырышып, күн перчатка белән битен уарга тотынды. Тиресе сыдырылып кан ага башлаганны да сизмәде. Шәрәфи аңа муенына бәйләгән шарфны салып бирде. Сарык йоныннан бәйләнгән йомшак шарф белән чорналгач, Галләмгә рәхәт булып китте.

## II

Авылга кайтып кергәндә өйләрдә ут алынган иде инде. Мәчет янына җитәрәк юлчылар, чанадан капчыкларын алып, су сипкән кебек таралып та беттеләр. Йөктән бушагач чана да җиңеләйде. Ат кызурак атлый башлады. Әтүтән аны авыл уртасындагы урыс капкалы йорт янына китереп туктатты. Галләм беренче кайтуында, гаиләсен алып килгәнче шушы йортта фатирчы булып торырга сөйләшеп киткән иде. Атны урамда калдырып, Әтүтән белән икесе бергә, ишегалдына корылган әвеслеккә керделәр. Шундый караңгы, күзгә төртсәләр дә күренә торган түгел.

— Хәнифә апай! Без кайтып җиттек,— дип кычкырды Әтүтән.

Шактый көтеп торганнан соң шыгырдап өй ишеге ачылды. Анда кулына шахтер лампасы тотып, башына иске пальто бөркегән, чүмәләгә охшаш фигура пәйда булды.

— Әйдәгез, әйдә! Ничек кайтып җиттегез, бик туңмадыгызмы?

Ишектән җылы һава бөркелде. Галләм сорауга җавап биреп тормады, тизрәк өйгә керергә ашыкты. Аны күреп өстәл артында дәрес әзерләп утырган үсмер кыз ачы тавыш белән кычкырып җибәрде. Галләм сискәнеп китте. Һәм бернәрсә аңламыйча аптырап, идән уртасында туктап калды.

— Нәрсә булды? Ник кычкырасың?— диде хуҗабикә кызына. Галләмнең тун якасына, муенындагы шарфына күзе төшеп иңеп китте. Тиресе сыдырылган битеннән .ол буе кан саркып, кып-кызыл булып каткан. Карарга куркыныч.

— Бигрәк начар инде һава, мондый көнне яхшы хуҗа этен дә урамга чыгармый.

Галләм мич кырыена барып басты. Ул шундый кызу итеп ягылган, кул тидерә торган түгел.

Хәнифә тиз генә кунакның өс киемен салдырды. Шул арада тун якасына сырышкан кар эреп, идән лычма су булды. Гади су түгел, кып-кызыл канлы су. Сугышта ике мәртәбә яраланып та Галләмнең каннан болай чирканганы юк иде әле.

— Авыртыр инде, битегез каты өшегән,— диде Хәнифә кызганулы тавыш белән,— каз мае сөртсәк яхшы булыр иде.

Сүз уңаенда узган ел казлардан уңмавы, көзлектә оясы белән төлкеме, бүреме буып китүе турында зарланып алды:

— Кызым! Йөгереп кенә күршегә кереп чык әле, Фагыйлә апаңнан каз мае сора, бирми калмас, бирер, үзебезгә түгел, прсидәтель битен өшеткән диген...

Сәкинә исемле кыз китап-дәфтәрләрен өстәл түренә этәреп, урыныннан торды. Аңа күкрәк чыгып килә, үреп артка салган чәч толымы көлтә кебек. Зифа буйлы. Ана белән бала бер-берсенә шулкадәр охшаганнар, белмәгән кеше аларны апалы-сеңелле дип кабул итәргә мөмкин.

Шулай маташа торгач, шактый вакыт үтте. Атын конюшнигә илтеп, Әтүтән килеп керде. Үзе генә түгел, Шәрәфи белән бергә.

— Сеңлем, Хәнифә, син безне ачулана күрмә инде,— диде Шәрәфи гафу үтенеп,— иптәш прсидәтель юлда бик туңды, җылытырга кирәк... Әтүтән чалбар кесәсеннән шешә чыгарды һәм аны кая куярга белми аптырап калды. Хәнифә уйланып торды да, аларны ак өйгә алып чыкты. Югыйсә, хәзер күп тә үтмәс, юк йомышны бар итеп күршеләре керә башлаячак. Чебен дә очырмыйлар, кая басканыңа кадәр күзәтеп, тикшереп кенә торалар.

Хәнифә колхоз рәисен йортына фатирчы итеп кертергә сыкранып кына ризалыгын бирде. Райком секретаре үзе аны кәнсәләргә чакырып сөйләшмәсә, нигезенә аяк бастырачак түгел иде. Зур түрәнең үтенечен кире кагарга батырчылык итмәде. Шулай да кисәтеп куйды:

— Бер шартым бар: туры атлап йөрсә генә фатирда тотам, андамонда сугылып болагайлана башласа, куам да чыгарам,— диде.

Ачыктан-ачык әйтмәсә дә, сүзнең нәрсә турында барганлыгы аңлашылды. Аңа кадәр эшләп киткән председательләр бар да тол хатыннар белән шаярды.

Хәнифәнең ак өе шактый иркен. Тәрәзәләре зур, чиста итеп җыештырылган. Түрдә чаршау белән корып алынган агач карават. Идән уртасында зур өстәл. Һәм берничә урындык. Ире барысын да үз кулы белән эшләгән иде. Игелеген генә күрә алмады. Өйләнешкәч бер ел гына торып калдылар. Сугышның беренче көнендә үк армиягә алынды һәм хәбәрсез югалды. Бигрәк инде үкенечле булды. Гомергә тигез мәхәббәт белән бергә яшәүне өмет итеп тормыш корганнар иде, хыял гына булып калды, җимерелде. Изге теләк челпәрәмә килде.

Хәнифә ак өен ире киткәндә нинди хәлдә булган, шул килеш тота. Менә-менә кояш төсле балкып Хәнифе кайтып керер төсле тоела. Ул сугышка киткәндә яңа туып калган кызы Сәкинә инде буй житеп килә. Аннан бирле күп сулар акты. Шулай да, өметен өзми, ире исән булырга тиеш дип уйлый. Бүгенгә кадәр ят ирләрне ак өйгә аяк бастырганы юк иде. Ничек соң әле ул, гомерендә бер мәртәбә дә күрмәгән, белмәгән бу ир кешене фатирчы итеп кертте? Үзенә-үзе гаҗәпләнә, хәерлегә булса ярар иде...

Председатель яшисе булгач, кәнсәләрдән бер олау утын китереп аударганнар иде — хуҗабикә мичкә күп итеп якты, өйнең кызу һавасы Галләмне тәмам изде. Әгәр, Шәрәфи белән Әтүтән килмәгән булса, ашап-эчеп тә тормас, тизрәк урын әзерләтеп, шунда түнү ягын караган булыр иде. Алардан яхшысынмады, олылап килгәннәр, түзәргә кирәк дип уйлады.

Хуҗабикә кунакларның күңелен күрергә тырышып, боҗыр кебек бөтерелеп йөри. Өстәлгә табак тутырып кайнар коймак чыгарып утыртты. Әтүтән шешәне Шәрәфигә бирде һәм, өстеннән зур бурыч төшкәнгә шатланып, җиңел сулап куйды. Шәрәфи күзе белән аракы бүләргә савыт эзләде. Беркайда күренмәгәч, Хәнифәгә мөрәҗәгать итте:

— Тагын сине борчырга туры килә,— диде аңа шешәне күрсәтеп,— менә бу зәхмәттән авыз итәсе иде...

— Без андый нәрсәне күргән кешемени...— Шулай сөйләнеп, Хәнифә шкафтан ике стакан алып өстәлгә куйды.

— Ә аңа? — диде Шәрәфи, Әтүтәнгә ымлап.

— Эчми генә торсын әле! — Аннан аракы шешәсенә күзен ялтыратып утырган Әтүтәнгә карап.— Әллә, шушы ябь-яшь башыңнан, олылар белән рәттән аракы эчеп утырыр иденме?! — дип, аның каршысына кайнар чәй китереп куйды.

Галләм исә килеп җитмәс борын болай җыелып сыйлануны өнәмәде:

— Карагыз әле, сез юкка мәшәкатьләнеп йөргәнсез, мин аның белән дус түгел бит,— диде, эчемлектән катгый рәвештә баш тартты.

— Авырып, урын өстендә ятасыгыз килмәсә, эчегез! — диде Шәрәфи, көчләп кулына стакан тоттырды.— Салкын тиюдән котылу өчен бердәнбер дару шушы.

— Мондый чагында аз гына ярый инде ул,— диде хуҗабикә.— Тотыгыз, тот! Эчегезгә җылы керсен.

Галләм башкача ялындырып тормады, тын да алмый эчеп бетерде дә, стаканны каплап куйды. Кабарга коймактан башка ашамлык юк иде. Хәнифә аның теләген сизгән шикелле:

— Сезгә, таза ир кешегә ит шулпасы кирәк тә бит, быел сугымлык хайван асрап булмады, курмы кытлыгы үзәккә үтә. Исән булсак, киләсе елга инде, Алла боерса...

Галләм хайван азыгы кытлыгының нәрсә икәнен күз алдына да китерә алмый иде әле, шуңа күрә хуҗабикә сүзләреннән берни дә аңламады. Шәрәфи сүзгә кушылып аз-маз ачыклык кертте:

— Минем карчык зират артындагы ерганактан шактый печән җыеп алып кайтты, язга кадәр җитәр дип уйлыйбыз.

— Минем кыюлык җитмәде, әрсез булырга кирәк икән.

Ни өчен әрсез булырга кирәк? Мәгънәсе һаман Галләмгә аңлашылмады. Колхозчыларга ташландык җирләрдән дә хайванга ашатыр өчен үлән җыярга рөхсәт ителмәвен белми иде шул...

— Сезгә, ике бөртек кешегә, ит әлләни күп тә кирәк түгел инде,— дип әңгәмәне дәвам иттерде Шәрәфи,— шулай да көздән әзерләп калдырсаң тынычрак була.

Ул Галләм өстәлгә каплаган стаканны алып, тутырып аракы агызды. Шәрәфи никадәр генә көчләмәсен, Галләм аны кулына тотып та карамады. Әле эчкән бер стакан аракы аны тәмам изде. Бөтен җире яныппешеп, манма тиргә батты. Бите генә түгел, колагы да өшегән икән, биялэй

кадәр булып асылынып төште. Каршыда, стенага эленгән көзгедә үзен күреп, төсе үзгәрде.

— Курыкма, курыкма, каз мае сөрткәч бетә ул,— диде Шәрәфи аны тынычландырырга теләп.

Өйалдында аяк тавышлары ишетелде. Ишекне төбенә кадәр ачып бер хатын килеп керде.

— Фатыйма апа! Җәй көне дип белдеңме әллә — яп тизрәк ишекне!— дип кычкырды Сәкинә. Фатыйма аның сүзләренә игътибар итмәде, түргә узды.

— Кара әле син боларны! Үзләре генә сыйланып утыралар, партком секретарен искә дә алучы юк.

Фатыйма бу авылга читтән килгән кеше,— туган җире каядыр Бөгелмә янында. Медучилище бетергәч, җибәрделәр аны. Хәзер медпунктта фельдшер булып эшли. Авыл халкы аны «безнең брач» апа дип атап йөртә.

Фатыйма Галләм белән кул биреп күреште дә Әтүтәнне әрләргә тотынды:

— Син нигә кайтып җитүегезне миңа хәбәр итмәдең? — диде ачулы тавыш белән.— Йөгереп килеп житкән, монда сиңа нәрсә калган?

Ишектә колхоз хисапчысы Таһир күренде. Фатыйманың Әтүтәнне әрләве белән мавыгып, аның өйгә керүен сизми дә калдылар.

Таһирның өстендә итәкләре тезенә кадәр житеп торган яшел тышлы сырма. Андый сырманы район үзәгендәге әртилдә таныш-белешләргә генә тегеп бирәләр. Өйгә керү белән төймәләрен чишеп җибәрде. Эчтән солдат гимнастеркасы кигән. Күкрәге тулы орден, медаль. Ул сугышның беренче көненнән ахырына кадәр фронтта булды. Җиңелчә яраланып госпитальдә ятып чыкты. Башыннан үткәннәрне бернинә мәртәбә арттырып, шапырынырга ярата. Күптән түгел дүртенче дистәне урталай ватты. Шакмаклап кыркып мыек йөртә. Мыегы бакыр төсле кып-кызыл. Көн аралаш чәчен алдыра. Сәбәбе — чәченең дә мыегы төсле кызыл булуында. Бала чагында иптәшләре үртәп: «Син мари арбасыннан төшеп калгансың»,— дип көләләр иде. Кемгә охшап тугандыр, нәселләрендә аның кебек кызыл чәчле кеше булуын хәтерләүче юк.

Таһир, урындык алып, Галләм янына килеп утырды:

— Исән-сау кайтып життекме? — Аның өшегән битенә күзе төшеп:— Әтүтән! — дип кычкырды.— Син станциягә барганда үзең белән толып алмаган идеңмени? Мин сине бит толып алырга кушып кисәтеп куйган идем.

Әтүтән аңлатма биреп тормады, колхоз хисапчысы ялганчы булып калачак ич. Түрәләр янында йөреп, аларның вак-төяк гаепләрен үз өстенә алырга күнеккән иде инде ул.

— Нәрсә әле сез, икәүләшеп егеткә бәйләнәсез? — диде Галләм.— Гаеп минем үземдә...

— Әтүтәннең тиресе калын, түзә ул,— диде Шәрәфи, сүзгә кушылып.

Галләм колагын тотып карады да:

— Борчылмагыз, ямавы өстендә,— диде аларны тынычландырырга теләп. Колхоз председателе булып сайлангач, райком секретаре аңа Таһирны «сиңа иң кирәкле кеше» дип тәкъдим иткән иде. Шуны исенә төшереп, аның белән сүзне үгезнең мөгезеннән тотып башлады:

— Йә, сөйләп җибәр,— диде,— сезнең хәлләр кай тирәдә?

Таһир мондый сорауга җавап бирергә әзер түгел иде. Күп уйлап тормады, турыдан бәрде:

— Мактанырлык түгел, бүген тагын өч ат аяктан егылган.

— Ничек егылган, әллә берәр йогышлы авыру таралганмы?

Шәрәфи белән Таһир бер-берсенә карашып алдылар.

— Ашатырга азык юк, күтәрәмгә чыгалар...

— Таһир, житәр сиңа! — диде Фатыйма боерган тавыш белән.— Эш турында сөйләшергә иртәгә дә көн бар, син әнә, өстәл өстен кайгырт...

Таһир Әтүтәнне өйалдына чыгарып җибәрде. Ул һәрвакыттагыча эшне тиз тотты. Ит күтәреп керде, сарыкның арт саны икән.

— Минем өчен булса, мәшәкатьләнмәгез,— диде Галләм,— мин тук...

Аның сүзләренә игътибар итүче булмады. Хәнифә мич алдындагы плитәгә ит турап бәрәңге куйды. Борынны кытыклап өйгә тәмле аш исе таралды. Өстәлгә тагын бер шешә менеп кунаклады. Галләм аны кем чыгарып куйганын да күрми калды.

Шәрәфи, китәргә җыенып, урыныннан торды.

— Син кая?— дип кычкырды Фатыйма, гәрчә эченнән аның китүен түземсезлек белән көтеп утырса да.

— Сез дә монда озакламагыз,— диде Шәрәфи,— иптәш Җиһаншин тынычлап ял итсен. Ул безнең белән бергә кайтып җиткәнче диярлек тәпи-тәпи атлады.

— Ничек тәпи-тәпи атлады?

Аңлатып биргәч, Фатыйма белән Таһир тагын Әтүтәнгә ташландылар. Галләм аларны көчкә туктатты:

— Тимәгез егеткә,— диде катгый рәвештә.— Ул үз өстенә йөкләнгән вазифаны менә дигән итеп үтәде.

Шәрәфи чыгып киткәч, сөйләшергә сүз таба алмый тынып калдылар.

— Хәнифә апай, буламы,— дип кычкырды Әтүтән сүз башлап. Ит турап пешергән бәрәңгедән авыз итмичә чыгып китәсе килми иде аның. Хәнифә бер тәлинкәгә күп итеп ит белән бәрәңге салды да аны кара өйгә алып чыгып китте.

— Үзе болай яхшы малай ул,— диде Таһир, алар чыгып киткәч Әтүтәнне мактап,— бер начар гадәте бар, сүз йөртә...

— Күргәннән күрмәгәне яхшы, ач моны,— диде Фатыйма шешәгә ымлап.

— Сез нәрсә? Мине аяктан екмакчы буласызмы?— диде Галләм, чиктән тыш нәфрәтләнеп.— Күземә күрсәтмәгез...

— Мин хатын-кыз башым белән дә тоткалыйм, безнең белән бераз авыз итсәгез, харам булмас...

— Мин дә бөтенләй эчмим дип әйтмим, булгалый. Бүген дә эчтем. Шул эчкән кадәресен сеңдерергә кирәк башта...

— Болай ярамый инде, иптәш Җиһаншин,— диде Фатыйма нәүмизләнгән булып.— Без тагын чын йөрәктән сезне сыйларга тырышып йөргән булабыз.

Алар китәргә җыендылар.

Хәнифә Галләмгә йокы урыны әзерләргә тотынды. Агач караваткка зур мамык түшәк җәеп, өстенә ябынырга атлас тышлы юрган бирде.

Урыны җайлы булса да, Галләм төне буе сызланып озак йокыга китә алмады. Суык тәмам үзәгенә үткән. Аптырагач, бала чагында, мәрхүм әнисе өйрәткән догаларны укып ятты. «Авыр минутларыңда шул догаларны исеңә төшереп, Аллага сыгын»,— дип үгетли торган иде әнисе. Йокыга киткәч, беренче хатыны төшенә кереп йөдәтте.

Фронтта яраланып эвакогоспитальдә ятканда, бер шәфкать туташы белән танышкан иде. Сугыштан шул марҗаны ияртеп кайтты. Килешеп яши алмадылар.

Галләм сугыштан шактый акча белән кайтты. Фатир сорап йөрдейөрде дә, очы-кырые күренмәгәч, шәһәр читеннән йорт сатып алды. Йорт сатып алу — четерекле эш. Райбашкармада, нотариуста төрле кәгазьләр яздырып калырга кирәк. Бу мәшәкатьле эшне Галләм тулысы белән хатыны Клавага тапшырды. Шуннан файдаланып, тегесе йортны үз исеменә яздырды. Өстәвенә, ирле-хатынлы булып торсалар да, никахлары теркәлмәгән иде. Тормышның мондый нечкәлекләренә игътибарсыз булу үзен бик тиз танытты. Хәләл акчасына сатып алынган йортны Галләм үзенеке дип ышанып йөри иде, мал бүлә башлагач, якын да җибәрмәделәр...

Бергә яшәүләренә бер ел да узмагандыр, Клава көн дә низаг чыгара башлады. Сөймәснеке сыймас дигәндәй, ул аның аяк атлап йөрүенә кадәр ошатмады. «Русча сөйләшә белмисең»,— дип, һәр сүзеннән гаеп табып көлде. Татар милләтеннән булган таныш-белешләре килсә, турсаеп каршы алды, соңга табарак өйгә дә кертми башлады. Бәлки, яхшылап әйткәнне аңлар дип, Галләм үгетләп тә карады. Көйгә килә торган булмады: «Өйрәтмә мине»,— дип бер генә кычкырды. Шушы хәлләрдән соң ул Клавага өйләнеп ялгышканын аңлый башлады. Ләкин өметен өзмәде. Аны үзенчә хөкем итеп, тормышын җайларга теләде.

Сугыштан соңгы елларда шәһәрдә чат саен закусочныйлар эшли иде. Галләм, эштән кайтышлый, шуларның берсенә кереп яхшы гына сыйланды. Аның белән генә чикләнеп калмады, өйгә дә бер яртыны кыстырып кайтты. Ул кайтып кергәндә Клава эчке күлмәктән генә, диванда ятып тора иде.

— Тор! Ашарга әзерлә,— дип акырды Галләм. Клава арты белән борылып ятты.— Торасыңмы, юкмы? — Ул соңгы вакытта шактый юанаеп, арт ягы куна тактасы кадәр булган иде.— Ах, син, кабаниха, телеңне йоттыңмы? — Галләм кайнарланып, аны кулыннан тартып торгызды. Клава әчкелтем-төчкелтем тавыш белән дуңгыз баласы кебек чинарга тотынды. Урам якка караган түр тәрәзәне ачты да:

— Караул, үтерәләр! — дип кычкырды. Кычкырып кына калмады, ачык тәрәзәдән урамга сикерде. «Ярым ялангач килеш ерак китә алмас»,— дип уйлады Галләм. Ярсыган йөрәген басарга теләп, шешә авызыннан гына бер-ике тапкыр аракы йотты. Ул арада ике милиционерны ияртеп Клава кайтып керде. Маңгае канга буялган. Тәрәзәдән сикергәндә тырналган булса кирәк.

— Буып үтерә иде, тәрәзәдән сикереп төшеп котылдым,— дип пулемет кебек такылдарга тотынды. Сүзләренең очы очка ялганмый.— Башыма сукты...

Милиционерлар аны тыңлап бетермәделәр, Галләмгә мөрәҗәгать итеп:

— Киен, киттек! — диделәр.

— Беркая бармыйм, мин үз өемдә...

— Син әле властька каршылык күрсәтәсеңме? — Тиз генә акт төзеп, Клавага кул куйдырдылар. Галләм орден-медальләрен күрсәтеп чәпчеп караган иде, авыз ачарга да ирек булмады.

— Айныгач сөйләшербез.

Ике кулын артка борып бәйләделәр дә алып чыгып киттеләр. Башка аңа бу йортка кайтып торырга туры килмәде. Ул милициядә яткан арада, Клава отставкадагы бер офицерны йортка кертте. Кая гына барып карамады Галләм! Берничек тә йортның үз акчасына алынуын исбатлый алмады. Ярый әле партбилетыннан колак какмады, каты шелтә белән котылды.

Йөрәк ярасы төзәлеп, күргән газаплары онытылып бара иде инде Галләмнең. Кирәк бит, яңа урынга күчеп килгәч, беренче төндә шул бичураны төштә күрергә! Клава әллә тагын аның башын әйләндерергә йөри инде — муенына асылынып: «Мин сине оныта алмыйм, үз өенә кайтып тор»,— дип ялварды.

Галләм манма тиргә батып уянып китте. Түшәккә җәйгән җәймә сыгып алырлык булган. Бик озак өнме, төшме икәнен аера алмый ятты. Тәрәзәгә төшкән яктылыкны күреп, торырга кирәк, дип уйлады. Авыл халкы таң белән уяна, дип сөйлиләр, сер бирергә ярамый, озак йоклап көлкегә калуың бар. Торып утыру белән шуңа игътибар итте, каз маеның файдасы тигән булса кирәк, колак яфракларының шеше кайткан. Ә менә бит алмасы кутырлаган. Медпунктка кереп, шулай да берәр төрле май сорап алмыйча булмас ахры.

Галләмнең уянганын сизеп, хуҗабикә керде.

— Йокыгызның рәте булмады, ахры, төне буе ыңгырашып чыктыгыз.— Ул караватк ырыена ләгән белән комган китереп куйды.— Гаеп итмәгез инде, бездә бөтенесе авылча, менә шулай комганнан юынып гомер итәбез.

Ни арада өлгергән, җылы су Галләмнең күңеленә хуш килде. Бик озаклап юынды. Сөртенергә кызыл башлы зур сөлге китереп тоттыргач, ничектер сәер булып тоелды. Күптәннән мондый сөлгене кулына тотканы юк иде. Ул юынып-киенгән арада ашарга да әзер булды. Өстәл өстендә кукраеп утырган аракы шешәсен күреп, Галләмнең күңеле болганды:

— Каян алып бу зәхмәтне монда чыгарып куйдыгыз әле?— Аракыны Таһир үзе белән алып киткәндер дип уйлаган иде.

Галләмнең катгый рәвештә аракыдан баш тартуы хуҗабикәне гаҗәпкә калдырды. Аңа кадәр эшләгән рәисләр табында шешә булмаса, ризыкны иснәп тә карамыйлар иде. Аракы эчмәгәч, районлагы хуҗалар белән ничек уртак тел табар икән дип, Хәнифә Галләмне кызганып куйды. Кичә әлләни күп тә эчмәде Галләм, әмма нык махмырлады. Аш үтми. Аның чемченеп утырганын күреп, хуҗабикә кайнар чәй чыгарды.

— Менә бусы минем азык!— Тиз генә эчте дә, тагын берне сорап алды.

Таһир белән Фатыйма килеп керделәр.

— Без тагын, йокыдан уятырбыз дип, керергә куркып торабыз,— диде Таһир.— Әнә, ул торып та утырган...

— Иркенләп ял итәргә кирәк иде,— диде Фатыйма. Галләм каршысына барып басты да сумкасынан пластырь чыгарды.

— Битегезне ямап куябыз, бу килеш күренсәгез, кешенең әллә нәрсә уйлавы бар.— Галләм шуңа игътибар итте, Фатыйма «сез» дип сөйләшә. Авылда сирәк очрый торган хәл. Ни әйтсәң дә, укыган кеше, укыган кеше шул. Төскә-биткә дә чибәр икән, авыл кызларыннан бик нык аерылып тора: ясанган, бизәнгән, хушбуй сөрткән.

— Нинди рәхмәтләр әйтим икән? Үзем дә сезнең янга медпунктка сугылырмын дип уйлап куйган идем.

Фатыйма нindидер май да кыстырып килгән, шуны сөртеп пластырь ябыштырып куйгач, ярты бите капланды.

— Минем кулым җиңел,— дип мактанды фельдшер,— берничә көннән өшегәннең эзе дә калмас.

Галләм ишек янындагы чөйгә эленгән тунын алып киде.

— Ашны кабып та карамадыгыз,— диде хуҗабикә, үпкәләп.— Яратмадыгыз, ахры.

— Йөреп кайткач ашырмын, тәмлерәк булыр.

Галләмне туры кәнсәләргә алып китмәкчеләр иде, риза булмады.

— Сез мине элек хуҗалык белән таныштырыгыз,— диде катгый итеп.— Кәнсәләрдә утырырга кайчан да өлгерербез.

Фатыйма белән Таһир бер-берсенә карашып алдылар, ләкин каршы килергә кыймадылар.

Сыер фермасына якын бара торган түгел, кар көрте — түбә кыегыннан.

— Ничек монда кереп-чыгып йөриләр?— диде Галләм гаҗәпләнеп.

— Хатын-кыз газаплана инде шунда...

— Карны көрәп, ишек тирәсенә юл ачарга ярамыймыни?

Җавап булмады. Арткы якта тәрәзә аша юл салынган икән, көч-хәл белән шунда узып, эчкә керделәр. Тагараклар шалтырап тора, маллар астында ник бер бөртек салам булсын. Барысы да муен тиентен үз тизәкләренә манчылганнар. Бер кырыйда өч үләксә аунап ята.

— Нигә дип боларны монда тоталар?

— Тиреләрен тунап алырга кирәк, акча тора...

«Кем дә булса, үләксәдән тунап алган тире белән файдалана»,— дип гаҗәпләнеп куйды Галләм.

Сыер фермасыннан ат абзарына киттеләр. Ул — олы урамда, утыз беренче елны авылдан сөрелгән кулак Сабирҗан Вәлие йорт урынында икән. Элекке хуҗасы исәндерме-юктырмы, шул китүдән суга төшкән кебек булып югалган. Хәер, монда хәзер заманыннан калган ярым җимерек мунчадан башка бер нәрсә дә юк. Йортларын икенче җиргә күчереп, мәктәп эшләделәр. Мунчаның да көле күккә очкан булыр иде, кирәге чыкты — эштән бушаган арада ат караучылар кереп ял итә хәзер. Вәли байның урталай ярылган бүрәнәдән салынган ат абзары бар иде, колхоз конюшние шуңа ялгап, саман кирпечтән эшләнде. Зур бу корылманың түбәсен салам белән яптылар. Ел саен булмаса да, түбәгә ябылган салам алыштырылып торылды. Килеп җитү белән Галләм түбәгә игътибар итте. Яртылаш ялангач калган...

— Нәрсә булган түбәгә? Җил алып ташлаган дип әйтимме...

— Ярый әле түбә саламы бар, сүтеп атларга ашатабыз,— диде Таһир.

Галләмнең ышанасы килмәде:

— Түбә саламын атларга ашатасыз?..

— Шуның белән җан саклыйлар, ул беткәч нишләсе булыр инде...

Галләм кызып китте:

— Барыгызны яткырып суктырырга кирәк! Шәһәрдә ат көченә мохтаҗлыкны белмисез мәллә?

— И-и иптәш Җиһаншин,— диде Таһир мескен тавыш белән,— сез авыл җирендәге тәртип белән таныш түгел шул, эшли башлагач белерсез әле...

— Сезнеңчә ничек, атларны тик яткырып күтәрәмгә чыгару — тәртипме? Тиз көндә, шәһәрдәге оешмалар белән шартнамә төзеп, хәллерәкләрен эшкә җибәрергә кирәк.

Ниһаять, Фатыйма түзеп тора алмады:

— Ат көчен таратырга райком рөхсәт итми,— диде сүзгә кушылып.

Галләм ат абзарын буеннан-буена йөреп чыкты. Берничә баш атны аерып тукландыралар икән.

— Колхоз кадәр колхозны бөтенләй тарту көчсез калдырырга ярамый бит,— диде Таһир аңлатма биреп.— Атна саен дип әйтерлек районга киңәшмәгә чакырып торалар, җәяү йөрергәме? Менә кичә станциягә барып сезне алып кайттык. Тормыш мәшәкатьне тудырып кына тора.

Галләм чак кына кабынып китмәде. Таһир моны сизмәде, сүзен дәвам иттерде:

— Урман чыгарырга нәрәт килгән, кайсы атны җибәрәсе булыр инде...

— Анысы нинди эш тагын?

— Ул гаять җаваплы эш. Быел нәрәт бер генә атка, узган елларны ике аттан да ким булмый торган иде.

Галләм үзенчә фикер йөртте. Урманчылыкка күбрәк ат җибәреп акча эшләргә уйлады. Нигә шәһәргә барып эш эзләп йөрергә?

— Анда түләү ягы ничек? — дип сорады.

— Нинди түләү ягы?

— Урман эше җиңел түгел. Минемчә, яхшы түләргә тиешләр...

Таһир кычкырып көлде:

— Түләү тагын! Кайчан колхозчыга эшләгән өчен акча түләгәннәре бар? Өстенә чыкмаса, риза инде ул, колхозчы мескен...

Галләмнең кәефе болай да чамалы иде, тагын да кырылды. Ничек итеп соң атларны аякка бастырырга? Атлар тернәкләнсә, колхозның эше җайланачак бит.

Ат абзарыннан туры кәнсәләргә юл тоттылар. Алар кайтып кергәндә анда баш тыгарлык түгел, халык белән тулган иде. Тәмәке төтенен балта эләрлек.

Умарта оясы кебек гөжләп торган кәнсәләр кинәттән тынып калды. Беләк буе итеп гәзит кәгазенә төрелгән тәмәкеләрен төкерек белән сүндереп, берәм-берәм кайсы идәнгә, кайсы мичкә ыргыта башлады.

Галләм халык өстеннән күзен йөртеп чыкты да:

— Исәнмесез, иптәшләр! — диде ягымлы тавыш белән. — Менә мин килеп тә җиттем, кабул итәсезме?

Җавап булмады.

— Димәк, барыгыз да битараф? Кисәтеп куям, мин эшләргә килдем. Үпкәләштән булмасын, сезне дә эшләтәм.

Шул сүзне ишетүгә, дәррәү ишеккә ябырылдылар. Кәнсәләрдә берничә кеше генә калды. Таһир, бүлмәне җилләтергә теләп, тәрәзә форточкасын ачты. Тыштан саф һава бөркелде, суларга җиңеләеп китте.

Кәнсәләрдә бервакытта да рәискә аерым кабинет булмады. Моңа кадәр эшләүчеләр хисапчы белән бергә шушы бүлмәгә сыйдылар. Эш кәгазьләре өчен икесенә бер шкаф җитте. Узган ел гына бик тырыша торгач, Таһир сейфлы булды. Аңынчы рәис кеше мөһерне кесәсендә йөртте. Штамп һәм башка документлар өстәл тартмасында сакланды.

Таһир беренче мәртәбә күргән төсле, кәнсәләр эчен күзеннән үткәрде дә:

— Иптәш Җиһаншин, сез кайсы өстәлгә утырырсыз икән? — диде.

— Утырып торырга вакыт булса, өстәле табылыр. Зур мәсьәлә түгел...

Таһир түргә ымлады:

— Урын җитәрлек, кабинет эшләтергә кирәк...

— Һәр эшнең үз вакыты бар, уйлашырбыз.

Галләм түрдәге өстәл янына узды һәм өстенә ябылган кызыл материяне сыдырып төшерде.

— Маскировка ясый беләсез икән, сүз дә юк, заманча!

Нинди имзалар гына куелмаган да, нинди сүзләр генә язылмаган өстәл тактасына! Кайберләрен укырга чирканыч. Урындыкка утырган иде, чак кына мәтәлмәде, Шәрәфи тотып калды. Таһир гафу үтенде:

— Җыештыручы хатынның арт сабагын укытмый булмас, ахры...

— Җыештыручыны гаепләмәгез, — диде Шәрәфи, — ватык урындыкны кая куйсын? Чыгарып ташларга ярамый, ничек кенә булмасын, социалистик милек исәбендә.

— Бөтен җиргә сиңа тыгылырга кирәк, — диде Фатыйма, аның сүзләрен гаепкә алып. — Бер кысылып үләрсең әле... — Сүзнең зурга китүеннән шүрләп, Шәрәфи бәхәскә кереп тормады.

— Ярар, юк белән баш катырмагыз, — диде Галләм, — йә якалаша башларсыз. Менә нәрсә, син мине колхозның финанс хәле белән таныштыр, — дип Таһиргә мөрәҗәгать итте.

Теге авыр сулап, йөзен чытты:

— Ничек дип әйтергә? Колхозның банктагы агым хисабында арест ята.

— Бернәрсә аңламыйм, нәрсә ул арест дигәне?

— Бурычларны түләп бетермичә, агымдагы хисаптан безгә акча бирмәскә кушып килгән боерыклар. Иң кәттәсе райфоныкы...

Таһирга тәфтишләп, колхозның берничә ел кеременнән алына торган салымны түләмәве турында сөйләп бирергә туры килде.

— Нинди керемнән алына ул салым? — диде Галләм гаҗәпсенеп. — Колхозның кереме дә бармыни?

— Бер дә юк түгел, бар инде ул. Ел буе чиләнеп, түземсезлек белән көтеп алган иген уңышының бөртеген дә үзебезгә калдырмыйча дәүләткә тапшырабыз. Ул гына да түгел, ит, сөт, җон йөкләмәләре бар. Шуларны түләгән өчен агымдагы хисапка аз булса да акча керә. Шунысы кызык: безгә дәүләт әзерләү бәһаләре белән түләп, ә игенчелектән, хайванчылыктан колхозның керемен исәпләгәндә бөтенләй башка норматив кулланыла.

Күпме тырышса да, Таһир Галләмнең аңына барып җитәрлек итеп сөйләп бирә алмады.

— Эшләр хөрти,— диде Галләм, соңгы сүзенең һәр хәрефенә басым ясап.— Көндәлек расходка акча каян табасыз?
— Җан биргәнгә, җүн бирә Ходай,— Таһир бу турыда артык җәелеп сөйләп тормады.— Җаен табабыз инде шунда.
Колхозның «кара кассасы» бар. Әлегә Таһир бу хакта сүз кузгатуны кирәк тапмады. «Кара касса» барлыгын хисапчы белән партком секретаре икесе генә белә.
Узган сезонда умартачылыктан яхшы керем алынды. Башка еллардагыдан аермалы буларак, балны җыеп сакламадылар. Бал, кудырткычтан чыгу белән, сельпога тапшырылды. Сельпо үз чиратында балны колхозчылардан кабул ителгән итеп, квитанция язып, акчасын түләп барды. Шул акча тулысы белән кешедән, бигрәк тә район түрәләреннән яшереп, «кара касса»да тотыла. Майламыйча таба купмый, сельпо рәисен көйләргә туры килде, әлбәттә. Тагын шунысы да бар, сизелсә барысының да буранын туздырачаклар.
Галләм алдында бөтен кискенлеге белән атларны эшкә җигеп, акча табу мәсьәләсе килеп басты.
— Ничек инде шушы кадәр тарту көче була торып, бер тиенгә тилмереп яшәргә кирәк?— диде ул өзгәләнеп. Төптән уйлаганда мәхлукларны абзарга биклэп ач тоту — җинаять. Ашатырга кулдан килмәгәч, ирекккә җибәрергә кирәк. Үз көннәрен үзләре күрсеннәр. Ниндидер бер киножурналда күргәне бар Галләмнең — Канадада бугай, ирекккә чыгып кыргыйлашкан атлар бар икән, рәхәтләнеп йөриләр.
Эш турында кайгыртасы урында, үзенең юк белән хыялланып утыруына ачуы килеп, кәнсәләрне икегә бүлгән такта янына барып басты:
— Җәмәгать! Бергәләп киңәшик әле, шәһәргә барып эш турында белешеп кайтырга кемне җибәрәбез?
Фатыйма шундук чәчрәп чыкты:
— Райком рөхсәтеннән башка шәһәргә эшкә бару турында авыз да ачмагыз.
Галләм аны бүлдерде:
— Мин сезнең фикерегезне беләм, колхозчылар белән сөйләшкәндә комачауламавыгызны сорыйм.
Колхозда ничә председатель эшләп китте, Фатыйма белән берсенең дә болай сөйләшкәне булмады. Бу нинди хәл? Ачудан аның йөзе зәңгәрләнде:
— Сез уйлап сөйләшәсезме?— Үзе шартлар дәрәҗәгә җитеп, тавышы калтырады.— Мин, партбюро секретаре, сезгә эшләргә комачаулыйммы?!
Бераздан Фатыйманың китәргә җыенганын күреп:
— Сез кая?— дип сорады Таһир. Җавап булмагач, Галләмгә күзен текәп тынып калды. Ни өчен икәнен әйтмәсә дә, Галләм аңлады:
— Мин берәүне дә кумыйм, Фатыйма иптәш үзенә карасын,— диде.
Фатыйма тораташ булып катып калды. Юк, юк — ул монда бер минут та тоткарланырга тиеш түгел! Үз-үзен белешми, ишекне каты ябып чыгып китте.
Кәнсәләрдәге халык Галләм белән Фатыйма арасында башланган бәхәсне күзәтеп, шәһәргә эш белешергә кеше җибәрү турындагы тәкъдимне игътибарсыз калдырды. Галләм үзе дә яңадан бу турыда сүз кузгатып тормады, өстәл артына кереп утырды да, кәгазь сорап алды. Таһир аңа укучы балалар дәфтәре тоттырды.
— Башка төрлесе юкмы?
— Монысын каян алдың дип сора. Мәктәпкә укырга йөрүче кызымның сумкасыннан чәлдердем.
Әйе, Галләм кабул итеп алганда колхозның кәгазь сатып алырга да акчасы юк иде. Колхозчының бер-бер эше төшеп, идарәдән белешмә яздырып алырга туры килсә, кәгазьне үзе алып килә.
Яңа рәис, кабул итеп алган көнгә колхозның нинди хәлдә булуын тасвирлап акт төзергә тотынды. Таһир өчен бу яңалык иде. Ул эшләгән дәвердә булып киткән рәисләр болай «вакланып» маташмадылар.

Акт колхоз хисапчысы Шакиров Таһир, колхозчылар Гимадиев Шәрәфи һәм Җамалиев Мәннаф катнашында төзелде. Мәннаф башта акт төзегәндә катнашырга теләмәде:

— Минем бер авызым пешкәне бар инде,— диде,— узган ел кибеттә ревизия акты төзегәндә катнаштырдылар да, судтан башым кайтып кермәде.

Аңлата торгач, күнде тагын. Актка беренче итеп атларның баш санын һәм нинди хәлдә булуларын теркәделәр. Аннан башка малларга күчтеләр.

Акт төзегәндә шул ачыкланды: чәчү инвентаре каралмаган, ә бит тиздән язгы чәчү башланачак.

— Бар ышаныч МТСта,— диде Таһир,— кыр эшләрен алар башкара...

— Шулаен шулай да, әнә Орнаш колхозы, МТС кертмәгәч, аз булса да ел саен уңыш бүлә,— диде Шәрәфи аңа каршы төшеп.— Безнең ярты икмәк натурплатага китә, колхозчыга шымытыр.

Натуралата түләү турында ишеткәне бар иде Галләмнең. Тик кемгә, ни өчен икәнен белми иде. Ул сүзгә катнашмады, алар сөйләгәнне мыегына чорнап бару белән чикләнде.

Иң аянычы шул: колхозның бер бөртек чәчү орлыгы юк иде.

— Көз көне бөтен җыйган уңышны икмәк заданиесенә илтеп тапшырабыз,— диде Таһир.— Адәм көлкесе бит, яз җиткәч ах-вах килеп, заготзернодан чәчү орлыгы ташыталар.

— Сере нәрсәдә?

— Минемчә, обкомда утыручы агайлар икмәк заданиесе буенча планны үтәүләре турында рапорт биреп, абруй казаналар.

Галләм ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Утыра торгач шактый вакыт үтте. Галләм хәл алырга теләп урыныннан торды. Халык барында игътибар итмәгән иде, бер карыш былчыракка каткан идәнгә күзе төште. Түшәм — кап-кара корым, мичнең акшары яртылаш купкан.

— Бу галәмәткә ничек түзеп утарасыз? Җыештыручы нәрсә эшли? — Таһирга уңайсыз булып китте:

— Безнең авыл халкы шулай күнеккән инде ул.

Кәнсәләр дигәнең клубның түбән башына ялгап эшләнгән. Иркен. Рәискә, хисапчыга аерым-аерым кабинет эшләргә дә урын җитәрлек. Тик Галләм әлегә бу турыда сүз кузгатмады.

Ул шулай уйланып утырганда, Сәкинә килеп керде.

— Әни көндезгә ашка чакырды, кайнар килеш ашап китәргә кушты.

Галләмдә ниндидер рәхәт тойгы уянды. Мондый хөрмәтне көтмәгән иде. Баш тартып булмас дип, чакыруны кабул итте.

Кайтып җитәрәк Шәрәфи куып җитте.

— Гафу итегез, сезнең үзегезгә генә әйтәсе сүзем бар.

Шулай дип әйтте дә, нәрсәдәндер шикләнеп артына борылып карады. Әйе, ул тамгалы кеше. Һәр сүзне үлчәп, җиде кат уйлап сөйләшә. Утыз җиденче елны кәҗәне «Сталин сыеры» дигән өчен ун ел чәпәделәр аңа. Бик тырыша торгач, кырык икедә фронтка китү «бәхетенә» иреште. Сугышта үзен аямады, орден-медальләр белән бүләкләнде. Кулына «судимость снимается» дигән кәгазь тоттырдылар. Кырык үлемне башыннан үткәреп, гаиләсе янына тыныч тормыш кору исәбе белән кайткан иде дә — юк икән, көчләп тагылган койрык арттан калмый икән... Кайтканына бер ай да үтмәде, газраил килеп тә җитте. Районга алып китеп, төне буе сорау алды. Шуны аңлады Шәрәфи: авылда яшәп калса, аңа тынычлык күрсәтәчәк түгелләр икән. Авылга кайтып хата эшләде. Хәзер алай ансат кына чыгып та китә алачак түгел...

— Сөйләгез, тыңлыйм,— диде Галләм.

— Сез атларны шәһәргә җибәреп эшләтү турында сүз кузгаттыгыз. Минемчә, бердәнбер дөрес юл. Югыйсә, колхоз атларсыз калачак.

— Ишетеп тордыгыз бит, «апай» ничек чәпчи.

— Беркемне дә тыңламагыз, үзегез уйлаганны ахырына җиткерегез! — Эшлекле тәкъдим, ләкин җиңел уйлый Шәрәфи.

— Райком якадан тотса, ничек җавап бирәбез?
— Мин сезгә юлын өйрәтәм, ләкин сөйләшкән ике арада калсын...
Галләм күңелендә шик туды. Мондый эштә нинди яшерен сер булырга мөмкин?! Сүзне ахырына җиткерергә теләп:
— Әйтеп бетерегез,— диде.
— Бер сарык түшкәсе илтеп бирсәң, рәтләнә...
— Кемгә бирергә? — Сабыйлар акылы чыкмаган икән әле бу кешедән, дип уйлап куйды Шәрәфи. Шуны да белмәгәч инде?!
Кемгә икәнен әйткәч, Галләмнең чәче үрә торырлык булды:
— Нәрсә син әкият сөйлисең? Мине эләктермәкче буласыңмы?
— Сезне эләктерүдән миңа ни файда?
— Күз алдымнан югал! — диде Галләм ярсып.— Минем тирәдә эзең булмасын...
— Бигайбә, иптәш председател, әйттем исә, кайттым. Мондый сөйләшү булмады дип исәпләгез. Хәер, шаһитлар юк.
Шәрәфи ашыгып китеп барды. Галләмгә карата күңелендә кызгану хисе туды. Болай булса, тиз көндә аның башын ашаячаклар.
Галләм үзенчә фикер йөртте. Нәрсә уйлап, күрмәгән кешегә ришвәт бирергә тәкъдим итәргә кирәк? Кемгә диген әле? Райкомның беренче секретарена. Тапкан кешесен дә! Акылы камил адәм мондый эшкә юл куямы соң? Галләм чын күңелдән ышана: партия органнарында сөттән дә ак, актан да ак кешеләр генә эшли. Шәрәфи киңәшен тыңлап ришвәт тәкъдим итсә, иң яхшы очракта аны җүләргә санаячаклар. Урыны акылдан язганнар шифаханәсендә булачак... (Бик сай йөзә иде шул Галләм...)
Ул чиктән тыш дулкынланып өйгә кайтып керде. Хуҗабикә нәрсәдер әмәлләгән. Тәмле исе хәтта ишегалдына чыккан.
— Яратырсызмы инде, үземчә бик тырышкан булдым,— дип, Хәнифә өстәлгә табак тутырып өчпочмак китереп куйды.
Өчпочмак Таһир белән Фатыйма алып килгән иттән пешергән булса кирәк. Кылт итеп шул исенә килеп төште дә, Галләмнең ашавы ашау булмады. Иткә бит акча түләнмәгән!..
Галләм хуҗабикәне ашарга утырырга чакырып караган иде, тартынды. Аны ялгыз калдырып, чыгып ук китте.
Яше кырыкка якынлашып килсә дә, Хәнифә әле кызлар шикелле иде. Зифа буйлы, алсу йөзле, сөрмәле күзле, һич тә бала тапкан хатын дип әйтмәссең. Өс-баш киеме авылча булса да, бөтен һәм чиста, үзенә килешеп тора.
Галләм аны кызганып куйды. Нигә инде яшь гомерне ялгыз, әрәмгә уздырырга? Сугыш тәмамланганга шактый вакыт үтте бит, кайтасы кеше кайтып бетте. Ә ул һаман ирен көтә. Хәбәрсез югалган ирен... Кайткан очракта да, андый кеше хатынына күз көеге генә булачак. Кайтмавы, бәлки, хәерлерәктер дә, чөнки андыйларга көн күрсәтмиләр. Үзенә генә түгел, гаиләсенә дә. Ничек итеп булса да, Хәнифәгә шуны аңлатырга иде. Җае чыкканда Галләм Хәнифә белән шул турыда сөйләшергә уйлап куйды. Ул бик нечкә күңелле хатын шикелле, уйлап җиткерми сүз башласаң, бураныңны туздырырга да күп сорамас, ашыгып эшне бозарга ярамый.

## III

Шәфиканың ирен авылга җибәрәсе килмәде. Обком тирәсендә таныш-белешләре булган хатыннар, әнә, ничектер, җайладылар. Аның беркеме дә юк шул. Этләнеп йөри торгач, Беренче кабул итте:
— Җиһаншин — Ленин-Сталин партиясенең бер солдаты! Партия кая җибәрә, ул шунда булырга тиеш,— диде таләпчән тостә.

Шулай итеп, Шәфика бер-бер артлы туган ике баласын кочаклап утырып калды. Аның тәрбиясендә тагын карт әнисе бар. Ярый әле фатирлары иркен. Иркен дигәч тә, хәзерге иркенлек белән чагыштыра торган түгел, әлбәттә. Гасыр башында ук бүрәнәдән салынган йортта — ике бүлмә. Бүлмә саен урамга карап торган икешәр тәрәзә. Ишегалдыннан кергәч тә кечкенә генә коридоры һәм кухнәсе бар. Бу йорт-җир, кайчандыр бөтенләе белән Шәфиканың әнисе, Фатыйха карчыкның үзенеке иде. Утызынчы еллар башында йортны конфискацияләп, аны урамга куып чыгардылар. Башта азык-төлек саклана торган чоланда яшәп тордылар. Ире Исмәгыйль кулыннан эш килә торган кеше иде. Чоланга тәрәзә тишеп, мүкләп, чутлап, кеше яшәрлек хәлгә китерде тагын.

Фатыйха абыстайның энергиясе ташып торган яшь чагы иде. Шикаять арты шикаять яздырып кая гына бармады... әмма үзенекен итте, шушы тәрәзәләре урамга карап торган өйгә керттеләр. Үз йортында фатирчы булып, хөкүмәткә акча түләп тора башлады.

Шәфиканың әтисе Исмәгыйль абзый сугыш беткән елны үлде. Әлләни карт та түгел иде. Кыска гомерле булды, мәрхүм. Ул үлгәч, тормышның бөтен авырлыгы Шәфика җилкәсенә төште. Әнисе Фатыйха абыстай үз гомерендә ялланып беркайда да эшләмәгән. Эш стажы булмагач, пенсия түләнми. Шәфиканың юклы-барлы стипендиясеннән башка килерләре юк. Тырыша торгач җае чыкты тагын. Фатыйха абыстай тегү машинасына утырды. Иртәдән кичкә кадәр баш күтәрми тегү тексте. Ул елларны иң үтемле товар — эченә мамык салып теккән сырма иде. Нинди фасонда гына текмәделәр аны! Халыкның күпчелеге кешелеккә дә сырма киде. Шул чактагы тормыш дәрәҗәсен билгеләүче бәхәссез күрсәткеч бу!

Сырманы тегү белән генә эш бетми, сатарга да кирәк. Сату Шәфикага йөкләнде. Иртәнге якта институтка лекция тыңларга йөрде, төштән соң базарга йөгерде. Сугыштан соңгы елларда сәүдә шулкадәр кызып китте, Лозовский урамындагы барахолка көн дә иртәдән кичкә кадәр кырмыска оясы кебек мыжлап торды. Шәфика анда ял көннәрендә генә бара иде. Күбрәк колхоз базарына чыгып сату итте. Аның товарын авыл кешеләре яратып ала. Кайсы көнне базарга кереп тә тормый, трамвайдан төшкәч тә сатып җибәрә.

Шәфика бер-ике ел иркенләп, берәүдән дә курыкмый сату итте. Үсмер кызга әлләни игътибар итүче булмады, балага санадылар булса кирәк. Тагын шунысы: башкалар кебек берничәне күтәреп йөрмәде, кулында бер сырма булды. Чибәрлеге дә ярдәм итте бугай. Бөтен гәүдәсе балкып торган үсмер кыз бер елмаеп караса, тикшерүчеләрнең яшьрәкләре эреп китә иде. Вакыт үтү белән аңа да караш үзгәрде, бик нык бәйләнә башладылар. Бер көнне конторага алып кереп протокол төзеп калдылар. Ярый әле паспорты үзе белән иде. Паспортсызлар белән сөйләшеп тә тормыйлар. Паспортыңны алып килгәч товарыңны бирербез дип, чыгарып җибәрәләр.

Шәфика базарда сату иткәндә тотылуның бөтен нечкәлекләрен белми иде әле.

— Җүләр! Акылың кая синең,— диде бер танышы,— аларга паспорт күрсәтергә ярыймы соң?! Хәзер төбеңне төшерми туктамаячаклар. Күр дә тор, озакламый өеңә тикшерү килеп җитәчәк.

Шәфика үкенеп бетә алмады. Бер сырма каян килеп, кая китмәгән, калдырып кына китәсе булган, югыйсә... Тик терсәк авызга бик якын да, тешләп булмый шул.

Таныш хатыны белеп лыгырдаган икән, тикшерү икенче көнне үк килде. Алла саклады, Фатыйха абыстайның машина белән тегеп утырган вакытына туры килмәде. Җомга көн иде — җомга көнне кулына эш тотмый ул. Мөселманнар өчен изге көндә иркенләп ял итә.

Тикшерүче килеп кергәндә Шәфика белән Фатыйха абыстай чүкердәшеп чәй эчеп утыралар иде. Табында кайнар кабартма, төрле кәрчәмәрчә... Чәйнең тәме китсә дә, хуҗаларның сер бирәсе килмәде. Якты йөз

күрсәтеп каршы алдылар. Фатыйха абыстай аңа өстәл яныннан урын тәкъдим итте. Тәкъдим игътибарсыз калды. Килгән кеше үзе белән таныштырып тормады, атылып-бәрелеп тегү машинасына барып ябышты. Шәфика карап-карап торды да, бөтен кыюлыгын җыеп:

— Ни хакыгыз бар сезнең безнең өйгә кереп актарынып йөрергә?— диде. Тикшерүче дәшми-тынмый машина өстенә ябылган җәймәне тартып төшерде, аяк астына коелган кием тышлыгы кыйпылчыкларын җыеп, өстәл өстенә куйды:

— Кем бу машинада тегү тегә?

— Мин прокурорга жалоба белән барам, хәзер үк чыгып китегез!

Таныш түгел кеше машина тирәсендә актарынуыннан туктап, кесәсеннән кызыл катыргы тышлы таныклык чыгарды. Шәфика:«Таныклык бирелә Свердлов район финанс бүлеге тарафыннан участок налог инспекторы Кадыйров Габделхәй Кадыйровичка» дигән сүзләрне укыды да өстәлгә ыргытты:

— Бу катыргы сезгә тентү ясарга хокук бирми, тентү ясар өчен прокурордан рөхсәт кирәк.

— Кем әле сездә тентү ясый? Мин бары эш урыны карыйм. Закон буенча эш урынын караганда налог инспекторына каршылык күрсәтүче каты җавапка тартыла.

— Тентү белән карауны гына аерабыз. Мин үзем биш минуттан финанс работнигы буласы кеше.

— Кайда укыйсыз?—дип сорады, Кадыйров дорфа гына.

— Эшли башлагач танышырбыз, анысы сезгә кирәкми.

— Кызым, син алай тыр-пыр килмә әле,—диде Фатыйха абыстай сүзгә кушылып,—рәтләп сөйләш! Күреп торасың, үзебезнең мөселман кешесе, әйбәтләп әйткәч аңлар.—Кадыйров та усаллык белән эш чыкмаслыгын аңлап, сөйләшү тонын үзгәртте:

— Менә әби маладис, ичмасам, акыллы карчык икәне йөзенә чыккан.—Ул портфеленнән сырма сатканда базарда Шәфика өстеннән төзелгән беркетмәне алды.— Әйдә, әби, кызың тыңлап торсын, икәү дусларча гәпләшик әле!—Төрле җирдә аунап, былчыранып беткән портфелен өстәлгә куймакчы иде, Шәфика тотып калды.

— Гафу итегез! Ашыксаң, менә шулай инде ул,—диде чакырылмаган кунак.

— Ашыкмагыз! Артыгыздан кумый торганнардыр ич?

— Ничек кенә әле? Хәер, үзегез эшли башлагач белерсез.— Чиста бланк алып карап торды да.—Кайсыгызны машинада тегү тегә дип языйм?—дип сорады.

— Аллага шөкер! Күршегә чыккан юк, үзебезгә кирәкне мин тегепматаштырган булам,—диде Фатыйха абыстай.—Яңага кулым ябышмый, иске-москыны гына...

— Кызыгызны базарда яңаны сатканда тотканнар бит.

Шәфика әнисе җавап бирә белмәс, керделе-чыктылы сөйли башлар дип шүрләгән иде, бер дә төртелеп тормады, чатнатып җавап бирде:

— Һай, улым, сез нәрсәдер бутыйсыз! Кызыма дип искедән әмәлләгән идем, ай буе энә белән баз казып утырдым. Сез яшьләргә ошарлык итеп тегеп буламыни? Ошатмады, сатарга алып чыгып китте. Әни сүзен тыңламасаң шулай була ул, менә! Әнисе теккәнне сата да, яңа фасон белән тегелгәнне ала, имеш.

Налог инспекторы кичтән яхшы гына «төшергән» булса кирәк, авызыннан аракы исе аңкый. Сизелеп тора, кәефе шәптән түгел. Алдындагы кәгазьгә нәрсәдер язды да Фатыйха абыстайның паспортын сорап алды.

— Энем, җаным, син кәгазь былчыратып торма инде,—диде ялынулы тавыш белән әнисе.—Исем, фамилия кәгазьгә язылгач зурга китә ул,—стенага терәп куелган шкафтан кызыл утызлык алып Кадыйровка сузды:—Хәзергә шуңа риза булып тор, соңгысы булмас...

— Син мине кем дип белдең?! — Кадыйров акырып-бакырып акчаны идәнгә ыргытты.— Утыз сумга сатып алмакчы буласыңмы?

Ялгышты әни, дип уйлады Шәфика, ашыкмаска кирәк иде. Болай булгач эшнең зурга китүе ихтимал. Өстәлдә аунап яткан әнисенең паспортын тиз генә алып шкафка тыкты.

— Сез нәрсә әле, җитмештәге карчыкның башын әйләндерәсез? — диде тыныч тавыш белән.— Базарда мин тотылдым, протоколны минем өстән төзеделәр.— Фатыйха абыстайның кулыннан җитәкләп икенче бүлмәгә чыгарып җибәрде. Шәфиканың инициативаны кулга алуы налог инспекторын бераз йомшартып, башкача сөйләшергә мәҗбүр итте. Ул чиста бланк алып, актын яңадан төзергә тотынды. Акчаны алмавына үкенеп куйды. Бу кыз барында артыгын өмет итү файдасыз. Үзе өчен бер нәрсәне ачыклады: аларның сырма тегеп, базарда сату итүләрендә шиге калмады. Исбат итәр өчен, ничек итеп булса да эш өстендә тотарга кирәк. Менә шунда ул сөйләшеп карар... «өендә кустарьчылык һөнәре белән шөгыльләнү факты расланмады» дип язды да, күрше бүлмәдән Фатыйха абыстайны алып чыгып, актка кул куйдырырга кушты.

— Мин генә кул куйсам ярамыймы?

— Актны аның исеменә төзедем, үзе кул куйсын.— Аннары куелган имзага карап торды да:— Комган хәрефләре,— диде, ризасызлыгын белдереп.

— Безне башкача өйрәтмәделәр ич,— диде Фатыйха абыстай авыр сулап.— Нәрсәгә кирәк булгандыр, гарәп хәрефләрен бетереп, надан итеп калдырдылар...

Кадыйровның махмырдан башы чатнап, авызы кипте. Фатыйха абыстай хәлен аңлап, чәй тәкъдим итте:

— Улым, тагын ачуланырсың инде? Бәлки, үзең дә беләсеңдер, безнең татарда гадәткә кергән, кунакны чәй эчерми җибәрмиләр.

Тикшерүче алдына чынаяк белән чәй китереп куйгач, йөзе яктырып китте:

— Ирең кайда? — диде, ягымлы булырга тырышып.

— Кызым белән ике бөртек кенә без, ирем вафат,— диде хуҗабикә, йөзендә тирән юксыну чагылды.— Тегү машинасы иремнеке, ул исән чагында яхшылап өйрәнеп кала алмадым. Болай бер тиенгә зар булып яшәмәс идек...

— Алдашма, кортка! Әллә мине бөтенләй ахмак адәмгә санныйсыз инде? — Сүзен исбатлар өчен идәннән җыелган кием тышлыгы кыйпылчыкларына ымлады.— Менә болар каян килгән?

— Алар минем чүп-чар,— диде Шәфика сүзгә кушылып.— Укудан бушаган арада мин тегәргә өйрәнеп утырам.

— Нәрсә? Сезне Институтта алдашырга өйрәтәләрме? — Шәфиканың бәхәскә кереп сүз көрәштерәсе килмәде, тизрәк аны озатырга теләп көлде дә бетерде. Кадыйровның бер чынаяк белән генә эче януы басылмады, икенчесен үзе сорап алып эчте.

— Мөхәммәт өммәтенә өч мәртәбә фарыз,— диде Фатыйха абыстай, каплап куйган чынаякны алып.— Тагын берне ясыйк...

Налог инспекторы чыгып киткәч, Шәфика әнисен әрләп алды:

— Кем дип белгәнсеңдер шул исерек дуңгызны? Хурланмыйча тәлинкә тотып торасың...

— Эт күңеле бер сөяк, утыз сумны алса, яхшырак була иде!

Эче күбенгәнче эчсен иде шунда...

— Хуҗаларына язып җибәрсәң, арт сабагын укыталар инде бу адәм актыгының!

Әнисе аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Кызым, җаным, бер үк андый эш белән маташа күрмә! Син дуамалга ышанып булмый, язып та җибәрерсең. Дөньяда иң начар кеше — әләкче...

Кем, кем, ә ул әләкнең нәрсә икәнен яхшы белә. Утызынчы елларда әләк аркасында мәрхүм ире НКВДдан кайтып кермәде. Бер дә гаепсезгә көн аралаш чакыртып сорау алдылар.

Әнисенең сүзләре Шәфика күңеленә мәңгегә сеңеп калды. Ул үз гомерендә, бервакытта да әләк язмады, әләкчене дә жене сөймәде. Андый кешеләр белән аралашудан катгый рәвештә баш тартты.

Налог инспекторы өйләренә килеп киткәннән соң башында кызык бер фикер туды. Быел ул финанс институтын тәмамлый. Райфога эшкә урнашса ничек булыр икән? Менә ул налог эшендә тәртип урнаштырыр иде!

## IV

Институт тәмамлар алдыннан чыгарылыш курс студентларына эш урыннары тәгаенләнә. Шәфика Казагызстанга китәргә тиеш булды. Казанда калу өчен аңа төрле белешмәләр җыеп, әнисенең ялгыз карчык икәнен, шушы бердәнбер кызы Шәфикадан башка тәрбиягә алырлык кешесе юклыгын исбатларга туры килде. Ул югары белемле кеше буларак, аяк терәп эш сайлап йөри алмады, нәрсә кушсалар шуңа риза булды.

Сугыштан соңгы елларда күп балалы һәм ялгыз аналарга акчаны район финанс бүлеге түли иде. Шәфика райфога шул эш буенча инспектор булып урнашты. Хезмәт хакы ипи-тозга да житәрлек түгел. Базар юлы ябылды. Кадаклап куйган кебек, беркая кузгалмыйча өстәл янында утырырга кирәк. Тагын бер кыен ягы бар: кустарьларны кычкыртып талаучы налог инспекторлары да шушы оешмада эшли. Әнисе теккән сырманы сатканда тотылса, иптәшләре күзенә нинди йөз белән күренер?.. Шулай да, ял көннәрендә бер-ике мәртәбә, курка-курка гына базарга чыгып керде. Аннан заказга гына тегә башладылар. Әмма заказга эшләп кенә мантып булмый шул!

Базарда тотылгач, өйләренә тикшерергә килгән Кадыйров та шушы райфода эшли. Күрү белән Шәфиканы таныды. Елмаеп исәнләште, ләкин башка бер сүз дә әйтмәде. Налог инспекторлары монда бер кәтү — күрше бүлмәдә утыралар. Кадыйров башкалардан чиста киенеп йөрүе белән аерылып тора: өстендә затлы мех тун, башында каракүл бүрек, аягында күзгә кебек итеп ялтыратылган хром итек. Галифиенең кесәләре шешә тыгып куйган кебек кабарып тора. Шәфика тагын шуны белде: Кадыйровның бары дүртмә, бишме класс кына белеме бар икән. Белеме булмагач армиядә тотмаганнар, сугыш беткәч, өлкән лейтенант чинында өенә җибәргәннәр. Бернинди һөнәре юк, аптырагач налог инспекторы булып эшкә урнашкан. Хәзер кичке мәктәптә укып маташа.

Шәфика, Кадыйров аның базарда тотылуы турында сөйләп дөньяны сасытыр дип шикләнгән иде, хәзергә ләм-мим. Гайбәтче түгел, күрәсең...

Тормыш көннән-көн катырак кыса башлагач, Шәфика бер бүлмәгә фатирчы кертергә уйлады. Моңа Фатыйха абыстай да каршы килмәде:

— Әйе шул, кызым, акчасы иш янына куш булыр,— диде аның фикерен хуплап.— Ягулык табуы да кыенлашты, кыш хәзер килеп җитә, алдан аяк киенеп куярга кирәк.

Соңгы вакытта фатир сорап килүчеләрнең исәбе-хисабы юк. Бигрәк тә студент халкы фатир таба алмый интегә. Фатыйха абыстай кызын кисәтеп куйды:

— Фатирчы табуны син үзең хәл ит, парлы кеше булмасын,— диде. Ләкин ахыр чиктә, бу мәсьәләне барыбер аның үзенә хәл итәргә туры килде.

Фатир эзләүчеләр көндез, Шәфика өйдә югында киләләр иде. Ул алардан: «Кызым өйдә юк, аннан башка бер сүз дә әйтә алмыйм»,— дип

котылып килде. Арадан берсе сагыз булды, сүзен сүз итми чыгып китәргә теләмәде. Аңа фатирның аерым бүлмә булуы ошады. Әйе, үзең ачып керәсең, үзең бикләп чыгасың.

— Мин ялгыз кешене генә фатирга кертәм, күреп торам, син яшь кеше түгел, хатының, балаларың бардыр,— дип әйтеп карады Фатыйха абыстай, авыз ачарга да ирек бирмәде. Ә теге паспортын чыгарып өстәлгә ыргытты:

— Мә, карагыз! Дөньяда миннән дә ялгыз кеше таба алмассыз,— диде. Бу — Галләм Җиһаншин иде. Клава өйдән куып чыгаргач, тәненә генә түгел, җанына да урын таба алмый каңгырып йөргән чагы иде.

Бусаганы атлап керү белән тегү машинасы артында утырган карчыкны күреп сискәнеп китте. Чиста киенгән, аякларында чигүле итек, башына ак батис яулык япкан. Яулык астыннан көмеш кебек ак чәчләре күренеп тора. Күзләрендә серле караш. Шундый таныш, тик кемгә ошатырга гына белмәде.

Ишек бикле булмагач, Галләм шакылдатып, рөхсәт сорап тормады. Дөресрәге, ишек ачылу белән туры өйгә килеп керермен дип уйламаган иде. Рөхсәтсез килеп керүе өчен гафу үтенде үтенүен, ләкин соң иде инде.

Фатыйма абыстай башта Галләмнән налог инспекторы түгел микән дип шикләнде. Ишекне ачык калдырып эшкә утыруы өчен эчтән генә үзен шелтәләп тә алды. Галләм исәнләшеп сүз башлау белән шиге юкка чыкты тагын. Налог инспекторлары әдәпнең нәрсә икәнен дә белмиләр, керү белән тегү машинасын барып ябышалар. Бу кеше бөтенләй башка. Ул сәгатьтән артык гомер хуҗабикәне авызына каратып әңгәмә корып утырды. Ләкин теләгенә ирешә алмады. Ахырда кызы кайткач кич килергә сөйләшеп китеп барды.

Галләм — вәгъдәсендә тора торган кеше. Әйттеме, эшли. Кечкенәдән шулай гадәтләнеп үсте. Фатыйма абыстайларга да ул сөйләшенгән вакытта килеп керде. Шәфика белән икесе бер трамвайда кайтканнар. Шәфика капка төпләрендә күршесе белән сөйләшеп калмаган булса, өйгә дә икесе бергә килеп керәсе булганнар икән.

— Нәрсәдер озаклады, башка вакытта болай тоткарланмый торган иде,— диде Галләмне каршы алып Фатыйха.

— Кунып кала торган гадәте юктыр ич? — дип сорады Галләм, сүзнең кызы турында барганын аңлап. Ул арада Шәфика үзе дә өйгә килеп керде.

— Кунак бар икән, әни ник урын тәкъдим итмисең? Аннан Галләмгә карап:— Утырыгыз, утыр! Ничек диләр әле руслар? Аяк өстендә дөреслек юк диләрме?

Кызның чибәрлегенә сокланып, Галләм югалып калды. Зәвык белән гади генә киенгән. Чәч толымнары көлтә кебек. Күзләрендә кешене үзенә тартып тора торган ягымлы караш. Бер дә килмәгән җире юк. Ниһаять, үзен кулга алып Галләм телгә килде:

— Бүген икенче мәртәбә килүем инде. Әниегезне алҗытып бетердем бугай, һич күндерер хәл юк.

— Фатир турында белешергә килдегезме? Ялгыз хәл итә торган эш түгел шул — уйлашырга, киңәшләшергә кирәк.

— Фатирчы кертергә уйласагыз, нигә аны сузарга?

— Белешми-сөйләшми генә кертеп булмый, төрле кеше бар...

— Ничек төрле кеше?

— Хәзер кешегә ышану кыен. Кереп арт ягы җылынырга өлгерми, күрмәгәнеңне күрсәтә башлый.

— Ничек аңларга? Мине дә шундый начар ният белән йөри дип уйлыйсызмы?

— Кем белә сезне? — Сүзләренең шаярып әйтелгәнен аңлатыр өчен кычкырып көлде.— Маңгаегызга язылмаган...

— Әйтегез, гадел кеше булуымны ничек исбатлыйм? — Мескен тавыш белән әйтелгән бу сүзләр Шәфика күңелендә кызгану тойгысы

уятты. Әдәпле, сүзендә тора торган кеше булса кирәк, дип уйлап конкрет сөйләшүгә күчте:

— Фатирга кертүен, керту дә, без куйган шартларга риза булырсыз микән?

Фатиха абыстай өстәлгә самавыр чыгарып утыртты:

— Кызым, син эштән кайткан кеше, ашыйсың килеп беткәндер, чәй эчеп сөйләшегез, кунакны да чакыр.

— Ах, хәтер диген инде,— дип Галләм башын тотты.— Онытып җибәрә язганмын!— Кесәсеннән бер төргәк чыгарып өстәлгә куйды.— Конфет алып килгән булган идем, яратырсызмы?— Төргәктә шул заманда сатуга сирәк чыгарыла торган шоколад конфет иде. Фатыйха абыстай да аннан калышмады, сынатмаска теләп булса кирәк, бал белән май чыгарып куйды. Гадәттә, мондый сый олы кунаклар килгәндә генә табынга куела иде.

Фатыйха абыстай беренче чиратта Галләмнең кайсы як кешесе булуы белән кызыксынды. Сүзнең азагы гаилә тормышына килеп терәлде. Ул үзенең ялгыз дүдәк булып йөрүен сугыш аркасында армиядә тоткарлануы белән аңлатты.

— Дөрес, армиядә хезмәт иткәндә дә өйләнергә мөмкин иде. Әмма шулай килеп чыкты, татар кызлары очрамады. Соңгы сүзләр Фатыйха абыстай күңеленә сары май булып ятты. Алдашмаса, буш кеше булмас дип уйлап куйды. Үзе дә сизмәстән, бер кызы Шәфикагә, бер Галләмгә карап алды:

— Сезгә кыз димләргә кирәк алайса...

— Әни! Юкны сөйләп утырма,— диде Шәфика ачулы тавыш белән. Галләм кайсы якны хупларга да белмәде, шулай да аптырап калмады:

— Фатир вәгъдә итәләр, өйләнү турында үз фатирым булгач, уйларбыз.

Бу сүзләре белән ул йорт хуҗаларының үзе турындагы шиген бер селтәнүдә юкка чыгарды.

— Фатир булыр кебекме соң?— дип сорады Шәфика.

— Гамәлдәге закон буенча демобилизацияләнгән офицерларга йә фатир, йә йорт салырга җир бирергә тиешләр... Сез мине вакытлыча фатирга кертеп торыгыз инде, югыйсә урамда торырга туры киләчәк.

— Моңарчы кайда яши идегез соң?

— Бер танышымда фатирга урнашкан идем, хәзер анда яшәү мөмкин түгел.— Сүзне озынга җибәрмәс өчен кисәтеп куюны кирәк тапты.— Сәбәбен сорамагыз, әгәр сездә торып калсам, үз җаем белән бер сөйләрмен.

Башта ук бөтенесен дөрес итеп сөйләргә кыенсынды. Күпме ялганларга була? Хәзергә алдап сөйләгәннең шул кадәресе җитеп торыр дип уйлады.

Шәфика җавап белән канәгатьләнде булса кирәк, сүзне икенчегә борып:

— Әни, нишлибез?— дип сорады.

— Әүвәл Аллага, аннан сиңа тапшырам, үзең хәл ит.

Шәфика Галләмнең өстәлдә яткан паспортын алып, күзеннән үткәрде.

— Менә болай, иптәш Җиһаншин,— диде бераздан.— Безнең шундый шартыбыз бар: фатир хакын ярты елга алдан түлисез, аннан кышка ягып чыгарга җитәрлек утын аласыз.

Галләм башын кашып куйды. Акчасы бар, анысын бирер. Ә менә утынны каян табарга?

— Сез куйган шартларга мин риза, кайчан күчеп килергә мөмкин?

...Шулай итеп, ул яңа фатирда яши башлады. Бүлмәсен чын күңелдән ошатты. Аның болай үзе теләгәнчә, иркенләп яшәгәне юк иде әле. Ашау-эчүне ул йорт хуҗалары белән бергә көйләп җибәрде.

— Үзегез әзерләгән ризыктан иртә-кич миңа да өлеш чыгарырсыз: көндезләрен кайтып йөрмәм,— диде.

Фатыйха абыстай икеләнеп калды. Иң кыены — азык табу мәсьәләсе. Итне колхоз базарыннан ташый. Күпләп алырга хәленнән килми. Кайсы көннәрне коры аш белән генә калырга туры килә. Аннан тагын шунысы: Галләм ул әзерләгән ашны яратырмы? Беренче көннән үк шул ачыкланды: Галләм ашауга талымсыз, нәрсә әзерләсәң — шуңа риза. Итне түшкәсе белән алып кайтып, Фатыйха абыстайны базарга йөрүдән коткарды. Сакларга урын булмау гына үзәккә үтә. Ул елларда хәзерге кебек суыткычлар юк иде шул әле.

Бер көнне Шәфика кичке аш янында ниндидер кинофильм турында сүз кузгатты:

— Халык шашкан, билетка чират урамнан... Инде берничә көнгә алдан сатылып беткән.— Галләмнең дә бу фильмны карыйсы килеп йөри иде — баш рольдә, дөрестерме-юктырмы, Гитлерның сөяркәсе уйный, имеш. Трофейга алынган фильм. «Хыялдагы кыз» дип атала. Немецчәсе «Дие мэдхен майне тройме». Ул Шәфиканең сүзләрен мыегына чорнап куйды. Икенче көнне берәр рәте чыкмасмы, дип уйлап билетка китте. Кассага якын да бара торган түгел, ә кулдан алырга була. Андый вакытта акча кызганалармы соң? Сатулашып маташмады, иллешәр сумнан ике билет алды. Заманында бу шактый зур акча иде.

Билетны ансат кулга төшерсә дә, Шәфиканы озак көйләргә туры килде.

— Айлык хезмәт хакымның чиреген бер мәртәбә кино караган өчен түләп кайтырга минем хәлдән килми,— дип кәҗәләнде.

— Акча түләп алмадым,— диде Галләм.— Эшләгән җирдән бирделәр... Шәфика ышанмаган булып маташты. Ахыры чиктә Фатыйха абыстай кушылырга мәҗбүр булды:

— Гөбәдиягә арт якны куярга ярамый,— диде ул, кызын үгетләп.— Берәү сине хөрмәт итеп киногa чакыра, нинди бармау ул? Тиз бул, киен аягыңны!

Алар кинода бер-берсен белмәгән, чит кешеләр кебек утырдылар. Галләм берничә мәртәбә Шәфиканың кулын тотарга талпынып карады, җавап булмады. Турысын гына әйткәндә, ул Галләмне үзенә тиң итеп исәпләми иде. Аларның яшь аермалары әлләни зур да түгел — сигез ел гына, тик Шәфиканың башында ниндидер бер җүләр фикер урнашып калды: ул сугышта йөреп кайткан ирләрне карт итеп күз алдына китерә. Үзе дә бит фронтка китүдән чак кына котылып калды.

1941 елны, сугыш башлангач, бер төркем комсомоллар үзләре теләп армиядә хезмәт итәргә язылдылар. Шәфика да шуларга иярде. Бу вакытта әле аңа унсигез яшь тә тулмаган иде. Шәһәр хәрби комиссариатында алар бөтенесе йөзгә якын кыз җыелды. Ул чакны ил язмышы кыл өстендә иде. Немец Мәскәүгә килеп житте. Халык арасында, Гитлер бинокльдән Кремльне күзәтә икән, дигән хәбәр таралды. Патриот кызларны хәрби комиссариатта озак тоткарламадылар. Икенче көнне үк сафка тезеп, вокзалга алып киттеләр. Болак буена җитәрәк бер өлкән лейтенант Шәфиканы сафтан тартып чыгарды да:

— Сиңа монда нәрсә калган? Тиз бул, өеңә кайт,— дип кычкырды. Шәфика аптырап калды.— Әле син командага буйсынмыйсыңмы? — диде арт ягына типкәләп.

Фатыйха абыстайның билгесез бу өлкән лейтенантны бер вакытта да догадан калдырганы юк. Бар бит Алланың мәрхәмәтле бәндәләре! Шушы хәлдән соң Шәфика ник бер мәртәбә авызын ачып армиягә китү турында сүз әйтеп карасын! Бала гына иде әле шул ул чагында.

Галләмнең киногa ике билет алуын Фатыйха абыстай чын күңелдән хуплады. Ул аның белән көннән-көн ныграк кызыксына башлады. Нинди кеше соң ул? Фатирда яши башлавына айдан артык вакыт узды, янына килгән, киткән кеше юк. Берәр дус-ише килеп чыкса, кактырып, суктырып кылын тартып карар иде ичмаса... Юк, беркемнең дә килгәне юк! Сөйләвенә караганда, Галләм авылда туган. Гадәттә, авыл кешесен

фатирга кертсәң, икенче көнне үк көтүе белән туганнары килеп житә торган иде. Моның туганнары да юк микәнни соң?!

Фатыйха абыстайның Галләм белән кызыксынуы юкка түгел иде. Төптән уйлаганда, ул аның кызына менә дигән пар бит. Юк, үзе очып килеп кергән алтын кошны кулдан ычкындырырга ярамый! Хатын-кызның хәле авыр, ирләр сугышта чебен кебек кырылды. Кызның бөтенләй ирсез дә калуы бар. Олы булса соң?! Ирләрнең хатыннан олы булганы яхшы. Аның үз ире дә — Шәфиканың атасы, Фатыйха абыстайдан күпкә олы иде. Менә дигән итеп яшәделәр әле, өрмәгән жиргә дә утыртмады!

Фатыйха абыстай кызын ашыгып кияүгә бирергә жыенмый, әлбәттә. «Ашыккан ашка пешә» дигән сүзләрнең мәгънәсен яхшы аңлап эш йөртә. Ләкин хәстәрлегән күрә башларга вакыт. «Аслыhи-нәслеhи» дигән сүз бар. Иң элек Галләмнең кем баласы, нинди гаиләдә тәрбия алуын белергә кирәк. Кактырып, суктырып сораша торгач, тәки теләгенә ирешә.

Галләм чыгышы белән авылдан икән. Сугыш алдыннан Донбасста яшәгәннәр. Ул армиягә дә шуннан алынган. Билгеле булганча, Донбасс вакытлы немец оккупациясендә булды. Азат ителгәч, хат язып карады, җавап килмәде. Шуннан соң башка хат язып тормады. Чөнки анда, аның өчен өзелеп торырлык кеше юк иде. Үз әнисен ул бик аз хәтерли. Алты яшендә ятим калды. Әтисе берничә хатын алыштырды. Бердәнбер бала булуга карамастан, аның турында кайгыртмады. Укуын да урыс мәктәбендә укыды ул. Гомумән, урысча тәрбияләнде. Ярый әле, әнисеннән өйрәнеп калган туган телен онытмады. Моңа күршедә яшәүче татар карчыгының да ярдәме тиде булса кирәк. Кечерәк вакытта ул ятим баланы үзләрендә асрады. Галләм кайтканда фатирлары бикле була, ул әтисе йә үги әнисе кайтканчы шушы күрше карчыгында торып тора иде. Карчык аны оныклары белән бергә утыртып ашата, эчертә иде. Үзара фәкать татарча гына сөйләштеләр. Карчык әле Галләмгә бер изге дога да өйрәтте. Дога әле дә хәтерендә. Әгәр, аның белән элемтәгә керә алса, акча белән ярдәм итәргә иде исәбе — тик хатларына җавап килмәде. Галләм карчыкның изгелеген бер вакытта да онытачак түгел. Армиядән демобилизацияләнгәч ул, бернинди икеләнүсез Казанга кайтты. Әбибабасы, мәрхүм әнисенең туган туфрагы үзенә тартты. Казанга кайту теләгенә ирешүен ирешүен, ләкин тормышы көйләнмәде. Каңгырып йөри торгач шуны аңлады: марҗа ияртеп кайтып ялгышты ул. Бер вакытта да үзеңне тудырган халыктан аерылырга ярамый икән! Кызлар үз милләтеннән булган егеткә кияүгә чыксын, егетләр үз милләте кызына өйләнсен! Шул чакта гына гаилә бәхетле була. Бу — аның тормышта аяусыз рәвештә расланган фикере.

Галләм үзе дә Фатыйха абыстайга фатирчы булып керүенә сөенеп бетә алмады. Бәхетемне тапсам, фәкать шушы йортта табачакмын, дип уйлады. Тик ничек итеп Шәфиканы үзенә кияүгә чыгарга күндерергә? Һәр сүзеннән сизелеп тора, ул аны тиңсенми. Кызлар башта санатка кияүгә чыгарга хыяллана, ди бит. Анннан, солдатка да риза булыр идем, дип әйтә ди. Күрәсең, Шәфика да бу чир белән авырый. Кайсы яктан кармак салып карарга?

Фатыйха абыстай белән Галләмнең дуслыгы көннән-көн ныгыды болай.

Фатыйха абыстайның үзе исәнендә, алай гына да түгел, аягына нык басып торганда, кызын башлы-күзле итәсе килә... Мәсьәлә Шәфикага килеп терәлде. Галләм тәкъдим ясагач: «Мин бер вакытта да кияүгә чыкмыйм»,— дип кырт кисте. Озак үгетләргә туры килде кызны. Тырышып үгетли торгач күнде тагын. Әле бусы башы гына иде. Эчкәрәк кергән саен каршылыклар берсе артыннан берсе туып кына торды. Галләм никах укытырга каршы килеп маташты. «Ничек инде, коммунист башым белән дини йоланы үтим?» — дип кәҗәләнде. Фатыйха абыстай сүзендә нык торды. «Никахсыз ир белән хатын булып яшәргә рөхсәтем

юк»,— дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды. Галләмгә буйсынудан башка чара калмады. Никах мәҗлесен Фатыйха абыстайның бер танышында үткәрделәр. Яшерен рәвештә. Мәчеттән мулла чакыртсалар, иртәгесен үк хәбәре тиешле оешмаларга барып җитәчәген яхшы беләләр иде.

Туй зурдан кубып үткәрелде. Беренче көнне яшьләр, икенчесендә парлылар җыйналды. Галләм акчаны кызганмады.

Фатыйха абыстай болай ук булыр дип өмет итмәгән иде. Теләгенә иреште. Җимеше дә озак көттермәде. Шәфика бер-бер артлы ике бала тапты. Бер малай, бер кыз. Әмма... Аларның бөтен ачысын картайган көнендә Фатыйха абыстайга татырга туры килде.

## V

Галләм идарә утырышы җыйды. Теләгән кешегә катнашырга рөхсәт ителде. Ләкин гади колхозчылардан килүче булмады дип әйтерлек. Көнаралаш үткәрелә торган утырыш, җыелышлар туйдырып бетерде. Чакыра баргач, күбесе качып кала. Йә төрле сәбәп табып килми генә. Идарә әгъзалары да утырышка йөрүдән баш тарта башлады. Бригадир Кәбирне эзли-эзли хәлдән тайдылар. Бүгенге утырышта ул — иң кирәкле кеше. Атлар мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Аның бригадасына беркетелгән атлар арсында гына җигеп йөрерлекләре бар. Бригададагы колхозчылар аланга хәл кадәренчә өйдән азык ташып ашаталар. Кайберәүләр атны үз ишегалларына алып кайтып тотарга рөхсәт сорап караганнар иде. Әмма бу социалистик милекне уңга, сулга таркату дип бәяләнәчәк. Андый эш өчен нинди җәза биреләчәге билгеле.

Рәис белән хисапчы киңәштеләр дә, Кәбир бригадасыннан берничә атны шәһәргә эшкә җибәрергә уйладылар. Икесе генә хәл итә торган эш түгел, райком гауга күтәрәчәк. Чөнки бу мәсьәлә буенча махсус карар кабул ителде. Тарту көчен читкә тарату тыела. Атларны идарә карары белән эшкә җибәрсәләр, бәлки бергәләп җавап бирүе җиңелрәк булыр. Шик тә юк, таякның юан башы Галләм җилкәсенә төшәчәк.

Җилкәсе калын, чыдар әле...

Утырыш шау-шулы булды. Фатыйма атларны шәһәргә җибәрүгә теше-тырнагы белән каршы чыкты. Яклаучы тапмагач, янарга тотынды:

— Иртәгә үк хәбәр итәм,— диде зәһәрен чәчеп,— аннан миңа үпкәләп йөрмәгез! — Ревизия комиссиясе әгъзасы Җаббар бабай сүз алып, бәхәсле сөйләшүләргә нокта куйды:

— Мин инде яшен яшәгән, ашын ашаган, үләсе кеше, кемне дә булса җавапка тарталар икән, гаепне миңа аударыгыз,— диде.— Атларны ашатып, эчертеп тәрбияләү — барыбызның да изге бурычы. Ул мәхлукларны ачлык белән тилмерткәнне Алла да, мулла да гафу итмәс...

Күпчелек тавыш белән «атларны шәһәргә җибәреп эшләтергә» дигән карар кабул ителде. Бу әле беренче адым гына иде. Иң элек берәр оешма белән элемтәгә кереп, шартнамә төзеп кайтырга кирәк. Кемгә ышанып тапшырырга? Уйлаша торгач, Шәрәфигә тукталдылар. Фатыйма бу тәкъдимгә дә каршы чыкты:

— Аның кем икәнен белеп эш кушыгыз,— диде.

Идарә утырышыннан соң рәис белән хисапчы икесе генә, иркенләп гәпләшеп утырдылар. Галләм, зур бер серне чишкән кебек итеп, Шәрәфинең райкомга сарык түшкәсе илтергә тәкъдим ясавы турында сөйләде.

— Ул хәзер гадәти хәлгә әйләнеп бара,— диде Таһир исе китмичә.— Куркырлык бер нәрсә дә юк.

— Ничек? — диде Галләм чиктән тыш әсәрләнеп,— бу бит ришвәт бирү! Алучыны да, бирүчене дә җавапка тарталар. Закон каты...

— Кемгә каты, кемгә юк,— диде Таһир мыек астыннан елмаеп.

— Закон каршында бар кеше дә бер тигез икәнне белмисең мәллә?..

Балаларча факер йөртә дип уйлап, Таһир җавап биреп тормады. Галләм үз чиратында, әллә инде мин акылдан язам, әллә инде минем тирәдәге кешеләр акылдан язалар дип уйлады.

— И-и-иптәш председатель,— диде Таһир аның уйларын бүлдереп,— йөгерә, йөгерә илтер идек, бүләккә бирерлек сарыгы да юк бит әле аның. Фермадагы коры сөякка калган малларны үз күзең белән күрдең бит.

Әңгәмә кызып җиткәч кенә Шәрәфи килеп керде. Таһир аны күтәреп алган кебек иттерде.

— Әйдүк, әйдүк, Шәрәфи дус! Озын гомерле булырсың, сине искә төшереп утыра идем.

— Мине дә санга сугар көн җитәр икән...

— Идарә утырышының карары белән сиңа гадәттән тыш җаваплы эш тапшырыла.

— Эшкә тотынгач чакыртып алмаслык булсагыз гына ризалыгымны бирәм,— диде ул үзенең беренче шартын итеп.

— Син бик иртә шарт куярга тотындың әле, иң элек эш күрсәт!

— Аннан соң була ул! Өченче ел, әнә акча эшли башлагач кына мари урманыннан чакыртып кайтардыгыз...

— Ул турыда тыныч бул,— Галләмгә ымлап күрсәтте дә:— иптәш Җиһаншин сүзендә тора торган кеше,— диде. Аннан сынаулы караш ташлап:— менә нәрсә, Шәрәфи дус,— дип сүзен дәвам итте:— Колхозга бер симез сарык кирәк, кисәтеп куям, сөйләшү ике арада гына калсын!

Шәрәфи аны-моны уйлап тормады:

— Миндә бар, сатам, ал!— диде.

— Үземә түгел, колхозга дип ачык иттереп әйттем, ләбаса. Колхозның нинди хәлдә икәнен беләсең...

— Миңа акчасы хәзер кирәк.

Сарык бәһасын атлар шәһәргә барып акча эшли башлагач түләргә килештеләр. Шәрәфи белән икесе бергә терәкле чанага утырып, район үзәгенә киттеләр. Сарык түшкәсен кирәкле кешесенә Таһир ялгызы гына кертеп бирде.

Хәзер инде шәһәрдә ат белән эшләрлек ирләр табу мәсьәләсе алга килеп басты. Авылда ирләр бар барын, ләкин физик хезмәткә яраклысы бернична генә. Ә менә кая барып сугылырга белмиче йөрүче үсмерләр буа буарлык! Мәктәп җиде еллык кына. Укуны дәвам иттерергә мөмкинлек юк. Урта мәктәп исә район үзәгендә — ун чакрым ераклыкта. Берсенең дә анда барып укып йөрергә хәленнән килми.

Шәрәфи, җиде класс тәмамлаган үсмерләрне шәһәргә алып китеп, эшкә кушарга тәкъдим ясады. Таза-таза егетләр, эшләсеннәр ат белән, югыйсә ташып торган көчләрен кая куярга урын таба алмый аптырап йөриләр.

Тәкъдим авыл халкы күңеленә хуш килде. Эшкә барырга теләүче үсмерләр саны кирәгеннән дә артып китте. Уйлаштылар да, аларны сменалап эшләтергә карар чыгардылар. Бер атна эшләп, бер атна ял итәргә. Ял итүче смена авылга кайтып торырга тиеш. Тырышып-тырышып еласаң сукыр күздән дә яшь чыга бит! Болай эшләү халыкны канәгатьләндерде. Югыйсә, кайбер көнчерәк аналар, шәһәрдә эшләргә үзләренең таныш-белешләрен генә алып китәләр дип, гауга чыгара башлаганнар иде.

Күп тә үтмәде, ат белән эшләүнең нәтиҗәсе дә күренде. Йортлар идарәсе дәүләт банкысындагы колхоз хисабына акча күчерде. Ләкин колхозның үзенә бер тиене дә эләкмәде. Акча тулысы белән керемгә алынган налогны капларга тотып калынды. Галләм керем налогыннан котылу юлын эзләп карады, барып чыга торган булмады. Райондагы властька колхозларны керем налогыннан коткару хокукы бирелмәгән икән. Гамәлдәге закон буенча бары Министрлар Советы карары белән генә коткарырга мөмкин. Анда да әле бәла-каза килгән очракта гына!

Ашыгыч рәвештә Шәрәфине чакырып кайтардылар. Бергә җыелып уйлаша торгач, эшләп алган акчаны колхозның үзенә калдыру юлы табылды. Моның өчен шартнамәне үзгәртеп корырга туры килде. Шәрәфи үзләре ялланган йортлар идарәсеннән акчаны ат белән эшләүчеләрнең кулына бирүне таләп итте. Әгәр шулай эшләмәсәгез, кайтып китәбез дип кисәткәч, ризалашырга мәҗбүр булдылар. Коры кашык авыз ерта, хезмәт хакыннан бераз чыгарырга туры килде, әлбәттә...

Шуннан соң эш майланган кебек тәгәрәде. Ат белән эшләүче малайлар ведомостька кул куеп алдылар да, акчаны Шәрәфигә тапшырдылар. Ә Шәрәфи исә тиененә кадәр колхоз хисапчысына кайтарып бирде. Акча кайтарып бирү белән генә дә чикләнмәде, сыра заводы белән элемтәгә кереп, барда сатып ала башлады. Аның бер өлешен атна саен колхозга җибәреп торды.

Шәһәрдә эш язга кадәр дәвам итте. Атларны тагын бераз вакыт анда эшләтеп торсаң яхшы була иде булуын, әмма язгы чәчү якынлашу сәбәпле, кайтарырга туры килде.

Шәрәфи уйлап йөрде дә, авылга кайтмаска кирәк дигән фикергә килде. Анда аңа көн күрсәтмәячәкләр. Алла үзе сакласын, теле тик тормый — тагын таш капчыкка утыртулары бар! Шәһәрнең үзендә төпләнеп калу турында уйларга да мөмкин түгел, чөнки паспорты юк. Паспорты булса да, аны пропискага алмаячаклар. Тагын шунысы: авылдан да ансат кына китә алмас әле. Ничектер, җаен эзләргә туры киләчәк.

Тиз генә авылга кайтып, өенә дә кереп тормыйча Галләм янына ашыкты. Куркып кына сүз башлаган иде, гаҗәпләнүенә каршы, эш ул теләгәнчә хәл ителде. Әмма колхоздан китәргә рөхсәт алу белән генә эш бетми, милициянең паспорт өстәлендә тоткарлаячаклар... Моның да юлы табылды. Тимерне кызуында сугарга теләп, сыерын суйды. Баш-аягын, эчәкләрен «болары сиңа» дип хатынына тоттырды. Итен милиция начальнигына илтеп бирде. Илтеп бирде дип әйтергә генә ансат. Бөтен кешенең дә кулыннан килә торган эш түгел, рәтен белергә кирәк.

Ләкин кулына паспорт керү белән Шәрәфи ашыгып авылдан китеп бармады. Элеккечә тырышып эшләвен дәвам иттерде.

Колхозның бер бөртек чәчү орлыгы юк иде. Кар эреп, юллар өзелгәч кенә, чәчү орлыгын барып алырга кушып наряд килде. Әйткән вакытында барып алмасаң, орлык югалачак. Аннан бөтен колхозың белән кая керергә тишек таба алмассың! Галләм чәчү орлыгын алып кайтуны Шәрәфигә тапшырды.

— Шунсыз беркая аяк атламыйсың! — диде.

Орлыкны егерме биш чакрымдагы заготзерного барып алырга кирәк. Елгаларга ташу төшкән вакыт, бөтен дөньяны су баскан. Ат җигеп юлга чыгарлык түгел. Казансу аркылы үтәргә кирәк. Язгы ташу вакытында аның күпере сүтеп алына. Төрле ерганакларның исәбе юк. Казанда эшләгәндә үзе җибәргән барданы ашатып, аз-маз тернәкләнгән атларны шул ерганакларда батырып калдырыргамы?

Заготзернодан чәчү орлыгы алып кайту мәсьәләсен хәл итәр өчен махсус идарә утырышы җыярга туры килде.

— Бу бәладән коткарса, безне «уфалла» коткарачак,— диде Шәрәфи, утырышта сүз алып. Үч иткән шикелле, аның «уфалла»сы да санаулы гына икән. Бөтен хуҗалыклар да кул белән тартып йөри торган чана тотмый. Җыйный торгач, йөз илледән артык йортлы авылда өч дистәгә якын чана табылды. Һәр чанага ике кеше беркетелде. Билгеле инде, бу эшкә хатын-кызлар җигелде. Ирләр бармак белән санарлык кына. Хатын-кызлар да әле юлга чыгарга ашыгып тормады: өйдән өйгә кереп, көйләп йөрергә туры килде. Ачыктан-ачык каршы килүчеләр белән сүзне кыска тоттылар. «Чәчү орлыгы алып кайтырга барырга теләмисеңме? Димәк, колхоз эшенә аяк чалучы! Алай гына да түгел, корткыч! МГБ кешеләре иснәнеп кенә йөри. Хәзер килеп җитәчәкләр. Алар белән сүзнең ничек тәмамланачагы билгеле. Аннан үзеңә үпкәлә...»

Чәчү орлыгы алырга баручылар кичтән юлга чыктылар. Әтүтән аларны ат җигеп озата барды. Юлда нәрсә булмаска мөмкин? Бар ягы исәпкә алынып эшләнде. Олырак яшьтәге хатын-кызлар алмаш-тилмәш чанага утырып, ял иткәләп тә алгаладылар.

Юлда барганда андый-мондый гадәттән тыш хәл булмады үзе, исән-сау барып җиттеләр. Барып җиткәч менә башланды... Документлардан гаеп табып алҗыттылар. Аннан кирәкле кешесен каядыр чакырып алдылар. Бик озак кайтмады. Тоткарлык артыннан тоткарлык туып кына торды.

Ә кайтыр юлга чыкканда кояш шактый югары күтәрелгән иде инде. Казансуны иртәнге туң белән аркылырга өлгерделәр. Югыйсә, эш харап иде. Кояш кыздырганнан, кар боламыкка әйләнде. Юлларда су тездән. Барысының да аягында чабата. Кайберәүләр юлның нинди буласын сизенеп, икешәр кием чабата алып чыкканнар. Аякларын чишенеп, чолгауларын алмаштырып алдылар. Ике хатын бер ерганакны чыкканда, бозлы суга чумды. Көчкә тартып чыгарып, Әтүтән янына утырттылар. «Уфалла»га төялгән чәчүлек орлык суда калды. Бәхетләренә, авылдан ерак түгел иделәр. Барып җитү белән хатынны иң кырыйдагы йортка керттеләр. Бик үтенгәч, йорт хуҗасы мунча ягып, парландырып чыгарды.

Чәчү орлыгын ерганакта суга батырып калдыру сәгате-минуты белән тиешле оешмага билгеле булды. Тикшерүче килеп тә җитте.

Суга баткан Зәйнәп исемле хатынның әтисе белән бертуган абыйсы утыз җиденче елны «халык дошманы» дип игълан ителеп, авылдан сөрелгән булган икән. Менә кая барып тоташа җепнең очы! Башка бер сәбәбе дә юк, ул хатын абыйсының үчен ала! Абыйсы гади дошман түгел, сәяси дошман! Гражданнар сугышы барган елларда, Троцкий Казанга килгәч, ул оештырган митингта катнашкан кеше абыйсы!

Зәйнәпнең ике баласы бар. Кечесе яңа тәпи йөри башлады. Ире — сугыш инвалиды. Хатынын көн саен кәнсәләргә чакырып сорау ала башлагач, бөтенләй бетерешге. Эчәргә үк сабышты.

Зәйнәпне кулга алудан ике нарасый бала гына коткарды булса кирәк. Эше судта каралып, «усал ният» белән суга батырылган чәчү орлыгының бәһасын эзләп алу белән генә чикләнделәр.

Галләм заготзерногa үзе бармаганга үкенеп бетә алмады. Юл төшкәнче үзләренә тиешле чәчү орлыгын шунда калдырып торырга сөйләшеп караган булыр иде. Бөтенләй бармаган булсалар да асып куймаслар иде әле. Зәйнәпне кызганып йөрәге авыртты. Татар акылы төштән соң шул...

Колхозны чәчү орлыгы белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Галләм райком бюросына чакырып тыңланды. Бу аның рәис булып эшли башлаганнан бирле әле беренче мәртәбә бюрога чакырылуы иде. Барысы турында да ныклап кисәтеп, исенә төшерделәр.

Иң элек Жданов исемендәге колхоз рәисенең эше каралды. Озакка сузылмады. Эчеп, исереп йөрүе һәм мораль яктан череп таралуы өчен партиядән чыгарырга дигән карар кабул иттеләр дә, шуның белән бетте. «Череп таралуы» нидән гыйбарәттер, Галләм игътибар итеп тормады, кем әйтмешли, үз хәле хәл иде.

Галләм эше буенча икенче секретарь Фәйзуллин информация ясады. Ул — чәчләренә ак кергән, кысык күзле, табак битле, урта яшьләрдәге ир. Маршал Буденныйга охшатып үстергән мыек чылгыйлары асылынып төшкән, үзенә бер дә килешми. Уң кулының бармаклары махорка төтененә саргайган, авызыннан бер чакрымга сасы ис аңкый. Ул Галләмне заготзернодан чәчү орлыгы алып кайтуны оештыра белмәүдә гаепләде. Гамьсезлектән файдаланып, орлык ташучылар арасына шикле кешеләр үтеп кергән, имеш.

— Берничә капчык гәрәбәдәй бодайның су астына җибәрелүе очраклы хәл түгел,— диде.— Тикшерү вакытында шул ачыкланды, сыйнфый дошман кулы уйный.

Фәйзуллинның фикерен куәтләп карт большевик Иванов чыгыш ясады. Аның тешләре юк. Сөйләгәндә селәгәе ага. Утырышта катнашучылар чирканып, аның йөзенә күз төшермәскә тырышалар. ул чыгышын Лениннан цитата китереп башлады.

— Сыйнфый уяулыкны бер вакытта да истән чыгармаска кирәк,— диде сүзен дәвам итеп.— Ә без юлбашчының бу турыда әйткән сүзләрен бик еш игътибарга алмыйбыз. Нәтиҗәсе күз алдында. Сыйнфый уяулыкны онытучы кешегә партия сафында урын булмаска тиеш.— Ул Галләмне партиядән чыгарырга тәкъдим итте.

— Мин иптәш Ивановның тәкъдимен яклыйм,— диде өстәл почмагында утырган Миңлекәева фамилияле хатын.— Иптәш Җиһаншин гафу ителмәслек ялгыш җибәргән.— Ул үзе гади колхозчы, әмма тыгылмаган җире юк. Бюро составына да исәп өчен генә кертелә. Җил кайсы яктан өргәнне чамалап, чыгышлар ясый. Бу юлы исә ялгышты.

Беренче секретарь чыгыш ясаучыларның тәкъдимнәре белән килешмәде. Галләмнең авылда күптән түгел эшләвен, кешеләр белән танышырга өлгермәвен исәпкә алырга өндәде.

— Без аңа вакыт бирик,— диде.— Өйрәнсен, кемнең дус, кемнең дошман икәнен ачыкласын. Аннан тагын мәсьәләнең башка ягы да бар, иптәш Җиһаншин — өлкә комитеты тарафыннан җибәрелгән кадр. Кайда кайда, өлкә комитетында кадрларны сайлый беләләр. Ашыгып, аннан җибәрелгән кешеләрне партиядән чыгарсак, үзебезне гаепләүләре бар.

Ул сүзен йомгак ясап, бюро әгъзаларын районда яшәүче һәр кешенең ничек сулыш алганын белеп торырга чакырды.

Шулай итеп, Ленин исемендәге колхозда язгы чәчүгә әзерлекнең торышы турындагы мәсьәләгә, беркемгә дә җәза бирмичә, нокта куелды. Мондый хәлнең күптән булганы юк иде.

## VI

Ирен колхозга җибәргәч, Шәфика нишләргә дә белмәде. Галләм китте дә югалды. Тормыш авырлыгы тулысы белән аның җилкәсенә менеп утырды. Ике бала, карт әнисе... Ярый әле әнисе исән. Ул булмаса, балаларны кая куяр иде? Бер хезмәт хакына дүрт җан яшәп кара әле? Хезмәт өчен түләнгән акчасын тартып-сузып, көчкә ашарга җиткерә. Балалар Фатыйха абыстайга тегүчелек белән шөгыльләнергә һич тә ирек бирми. Шулай да, тырышып-тырмашып атнага бер сырма өлгертә. Акчасы да иш янына куш була.

Һәр елны май бәйрәме алдыннан райбашкармада җыелыш үткәрелә. Быел ул аеруча тантаналы үтте. Хатын-кызлар киенеп, ясанып, ирләрен ияртеп килгәннәр. «Мин дә ир белән гомер итәм инде»,— дип уйлады Шәфика.

Докладтан соң бер төркем хезмәткәрләргә мактау грамоталары тапшырылды. Тагын берничә кешегә райбашкарма рәисе тарафыннан яхшы эшләүләре өчен рәхмәт белдерелде. Соңгылары арасында Шәфика да бар иде. Уйга батып утырып, ул үз исемен ишетми дә калды.

— Әнә, сезне мактап телгә алдылар,— диде аңа янәшәсендә утырган Кадыйров. Шәфика игътибар итмәгәч, кабатларга мәҗбүр булды. Каян килеп утырды, җен! Шәфиканың һич тә аны күрәсе килеп тормый иде. Шундый киенеп, ясанып килгән, өстеннән таракан таярлык. Өр-яңа костюм, аякларында модельле туфли. Ак күлмәккә кара галстук таккан. Ул елларны галстук тагып йөрүче ирләр сирәк иде әле.

Сизелеп тора, Кадыйровның ничек итеп булса да Шәфиканы сөйләштерәсе килә:

— Сез нишләп ялгыз? — дип сорады.

— Ял йортында,— диде Шәфика төксе генә, бөтенләй җавапсыз калдырырга яхшысынмады. Кадыйров аның иренең колхозга утызмеңче итеп җибәрелүе турында ишетеп белә иде. Мыек астыннан елмайды да:

— Бәхетле кешеләр шулай инде ул, бәйрәмне үзләре теләгәнчә үткәрә,— диде авыр сулаган булып.— Ә менә мин хатынны санаториягә җибәрергә ни тырышып карадым, теләмәде... Кадыйров сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, тантанлы җыелыш тәмамланып халык тарала башлады.

Һәрбер бүлектә бәйрәм хөрмәтенә күмәкләшеп сыйлану оештырыла. Райфода да өстәл әзерләнгән. Җиренә җиткереп, бай әзерләгәннәр. Эчемлек коеныргылык: һәр кеше алдында бер шешә ак, бер шешә кызыл. Кабарга нәрсә генә юк!? Хәтта пилмәнгә кадәр пешереп алып килгәннәр. Ни гаҗәптер, Шәфика белән Кадыйровның урыннары монда да янәшә туры килде.

Шәфиканың тамагыннан ризык үтмәде, ирен күз алдына китереп, чеметеп кенә утырды. Кадыйров рөхсәт сорап вакланмады, Шәфиканың рюмкасына «столичный» койды.

— Сез нәрсә?..— Шәфика күзләрен зур ачып карап торды да рюмканы кырыйга этәрде.

— Эчмисез? Болай әдәпле булгач, ирегез түтелдәтеп кенә тота торгандыр сезне...

— Аллага шөкер, өрмәгән җиргә дә утыртмый.— Шулай дип әйтте дә, үзе арттырып җибәрдем бугай, дип үкенеп куйды.

— Менә минем хатын болай эчә,— диде Кадыйров. Тулы стаканны бушатып та куйды. Шәфика урыныннан торды.

— Сез кая?

— Мин исерек ирләрдән куркам.

— Кем исерек? Минме? Курыкмагыз, курыкма! — диде ул тынычландырырга теләп.— Бер стакан аракыдан исергән ир ир буламыни? — Ул өстәлдәге ашамлыкларны рәттән сыпырта башлады. Шәфика аннан котылырга теләп коридорга чыкты. Коридорда кеше күренмәгәч, залга барып керде. Анда да бары музыкантлар гына утыралар иде. Бәйрәм саен күршедәге мәдәният йортыннан махсус, күңел ачар өчен чакырталар аларны. Музыкасыз бәйрәм бәйрәм буламыни ул! Бигрәк тә яшь-җилкенчәк музыканы көтеп кенә тора. Музыкантлар халыкны аяктан егылганчы биетә. Берәр рюмка «төшереп» алгач, хатын-кыз чикне белми бит ул!

Шәфика бер кырыйга барып утырды да музыкантларны күзәтте. Бар да яшьләр. Араларында кызлар да бар. Оркестр студентлардан оештырылган булса кирәк. Күп тә үтмәде, залга халык керә башлады. Түшәмне күтәрерлек итеп музыка яңгырады. Шәфика сизми дә калды, янына Кадыйров килеп утырды. «Нәрсә әле бу бәндә сагыз булды»,— дип уйлады хатын. Беренче мәртәбә күргән төсле, аны күзеннән үткәрде. Сыйланып утырганда, ул стакан тутырып аракы эчкәч аягына да басып тора алмас дип уйлаган иде — йөзендә исереклекнең әсәре дә юк. Кадыйров аны биергә чакырды:

— Әйдәгез, әйдә! Бераз сикергәләп алабыз! Утырмагыз боегып... Шәфика теләмичә генә чакыруны кабул итте. Ул үзе кечкенәдән танцы ярата. Мәктәптә укыганда биергә өйрәнү түгәрәгенә дә йөрде. Балерина булырга да теләге бар иде. Әнисе катгый рәвештә тыйгач кына тукталып калды.

Кадыйров оста бии икән. Гадәттә, татар егетләренең күбесе танцыны белми. Бигрәк тә авылдан килгәннәре.

Танцевать итә башлагач, Шәфиканың күңеле күтәрелеп китте. Ул шашып биеде. Бераздан Кадыйров яныш-пешеп, манма тиргә батты. Тәмам хәлдән таеп урындыкка юнәлде, үзе белән Шәфиканы да өстерәде.

— Ял итик! Югыйсә, аяктан егылам.

Күпме хатыннар белән биеп, мондыйны очратканы юк иде аның. Шәфиканың да маңгаена тир бәреп чыкты. Кульяулыгын тартып чыгарды. Кульяулыктан таралган хуш ис, Кадыйровның күңелендә рәхәт тойгы уятты.

— Миңа китәргә вакыт,— диде Шәфика, урыныннан торып.

— Нишләп бик иртә?

— Малаем бик көйсез, әнием озак йөри күрмә дип, кисәтеп калды.— Соңгы сүзләрне ишеткәч, Кадыйров елмаеп куйды. Бала чагы исенә төште. Уенга чыгып озаграк йөрсә, әни ачулана дип тизрәк өенә йөгерә торган иде.

— Малаегызга ничә яшь?

— Кечкенә шул әле, җидесе тулды.

Шәфика өстен киенеп кайтырга чыкканда аны Кадыйров көтеп тора иде инде. Үзен озатырга чыккандыр дип башына да китермәде.

— Әллә сез дә өегезгә кайтасызмы?

— Сез киткәч, анда бер кызык та калмады.— Шәфика аның бу сүзләрен ничек аңларга да белмәде.

Бу кичне көн аеруча матур иде. Ниндидер сәер тынлык хөкем сөрә. Бөтен җирдә яз исе аңкый.

— Сез кайсы якка? Мин трамвайга киттем...

— Бәлки, бераз сөйләшеп йөрербез. Мондый матур кич һаман булмый.

Шәфика күңеленә вәсвәсә төште. Чыннан да, өйгә кайтырга әле иртәрәк бит. Әнисе ачуланыр да, шуның белән бетәр. Чит кеше түгел ич, үз әнисе. Салмак атлап Кабан күле буена килеп чыктылар.

— Җүләр дә инде мин! Берәрсе очраса, нәрсә дип әйтермен?..

— Нәрсәдән куркасыз? Бер гөнаһ та эшләгәнебез юк бит әле...

— Ирле хатынның ят иргә тагылып йөрүе үзе зур гөнаһ.

Шәфика кире борылды. Зур урамга чыгу белән беренче очраган трамвайга менеп утырды.

Кадыйров үзен бик уңайсыз хәлдә калган итеп сизде. Аны әле бер хатынның да болай ташлап киткәне юк иде. Кайчан да булса, мин моның ачуын кайтырырга тиеш, дип күңеленә беркетеп куйды.

...Шәфика әлсерәп өйләренә кайтып кергәндә, ишегалларында ике егет арбадан капчык бушатып маташалар иде. Аларны Галләм җибәргән икән. Бәрәңге төяп килгәннәр. Бераз ит тә тыккан. Сарыкның арт саны. Шәфика шундый уңайсызланды эченнән генә, үзен «җирбит» дип сүкте. «Ул әнә, безнең турыда кайгырта, мин ят ирләр белән өстерәлеп йөрим».

Егетләр бик кыю күренә. Йөкләрне бушатып бетерүгә, өйгә кереп өсләрен чишенеп ташладылар. Фатыйха абыстай самавыр кайнатып куйган иде. Яшьрәге өстәл янына барып утырды, үзе чәй агызып эчә дә башлады.

— Без сездә кунып китәбез,— диде ул.

Бу яшүсмер егет Әтүтән иде. Аның әле кайгылы чагы. Урман кисәргә барган җирдә ат калдырып кайтты. Атның бәһасен эзләп алырга маташалар. Ә ул бете белән түләсенмени?! Әти-әнисе аны көн-төн талый. Җанын кая куярга белми йөри. Галләм шәһәргә барырга кушкач, шатланып риза булды.

Шәфика кайнар ризык әзерләмәкче иде, егетләрнең көтәсе килмәде. Идәнгә сузылып яттылар да йокыга чумдылар.

Ә Шәфиканың күзен йокы алмады. Иртүк торып иренә хат язды. «Монда ялгызыма тормыш алып бару бик авыр,— диде,— ничек итеп булса да кайтырга тырыш. Җибәрмәсәләр, ташла да, кайт. Муены булса, камыты табылыр, эшсез булмассың әле. Балалар күзгә күренеп үсә. Әти дип сине искә алмаган көннәре юк. «Ул кайчан кайта?» дип теңкәмә тиярләр. Иртәгә, берсекөнгә дип алдап килдем, хәзер сүзләремә ышанмыйлар. Алар каршында ялганчы булып калам, ахры. Шундый кызганыч, тере әтиләрен бер күрергә зар булып үсәләр».

Егетләр йокыдан торганда, алар алып килгән иттән пешерелгән бәлеш өстәлгә чыгып утырган иде. Яратып ашадылар. Чыннан да, Шәфика пешергән кайнар бәлеш телеңне йотарлык иде.

— Апа! Тизрәк ирегез янына кайтыгыз, авыл хатыннарын шушылай тәмле итеп бәлеш пешерергә өйрәтерсез,— диде Әтүтән.

— Энем, җаным, син мине авылга чакырма Мин анда эшкә ярый торган кеше түгел. Ходай кушып, үзе кайтсын иде...

Әтүтән күп уйлап тормады, уены-чыны белән:

— Карагыз аны, берсеннән-берсе чибәр тол хатыннар күп, Галләм абыйның башын әйләндереп куймасыннар,— диде.

Кытыкланса да, Шәфиканың сер бирәсе килмәде:

— Фи, безнең монда, шәһәрдә ирләрнең поты бер тиен,— дигән булды. Аннан кактырып-суктырып иренең фатирга нинди кешегә урнашуы турында сораша башлады. Фатир хуҗасының тол хатын икәнен белгәч, йөзе үзгәрде.

— Курыкмагыз, курыкма! — диде Әтүтән тынычландырырга теләп.— Хәнифә апа ирләргә борылып та карый торган хатын түгел. Артыннан йөрүчеләр күп булды, берсенә дә якты чырай күрсәтмәде.

Шәфика иренә күчтәнәчкә вак бәлеш әзерләп тыкты. Аны кат-кат чиста сөлге белән төрде.

— Хуҗабикәсе җылытып ашатсын,— диде Әтүтәнне кисәтеп.— Галләм абыең кайнар килеш ашарга ярата.

Авылдан килгән егетләр белән кызының болай вакланып маташуын Фатыйха абыстай ошатмады:

— Андый вакытта авызың тулы кара кан булса да төкермәскә кирәк,— диде,— шул селәгәйләргә көнләшүеңне белдереп торасың тагын...

Шәфика үкенде, ләкин эш узган иде инде.

## VII

Заготзернодан чәчү орлыгын мең газап белән ташып бетергәннәр генә иде, яңа бәла туды. Урман чыгарырга бер кеше белән бер ат җибәрергә кушып наряд килде. Бу авыр эшне кемгә йөкләргә белми аптырап калдылар. Ни аты, ни кешесе юк! Аннан да бигрәк — юллар өзелгән вакыт. Галләм үзе генә хәл итә алмады, мәсьәләне идарә утырышына куйды. Урманчылык авылдан артык ерак түгел — утыз чакрым чамасында. Кемне җибәрергә? Ирләрдән анда эшләрлек кеше юк. Нарядтан тарту мөмкин түгел. Хатын-кызлардан кемне булса да елатырга туры килә. Уйлаштылар да, Әсмага тукталдылар. Бала-чагасы юк, ат кебек таза, тол хатын. Сугыш алдыннан кияүгә чыккан иде, бер ай чамасы гына торып калдылар. Ире сугыш башлану белән армиягә алынды. Җиңү бәйрәме көнне батырларча һәлак булуы хакында хәбәр килде. Кирәк бит шулай туры килергә! Бер көн дә түгел, иртә дә түгел. Халык шашып бәйрәм иткәндә, ул күз яше түкте. Нигә соң язмыш аерым кешеләргә бу кадәр рәхимсез икән, дип өзгәләнде. Бик авыр булды Әсмага ул көннәрне! Шуннан бирле аның Җиңү бәйрәмендә бер генә мәртәбә дә кеше төсле күңел ачып утырганы юк. Матур кояшлы көн булса, кырга чыгып йөри, аннан кайткач зиратка кереп, әнисе кабере баш очына утыра да белгәннәрен укып дога кыла.

Әсма — Әтүтәннең әнисе белән бертуган апасы. Ул аны Алмапа дип йөри. Серләре уртак. Күрә торып ничек инде аны урман чыгарырга җибәрсен? Элекке рәисләр булса, аяк та атлатмас иде. Кыңгыр эшләрен белгәнгәме, юк-юк та, Әтүтәннән шүрлиләр иде алар. Галләм исә аны

санга сукмый. Тел әрәм итеп ялынып тормады. Ышанычлырак юлны сайлады. Идарәгә кереп:

— Алмапам урынына мине җибәрегез,— диде катгый рәвештә. Ике сөйләшергә урын калдырмады. Шулай да идарә әгъзаларыннан икеләнеп калучылар булды.

— Барсын,— диде Таһир,— искитәрлек эш мәллә? Аның кебек вакытта без мылтык асып фронтка киттек. Ни әйтсәң дә, сугыш сугыш инде ул, урман кисү белән тиңләп булмый.

Алмапасының үз энесе Әтүтәнне урман чыгарырга җибәрәсе килмәде:

— Сүземне тыңламыйсың? Ул вакытта икәү бергә барабыз...

Әтүтән авыз ачарга да ирек бирмәде.

Әсма юлга икмәк пешереп тыкты. Актык тавыгын да суйды. Әтүтән боларына каршы килмәде. Белә, Алмапасы барыбер үзенчә эшләячәк. Бу яктан алар бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаганнар, үзсүзлеләр.

Әтүтән ярты юлны хәвеф-хәтәрсез узды. Юл үргә түбән булганда аты юырткалап та алды. Көннең икенче яртысында һава кинәт җылытып җибәрде. Бөтен дөньяны су басты. Урыны-урыны белән ат тездән бата башлады. Тәмам арыды. Алда бер чиркәүле авыл күренде. Шунда барып җитә алса, кунып калырга исәпләде. Анда барып җиткәнче бер ерганакны үтәргә кирәк иде. Ерганак шактый тирән икән. Атны яр кырыенда туктатып, төбен карап менде. Су ташып, менә-менә юл өстен басарга тора. Тиздән аргы якка чыгып калырга теләп, Әтүтән тәвәккәлләде. Ләкин ерганакның нәкъ урта бер җирендә ат батты. Чыгарга талпынып карады, булдыра алмады. Арт саны бөтенләй суга чумды. Инде нишләргә? Артта да, алда да җан иясе күренми. Авылга барып ярдәм сорарга җыенды. Аннан әйләнеп килгәнче ат бөтенләй суга чуммасмы? Шулай уйлап аптырап торганда бер ир кеше куып җитте. Таза гәүдәле. Җылы киенгән. Аякларында кирза итек.

— Их, син голова садовая,— диде башын чайкап,— күзең кайда синең? Ат белән шушылай тулып ташыган ерганакка килеп керәләрме?!

Әтүтән кычкырып елап җибәрде.

— Әйдә, булыш атка! Егет кешегә күз яше агызып, җебеп тору килешми.— Ул тиз генә камыт чиште, аркалыкны җибәрде. Дуганы алып бер кырыйга ыргытты. Тугарылгач, ат җиңел сулап талпынып карады, ләкин арт санын баткан җиреннән өстерәп ала алмады. Бик тырыша торгач алгы аяклары белән каты җиргә басты. Һәм өскә ыргылды. Әллә, куркудан, әллә бозлы суда торып туңудан ат дер-дер килә. Әтүтән һаман елаудан тыела алмый иде әле.

— Җитте сиңа! Атны авылга алып барып, җылырак җиргә кертеп тор!

Чанада Алмапасы биреп җибәргән бер чиләк чамасы солы бар иде. Ул аны «юлда барганда атың арса, капкалатып алырсың» дип бирде. Ничек итсә, итте, солыны алып иңенә асты, аннан атны җитәкләп авылга таба юл тотты.

Колхозның ат абзары юл уңаенда, авыл кырыенда икән. Әтүтән атны җитәкләп туры шунда барып керде. Ул үзенең бил тиңентен лачма су икәнен бары шунда гына сизде.

Конюшнидә бер хатын атларга ашарга салам таратып йөри иде. Бер-берсенә карашып аптырап калдылар. Марҗа бер сүз дә татарча аңламый, Әтүтән урысча белми. Ул кулы белән ишарәләп, кайбер урыс сүзләрен әйтеп, эшнең нәрсәдә икәнен аңлатты.

Конюшни янында ат караучылар кереп торыр өчен эшләнгән өй бар икән, марҗа аны шунда алып кереп чишенергә кушты. Миче кайнар. Әтүтән тышкы киемнәрен мич янына кибәргә элде. Бераздан өйгә шактый олы яшьтәге ир кеше килеп керде. Әтүтән аның белән дә аңлаша алмады. Алар марҗа белән көлешеп нәрсә турындадыр сөйләшә башладылар. Әтүтән моны алар аның урысча белмәвеннән көләләр дип кабул итте. Ачуы чыкты:

— Мин әле урысча бер-ике сүз булса да җырмачлыйм, сез үзегез татарча аны да әйтә алмыйсыз,— диде татарчалатып.

— Что он бормочет? — дип сорады хатын.

Әлеге ир кеше бригадир яки башка берәр нәчәльниксыман нәрсә булса кирәк, марҗаны каядыр алып чыгып китте. Әтүтән мичкә аркасын терәп утырды да Алмапасы биреп җибәргән тавыкның бер ботын бер телем икмәк белән бөкләп куйды. Тамак ялгагач, хәл кереп китте. Шактый вакыт ул өйдә ялгызы гына утырды. Мич кырыена элгән киемнәре дә кибеп, өскә киярлек хәлгә килде. «Әллә болар минем монда икәнне бөтенләй онытты-лар инде,— дип уйлады, кинәт күңеленә шик төшеп,— ат белән берәр хәл булмады микән»,— дип, аны карарга чыкты. Ат ятып тора. Сулышы авыр. Шунда бер кырыйда ирләр җыелган. Берсе Әтүтән янына килеп, чиста татар телендә сүз башлады. Башта аның кайдан булуын һәм нинди йомыш белән йөрүе турында сорашты. Туган телендә сөйләшүчеләрне очраткач, Әтүтәнгә җан керде. Ул районнан килгән вәкил икән. Сүз уңаеннан Әтүтән аның райкомда эшләүче кеше булуын да белде.

Ат хәзер генә юлга алып чыгарлык түгел иде. Нишләргә? Монда калдырып торса ничек булыр икән?

Районнан килгән вәкил атны монда калдыруны мәгъкул күрде:

— Җир кибеп, юл төшкәч килеп алып китәрсең,— диде. Кулы белән чигәсен тотып уйланып торды да:— Идарәдән атыңны калдырганлыкка белешмә алырга онытма,— дип өстәде.

Идарәгә баргач, ул үзенең үтенечен аңлата алмый алҗыды. Анын бәхетенә, шактый олы яшьтәге хатын килеп керде. Ватып-җимереп татар-ча сөйләшә белә икән. Әтүтәнне дикъкать белән тыңлап торды да, эшнең нәрсәдә икәнен аңлатты:

— Ул безнең конюшнига ниндидер ат кертеп калдырмакчы була, шуны раслап белешмә язып бирүегезне сорый,— диде.

— Белешмә тагын аңа,— диде түрдәге өстәл артында утыручы кайры тунлы, башына колакчынлы бүрек кигән сакаллы кеше.— Үзебезнең кү-тәрәмгә чыккан атларны кая куярга белгән юк, алсын да китсен атын...

Никадәр тырышса да, Әтүтән үтенечен аңлата алмады. Дөресрәге, аны аңларга теләмәделәр. Ул стенага терәлеп басып торды да бернинди документсыз атны калдырып кайтып китәргә мәҗбүр булды. Авылга кайткач та аңа якты йөз күрсәтүче табылмады. Партоешма секретаре Фатыйма мәче кебек ябышты:

— Алмапаңның байлыгы җитәрлек, ат белән андый-мондый хәл ки-леп чыкса, бәһасен аннан эзләп алырбыз,— диде.

Үч иткән кебек, яз озак килде. Апрель азакларында өзлексез карлы-бозлы яңгырлар ява башлады. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, ат өчен янып-көеп йөргәндә, Галләм аны ит, май, бәрәңге төяп шәһәргә җибәрде. Башта бармаска җыенган иде. Чөнки дөнья хәлен белеп булмый, атны исән-сау килеш алып кайтып колхозга тапшырмаса, бәһасен алып кына калмаслар, читлеккә кертеп утыртырга да күп сорамаслар.

Галләм яхшылыкны аңлый торган кеше булып чыкты. Бурычлы булып калмады. Казаннан кайткач, үзе әйтеп атын биреп торды. Әтүтән шуны җигеп урман чыгарырга барганда калдырып кайткан аты артыннан китте. Көнен әйләнеп кайтырга исәпләп юлга чыккан иде. Тик кайда ул көнен әйләнеп кайту?! Бер нәрсәгә акылы җитте: анда-монда сугылып тормады, туры атын калдырган конюшнигә барып төште. Күрү белән таныды. Ат исән! Такта белән бүленеп алган бер почмакка ябып куйган-нар. Ат та Әтүтәнне таныды булса кирәк. Ул муенына барып асылынгач, иркәләнеп торган кебек тоелды.

Ат караучы марҗа Әтүтәнгә атны бирмәде. Идарәгә барып рөхсәт алырга кушты.

Идарәдә шул бер үк Әтүтәнгә таныш кешеләр утыра иде. Көн шактый җылы булуга карамастан, сакаллы һаман әле кайры тунын, колакчынлы бүреген салмаган.

— Килеп җиттекме? Озак йөрдең,— диде, беренче сүз итеп, Әтүтән биргән сәләмгә каршы, аннан уң як артында утырган хатынга мөрәҗәгать итте: — Марфа! Ул калдырып киткән ат үлде дип яз белешмә, китсен тизрәк, йөрмәсен монда баш әйләндереп.— Әтүтән бөтен сүзләрен аңлап бетермәсә дә «ат үлде» дигәнне ачык төшенеп чәче үрә торырлык булды. Үз күзләре белән күрмәсә икән! Ярый әле, акылы җитте, башта ат абзарына кереп, аннан монда — кәнсәләргә килде. Ат исән, исән! Әтүтәннең аптырап торганын күреп:

— Нәрсә, аңламадыңмы? — диде, кәнсәләр хуҗасы.— Капут, капут! — дип шул заманда, үлгәнне аңлатыр өчен әйтелә торган, халык теленә кергән немецчә сүзне тәкърарлады. Бу сүз сугышта йөргән солдатларга ияреп кайткан иде. Һәм озак еллар телдән төшмәде.

— Мин әле ат янында булдым, алып китәргә рөхсәт итегез,— диде Әтүтән татарчалатып.

— Нәрсә лыгырдый ул? Берәрегез аңладымы?

Барьер артында басып торган шактый олы яшьтәге бер хатын ярдәмгә килде:

— Малайка төшеп калганнардан түгел, атны күреп килгән инде...

— Тилмертмәгез егетне! Берегез дә җибәрегез,— дип бер ир кеше сүзгә кушылды.

— Егор! Мин сине, мондый акыллы баштырсың дип уйламый идем. Айдан артык атны үзебезнекеләр белән рәттән ашатып тоттык, хакын кем түли?

— Анысы дөрес, ашаткан хакын түләтергә кирәк...

— Малай аны бете белән түләсенме?

Аңлаткач, Әтүтән аптырап калмады:

— Түлим! Бер сүзсез түлим! — диде.— Күпме түләргә икәнен язып бирегез, атна азагына кадәр китереп җиткерәм.— Барысы да кычкырып көлделәр. Сөйләшә торгач, атны ашатып тоткан өчен хакын түләү юлы да табылды.

— Урманчылыктагы мәктәпкә бирелгән утынны ташытырга кирәк,— диде битен сакал баскан яшь егет.

— Нәкъ үзе, кешесе табылды,— диде читтән карап торучы бер хатын,— утынны ничек алып кайтырга белми аптырап йөрисез. Аңа нәрсә тора ул? Бер-ике көндә ташып бетерәчәк.

Әтүтәнгә килешүдән башка чара калмады. Эш шактый озакка тартылды. Аны эзләп Алмапасы килеп җитте. Ул килмәсә, Әтүтән бөтенләй эштән чыгачак иде. Алмапасы алып килгән ит, май аны аякка бастырды.

## VIII

Ниһаять, Шәрәфи эшкә керешге. Урман каравылчысы. Шәһәр яны урманчылыгыныкы. Алар монда ике кеше эшләргә тиеш. Икенче кеше итеп хатыны Хәмсәнәне тәкъдим итте.

Каравылчы өчен бүрәнәдән йорт салынган. Хәзергә ярап торырлык. Йорт такта коймa белән әйләндереп алынган. Эте дә бар. Шундый усал эт, чебен дә очырмый. Беренче көннәрдә Шәрәфинең үзенә дә фырлап алҗытты. Тора-бара ияләнде тагын, бер минутка да артыннан калмый. Шәрәфигә ат вәгъдә итәләр. Кулына ат тоттырсалар, нишләргә икәнен үзе белер иде... Эш урынының тагын бер уңай ягы бар — шәһәргә якын. Ул яшәгән йорттан трамвайга ун чакрым чамасы гына. Туган авылына да ерак түгел. Җәяүләп көнен кайтып килергә мөмкин.

Шәрәфи яңа урынга бик авырлык белән ияләнде. Авылдан китүенә үкенеп тә куйды. Шулай ук андагы нигезне бетерергә туры килер микәнни?! Иртәме, соңмы, бөтен гаиләсен монда күчерергә кирәк була ич...

«Анда калсалар, аларга көн күрсәтәчәк түгелләр. Юк, туып-үскән нигезне дә бетерергә ярамый. Ул — изге җир. Ничә буын кешеләре ул җирне тире белән ашлаган!

Күптән түгел аның бертуган сеңлесенең улы армиядән кайтты. Шул егетне йортына кертеп калдырырга булмасмы икән? Әбрар ялгыз егет. Әнисе ул армиядә хезмәт иткән чагында үлде. Йортлары кыш торырга яраклы түгел. Әбрар әтисен аз хәтерли. Аны сугышка җибәргәндә бары дүрт яшьтә генә иде. Дөнья бәһасе егет иде әтисе Габделвәли. Кулыннан килмәгән эше юк иде. Сугышта хәбәрсез югалды. Бик авырлык белән үстерде әнисе Әбрарны. Тик менә игелеген генә күрә алмады шул.

Шәрәфи Әбрарны үз өйләренә кертеп калдыру турында сөйләшергә теләп авылга кайтты. Ул кайтышка хатыны мунча ягып куйган, күп итеп өчпочмак пешергән.

— Әбрар килгәне бармы? — дип сорады Шәрәфи, исәнләшкәннән соң беренче сүз итеп.

— Үзе күренгәне юк, йортын утынга сүтеп, сатарга йөри дигән хәбәре бар. — Шәрәфи йөрәк авазы белән ыңгырашып куйды. Хатыны Хәмсәнә куркып китте:

— Нәрсә булды? Авырып кайттыңмы әллә... Ходаем...

— Коры авыру гына булса иде?!

Хәмсәнә артык төпченеп тормады, иренең холкы белән таныш, мондый халәттә аның авызыннан сүзне эскәк белән дә тартып алып булмый. — Кызны җибәр! Тиз генә Әбрар абыйсын чакыртып кайтсын! — Шәрәфи өй эченнән күз йөртеп алды: — Ул кайда? Күренми..

— Өйдән киткәнеңә әле күптәнме? Бу вакытта кызыңның кайда булганын оныткансың да... — Шәрәфи үзенә үзе шаккатып, төкеренеп куйды. Кызы Резидә бит аның күрше авылда, урта мәктәптә укый. Авыл шактый ерак, ял көннәрендә генә кайтып йөри. Иртәгә якшәмбе, бүген кайтырга тиеш.

Хәмсәнә Әбрарны чакырып кайтырга җыенгач кына, ул үзе килеп керде. Хәрби киемнән. Егет таза, арка-җилкәсе куна кебек. Күрешкәндә абыйсының кулын шундый итеп кысты, өзеп аламы дип тора Шәрәфи.

— Энем, ташла бу гадәтеңне, — диде Шәрәфи аны кисәтеп, — кешене гарип итеп калдыруың бар... — Хәмсәнә түргә узарга чакырды.

— Чит кеше кебек ишек төбендә калкынып тормагыз, — диде. Үзе өстәл әзерләргә тотынды. Мичтән таба белән кайнар өчпочмак тартып чыгарды. Борынны ярып, өйгә хуш ис таралды.

— Син кайчан өйләнәсең? — дип сорады Шәрәфи, өстәл янына килеп утыру белән. — Мин туйга кайттым.

— Иң элек торырга урын кирәк әле. Авылдан китәргә исәбем...

— Андый сүзне авызыңнан җил алсын! Бүген үк менә моны салып ташлыйсың, — диде гимнастерка җиңеннән тотып. Аннан түрдәге шкафтан өр-яңа костюм-чалбар алып, Әбрарга сузды: — Кеше арасында йөргәндә киеп йөре, ятмасын шкаф саклап.

Әбрар костюмны алмый маташты.

— Син киреләнмә! — диде, Шәрәфи катгый рәвештә, — абыеңның сүзен тыңласаң уңарсың! — Хәмсәнә иренең Әбрар белән сөйләшкәнен ишетеп аптырапта калды. Актык костюмын чыгарып аңа тоттыргач, йөрәге авыртты. «Картая-картая акылга җиңеләяме икән әллә?» — дип уйлады.

— Син менә нәрсә, энекәш, — диде Шәрәфи, хатыны Хәмсәнә өчен һаман әле серле булып калган сүзен дәвам иттереп, — өйләнү мәсьәләсен сузма! Авылда кызлар буа буарлык, кайсын телисең, шунысын сайлап алырга мөмкин.

— Син чынлап сөйләшәсеңме? — диде Хәмсәнә сүзгә кушылып. Җавап көтеп тормады, Әбрарга мөрәҗәгать итте: — Энем, җаным, ашыгып бер үк башыңны бәйли күрмә, хатын-кыз беркая да качмый ул, — диде.

Шәрәфи Әбрарга костюмны киертеп карады:

— Әзрәк таррак икән, ни күреп симергәнсеңдер,— диде костюмның иңбашларын тарткалап.

— Солдат икмәге килешкән аңа,— диде Хәмсәнә.

— Зарар юк, колхозда эшли башлагач корсагы шиңеп, таман гына булыр.

Костюм кигәч, Әбрар үзгәрде.

— Менә хәзер кеше кыяфәте керде,— диде Шәрәфи аны мактап.— Киеп йөре, салма, тузса яңасын алырбыз.

— Сөйләшеп тә карыйсың инде,— диде Хәмсәнә,— нәрсәң белән яңа костюм алмакчы буласың? Ярый әле телең бар, телең булмаса, күптән карга күтәреп алып киткән булыр иде.

Әбрар ике ут арасында калды. Сизелеп тора, җиңгәсенең костюмга эче поша. Салып эскәмия башына элмәкче иде, Шәрәфи ирек бирмәде. Хәмсәнә үзенең ялгышын аңлап сүзне икенчегә борды:

— Әйдәгез әле, кайнар килеш ашыйк, суынгач тәме бетә,— дип кунакны кулыннан тартып өстәл янына утыртты. Өчпочмак гаҗәп тәмле иде. Әбрарның күптән мондый ләззәтле ризыктан авыз иткәне юк шул. Сүз яңадан иске эзенә, Әбрарны башлы-күзле итү мәсьәләсенә кайтып төште.

— Энем, җаным,— диде Хәмсәнә,— синең яныңда фельдшер Фатыйма чуала дип сөйлиләр. Ерак кача күр! Муеныңа менеп атланганны сизми дә калырсың.

Чыннан да, Фатыйма Әбрарны кармагына эләктерергә йөри. Көн саен дип әйтерлек, төрле йомыш табып, ул йокыдан торганчы ук өенә килеп җитә. Берничә мәртәбә идәнен юып чыгарды. Бертуктаусыз «хатын-кыздан башка өйнең яме юк» дип колагына тукый. Шундый бер сөйләшү вакытында Әбрар «нинди хатын-кызга эләгәсең» бит дип әйтеп ташлады.

— Мине нинди хатын-кызлар рәтенә кертәсең? — диде Фатыйма.

Әбрар уйга калды. Катырак әйтеп, аның кәефен җибәрәсе килмәде:

— Кешене белер өчен аның белән бергә бер пот тоз ашарга кирәк.

Бу сүзләр Фатыйма күңеленә хуш килде:

— Әйдә, бергә торып карыйбыз! Тозын да ашарбыз, башкасыннан да авыз итәрбез...— Әбрар колакларына ышанмады, ялгыш ишеттем микән әллә дип шикләнеп торды. Фатыйма аңына килергә ирек бирмәде, муеныннан кочаклап, үбеп тә алды.

— Ник дәшмисең?

— Мин өйләнеп торырга әзер түгел.— Әбрар шушы минутка кадәр егетләр белән болай ачыктан-ачык сөйләшергә марҗа кызлары гына сәләтле дип уйлап йөри иде. Андыйлар татар кызлары арасында да бар икән ләбаса! Ни өчен икәнен үзе дә белми, ләкин күңеле моны һич кенә дә кабул итә алмый. Ул тумыштан «кыз кеше әдәпле булырга тиеш» дигән сүзләр ишетеп үсте. Җиңгәсенең кисәтүе аның дөрес юлда булуын исенә төшереп, чиксез шатландырды.

— Син, карчык, бар үз эшеңне кара әле,— диде Шәрәфи,— бертуктаусыз тәкелдәп, энекәш белән сөйләшергә ирек бирмисең.

— Синең шул булыр инде! — Хәмсәнә үпкәләп икенче бүлмәгә чыгып китте. Шәрәфи аның артыннан ишекне ябып ук куйды.

— Менә нәрсә, энем,— дип үгезнең мөгезеннән тотып башлады ул сүзне:— Син авылны ташлап китү турындагы җүләр уеңны башыңнан чыгарып ташла! Монда безнең нәселнең нигезе корырга тиеш түгел. Гасырлар буе яшәп килгән шул нигезне сакларга синнән башка лаеклы кешебез юк. Бөтен ышаныч синдә...

Ул Әбрар абыйсына үз сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Син абый мине дә тыңла әле,— диде ул еламсыраган тавыш белән,— минем һич тә әти-әнидән калган нигезне бетерергә исәбем юк. Күреп торасың бит, безнең йорт торырга яраклы түгел. Аны аякка бастырыр өчен акча кирәк. Монда авылда акча эшләү мөмкин түгел. Акчаны бары, читкә китеп эшләп кенә табып була. Минем исәп әле

Армиядән үк шахта тирәсенә китеп, акча эшләү иде. Әмма авылга, туган нигезгә Коръән укытмый, анда китәргә аягым тартмады.

— Бу эшеңне хуплыйм,— диде Шәрәфи шатлыклы тавыш белән,— монысына акылың җиткән. Инде мин әйткәнне дә тыңласаң — бара да чыга! Син минә нәрсә, хәзергә безнең өйдә калып торасың...

— Сез кая китәсез?

— Мин урман каравылчысы булып яллandым, шәһәр яны урманчылыгына.

— Ә Хәмсәнә җиңги белән Резидә?..

— Аларны да үзем белән алып китәм, алда тагын күз күрер.

Шәрәфи сүз уңаенда энесенә күптән уйлап йөргән планының бер өлешен аңлатып бирде. Ә үзенә хәзергә колхозда эшләп торырга киңәш итте.

— Колхоз рәисе яңа, акыллы кеше күренә. Ничек итеп булса да аның белән уртак тел табарга тырыш.

Сөйләшә торгач, алар шундый нәтиҗәгә килделәр: Әбрар колхозда эшләп, әкренләп белән үз йортын аякка бастырырга булды. Иң мөһиме — төзү материалы табу. Шәрәфи аңа төзү материалы табарга вәгъдә бирде.

— Ходай кушып урманчылыкта эшләп торганда, төзү материалы табу кыен булачак түгел,— диде.

Армиядә хезмәт иткәндә Әбрар трактор йөртергә өйрәнгән икән. Аның өчен иң кулай эш тракторчы булу иде. МТСның трактор бригадиры да үз авыллары кешесе — Мөбәракша исемле егет. Эшкә урнашырга ярдәм итми калмас, дип уйлады Шәрәфи. Шулай да, элек колхоз рәисе Галләм белән сөйләшүне кирәк тапты. Тамак ялгап алгач икәүләп колхоз кәнсәләренә киттеләр.

Кәнсәләрнең эче танымаслык булып үзгәргән. Каян табып алганнардыр, яңа өстәлләр куйганнар. Бөтен җирдә чисталык. Хисапчы Таһир ялгызы эшләп утыра иде. Ул аларны якты йөз белән каршы алды:

— Армиядән кайтканыңа күпме вакыт узды, безнең янга кереп тә карамыйсың,— диде ул Әбрарга үпкә белдереп. Алар шулай сөйләшеп торганда, Галләм килеп керде. Кычкырып сәлам бирде дә бүлмәсенә кереп китте.

— Аның янына мөмкинме? — диде Шәрәфи.

— Кергән кешене борып чыгарганы юк, керегез, кер!

Армиядә хезмәт итеп кайтучы яшьләрдән берсенең дә авылда калганы юк иде. Кайтып, әти-әниләре янында иң күбендә атна-ун көн торалар да чыгып ычкыналар. Ялгыз егетнең авылда калырга теләк белдерүе рәис күңелендә шик тудырды. Аның берәр мәкерле уе юк микән, дип шикләнде ул. Йә булмаса, кулыннан бернинди эш килми торган мәми авыз егет түгел микән?.. Хәтта, соңгы шиге беренчесеннән өстенрәк тә иде әле. Әбрарның тракторчы икәнен белгәч, аның авылда калырга теләк белдерүе сәеррәк булып тоелды һәм аны күңелдән кызганып та куйды. Монда бер тиен акчага тилмереп, бушка эшләп йөргәнче, шәһәрдә урнашып калган булса, ак сакаллы карт булыр иде. Шулай да, үз-үзенә каршы төшеп, Әбрарны кулдан ычкындырмаска кирәк, дигән фикергә килде. Мөбәракша белән сөйләшеп, аның бригадасына эшкә урнаштырып булмасмы икән дип тә уйлады. Ни әйтсәң дә, тракторчының эше гади колхозчыларныкы белән чагыштыра торган түгел бит.

— Бакчаңа бәрәңге утырттыңмы?

Әбрар бер Шәрәфигә, бер рәискә карап, аптырап калды.

— Быелга ул бакча кысыр калыр инде,— диде Шәрәфи энесе өчен җавап биреп.— Кайчан җирен казыр да, кайчан орлыгын табар? Аннан вакыты да узып бара.

Галләм хисапчыны чакырып кертте:

— Иптәш Шакиров! Менә бу егет яңа гына армиядә хезмәт итеп кайткан, танышсыздыр дип уйлыйм. Ялгыз егет, бәрәңгесе утыртылмаган...

Таһир рәиснең сүзләрен аңламаганга салышты:

— Бу эштә минем нинди катнашым бар?

— Көзгә түләү шарты белән бәрәңге бирергә кирәк. Аннан, тиз генә бакчасын сукалап ташласыннар!

Хисапчы рәиснең сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Колхозның үзенең дә орлык бәрәңгесе такы-токы. Аны да әле хуҗалыклардан бурычка җыйдылар. Моңа кадәр бервакытта да колхоз аты белән шәхси хуҗалыкларның бәрәңге бакчаларын сукалаганнары булмады. Авылда ялгыз карт-карчыклар бар. Әбрар бакчасын ат белән сукалап бирсәң, алар нәрсә әйтер? Бу бит халыкны бозу, тәртипсезлек башланачак.

Таһир чит кешеләр барында рәискә каршы сүз әйтергә кыймады. Ләкин ризасызлыгы йөзенә чыккан иде. Галләм сүзне кыска тотты:

— Барыгыз, бар, иптәш Шакиров, әйткәнне эшләгез! — диде. Хисапчы чыгып киткәч: — Сезнең эшләр кай тирәдә? — дип сорады Шәрәфидән.

— Рәтләнеп килә кебек, озакламый җәмәгатемне алып китәм.

— Бусы ничек була инде? Авылда тагын бер хуҗалык кимиме?

Галләм Шәрәфинең гаиләсе белән авылны ташлап китәсен белгән булса ничек тә тоткарлаган булыр иде. Вакытлыча читкә китеп, акча эшләп кайтырга җыена дип уйлады бит ул.

— Курыкмагыз, курыкма! — диде Шәрәфи аны тынычландырырга теләп, — мин йортны япмыйм, энекәшне кертеп калдырам.

— Аның үз йортын нишләтмәкче буласыз?

— Үз йорты кыш торырга яраклы түгел. Эше җайланып китсә, исәбе әкеренләп ремонтларга.

— Ярар, күрербез дип әйткәнме сукыр? Шуның кебек без дә карарбыз!

Алар озак гәпләшеп утырдылар. Шәрәфи энекәшенә буралык бүрәнә әзерләргә җыенуын әйткәч, сөйләшү тагын да җанланып китте. Чөнки төзү материалына кытлык. Бүрәнәне беркайдан таба торган түгел. Әгәр авылда төпләнеп калса, Галләмнең үзенә дә йорт торгызырга туры киләчәк бит. Шәрәфинең ярдәме кайчан кирәк булачак! Хәзергә ул бу турыда белдермәде.

— Син авылны онытып бетермә инде! — диде, кәнсәләрдән чыгып киткәндә Шәрәфине кисәтеп.

## IX

Әбрар авыл тормышына читен ияләште. Ялгыз калган минутларында бигрәк тә авыр, мәрхүм анасы күз алдына килә дә баса. Ул армиядән кайтканчы гына да яши алмады ичмаса... Әтисе өчен алай ук үзәге өзелми аның. Ул сугышта хәбәрсез югалды... Бәлки, тагын шунадыр: бик кечкенә иде әле ул әтисе киткәндә. Алар аны әнисе белән басу капкасына кадәр озата бардылар.

Сугыштан соңгы берничә ел бик авыр булды. Ачлык теңкәгә тиде. Кырда калган өшегән бәрәңгене казып алып кайтып ашадылар. Өйне җылытырга бер агач утын юк. Кысыр калган колхоз басуында котырып әрем үсә иде. Әбрар кырдан шул әремне ташып ягулык әзерләде.

Бер елны аларда колхоз рәисе булып районнан җибәрелгән кеше эшләде. Шул Хатип исемле рәис, көнаралаш аларга килеп, әнисенең үзәгенә үтте. Лаякыл исерек була. Әнисе тәрәзәдән төшеп каравыл кычкыргач кына килүдән туктады.

Иген өлгергәч, ач халык колхоз кырына чыга, башак уып тамак ялгый иде. Әбрар да арыш басуына чыгып тамак туйдыра башлады. Ә бер көнне кырда йөргәндә аны колхоз рәисе тотты. Алар районнан килгән

бер кеше белән тарантаска ат җигеп, махсус башак җыеп ашаучыларны тотарга чыкканнар икән. Әбрар шул кадәр мавыгып башак җыя иде, янына җигелгән ат килеп туктаганны сизми дә калды. Районнан килгән кеше милиционер булып чыкты. Ул тарантастан төшеп Әбрарны тотып алды. Әбрар куркудан ачыргаланып кычкырып җибәрде һәм милиционерның кулыннан ычкынды. Куышып йөри торгач тагын тотылды. Дилбегә белән бәйләп тарантас артына тактылар. Киттеләр басу юлы буйлап. Ат урыны-урыны белән йөгертеп алгалый. Ә Әбрар — яланаяк. Нindидер каты әйбергә сөртенеп аяк бармагын канатты. Авылга кайтып кергәндә тиргә манчылып, күлмәге сыгып алырлык булган иде. Кәнсәләргә алып кереп берәр бүлмәгә ябып куялар дип уйлады. Юк — анда алып кермәделәр. Башкаларга гыйбрәт өчен тарантас артына тагылган килеш урам әйләндерергә тотындылар. Хәбәре бөтен авылга таралды. Әлсерәп әнисе килеп җитте. Милиционер аны малае янына якын да җибәрмәде.

— Синең үзеңне җавапка тарттырабыз,— дип акырды,— малаеңны урлашырга өйрәткәнсең...

Икесен бергә кәнсәләргә алып кайттылар. Милиционер озаклап беркетмә төзеде. Беркетмәгә шаһитлардан кул куйдырырга кирәк иде. Халык эшнең нәрсәдә икәнен сизеп, тиз генә кәнсәләрдән чыгып сызды. Шаһит булып бердәнбер кеше, колхоз рәисе Хатип үзе кул куйды.

— Каберең якын булмасын бу авылдагы халык белән,— диде. Үлгәндә авызыңа су салучы табылмас.

Әбрарның әнисе Нәфисә елады да елады. Авызын ачып сүз әйтерлек хәле калмады. Рәис аңа ташланды:

— Җир бит икәнсең,— дип хурлады,— каракларга колхозда урын юк, авылдан кудырам!

Нәфисә яхшы аңлый: рәис шулай җикеренеп, янына яткырып йоклатмаган өчен үч ала.

— Тимәгез минем әнигә,— диде Әбрар,— ире сугышта үлгән хатынны мыскылларга хакыгыз юк!

— Кара әле син бу әнчекне! Хәбәрсез югалган әтисен сугышта һәлак булды дигән була. Кем белә аны, бәлки Власов армиясендә хезмәт итеп, Германиядә качып ята торгандыр...

Нәфисә улына рәис белән әрләшергә ирек бирмәде, тизрәк кәнсәләрдән алып чыгып китү ягын карады. Беркетмәне укып тормады, кул куйды. Эш шуның белән беткән булса, әлләни бирешмәс тә иде. Бетмәде шул, судка барып җитте.

Суд клубта, күрше авыллардан да кешеләр чакыртып, күргәзмә рәвешендә үткәрелде. Прокурор Нәфисәне иректән мәхрүм итеп, улы Әбрарны балалар йортына җибәрергә хөкем итүне сорады. Имеш, ана бердәнбер баласын җәмгыятькә яраксыз итеп тәрбияли — урлашырга өйрәтә.

Клуб халык белән шыгрым тулы иде. Хөкем карарын тын да алмый тыңладылар.

Социалистик милеккә кул сузган өчен Нәфисә иң каты җәзага тартылырга тиеш булса да, иренең Бөек Ватан сугышында юкка чыгуын исәпкә алып, суд аны алты айга мәҗбүри хезмәткә хөкем итте. Мәҗбүри хезмәт дәүләт файдасынв 20 процент хезмәт хакын тотып калып, колхозда үтәлергә тиеш дигән аерым карар кабул итте.

Хөкем карарын игълан иткәндә, Нәфисә чиктән тыш дулкынланды. Йөзенә мәет төсе кереп, аягына басып торырлык хәле калмады. Өенә җитәкләп алып кайттылар. Өендә аны тагы да ачырак кайгы көтә иде. Бер кабарлык ризык юк, ничек тамак туйдырырга? Үзеннән дә бигрәк Әбрар турында кайгырды.

Күршесе Гаҗби карчыкның кәҗәсе бар. Ул көтү кайткач, яңа сауган сөт кертте. Аргы якның озын Мәрьям бер бөтен икмәк белән бераз бал чыгарды. Бал кабып, җылы кәҗә сөте эчкәч, хәл кереп киткән төсле булды.

«Иртәгә нишләргә?» дигән сорау алга килеп басты. Улын җитәкләп соранырга чыгаргамы? Юк, юк, мондый хәл булырга тиеш түгел! Кайчандыр чибәрлеге белән авылның йөзек кашы саналган хатын хәер эстәп түгел, эшләп ашарга тиеш! Нәфисә чәче белән җир себерергә әзер. Эш табарга кирәк, эш! Әнисе белән бертуган Шәрәфи абыйсы авылда булса, аны бу авыр хәлдән коткарыр иде, ул өйдә юк. Акча эшләргә исәпләп читкә чыгып китте.

Әнисе өчен үзәге өзелеп, Әбрарның төн йокысы качты. Сиздермичә генә елап та алгалый. Аның хәле көннән-көн начарлана. Ул үлеп китсә, ничек көн күрер? Дөньяда ямь калмаячак бит.

Түбән очның Гали Әбрарга эш тапты. Дөнья бәһасе кеше Гали абый. Ятимнәргә, фәкыйрьләргә гел ярдәм итә.

Каз көтүчесе булып акылга туймаганрак Миңхәйретдин исемле яшүсмер егет эшли иде. Ул көннән-көн ныграк саташа башлады. Көтүдән аерылып бодай кырына кергән каз бәбкәләренең муенын борып ыргыткан. Аптырап калмаган, җавабын да тапкан: «Мин аларга, социалистик милеккә борыннарын сузган өчен җәза бирдем»,— дигән.

Миңхәйретдинне диваналар шифаханәсенә озаткач, Гали аның урынына Әбрарны тәкъдим итте. Хезмәт хакын натуралата түләргә сөйләште. Өстәвенә, көтү кайткач каз хуҗалары чираттан көн саен бер мәртәбә ашаталар. Шулай итеп, аларның тамак ягы көйләнеп китте. Тик менә Нәфисә генә тернәкләнә алмады. Фәкыйрьлекнең аерылмас юлдашы — үпкә авыруы белән газап чигә башлады.

Әбрарның «үпкә авыруына иң яхшы дәва — кәҗә сөте» дип ишеткәне бар иде. Тиенләп җыйган акчасына кәҗә бәтие алып җибәрде. Әнисенең шатланганын күрсәң, башы күккә тигәндәй булды.

Дөнья артыннан куып, Әбрар егет булып үсеп җитүен сизми дә калды. Армиягә каралырга баргач, әнисенең авыруын сәбәп итеп, калдырып торуларын сораган иде, игътибар итмәделәр.

Ул армиягә алынып бер ел дә үтмәде, Нәфисә дөнья белән хушлашты. Әбрар күмәргә кайта алмады. Телеграмма хәрби комиссариат тарафыннан расланмаган дип, җибәрмәделәр. Ул заманда гади халык мондый нечкәлекләр белән таныш түгел иде шул.

Әнисенең гүр иясе булуына ике атна узгач кына, авылга кайтты Әбрар. Аның үлеменә һич ышанасы килмәде. Ишегалдына, урамга чыгып эзләде. Ул каядыр, якында гына йөри төсле тоелды. Ниһаять, монда тоткарлансам, Миңхәйретдин төсле саташа башлавым бар дип, китәргә ашыкты.

Тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадаклап, туган йортны ташлап китүдән дә авыр хәл бар микән? Әмма адәм баласы барысына да түзә.

Зиратка кереп, бик озак әнисе каберенең баш очында утырды. Белгәннәрен укып дога кылды. Зират әһелләренең күбесен искә төшерде. Әнисе аларны догадан калдырмаска куша торган иде бит.

Ул авылга башка кайтмаска уйлап чыгып киткән иде. Ярый әле уйларын беркемгә дә сөйләмәде. Эчендә җаны бар адәм туган җирен онытамы соң? Поездга утыру белән, өзелеп-өзелеп авылын сагына башлады. Кырлары, болыннары турында әйткән дә юк, каз көткәндә йөргән сукмакларына кадәр күз алдына килеп басты.

Армиядә хезмәт иткәндә вакыт шулкадәр авыр узды, көне — ай, ае ел кебек, озак булып тоелды. Хезмәт срогын тутырып, кайтып җитәр кебек булмады. Кайтып өй ишеген ачып кергәч, күп тә үтмәде, күршеләре Гажби карчык килеп керде.

— Улым, исән-сау кайттыңмы? — Ике кулын биреп күреште дә, сәке кырыена барып утырып дога кылды. Әбрар югында шул карчык өйгә күз-колак булып торган. Югыйсә, ваклап бөтен өйне ташып бетергән булырлар иде.

Әбрар капчыгыннан алып карчыкка баш яулыгы тоттырды. Хезмәт итә башлагач та әнисенә адарынып алып куйган иде. Менә кемгә насыйп икән.

Яулык кулына кергәч, Гажби карчык елап җибәрде:

— Улым! Зур бүләк белән кайткансың ич, мондый хөрмәтне үз туганнарымнан да күргәнем юк иде.— Тиз генә өенә чыгып чәй куйды, төче коймак әмәлләде. Озак гәпләшеп утырдылар. Кактырып, суктырып Әбрардан, алдагы көндә ничек тормыш итәргә уйлавы турында сорашты. Ул үзенең авылда калырга теләге юклыгын әйткәч, хуплады:

— Ничек итеп булса да шәһәргә китеп урнашырга тырыш,— диде. Анда эшләгән кеше уч тутырып акчасын ала.— Бу сүзләр Әбрарның болай да иләс-миләс килгән күңелен ныграк җилкендерде. Гажби карчык яныннан чыкканда, йортны сатып шәһәргә китәргә кирәк, дигән уй күңелен тулысы белән билән алган иде инде.

Өенә кергәч, тәрәзә каршына басып урамны озак күзәтте. Нинди ямьле күренеш! Кызганыч, ләкин китәргә кирәк! Гажби карчык дөрес әйтә, авылда яшәүдән мәгънә юк!

Почмак яктагы әнисеннән калган сандыкка күзе төшеп, эче жу итте. Анда анның киемнәре тутырылган булырга тиеш. Курка-курка гына сандык капкачын ачты. Исән, бар да исән! Монда әле чит кеше кулы кермәгән. Иң өстә кара плюш жакет. Ул аны саклап, кешелеккә генә киеп тотты. Кешелеккә киеп йөри торган бердәнбер күлмәге дә шушында. Шул заманда авыл хатын-кызлары арасында модада булган штапель материядән тегелгән. Юа-юа таушалып беткән.

Менә сандык кырыена беркетелгән тартмада — көмеш беләзек. Әбрар яхшы хәтерли, әнисе аны бервакытта да кулыннан төшермәде. Туйда мәһәргә кушып бирелгән булган ул. Кырык ямаулы күлмәкләренә кадәр шушында — барысы да юып, пөхтәләп тутырылган. Үләргә җыенмаган, җиргә нык басып яшәргә тырышкан әнисе.

Йорт утынга сүтеп сатылса, нигез ябылачак. Сандыкны кая куеп торырга? Әнисеннән калган истәлекне юкка чыгарыргамы? Үзе исән чагында Әбрар аларны саклап тотарга тиеш! Шәрәфи абыйсында калдырып торса ничек булыр икән? Шул турыда сөйләшеп карарга уйлап анның янына барган иде, ул авылны ташлап китү турында ишетергә дә теләмәде, аны колхоз кәнсәләренә — рәис янына алып барды. Тракторчыларга мохтаҗлык зур иде. Ничек инде күрә торып әзер кадрны читкә җибәрергә кирәк?!

Әбрарның тракторчы икәнен белгәч, Галләм эшне кызу тотты. МТС директоры белән элемтәгә кереп, аны авылдашлары Мөбарәкша бригадасына эшкә урнаштырды.

Армиядән кайткан егетләр гадәттә, иркенләп ял итәләр. Ә Әбрар икенче көнне үк эшкә кереште — чөнки бүтән мөмкинлеге юк, кабырга кыса.

## X

Беркөнне эштән кайтканда райбашкарма ишеге төбендә Кадыйров басып тора иде. Шәфика игътибар итмичә, тиз генә узып китмәкче иде дә, ул аны җиңеннән тартып туктатты:

— Ашыкма, бергә кайтабыз!

Бу юньсезгә миннән нәрсә кирәк икән, дип уйлады Шәфика. Бер дә аны ияртәсе килмәде. Ә теге юлга аркылы басты:

— Сөйләшәсе сүз бар, бик җитди...

— Вакытым тар, өйдә балаларым көтә,— диде Шәфика ясалма елмаеп.

— Кара аны, кызый, янасың бит!

— Нәрсә бар ул кадәр янарлык?

— Белмәгәнгә салышма! Кәҗә билеты тоттырырга да күп сорамаслар!

Шәфика бик авырлык белән тормышның очын очка ялгап бара. Бер хезмәт хакына карт анасы белән ике баланы тәрбияләү көннән-көн

кыенлаша. Ичмасам, хезмәт хакы кешенеке төсле булса икән! Өч йөз сум акчамыни ул хәзерге заманда? Әнисе теккән сырманы базарга алып чыгып сатканда тормышлары иркенрәк булган икән. Ерак бер истәлек булып кына калыр ахры ул вакытлар! Кустарьларны шундый кысалар, үзең теккән киемне сатуга чыгару җинаять санала. Базарда, налог инспекторлары белән бергә, милиция дә дежур тора.

Фатыйха абыстай эшен бөтенләй ташламады әле, аз-маз кыймылдый. Таныш-белешләреннән заказлар кабул итә. Югыйсә, ачлы-туклы яшәргә туры киләчәк бит!

Галләмнең хаты килеп тора үзе, «түзегез»дән башка сүзе юк. Имеш, озакламый колхозны аякка бастырачак, шунда инде менә тормышлары рәтләнер.

Кадыйров сер итеп кенә Шәфикага аның әнисе турында райфога бик җитди сигнал керүе турында әйтте.

— Сигналны тикшерергә, «өлкән» үзе барачак, мине дә ияртүе мөмкин,— диде. Шәфиканың өстенә кайнар су сипкән төсле булды:

— Мин нишләргә тиеш? — диде кыяр-кыймас кына.

— Шуны да белмәскә инде! Бала-чага булма!

— Валлаһи белмим.

— Әзерләнеп тор! — Шәфика аптыраштa калды, «әзерләнеп тор» дигәнне ничек аңларга да белмәде.

— Тегү машинасын кая булса да олактыр, эзе калмасын! — Күзләренә сынап карап торды да: — Калганын тагын үзең карарсың,— дип өстәде.— Нәрсә, аңламадыңмы? Ярар, әгәр мине ияртеп алып барса, анысын үзем җайлармын.

Райфога көн саен иң кимендә ике-өч хат килә. Гадәттә, ул кемнең булса да өендә яшерен рәвештә кустарьчылык һөнәре белән шөгыльләнүе турында хәбәр итеп язылган әләк була. Бөтенесе дә имзасыз, кем язганлыгы билгеле түгел. Күбесе райфо адресына янау белән тәмамлана. Фатыйха абыстай өстеннән язылган хатта да шуңа охшашлы юллар бар иде: «... кызы сездә эшләгәч, иркенләп өендә тегү тегә, яшеренеп эшләүне кирәк тә тапмый. Ашыгыч чара күрелмәсә, югарыга хәбәр итәргә мәҗбүр булабыз». Хат дәфтәр битенең ике ягын да тутырып язылган. Нинди сүзләр генә юк иде анда?! Аларның нәселдән килгән сәүдәгәрләр булуын хәбәр итү белән бергә, Фатыйха абыстайның гомер-гомергә җәмгыятебез өчен бер тиенлек файдалы эш эшләмәве, паразит булып яшәп, череп баеп бетүе дисеңме — берсе дә калмаган.

Мондый хатлар иң элек секретарь алып бара торган гомуми журналда теркәлә, аннан налог һәм җыемнар инспекциясендә аерым исәптә тора — шулай итеп икеләтә контроль урнаша! Алар буенча елына берничә мәртәбә урынга чыгып тикшерү дә үткәрелә.

Өлкән налог инспекторы Евлампий Иванович кем тарафыннан язылганлыгы билгеле булмаган мондый хатлардан тәмам гарык. Аерым контрольдә торганлыктан, алар белән эшләү бик мәшәкатьле һәм җаваплы. Райфоны тикшерергә килгән ревизорлар да эшне шул аноним хатлардан башлый. Имеш, райфоның үз хезмәткәрләре шул, яшерен эшләп ятучы кустарьләр белән элемтәгә кермәгәнме?

Евлампий Иванович тагын шуңа гаҗәпләнә: аноним хатлар күпчелек очракта татар милләтеннән булган кешеләр өстеннән языла. Аның күңелендә, бу — татарларга хас бер чир түгел микән, дигән фикер туды.

Ул Фатыйха абыстай өстеннән язылган әләкне Кадыйровка тотырды:

— Менә синең участогыңда нинди кустарьлар яши! Моны ничек әйтергә, сәяси сукырлык дипме?

— Гаепнең зурысын чәпеде. Мондый сүз аның авызыннан сирәк чыга. Димәк эш җитди. Кадыйров сигналны дикъкать белән укып чыкты.

— Мондый сигналны ялгыз гына барып тикшерү куркыныч, ике кеше кирәк,— диде. Евлампий Иванович сәбәбен сорап тормады, хатны өстәл тартмасына тыгып куйды.

Евлампий Иванович Фатыйха абыстайны тикшерергә икенче бер участок инспекторы белән барган, Кадыйровны ияртмәгән.

Шушы вакыйгадан соң Шәфика Кадыйровны ялгызы гына очрата алмый алҗыды. Ничек инде ана изге теләкләр теләп, рәхмәт әйтмисен!

— Әнием, көн дә намаз артыннан, сезгә сәламәтлек теләп, дога кыла,— диде. Габделхәй аның белән генә канәгатьләнмәде:

— Ә үзең?..— Шәфика аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— О, минеке инде ул чиксез! Рәхмәтемнең зурлыгын аңлатырга сүз генә таба алмыйм.

Кадыйров тартынып тормады, турыдан-туры:

— Юк инде, дускай! Коры рәхмәт белән генә котыла алмыйсың...

— Юеше нинди була соң?

— Миңа күп кирәк түгел,— диде Кадыйров авызын чупылдатып,— бер әп итсәң шул җитә.— Шәфиканың бите чөгендер кебек булды:

— Анысы ук булмас инде,— диде мескен тавыш белән.

— Тормышта булмый торган хәлме әллә?! Гомер ике килми, кадерен белергә кирәк.

— Шәфика аның бу сүзләрен чираттагы бер шаяру дип кабул итте. Шулай да, аны бүләксез калдырасы килмәде. Актык акчасына биш йолдызлы коньяк алды да, иртәрәк эшкә килеп, шешәне аның өстәл тартмасына, кәгазьләр арасына тыгып куйды.

Бертөрле тамгасы булмаса да, Кадыйров коньякның кем бүләге икәнен аңлады. «Юк, кызый, ялгышасың,— диде эченнән генә,— миңа коньяк түгел, син үзең кирәк». Шул рәвешле алар арасында кызыклы уен башланды. Бу уен мәче белән тычканны хәтерләтә иде.

Кадыйров башта, кечкенә генә хат язып, коньякны Шәфиканың үз өстәленә кертеп куярга җыенды. Шәфиканы бүлмәдәшләре алдында фаш итүдән куркып, кире уйлады. Белмәсләр коньякның аның үзенеке икәнен. Кадыйров бүләге дип дөньяны сасытырлар! Гайбәт хатынына ишетелсә җәнҗал чыгуын көт тә тор!

Эштән кайтканда Шәфиканы көтеп алды да, коньяк шешәсен кулына тоттырды:

— Нәрсә, мин моны ялгыз эчеп утырыйммы?— Хәйлә Шәфикага аңлашылмады:

— Минем бирүем хак булсын, калганы турында үзең кайгырт!— Кинәт башында бүләкне азсына дигән фикер туды:— Күбрәк тә биргән булыр идем дә, башкача мөмкинлегем юк.

Кадыйров кычкырып көлде:

— Аңла, минем синең белән бергә утырып эчәсем килә! Әйдә, берәр ресторанга керәбез!

Шәфиканың ресторанга аяк басканы юк, чәче үрә торырдай булды. Ят ир белән рестораннда ашап-эчеп утырганын берәрсе күрсә, ун мәртәбә арттырып гайбәт таралачак. Әнисенә нинди йөз белән күренер дә, иренә ничек җавап бирер?

— Ялгызым сезнең белән ресторанда утырыргамы? Юк, мин алай булдыра алмыйм.

— Иптәшкә берәр дус хатыныңны чакыр!— диде. Кызык тәкъдим. Шул турыда бала чагыннан ук бергә аралашып үскән дус хатынына сөйләгән иде, аларга ияреп ресторанга барырга ризалыгын бирде:

— Исең киткән икән иске чикмәнгә,— диде Сөембикә,— анда безнең кебек ике аяклы хатыннар кереп утыра торганнардыр ич...

Аның ире фәнни тикшеренү институтында эшли. Иркен яшиләр. Ел саен ук булмаса да, ике баласын иренә калдырып, җәйге сезонда көньякка барып кайткалый. Ул төскә-биткә ярыйсы гына, шомырт кара күзләре ут уйнап тора. Озын буйлы, зур күкрәкле, чәч ясалган. Ирләр янында югалып калмый, теләсә нинди темага сөйләшә.

Сөембикә дусты Шәфикага ят ирләр белән күңел ачып йөрүнең кайбер кагыйдәләрен дә өйрәтте:

— Алар белән мөмкин кадәр, эш сәгатьләрендә йөрергә кирәк,— диде.— Тагын бер шарт бар, анысы — вакытында өйгә кайта белү.

Шәфика бу серле сүзләрнең мәгънәсен аңлап бетермәде, әлбәттә. Иргә хыянәт итү генә җитмәгән, хезмәт дисциплинасын да боз, имеш. Күңеле белән дустының киңәшен кабул итәсе килмәде.

Шәһәр читендәге бер ресторанга барырга булдылар. Бу тирәләргә Шәфиканың беркайчан да аяк басканы юк иде. Күп катлы йортларны күреп шаккатты. Үзен бөтенләй икенче дөньяда кебек итеп хис итте. Үзе яшәгән урамны күз алдына китереп, «мин дә шәһәрдә яшим дип йөргән булам инде», дип уйлады.

Кадыйровның хезмәт урыны урамда дияргә була: йорттан йортка йөреп, керемле кешеләр эзләп үтә. Кая тели, шунда бара ала, вакыты да чикләнмәгән. Шәфикага исә, эштән китү ансат булмады. Эзли торгач юлы табылды. Урынга чыгып, пособие алучы бер ялгыз ананы тикшереп кайтырга кирәк иде. Райфодан шунда барам дип, чыгып китте. Кабаланды, кызарды, бүртенде. Бергә эшләгән хезмәттәшләре аның бу кырын эшен сизенә кебек булып тоелды.

Башта Сөембикә белән очрашырга кирәк иде. Ул билгеләнгән урынга шактый соңга калып килде. Шәфика үпкәсен белдерә башлаган иде, кычкырып көлде:

— Бигрәк тормыштан артта калгансың инде син,— диде. Акыллы хатын егетләр белән көрешергә көттереп барырга тиеш, шулай эшләмәсәң — алар каршында потың бер тиен!

Бу өлкәдә Кадыйровның тәҗрибәсе зур. Берничә хатын янына барып йөри. Барысы да тол хатыннар. Аның килгәнен түземсезлек белән көтеп торалар. Коры кул белән түгел, мул итеп сый хәзерләп каршы алалар. Яратып йөрми ул аларны, гәрчә, араларында чибәрләре дә бар. Барысын да бер аршын белән үлчәп, хаҗәтен үти дә, кеше-кара күргәнче, тизрәк таю ягын карый.

Хатынына да яратып өйләнмәде. Аның кешене кызгана торган гадәте бар. Зәйтүнә белән очраклы гына таныштылар. Авылдан килгән кыз. Колхозда авыр эштә йөреп, томанага әйләнгән. Шәһәрдә дә эше җиңел түгел. Мех фабрикасының чимал базасында иза чигә. Әмма ул шуңа да бик шат. Эшләгәне өчен акча түлиләр. Колхоздагы кебек бушка вакыт уздырмый. Габделхәй аны чын күңелдән кызганды. Таныш-белешләре белән сөйләшеп, икенче җиңел эшкә күчәргә булышты. Зәйтүнә дә бурычлы булып калмады. Кызлыгын бүләк итте. Уеннан уймак чыкты — балага узды. Ничек инде баланы ятим итәргә кирәк? Габделхәй үзе ятимлекнең бөтен ачысын татып үскән егет. Аның баласы ятим булырга тиеш түгел! Алар бергә кушылып яши башлауларын сизми дә алдылар. Туйлары да булмады, никах та укытмадылар. Хәзер өч балалары бар. Яшиләрме, яшиләр...

Габделхәй үз җаен үзе карый. Зәйтүнә аны көнләшеп борчымый. Бик еш читтә йөреп, куныл кайткан көннәре дә була. «Кайда йөрдең?» дип сорау юк. Кадыйров хезмәт хакын тиенenә кадәр Зәйтүнәгә алып кайтып бирә, кырын кергән акчаны гына үз кирәгенә тота.

Менә шулай тыныч кына яшәгәндә Габделхәйнең йөрәгенә ут капты. Ул чын ярату белән Шәфиканы ярата башлады. Ни өчен ятратканын үзе дә аңламый. Төн йокысы качты. Нишләргә дә белми. Кызык ярату белән ярата ул аны. Алдагы көне турында уена да кереп караганы юк. Чөнки берниндн очракта да хатынын ташлап, балаларын ятим калдырырга риза булачак түгел.

Билгеләнгән урынга Шәфика белән Сөембикә килеп җиткәндә, Габделхәй аларны көтә-көтә көтек булган иде инде. Күпкә алдан килеп басты. Башта тыныч кына басып торды. Аннан түземлеге бетеп, арлы-бирле йөри башлады. Килгәннәрен күрми калдым микән әллә, дип, берничә мәртәбә ресторанга кереп чыкты. Шулкадәр дулкынланды, аяк өстендә йөреп бер кап сигарет тартып бетерде. Өметен өзеп, кайтып

китәргә җыенгач кына Шәфика белән Сөембикә троллейбустан төштеләр. Габделхәй аларны күреп телсез калды. Нәрсә әйтергә дә белмәде. Ачуланса, үпкәләп кайтып китүләреннән курыкты. Алар исәнләшеп тормадылар, аңа ымлап ресторанга кереп киттеләр. Габделхәй барып кергәндә караңгы почмактагы өстәл артында утыралар иде инде. Шәфика ишектән кергән бер кешене күзеннән үткәреп, бертуктаусыз як-ягына карана. Танышларын очратудан шикләнә.

— Ай-яй сез...— диде Габделхәй. Шәфика белән Сөембикә бер-берсенә карап елмаештылар. Каршы бер сүз әйтмәделәр. Ул арада официант хатын өстәлгә меню китереп куйды да, китеп тә барды.

— Кая китте инде ул?— диде Шәфика ризасызлык белдереп. Аштан авыз итеп, тизрәк чыгып таярга уйлады.

— Монда гадәти ашханәдәге кебек түгел,— диде Сөембикә аңлатма биреп,— теләсәң-теләмәсәң озаклап утырырга туры килә.

Шәфиканың үз-үзен тотышыннан ресторанда беренче мәртәбә булуы ачык күренеп тора иде.

Габделхәй менюны Сөембикәгә тоттырды:

— Җаныгыз теләгәнне сайлагыз!— диде.

— Чамалап,— диде Шәфика, аны кисәтеп.

— Нинди чамалап ул,— диде Сөембикә,— шушындый берсеннән-берсе чибәр ике даманы сыйларга хәленнән килмәгәч, ресторанга килеп йөрергә дә кирәк түгел.

Габделхәй сер бирмәде:

— Бер мәртәбә әйттем бит инде, үзең теләгәнне сайла...

— Безгә нәрсә: акчаң җитмәсә залогка үзеңне калдырабыз да, чыгып китәбез.— Бер-берсенә карашып шыпырт кына көлешеп алдылар.

Габделхәй бер шешә шампанский, кеше башына йөзәр грамм акны китертте. Кабарга да иң яхшысын сайлады.

Шәфика үзен энә өстендә утырган кебек тойды. Шампанскийдан авыз итте, аракыны тотып та карамады.

— Эчмәсәң эчмә, барыбер акчасын түләтәбез,— диде Сөембикә шаяртып. Алар рестораннан чыкканда эш сәгатьләре бетеп, урам халык белән мыжлап тора иде.

## XI

Колхоз ел саен умартачылыктан яхшы гына керем ала. Уңышны нигездә корт караучы хезмәте хәл итә дисәк, ялгыш булмастыр.

Умартачылыкта гомере буе шул эш белән шөгыльләнгән Зариф мулла эшли. Ул умартачылык буенча нәшер ителгән китап-журналларны укып бара. Хезмәтне фәнни нигездә башкара. Өстәвенә бик гадел. Бал янына беркемне дә якын китерми. «Бал дисәң, бер кими, бармак тигерсәң, ике кими»,— дип кенә җибәрә.

Зариф хәзрәт гасыр башында шушы авылга указлы мулла булып килгән иде. Байлыкка хирeслеге булмады. Бер ат, бер сыер асрады. Яллы хезмәттән файдаланмады. Бөтен эшне үз кул көче белән башкарды. Авыл халкы белән рәттән иген икте. Каралты-кура да башкаларныкыннан әлләни аерылып тормады. Кара-каршы салынган ике йорт, такта койма белән корып алынган алма бакчасы. Бакча эчендә умарта оялары. Кайсы елны алар ун баштан да артып китә иде.

Утызынчы еллар башында бөтен милке конфискацияләнеп, умарталары колхозга бирелде. Үзен дә гаиләсе белән Себергә сөрмәкчеләр иде, авыл халкы каршы чыкты. Форма өчен булса кирәк, кемне дә булса Себер җибәрер алдыннан халыкны җыеп, киңәш иткән булалар иде.

Чират Зариф муллага житкәч, ризалык бирелмәде. Йорт җирен конфискацияләп, үзен мунчага куып чыгару белән чикләнделәр.

Соңыннан конфискацияләнгән ике йортның берсен кайтарып бирделәр. Хәзер дә шул йортта торалар. Гаиләләре зур түгел — өч кеше. Абыстайның картаеп беткәч тапкан кызы Сания һәм ирле-хатынлы икесе.

Ниләр генә күрмәде Зариф хәзрәтнең газиз башы! Төн уртасында өеннән алып китеп ГПУ подвалына ябып тоту, рәхимсез рәвештә кыйнау дисеңме — берсе дә калмады. Алладан баш тартып, динне хурлап, матбугатта язмача белдерү белән чыгыш ясарга мәҗбүр итмәкче булдылар. Каты торды:

— Мин иманымнан ваз кичмим, үлем хак, атып үтерегез! — диде. Мәчетне ябып, манарасын төшергәч күз яше белән елады. Мәчет ябылганга карап, дини йолаларны үтәүдән туктамады. Мәет күмде, чакырган кешенең өенә барып Коръән укыды. Тормышны авыр кешеләрдән дога кылып сәдакасын алды да, үзләренә кире кайтарды.

Сугыш алдыннан районнан килеп, колхозга алуны сорап гариза язарга куштылар. Каршы килмәде, язды. Колхозга кергәч, бернинди эштән баш тартмады, нәрсә кушсалар, шуны эшләде. Бер елны көтү көттерә башлаганнар иде, халык мыскылларга ирек бирмәде. Хәзрәт өчен чиратлап көтү көттеләр. Бу хәл райондагыларга ишетелеп гауга куптарып караганнар иде, барып чыкмады. Умарта карарга күчерделәр. Зариф хәзрәт эшли башлагач, умартачылык аякка басты. Тора-бара колхозның бердәнбер тотрыклы керем чыганагына әйләнде. Бу эштә кызы Сания дә булыша. Ул авылда иң тәртипле кыз санала. Мутлыгы сизелгәне юк. Күрше авылга йөреп урта мәктәпне тәмамлагач, беркая китмәде. Карт әтисе белән әнисен ялгыз калдырасы килмәде. Менә инде сазаеп бара, ләкин кияүгә чыгарга уйламый.

Шәрәфи хатыны Хәмсәнә Санияне күптән күзәтеп йөри икән.

— Син ничек уйлыйсың? — диде ул иренә,— әгәр Санияне Әбрарга димләсәк, риза булыр микән?..— Шәрәфи, һәрвакыттагы гадәтенчә, өзеп җавап бирмәде:

— Үзләре белән сөйләш,— диде.

Хәмсәнәнең бу мәсьәләне озакка сузасы килмәде, югыйсә, Фатыйманың егет башын тәмам әйләндереп куюы бар.

Халык арасында фельдшер кызның төрле юк-бар йомыш табып, Әбрар янына йөрүен мәзәк итеп сөйли башладылар. Ә Хәмсәнә иренең туганнан туган энесен һич тә бәхетсез итәргә теләми.

Шәрәфи авылга кайтып озак тормады, йомышын йомышлады да китеп барды. Ни әйтсәң дә, эш кешесе — вакыты тар. Озакламый Хәмсәнәне дә алып китәргә җыенып йөри.

Хәмсәнә үзе авылда чагында Әбрар белән Санияне кавыштырып калдырырга кирәк диган фикергә килде. Башта кыз һәм егет белән аерым-аерым сөйләшеп карарга уйлады. Бик еш булмаса да, кызы Резидә Сания белән очрашып тора. Бер-берсеннән серләрен дә яшермиләр бугай.

Кичкә кырын кабартма пешереп чәй әзерләде дә, Резидәне җибәреп Санияне чакыртып алды. Иркенләп сөйләшеп утырдылар. Башта сүз күргән-белгән турында барды. Сөйләшә торгач, Хәмсәнә шуны сизде: Сания кияүгә чыгу турында уйлап та карамый икән.

— Син күңелеңә авыр алма,— диде серле итеп,— беребез дә бу дөньяга мәңгегә килмәгән. Мулла абзый белән абыстай да картайдылар, алар исән чагында үзеңә лаеклы иптәш табып калсаң яхшы булыр иде, шул турыда уйлаганың бармы?

Сания сорауны аңлап бетермәде, Хәмсәнәгә ачыкларга туры килде:

— Кызларга вакытында иргә чыгу хәерле, югыйсә ялгыз утырып калуың бар. Олыгайгач, лаеклы егет очратуы кыен. Аеруча, безнең заманда.— Сания кулы белән битен каплады.— Оялырлык бернәрсә дә юк, дөнья шулай бара инде ул. Дөрес, хәзерге заманда димләп кияүгә чыгу гадәте онытылып бара, кызык булсын, без шул гадәтне торгызыйк әле.

Резидә мондый сөйләшүне көтмәгән дә, күрәсең:

— Әни син бигрәк инде,— диде,— гел искелеккә ябышып яшисең! Әллә Сания үзе кияү тапмас дип беләсеңме?

— Кызым син кушылма! Димләп чыккан ир мәңгелек була ул. Хәзер әнә, бер-берсен яхшылап белми өйләнешәләр дә, өч көн дә тормыйча аерылып кайталар.

Сания чын-чынлап уйга калды. Кемгә димләгәнне беләсе килде, ләкин сорарга кыймады.

— Беләсеңме, мин сине кемгә димлим? Әгәр аңа кияүгә чыксаң, безнең белән туганлашасың...

— Әбрар абыйгамы? — диде Резидә әнисенең сүзен бүлдереп.— Тапкансың кешесен дә! Фатыймага ишетелсә, икегезнең дә башыгызда бер бөртек чәчегезне калдырмас.

— Фатыймадан куркып торган юк инде анысы! Сания генә ризалык бирсен...— Ана белән кыз күзләрен аңа текәп, тынып калдылар.

— Мин әти-әни белән сөйләшмичә бер сүз дә әйтә алмыйм.

Җавап Хәмсәнәгә ошады, акыллы кыз башкача булдыра алмый. Ул Санияне көтеп тормады, үзе алданрак барып сөйләште. Хәмсәнә бер эшкә алынса, ярты юлда туктап калмый. Тырыша торгач, тәки Сания белән Әбрарны кавыштырды.

Зариф мулланы көйгә китерү кыен булмады. Кешегә әйтеп, шаулап йөрмәгәч тә, үзе исәнендә кызын урнаштырып калу турында Хәмсәнәдән ким кайгыртмый иде. Әбрарны кызына лаеклы ир булыр дип тапты. Егет аның күз алдында үсте. Авыру әнисен тәрбияләп бөтен авыл халкының хөрмәтен казанды.

Зарифа абыстай гына кияү буласы кешене ошатып бетермәде. Берданбер кызын укымышлы кешегә бирергә хыяллана иде.

— Бигрәк чи авыл мужигы инде,— диде офтанып.— Кызымны тракторчының майлы киемен юып газапланыр өчен үстермәгән идем...

— Кызыңны кем дип беләсең соң син? — диде Зариф хәзрәт, карчыгының авызын капларга башка сүз тапмыйча. Чыннан да, шул «чи авыл мужигыннан» кай җире артык Саниянең? Төптән уйлаганда, Әбрар аннан күпкә өстен, менә дигән һөнәре бар. Һөнәрле үлмәс, дип юкка гына әйтми торганнардыр.

Хәмсәнә белән Әбрар Санияне сорарга икесе бергә бардылар. Һәрвакыттагыча, дога кылып хәл-әхвәл сорашкач, турыдан-туры эшлекле сөйләшү башланды. Зариф хәзрәт икеләнеп тормады:

— Кызымны иң элек Аллага, аннан сиңа тапшырам,— диде. Шушы сүзләрне ишеткәч, Әбрарның башы күккә тигәндәй булды. Ризалык бирмәсәләр.. дип куркыбрак килгән иде. Ни әйтсәң дә, Сания гади кешенең кызы түгел. Дөрес, дин әһелләре хакимият тарафыннан төрлечә хурлап, кимсетеп телгә алына. Аларны халык тормышыннан читләтер өчен нинди чаралар гына күрелми? Алланы бар һәм бер дип белгән адәм һәр адымын муллага үлчәп атларга тырыша. Үлем якасыннан китереп тоткач, атеист булып, Алланы сүгеп йөргән коммунистларның да кайберләре соңгы юлга мулла белән озатырга васыять әйтеп калдыра. Менә бит Әбрарга нинди кешенең кызы белән гомер итәргә туры киләчәк! Заманы өчен кыю адым. Ни язган — шул булыр.

Никахны Зариф хәзрәт үзе укыды. Никах мәҗлесенә Шәрәфи дә кайткан иде. Бергәләп киңәшкәннән соң, туй мәҗлесен Ходай кушып тормышлар рәтләнеп китсә, зурлап үткәрергә ниятләделәр.

Беренче кичне кыз белән кияү Шәрәфинең ак өендә үткәрделәр. Алдан сөйләшеп куелганча, алар шунда торып та калдылар.

Шушы хәлләрдән соң күп тә үтмәде, Шәрәфи хатыны белән кызын үз янына, урманчылыкка алып китте. Әбрар белән Сания иркен йортта икесе генә яши башладылар.

Тракторчылар бригадасына эшкә урнашкач, Әбрарның тормышы көйләнде. Көнне төнгә ялгап эшләде, бригададагы иптәшләренең хөрмәтен бик тиз казанды. Исеме МТСның мактау тактасына язылды.

Аның алдына бөтен кискенлеге белән үз йортын аякка бастыру мәсьәләсе килеп басты. Читтән ярдәм өмет итәрлек түгел, барысын үзенә ышанып башларга туры киләчәк.

Иң элек өйнең астагы ике ниргә бүрәнәсен алмаштырырга кирәк. Җиргә тиеп торган бүрәнәләр шундый муртайган, бармак кереп китәрлек. Кыш көнендә бүрәнә арасыннан җылы йөрү нәтиҗәсе инде бу.

Әбрар бүрәнәне Әтнә базарыннан алып кайтырга уйлады. Марилар алып килеп сата. Махсус көйләнгән арбаларга икешәр бүрәнә салалар да, кичтән киләләр.

Бер якшәмбене Сания белән бергә базарга барып, бүрәнә җыйдылар. Сигез аршынлы унике бүрәнә. Акчалары җитәрлек түгел иде, Зариф хәзрәт биреп торды. Бөтен булган акчасын кырып-себереп бирде.

Бүрәнәләрне базардан читкәрәк алып китеп, бер кешенең капка төбенә өеп, калдырып тордылар. Бушка түгел, әлбәттә. Тиешле хакын түләтте. Аларны анда озак тотарга ярамый иде. Алып кайтырга колхоз рәисе үзе әйтеп ике ат бирде. Үзенә генә кыен булыр иде, Әтүтән ярдәм итте. Ул күзгә күренеп үсә. Борын астына мыек чыгып, тамагына ирләр тавышы керде.

Әбрар белән Әтүтән бүрәнә ташыганда дуслашып киттеләр. Әтүтән нинди дә булса йомыш табып, иртәдән үк килеп җитә. Аш ашаган вакыт туры килсә, тартынып тормыйча өстәл янына килеп утыра.

— Бүрәнәсе кайтты, балта эше калды,— диде Әбрар,— әллә сине генә кушасы инде?

— Булмас дип уйлыйсыңмы әллә?—Уйнап әйтелгән сүзне Әтүтән чын итеп кабул итте. Кая барып сугылырга урын таба алмый йөри иде, икенче көнне үк эшкә тотынды. Хәйран кулы ябыша икән үзенең, атна арасында базардан сатып алып кайткан бүрәнәләрне чутлап та куйды. Урнаштырасы гына калды. Бусы инде алар икесе генә башкара ала торган эш түгел иде. Кечкенә генә өмә үткәрергә туры килде.

Өмәгә унлап кеше килде. Партбюро секретаре Фатыйма да килеп карап китте. Берничә мәртәбә өй эченә кереп чыкты.

Бүрәнә чутлаганда Әтүтән йомычканы өйгә сылап эшләнгән лапаска тутырып барган иде. Фатыйма йомычкага да игътибар итте. Лапаска кереп бик озак нәрсәдер күзәтеп торды. Шул арада Әбрар янына килеп үпкәсен әйтергә дә өлгерде:

— Ялгыштың Әбрар дус, ялгыштың! Мулла кызына өйләнмәсәң, үзеңә тиңе дә табылган булыр иде әле.

Бер кырыйда аның сүзен тыңлап торган Шәвәли карт түзмәде:

— Нәрсә сөйлисең син, кызым Фатыйма?—диде гаҗәпләнеп,—Сания нишләп Әбрарга тиң булмасын икән? Икесе дә пар килгәннәр...

— Ни әйтсәң дә, мулла кызы — мулла кызы инде ул, безнең халык түгел.

— Нәрсәдән чыгып алай дип әйтәсең? Нишләп Сания безнең халык булмасын ди?

— Сыйнфый дошман калдыгы. Бүрене ничек кенә тәрбияләмә, урманга карый диләр.

— Тузга язмаган сүз сөйләп, күңелне болгатма әле, Фатыйма апай!— диде Әтүтән сүзгә кушылып.— Йә ач карыннан костырырсың...

— Тик тор! Сиңа бик иртә олылар сүзенә кушылырга.

— Монда партия җыелышы түгел, өйрәнгән син анда кешенең авызын ябып...

— Әй, син ипи шүрлегеңне чамалап ач! Малай дип тормам, мин сиңа урын табармын...

— Озакламый миңа 18 тула, урын кирәк булса мин үзем дә табам!

Фатыйма хурланды булса кирәк, тизрәк китеп барды.

— Маладис энем,— диде Шәвәли Әтүтәнне мактап,— яхшы әйттең! Йөрмәсен кукраеп, соңгы вакытта азуы хәттин ашты.

Җил-җил атлап ишегалдына Зариф хәзрәт килеп керде. Аны күреп Шәвәли тәмәкесен яшерде. Авыл халкы шулай гадәтләнгән, олысы-кечесе хөрмәт йөзеннән муллага тәмәкене күрсәтми.

Хәзрәт кычкырып сәлам бирде, аннары баскыч төбенә утырып, изге теләкләр теләп дога кылды.

— Кияү! — диде Әбрарга мөрәҗәгать итеп,— абыстай ашарга әзерләгән иде, бәлки, тамак ялгап китәрсез?

Кояш баш түбәсенә менеп, төш вакыты җитеп килә иде.

— Нишлибез, җәмәгать? — диде Шәвәли. Ул — яше житмешкә якынлашып килүче карт, тирә-юньдә данлыклы балта остасы. Монда бар да аның җитәкчелегендә эшләнә. Соңгы вакытта эшкә чакырсалар, ялындырып кына бара. Ә менә Әбрарга үзе әйтеп килде.

Өмәдә катнашучылар Шәвәли янына җыелып, тын калдылар.

— Барабыз, барабыз! — диде Әтүтән,— абыстай пешергән аштан баш тарту килешмәс.

Зариф хәзрәтнең симез сарык бәтие бар, шуны суйган иде. Күп итеп ит пешерделәр. Беренчегә салам кебек нечкә итеп киселгән токмачлы аш, икенчегә ит белән бәрәңге бирелде.

Авылда токмачны болай салам кебек нечкә итеп Зарифа абыстай гына кисә белә. Кунак җыйганда, хәлле кешеләр аш әзерләргә гел аны чакыралар.

Зарифа абыстай — крестьян кызы. Яшьлегендә бер эштән дә тартынмады. Хуҗалыкта нинди эш бар, барысын да эшләп үсте. Кияүгә чыккач мулла хатыны өстенә йөкләнә торган дини вазифаларны үтәргә аны ире өйрәтте. Шундый итеп үзләштерде, мулла гаиләсендә туып үскән абыстайлар белән ярышырлык булды.

Өмәчеләргә ашны саф һавада, алма бакчасында әзерләделәр. Анда агач арасында, аякларын җиргә беркетеп эшләнгән өстәл бар иде. Шуңа өйдәге өстәлне алып чыгып ялгагач, барысы да сыярлык булды.

Ашарга утырганчы Зариф хәзрәт кунакларның кулын юдыртты. Сания комганнан су салып торды. Күбесенең мондый хөрмәтне күргәне юк иде. Салкынча чишмә суы арыганны бетереп, рәхәтләнеп җибәрде.

Ашны бик яратып ашадылар. Майлы шулпа барысына да охшады. Аштан соң чәй әзерләнде. Чәй янына зур табак белән яңа аертылган бал куйдылар.

— Җәмәгать! Быел бал күп булды, тартынмый ашагыз,— диде хуҗа.

Абыстай әзерләгән сый өмәчеләрнең күңелен күтәреп җибәрде. Төрле уен-көлкеле сүзгә чик булмады.

— Егетләр, карагыз әле, теге шайтан суыннан башка да күңелле итеп утырып була икән,— диде Бари.

Мәҗлес ашка дога кылып тәмамланды.

## XII

Утызменче буларак Галләмгә райкомнан хезмәт хакы түли башладылар. Берничә айныкын бергә түләделәр. Кесәсенә акча кергәч, шәһәргә, гаиләсе янына кайтып килергә җыенды. Хатынын, балаларын шулкадәр сагынды, күреп туярлык булмады. Шәфика чираттагы ялын алгач, аларны берничә көнгә генә булса да, үз янына авылга алып кайтырга кирәк дип уйлады. Ятмасыннар анда пыскып, Хәнифәнең өе иркен, сыйдырыр әле. Авыл һавасы сулап китсеннәр. Көзгә аларны бөтенләй авылга алып килү турында уйларга кирәк булыр. Хатыны, балалары була торып, ялгыз яшәү килешә торган эш түгел.

Галләм буш кул белән кайтмады. Хәленнән килгәнчә бүләкләр алды. Иң элек каенанасының күңелен күрергә теләде. Алырга әйберсе дә юк бит әле аның, бөтен нәрсәгә кытлык.

Авыл кибетендә азау ярган бер тол хатын эшли. Гомумән, Галләм ул хатыннан читтәрәк йөрергә тырыша. Мут хатын чөнки. Нахакка телгә кереп, халык арасында яман атың таралуы бар. Әмма башына төшкәч, мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды.

Галләм кибеткә кергәндә Саимә ялгыз иде. Ул утыз яшьләр тирәсендә, алсу шомырт кара күзле. Нәфис гәүдәсе теләсә кайсы ирне җәлеп итәрлек. Сүзгә дә кесәгә керә торганнардан түгел.

— О, кемне күрәм, кояш киредән чыкмаса ярар иде!.. Берәр гадәттән тыш хәл юктыр ич...

Галләм бу төче сүзләргә игътибар итмәде, кибет эченнән күзен йөртеп чыкты. Бер кырыйда тозлы балык тутырылган мичкә тора, сасы исе бөтен кибет эчен аңкыта. Прилавка өстендә брезенттан тегелгән иләмсез зур аяк киемнәре аунап ята. Шулар янында лычкылдап изелгән конфет — артель эшләп чыгарган товар. Киштәләр буш, күңелне җәлеп итәрлек әйбер күренми.

— Нәрсә белән сату итәсез соң сез?

— Бер дә юк түгел үзе, товар кайткалый. Кичә генә, хатын-кыз яратып ала торган штапель, ситсы кайткан иде.

— Күренми ич...

— Сезгә кирәк идеме әллә? — Саимә йөгереп барып ишекнең келәсен төшерде. Аннан прилавка астыннан кәгазьгә уралган бер төргәк тартып чыгарды.

— Менә, яратсагыз карап карагыз! — Галләм бер бикле ишеккә, бер прилавка өстендә яткан төргәккә карап, аптырап торды.

— Курыкмагыз, курыкма,— диде Саимә,— ирләргә ябыша торган гадәтем юк.— Ул тиз генә зур бер кисәк ситсы кисеп, кәгазьгә төрде, аның янына күп итеп конфет салды. Галләм кибетченең мондый яхшы конфетны каян алганын күрми дә калды.

Саимә көчләп дип әйтерлек төргәкне Галләм кулына тоттырды. Ул атка утырып юлга чыккач кына аңына килде: акча түләмәде бит... Шәһәрдән кайту белән, алган әйберләренең бәһасен тиенена кадәр исәпләтеп, бурычын түләп чыкты. Саимә аның бурыч түләвен үзенчә кабул итте:

— Тавык йөрәкле икәнсез, мин сезне башкача күз алдына китергән идем,— диде.

...Галләм барып кергәндә көн кичке якка авышкан, Шәфика эштән кайтмаган иде әле. Аны күрү белән балалар икесе ике ягына килеп асылындылар. Галләмнең янында бала күңелен күрерлек әйбере юк иде, нишләргә дә белмәде.

— Менә, әтиегез ничек ярата,— диде Фатыйха абыстай Галләмгә төрттереп. Ишегалдында тарантаста калган күчтәнәчләрне алып кереп кулына биргәч кенә, чырае ягтырып чәй куеп җибәрде. Балаларга ипигә бал белән май ягып тоттырды. Аларның күчтәнәчкә әлләни исе китмәде: берсеннән-берсе узышып әтиләренә һөнәрләрен күрсәттеләр.

Фәрит көзгә укырга керергә әзерләнә икән, әбисе аңа Әлифба алып биргән. Хәреф таный башлавы белән мактанды. Ул арада Фәридәсе зарланып алды:

— Барысы да Фәриткә генә, миңа бернәрсә дә юк,— диде.

Эш сәгатьләре бетеп шактый вакыт үтүгә карамастан, Шәфика һаман күренмәде. Галләм түземлеген югалтып, аны каршы алырга чыгып китте. Ул хатынын Ленин бакчасы янында очратты. Күзләренә ак-кара күренми, дөньяларын онытып бер ир кеше белән сөйләшеп торалар. Галләмгә эсселе-суыклы булып китте.

— Шәфика! — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

— Сине дә күрер көннәр бар икән! — диде тегесе аңа ике кулын сузып,— күптән кайттыңмы? — Ул үзен бик тыныч тота: — Иптәш Кадыйров, таныш булыгыз, минем ирем,— дип аны сөйләшеп торган юлдашына тәкъдим итте. Алар салкын гына кул бирешеп күрештеләр. Шәфика ашыгып бергә кайтуларының сәбәбен аңлатырга тотынды:

— Без иптәш Кадыйров белән бер оешмада эшлибез. Бүген эштән соң гомуми җыелыш булды.— Шулай итеп, җыелышта социалистик йөкләмәләрнең үтәлүе турында сөйләшү, хуҗаның коллектив эшеннән канәгать булмавы, бик нык әрләве турында тезеп сөйләп китте.

Галләм хатынының аңлатмасын тыңлап, вакыт әрәм итеп тормады, өйгә ашыкты. Кадыйров та тизрәк алар янынннан таю ягын карады. Шәфиканың ире алдында ялгыш сүз ычкындыруыннан курыкты.

Соңгы вакытта алар яхшы ук кызып киттеләр: эштән кайтканда көн саен дип әйтерлек Габделхәй Шәфиканы озата. Гади генә озату түгел, сәер озату. Һава яхшы булганда бер-берсен озатышып, ярты төнгә кадәр йөриләр. Габделхәй берничә мәртәбә якындагы бакчага кереп утырырга тәкъдим итеп карады, Шәфика курыкты. Андый чакта, үч иткән шикелле, таныш-белешләр очрап кына тора. Һәркем үзенчә уйлый, белмәсләр бер гөнаһың юклыгын — бөтен дөньяны сасытырлар! Ә урамда йөрү әлләни күзгә чагылмый, анда йөргәндә кемгә кем очрамас?! Ахыр чиктә Габделхәй шул урамда йөрүгә дә риза иде. Хәзергә артыгын өмет итми. Һәркөн аерылышканда Шәфика аны кисәтеп:

— Безнең болай озатышып йөрүнең ахыры яхшыга илтмәс, бетерәбез,— ди. Әмма тукран тәүбәсе. Икенче көнне тагын яңадан башлана.

Эштән кайтканда алар урамга аерым-аерым чыга. Райбашкарма бинасыннан ерак түгел билгеләнгән урын бар. Шунда бер-берсен көтеп торалар.

Шәфика сынап карарга теләп, шул урынга килә. Янәсе, яратуы рас булса, башка очрашмыйбыз дип әйткәнгә карамаска, барыбер шул урынга килергә тиеш. Ә Габделхәй исә Шәфиканы ярты төнгә кадәр көтеп торырга әзер, бары килсен генә!

Шәфика үзен һич аңлый алмый. Ике баласы, менә дигән ире бар, нигә ул болай өстерәлеп йөри, аңа нәрсә кирәк? Әмма Галләмнән аерылып, Габделхәйгә кияүгә чыгарга риза булачак түгел ул. Эш аңа барып җитсә, Габделхәй дә аңа өйләнмәячәк. Ә шулай да, ул бөтен йөрәге белән аны үзенә якын итеп сизә. Нәрсәсе белән әсир итте, һич төшенми!

Галләм каршында Шәфиканың бөтен гөнаһысы — балаларын әнисенә калдырып, ят ир белән урамда җитәкләшеп йөрүдән гыйбарәт. Әгәр ире янында булса Габделхәй белән өстерәлер идеме? Юк, аяк та атламас иде! Нигә соң аларны аерым яшәргә мәҗбүр итәләр?

Галләмне күргәч, Шәфика чын-чынлап курка калды. Үзенең гөнаһларын яшермичә иренә сөйләп бирүдән курыкты. Габделхәй алар яныннан киткәч, күз яшен тыя алмады, җылый башлады.

— Нәрсә булды? — диде Галләм аны култыгыннан алып.

— Син тагын күпме мине ялгыз калдырып йөрергә уйлыйсың? Акылдан шаштырырга исәбең булмаса, кайт тизрәк! — Хатынының катгый таләбе ирне аптырашта калдырды.

— Җибәрсәләр, бүген үк кайтыр идем, җибәрмиләр бит...

— Мине хатын итсәң, кайт тизрәк! — Ире күңелендә үз тугрылыгына шик-шөбһә тудырмаска теләп, һөҗүмне көчәйтте: — Авылда чибәр тол хатыннар күп дип сөйлиләр, әллә берәрсенә ияләндеңме?

— Нәрсә сөйлисең син? Уема да кереп караганы юк.

Алар шулай сөйләшеп өйгә кайтып керүләрен сизми дә калдылар. Араларында нинди дер бәхәс купканны сизеп, Фатыйха абыстай куркып калды. «Әллә, ходаем, Галләм берәр ят кеше белән тотты микән?» — дип курыкты. Кызының көн дә эштән соңга калып кайтуы күптән инде эчен пошыра иде. Ачуланып та карады, әмма ул турыда сүз башласа, кызы көлкегә әйләндерә дә бетерә. Кайсы вакытта аның соңга калып йөрүен үзенчә, кара акыл белән аклап та куйгалады. Кызының шундый вакыты, ничек инде ире була торып, гомерне ялгыз үткәрергә кирәк?

Шундый шөбһәле уйлар дулкынында йөзә-йөзә, Галләм Шәфиканы каршы алып йөргән арада ул ашарга әзерләде. Галләм алып кайткан итне тиз генә иттурагычтан үткәреп, таба пәрәмәче пешерде. Кызы белән

кияве кайтып кергәндә пәрәмәчнең хуш исе борынны кытыклап, ашыйсыны китереп тора иде инде.

Шау-гөр килеп ашарга утырдылар. Өстәл яны түгәрәкләнде. Балаларның шатлыктан башлары күккә тигәндәй булды. Әтиләренең икесе ике ягына утырып аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр.

Ә Шәфиканың тамагыннан аш үтмәде. Эче янганга чыдый алмый, бертуктаусыз чәй эчте. «Нинди начар хатын мин»,— дип уйлап, йөрәге әрнеде.

Галләм пәрәмәчне яратып ашады. Авылда аның каенанасы кебек тәмле итеп әзерли белмиләр шул.

— Сине сыйлап кайтарганнар, ахры,— диде ул хатынының ризыкны чемченеп кенә утырганын күреп. Аны-моны уйлап әйтелмәсә дә, бу сүзләр Шәфиканың йөрәгенә энә булып кадалды. Әйе, курыкканга куш күренә. Җавабы табылды тагын:

— Көндез артыграк ашап ташлаганмын, безнең райбашкарма ашханәсендә ашны яхшы әзерлиләр бит...

Галләм бу сүзләргә ышанды, әлбәттә. Хатынының бакчада, Габделхәй алып килгән татлы ризыкны ашап утыруын күз алдына да китерми иде.

Ничек кенә булмасын, Шәфика ирен бик сагынган иде. Ашап-эчеп, өстәл яныннан тору белән ял итәргә урын әзерләде. Сүзләре сөйләшеп кенә бетә торган түгел иде. Төн шундый кыска тоелды, үткәне сизелми дә калды.

Иртәгесен Галләмгә китәргә кирәк иде. Шәфика, тагын бер кичкә кал дип ялынса да, тыңламады. Ул шулай тәрбияләнгән, аның өчен беренче чиратта дәүләт эше тора, шәхси мәнфәгать соңыннан...

Галләм хатынын үз янына алдырырга кирәк дигән фикергә килде. Торыр урын булдыру мәсьәләсе бөтен җитдилеге белән алга килеп басты. Бу шактый авыр мәсьәлә. Төзегәч, төзегәч, йортны яңаны эшләтергә кирәк. Бер көнлек кенә итеп түгел, гомерлек итеп! Ә менә төзү материалын ничек юнәтергә? Ул юл уңаенда Шәрәфи янына кереп чыгарга уйлады. Шәрәфинең кылын тартып карарга кирәк, бер буралык бүрәнә табып бирә алмасмы? Сораулар, сораулар! Бер кеше башына гына сыйдырып бетерерлек түгел.

Иртән йокыдан тору белән юлга әзерләнә башлады. Иң элек атын ашатып, эчертте. Әтиләрен озатырга балалар да тордылар. Ә башка көнне Фатыйха абыстай аларны йокыдан уята алмый алҗый иде.

— Кара әле, бу кирәкле кишер яфракларын,— диде ул киная белән,— торып та утырганнар! — Ул аларны өстәл янына утыртты. Табын тагын түгәрәкләнде.

Ашап-эчкән арада Шәфикага да эшкә барыр вакыт җитте. Аның эш урыны Галләмнең юлы уңаенда иде.

— Тагын кайчан эләгә, бер тарантаска утырып җилдерим әле,— диде ул иренә,— мине эшкә кертеп чык! — Тәкъдим теләп кабул ителде. Балалар да әниләреннән калышмады:

— Безне дә атка утыртып йөрт,— дип дауладылар. Аларның сүзен тыңламый буламы соң?! Ике бистә арасын узганчы тарантаска утырып бардылар. Аннан соң да әле Фәрит тарантастан төшми алҗытты.

— Озакламый бөтенегезне җыйнап авылга алып китәм, шунда үзеңә бер ат бүләк итәрмен,— дигәч кенә көйләнде. Шәфикага иренең бу сүзләре ошамады, әлбәттә. «Балаларны котыртма» дип әйтмәкче иде, тешен кысып булса да түзде, эндәшмәде.

Фәрит белән Фәридә төшеп калгач, Галләм атны кызулатты:

— Тагын мине ташлап китәсең инде,— диде Шәфика. Күзләрендә энҗе кебек ялтырап яшь бөртекләре күренде. Бу ясалма түгел, чын йөрәктән чыккан күз яшьләре иде. Ул үзе өчен курка. Ә Галләм аны үзеннән шикләнә дип кабул итте. Чын күңелдән кызганды.

Галләм хатынын райбашкарма ишеге төбенә кадәр илтеп куйды. Анда тагын Кадыйров басып тора иде. Күренмәскә теләп эчкә кереп китте.

Шәфика иренең ике битеннән үбеп, тарантастан төште. Ул күздән югалганчы баскан урыннан кузгалмады. Урам халык белән мыжлап тора. Ашыгып эшкә баралар. Колхозга җибәрмәгән булсалар, Галләм дә шулар арасында булыр иде. Ямансулады, үзәге өзелеп ямансулады.

Менә Арча артта калды. Хәрби шәһәрчекне узгач, иген кырына килеп чыкты. Быел анда ашлык чәчелмәгән. Җир кысыр калган. Сугыштан соң елларда бу тирәдәге җирне шәһәр халкына бәрәңге утыртырга бүлеп бирәләр иде. Галләмгә дә бер кишәрлек җир биргәннәр иде. Бер-ике ел бәрәңге утыртып яхшы гына уңыш та алды. Хәзер ул бәрәңге утырткан җирне казып бетергәннәр, чокыр да чакыр... Шул тирәдән ерак түгел зур төзелеш башланган. Германиядән кайтартылган тимер каркасларны монтажлап, бина корып маташалар.

Тар гына арада ике мәртәбә тимер юлны аркылы чыгарга туры килде. Сул якта, Казан суы буенда ял йорты. Ул табигатьнең гүзәл почмагына урнашкан. Җәй көннәрендә анда зур җитәкчеләр ял итә дип сөйлиләр. Галләм ише гади кешеләргә юл ябык. Ә тау астында, сазлык кырыенда шырпы тартмасы кебек вак-вак йортлар тезелеп киткән. Алар «халыклар атасы» үлгәч барлыкка килде. Халык бераз иркен сулап, торак мәсьәләсен хәл итүне кулына алды. Шәһәр читендәге ерганаклар, тау кырыйлары рөхсәтсез салынган такта йортлар белән тулды. Уты, эчәргә яраклы суы булмаса да, шәһәрдәге ярым җимерек, сасы подвал түгел иде инде бу. Бала-чага саф һава сулап үсә.

Як-ягына мәһабәт тупыллар үсеп утырган таш түшәлгән юл буйлап бара торгач, Шәрәфи каравылчы булып ялланган урманга да барып җитте. Уң якта, куе куаклар арасында йорт түбәсе күренде. Галләм атны шунда таба борды. Тал чыбыгы түшәп юл салынган сазлык аша узгач бер йорт янына килеп чыкты. Ул шактый биек такта койма белән уратып алынган. Капка төбендә коедан Шәрәфинең кызы Резидә су алып маташа иде. Күрү белән таныды:

— Әти, Галләм абый! — дип кычкырды. Капкадан ашыгып Шәрәфи килеп чыкты. Һәм ике кулын сузып Галләм каршына килеп басты.

— Көтмәгән идем, мәрхәбә! Кадерле кунак килгән...

— Менә кая килеп оялагансыз! Эзләп таба торган түгел...

Шәрәфи капканы ачты, сорап та тормады, атны җитәкләп ишегалдына алып кереп китте. Ишегалды иркен, эреле-ваклы хайван белән мыжлап тора. Баскыч төбендә хуҗабикә күренде:

— Кунак бар икән! Әйдәгез, әйдә, өйгә рәхим итегез!

— Анда керсәм озак торам, — диде Галләм, — шушында бераз сөйләшик тә, китәм...

— Булмаганны... — дип, ир белән хатын авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Шәрәфи Галләмнең атын туарып, алдына яңа чабып алып кайткан хуш исле печән салды. Аннан бергәләп өйгә керделәр.

Өй эче татарча җиһазландырылган. Почмак якта сәке, ак якта имән өстәл, түрдә чаршау корылган агач карават. Бөтен җир пөхтә итеп җыештырылган.

— Менә шулай яшәп ятабыз, — дип, Шәрәфи өстәл кырыена барып утырды. — Әйдәгез, бер дога! — Галләм мөселманнарның бу гадәтенә яңа өйрәнеп кенә килә иде әле, Шәрәфигә ияреп ул да ике кулын күтәрде. Хәмсәнә өстәлгә шакмаклы кызыл ашъяулык япты.

— Күрәм, сез зурдан кубасыз, — диде Галләм уңайсызланып. — Мин сезне болай мәшәкатьләнерсез дип уйламаган идем.

— Мактап йөрисез икән, — диде Хәмсәнә, — бүген мич ашы пешергән идем. — Өстәлгә таба белән кайнар бәлеш килеп утырды. Ир белән хатын серле итеп бер-берсенә карашып алдылар.

— Китер, китер! — диде Шәрәфи, боерган тавыш белән.

Хәмсәнә почмак яктан алып чыгып өстәлгә утырткан шешәне Галләм идәнгә алып куйды.

— Бусы кирәкми,— диде, аракыдан катгый рәвештә баш тартты.— Ул каһәр суккан эчкә керсә, сөйләшүнең рәте булмый, минем әле юл йөрисем бар.

— Бер дә исегез китмәсен, өй иркен, куныш китәрсез,— диде Хәмсәнә сүзгә кушылып.— Рәхәтләнеп ял итегез!

Шулай сөйләшә-сөйләшә хуҗабикә ак чәшкәләргә хуш исле чәй ясап китерде, табак белән бал куйды.

— Болар менә минем ризык,— диде Галләм,— алар хәзер авыл халкының төшенә дә керми.

Ул тамагы тук булса да симез сарык ите турап пешерелгән бәлештән авыз итте. Бәлеш ашап туйгысыз иде.

Сыйланып сөйләшә торгач сүз шактый тирәнгә керде. Шәрәфи сәяси темага күчте. Бу темага авызымны да ачмам дип сүз биргәне булса да, тыелып кала алмады:

— Әйтегез әле, болай тагын күпме яшәргә була? — диде. Җавап көтеп тормады, сүзен тагын дәвам иттерде.— Инде менә сугыш беткәнгә ничә ел, тормыш көннән-көн авырая, көннән-көн кысалар. Колхозчы мескен кол хәлендә, крепостной крестьянне дә болай җәберләмәгәннәрдер!

Галләм үзе дә шулай уйлый, ләкин үзе уйлаганча җавап бирергә шүрләде:

— Партия авыл халкының тормышын яхшыртырга бөтен көчен куя,— диде, көндәлек матбугатта зур хәрефләр белән языла торган сүзләрне кабатлап.— Көтик, үзгәреш булырга тиеш. Авыл җирендә җитәкче кадрларны ныгыту шул юлда бер адым бит.

— Шәһәрдән колхоз рәисләре җибәреп, тормышны яхшыртып булыр дип уйлыйсыңмы? — Шәрәфи Галләмгә текәп карап торды да, бер башлагач ахырына кадәр әйтеп бетерергә кирәк дип уйлады: — Минемчә системаны үзгәртергә кирәк, колхозчының авыр хәленә система гаепле...

Менә ничек?! Болай ачыктан-ачык сөйләшергә ярыймы соң? Галләм Шәрәфине ничек туктатырга белмәде. Авызы пешкәне бар. Шундый сөйләшүдә катнашып көчкә котылды. МГБга чакыртып җанын алдылар. Ярый әле, тыңлап кына утырган иде. Әгәр ул сүзләр аның авызыннан чыккан булса, белмим, ахыры нәрсә белән беткән булыр иде! Халыкны авызлыклау мөмкин эш түгел икән шул! Палач балтасы астында да фикерен әйтми калмый, юлын таба ул.

— Син, энем, миннән курыкма! — диде Шәрәфи, Галләмнең куркып калганын сизеп.— Мин кешене кешедән аера беләм. Әгәр ышанмасам, авыз да ачмаган булыр идем. Минемчә, безгә, крестъян халкына ирек бирергә кирәк. Ирекле булса, ул дөньяның астын өскә әйләндерергә сәләтле. Гражданнар сугышыннан соң илнең хәле хәзергедән йөз мәртәбә авыррак иде. Син ул чорны күз алдыңа китерә алмыйсың, әлбәттә. Сиңа ничә яшь әле? Күреп торам, яңа туган бала гына булгансың шул. Менә алайса тыңла! Революциядән соң Ленин бөлгенлектән котылу юлын тапты. НЭП игълан итеп, халыкка ирек бирде. Бер-ике елдан ил аякка басты. Билгеле булганча, патша заманында Рәсәй крестьян иле иде. Гомер-гомергә крестьян җирсез булды, тамагы туймады. Ленин аларны «җиргә үзегез хуҗа буласыз!» дип алдады. Шушы алдау аңа революциядә җиңү китерде. Чөнки гражданнар сугышында Кызыл Армия башлыча крестьян егетләреннән тора иде. Дөрес, революциядән соң җирне җан башыннан тигез итеп бүлделәр. Үзе исән булса, бәлки шулай калган да булыр иде. Сталин башны ашады. Халыкны сарык көтүе кебек колхозга куып кертеп, бер нәрсәсез калдырды. Нәтиҗәсе күз алдында. Бу бит тарихта күрелмәгән хәл: көн-төн бушка эшләп, ачлыкта тилмерәбез! Шул эшмени инде — үстергән икмәгеңнең бөртеген дә калдырмый, дәүләткә илтеп тапшыр да, үзең шәһәрдән сатып алып кайтып, тамак туйдыр!

Сүзгә Хәмсәнә кушылды:

— Җитәр инде сиңа, туктаусыз такылдап, кунакка ашарга ирек бирмисең,— диде ирен битәрләп.— Һич тыңлата торган хәл юк,— дип тагын Галләмгә карады,— сүзнең берәр файдасы булса икән?! Таш капчыкка илтеп тыгарлар әле менә...

Шәрәфи крестьянгә хас булган акыл белән фикер йөртә. Бөтен сүзләре белән килешмәсә дә, Галләм эченнән аның яклы иде. Ул ачыктан-ачык үз фикерен аңа белдерергә кыймады. Хәмсәнәне яклап берничә сүз әйтүне кирәк тапты.

— Хатынның акыллы киңәш бирә, сөйләшкәндә сак булырга кирәк,— диде.— Безнең заман шундый заман, бер сүз өчен тормышың җимерелергә мөмкин.

— Беләм, беләм! Нишлим соң, йөрәккә чыдап булмый бит?! Аптыраган үрдәк арты белән күлгә чумган диләрме әле?!.

Әйе, халыкның күпчелеге тормыштан риза түгел.

— Шеш тула да, бер тишелә,— диде Шәрәфи авыр сулап,— халык үз сүзен әйтми калмас.

Галләм ниндидер бер китапта Наполеонның үз солдатлары турында «ворчат, но шагают» дигән сүзләрен укыган иде. Хәзергә бездә бөтен ил күләмендә шундыйрак хәл бит дип уйлап куйды.

— Ярар, ул да торсын, бу да торсын, күп сүз — юк сүз дип юкка әйтми торганнардыр,— диде Галләм.— Беләсезме, мин сезнең янга ни өчен сугылдым?

Сорау Шәрәфине сискәндереп җибәрде:

— Әйтеп карагыз?

— Миңа бер өйлек бүрәнә кирәк.

— Нәрсә, әллә авылда төпләнеп калыргамы исәп?

— Камытның кәттәсен киерттеләр, тиз генә ычкынып булмас ахры...

— Хәзер генә әзер бүрәнә юк, уйлап карарга кирәк.

Шәрәфи монда килеп урнашкач, үз кулы белән шактый зур бура бураган иде, бер атна чамасы элек сатып җибәрде. Казан артыннан килеп алып киттеләр. Сабыр итсә дә ярыйсы булган икән, хуҗа ашыктырды бит. Аның рөхсәтеннән башка эшләнә торган эш түгел. Хезмәт кенә Шәрәфинеке, калганы бар да аларныкы. Ул бу турыда Галләмгә тәфтишләп сөйләп тормады.

— Җае чыгу белән хәбәр итәрмен.

— Миңа ашыгыч түгел, көзгә гаиләмне алып килергә уйлыйм. Аларны кеше почмагына алып килеп булмый бит...


Галләм аш өчен рәхмәт әйтеп, урыныннан торды. Шәрәфи кечкенәдән гадәтләнгәнчә дога кылды, аннан соң гына урыныннан кузгалды.

— Була торган булса, озакка сузмаска иде,— диде Галләм, тагын бер мәртәбә үтенечен искә төшереп.— Коры вакытта ташып калдырырга кирәк.

Шәрәфи хуҗа белән сөйләшеп бер буралык бүрәнә әзерләргә һәм бурап та куярга вәгъдә бирде. Ул монда баш урманчы белән элемтәгә кереп, тамырын шактый тирәнгә җибәреп бара иде инде. Корыган агачларны кисү сылтавы белән шактый күп бүрәнә әзерләнде. Бу турыда алар баш урманчы белән икесе генә белә. Корыган агачлар утынга сатыла. Менә шул вакытта бер буралык бүрәнәне Галләм Җиһаншин исеменә ягулык өчен сатылган утын хисабына кертеп җибәрергә туры киләчәк...

*Ахыры бар.*

# ШИГЪРИЯТ



## Роберт Миңнуллин

### ҖӘЙНЕ ОЗАТУ

**Бүгенге хәлләребез**

Йодрыклар чыкты кесәдән,
Бүген һәркем гайрәтле!
Буташтырып бетерделәр
Яман белән әйбәтне.

Өскә чыкты еллар буе
Сәрсеп яткан явызлык.
Тыялмый ул явызлыкны
Бернинди дә авызлык.

Нинди сандыкларда яткан
Соң бу этлек, кәчеклек.
Кемгә генә кагылсаң да
Кәнчелек тә хөсетлек.

Эшләүче аз — элеккечә
Бар да таләп итәләр.
Дәшми торсаң, бәгыреңне
Эттәй талап китәләр.

Бу кешеләр бер-берләрен
Тотып ашарлар иде;
Ирек бирсәң, бер-берләрен
Тотып асарлар иде;

Утыз җиденче ел булса,
Тәмләп сатарлар иде;
Йә булмаса, диварларга
Терәп атарлар иде;

Бар кешелегеңне җиргә
Салып таптарлар иде...
Уйлап куям — болар да бит
Безнең татарлар инде.

Почетта хәзер юньсезлек,
Намуссызлык, нахаллык.
Нәрсә булды соң әле бу? —
Ну, замана! Ну, халык!

## Алдамыйк үзебезне!

Кинәт кенә диндарландык
Элекке имансызлар.
Башыбызда — шәл, түбәтәй...
Күрсеннәр, инансыннар.

Бәйрәмнәрдә, мәҗлесләрдә
Үзем дә килештерәм:
Мәчетләргә йөрештерәм,
Хәерләр бирештерәм.

Түбәтәй дә киештерәм,
Кия иде бабам да.
Коръәнне дә сыйпап карыйм,
Тукай кебек, алам да...

Үзе генә белсен кеше
Ышанганын аллага.
Мин диндар, дип, кешене дә,
Үзеңне дә алдама!

Гөнаһтан куркыйк аз гына —
Ходай белә барсын да.
Зинһар өчен, дим, гөнаһлы
Булмыйк ходай каршында.

Диндарлык килер безгә дә...
Ул юл — изге, ул юл — ак.
Ходайга юл җиңел түгел,
Ходайга юл ул ерак.

## Казан. Кремль. Ак диварлар

Казан.
Кремль.
Ак диварлар...
Балкый ул әллә каян.
Авасың бит, Сөембикә —
Әйдә, үземә таян!

Казан.
Кремль.
Ак диварлар...
Чал тарихлардан калган.
Ташларына татарларның
Кайнар каннары тамган.

Казан.
Кремль.
Ак диварлар...
Капкаңны кемнәр кагыр?
Сине тагын кемнәр алыр?
Һәм кемнәр саклап калыр?!.

Казан.
Кремль.
Ак диварлар...
Татарның баш дивары.
Син — татарның йөзек кашы...
Син — таш кына нибары...

## Оялам мин каеннардан

Тәрәз төбендә каеннар,
Каеннарныңаклары.
Ахрысы, ак каеннарның
Гашыйк булган чаклары.

Үзләренә алар урын
Табалмый басып тора:
Дәрманнары ташып тора,
Күкләргә ашып тора.

Син булмасаң, каеннарга
Булыр идем, аһ, гашыйк!
Каеннар карый бүлмәгә,
Тәрәзләрем ап-ачык.

Алар безгә карап тора,
Күреп тора һәммәсен.
Оялам мин каеннардан,
Яп тәрәзә пәрдәсен.

## Җәйне озату

Көннәр һаман җылы әле.
Сентябрьнең бише.
Җиңелчә, җәйчә киенеп
Йөри әле кеше.

Яфраклар гына акрынлап
Керә сары төскә.
Күнегәбез, буйсынабыз
Без дә сары көчкә.

Тышта җәйчә челлә әле,
Эчтә — сагыш кына.
Мондый хәлләр табигатьтә
Була ялгыш кына.

Ак болытлар шундый биек,
Җилләр йөри биеп.
Кыштырдый сары яфраклар
Бәгырьләргә тиеп.

Дөньяның хозурлыгына
Буламы соң туеп!
Күзләрне дә, кышларны да
Буламы соң тыеп?

Кояш. Рәхәт. Ак каеннар
Утыралар оеп.
Күңел генә күзне тоя —
Шуңа, ахры, боек.

* * *

Бараба, Барда, Барыш...
Татарларыма тартылам,
Татарларыма барыш.

Чакмагыш, Чишмә, Илеш...
Татарларым күтә мине —
Илемә кайтып килеш.

Касыйм, Ижау, Каргалы...
Кайларга чыгып китсәң дә
Үз илеңә бармалы.

Әстерхан, Курган, Кырым...
Кайчандыр ата-бабалар
Нигезләр корган урын.

Ырынбур, Нижгар, Бүздәк...
Китеп барам туганнарны —
Татарларымны эзләп.

Чиләбе, Тобол, Төмән...
Анда да татарлар күтә
Ипи-тозлары белән.

Бу татар, һай, сибелгән...
Рәсәйнең бөтен картасы
Татар белән чигелгән.

## 1994. Актаныш. Сабантуй

Атлар чаба. Чабышкылар.
Чабыш бара каты!
Иң беренче булып килә
Президентның аты.

Килә аты уйнап кына,
Күзнең явын алып.
Йөрәкләр куйды кысылып,
Ах, дип куйды халык.

Бүтән бөтен атлардан да
Тора аерылып.
Тик ул кинәт кереп китте
Читкә каерылып.

Кереп китте урманга ук
Һәм югалды күздән...
Ах, ничекләр җилә иде,
Җиңә иде тиздән!

Менә бит әй, чит тарафка
Кереп китте дулап —
Президентның үзенә һич
Охшамаган бу ат.

## Шагыйрьләрне яраталар...

Шагыйрьләрне яраталар!..
Шуңа яла ягалар,
Шуңа ярлыклар тагалар,
Авызларын ябалар.

Шагыйрьләрне яраталар!..
Шуңа күрә өрәләр,
Шуңа башларын кисәләр,
Йә сөргенгә сөрәләр.

Шагыйрьләрне яраталар!..
Шуңа күрә саталар,
Төрмәләргә утырталар,
Асалар йә аталар.

Шагыйрьләрне яраталар!..
Ачтан да үтерәләр...
Үзе үлгәч, үзен күмгәч,
Бәрхетләргә төрәләр.

## Сөн буенда кояш байый

Сөн буенда кояш байый,
Байый күзгә күренеп.
Нурларына рәхәтләнеп
Куеп була кер элеп.

Кызыл шәфәкъ. Кызыл болыт.
Кызылдан кызыл кояш.
Бигрәк ямансу — кояшның
Тиздән батасын тойгач.

Сөн буенда кояш байый...
Сүрәнләнә, сүрелә.
Ничек кенә төшенергә
Бу кояшның серенә?

Төшеп бара кызыл кояш
Нәкъ Актаныш янына.
Анда — якты...
Безнең авыл
Инде төнне ябына.

Сөн буенда кояш байый
Моңсу гына, соң гына.
Кояш түгел, гомерләрем
Байый сыман тын гына.

## Кылганнар

Әй, кылганнар, кылганнар.
Әнкәемнең чәчләренә
Көмеш булып кунганнар...

Тавышсыз-тынсыз гына
Җилфер-җилфер җилфердиләр,
Җырсыз да моңсыз гына...

Дулкынлана кылганнар.
Кылганнар ниләр кылганнар,
Кылганнар ник тынганнар?..

Көйләр көйлидер алар.
Без белмәгән, без телгән
Серләр сөйлидер алар...

Узып барышларыдыр.
Болар — Болгар кылганнары,
Болгар сагышларыдыр...

Чынлап, алардыр, алар.
Болгардан Татар Иленә
Ашыгалардыр алар...

Җилфердиләр җилсез дә.
Кылганнарның җыр-моңнарын
Ничек җиткерим сезгә?..

* * *

«Мин чибәрме?» — дип сорыйсың.
Чибәр инде, чибәр!
Тагын да чибәрләнерсең,
Бер елмаеп җибәр!

Чибәрлегең тирә-якка
Якты нурын сибәр...
Ничек инде мин сөйгән кыз
Булмасын ди чибәр?!

## ХИСАМ КАМАЛОВКА 70 ЯШЬ



# ӘҖӘЛНЕ ҖИҢГӘН ӘДИП

Сугыш гарасатын үз башыннан, үз җаны аша кичергән язучылар, шагыйрьләр бар. Үлем белән күзгә-күз очрашып та исән калу бәхетенә ирешкән, шуңа күрә тормыш кадерен белеп яшәүче, үзенә аерым бер үҗәтлек белән иҗатта яңадан-яңа үрләр яулаучы буын. Кызганыч ки, әлеге буын әдипләренең сафы һаман саен сирәгәя бара...

Хисам Камалов — әнә шушы фронтовик-әдипләр гвардиясеннән. Татар укучысы аны «Яңадан сафка» (1956) исемле беренче шигырьләр китабыннан ук үз итте, яратты һәм әлегәчә күздән югалтмый. Хисам Камалов үз укучыларының җылы мөнәсәбәтен, ышанычын тулысынча аклады, еллар узган саен үз иҗатының яңа матур яклары белән ачыла барды. Образлы фикерләүне, фәлсәфилекне нигез итеп язылган һәм замандашларыбызның асыл сыйфатларын чагылдыручы күпләгән шигырьләр, поэмалар, фронт хәлләрен реаль сурәтләүче «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым» романнары һәм башка әсәрләре әнә шуңа дәлил.

Нинди генә темага иҗат иткәндә дә, Хисам Камаловка тормышның ачы-төчесен күп күргән булуы, күпләгән замандашларының язмышын үз йөрәге, үз аңы аша уздыруы, тормыш һәм рухи биографиясе ярдәмгә килә.

Хисам Нуретдин улы Камалов 1926 елның 14 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы, Кама Исмәгыйль авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлауга колхоз эшенә җигелгән, атлар караган. Унҗиде яше тулуга, 1943 елның көзендә фронтка алына. Икенче Балтик буе фронты гаскәрләре сафында немец-фашистларына каршы сугышларда катнаша. 1944 елның җәендә яраланып, ике ай госпитальдә ятып чыга да яңадан — фронтка. Артиллерия полкының элемтәчесе булып, Латвия җирләрен дошманнардан азат итешә. 1945 елның февралендә яңадан каты яралана. Төрле госпитальләрдә ел ярым үлем белән көрәшкәннән соң, Әҗәл авызында бер аягын калдырып, яңадан тормышка кайта.

Яшь-яшь килеш гарип калу хәсрәтен, сызлану газапларын эченә йотып, башта Бөгелмә педагогия училищесын, аннары Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Шул елларда ул

институттагы һәм «Татарстан яшьләре» газите редакциясе каршындагы әдәби түгәрәкләргә актив йөри, иҗат эше белән шөгыльләнә башлый, табигать биргән талантын үстерә. Дистә елдан артык Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар редакциясендә редактор булып эшләве дә аның иҗатына уңай йогынты ясый. Ә 1967 елдан Хисам Камалов әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Ул — 1958 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Әдәби җәмәгатьчелек Хисам Камаловның нәтиҗәле иҗатын югары бәяләде. Ул югарыда телгә алынган романнары өчен 1986 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Хисам Камалов, шөкер, талантлы каләмен әле дә кулыннан төшерми, яңадан-яңа әсәрләр язуын дәвам итә. Шуның нәтиҗәсе буларак, аның узган ел «Казан утлары» журналында (1—2—3 саннар) «Түләнмәгән күз яше» исемле яңа романы дөнья күрде. Татарстан нефтьчеләре тормышының әлегәчә күләгәдәрәк кала килгән якларын яктырткан, җир-суыбызның чисталыгы, җаннарыбызның иманлы булуы кебек әхлакый мәсьәләләрне күтәргән бу әсәрендә дә узган сугышның фаҗигале кайтавазлары ачык ишетелә...

Халкыбызның күренекле әдибе Хисам абый Камаловны без олуг юбилее белән ихлас котлыйбыз, аңа озын гомер, яңа иҗади сөенечләр телибез.

Бу санда журналыбыз укучыларына әдипнең фронт истәлеген тәкъдим итәбез.

## Хисам Камалов

# СУГЫШТА УСТАВ ЮК...

ФРОНТ ИСТӘЛЕГЕ

1944 нче елның ноябре. Балтик буе илләре фашистлардан азат ителеп беткән дип әйтерлек. Тик Латвиянең диңгез буендагы Курляндия дигән җирендә немецлар һаман каршылык күрсәтеп яталар. Аларның бередә кадровый армия төркеме тупланган, Хәрби техника бик күп һәм тыгыз урнашкан. Шуңа бик каты каршы торалар, һич чигенмиләр. Берничә эшелонлы оборона корганнар: өч-дүрт катлы траншеялары, хәйләле ут нокталары... Ә танкларны җиргә күмеп куялар да, ул тик атып ята. Аны берни белән дә ала алмыйсың.

Ә безнең як нишли? Бездә дә техника бик куәтле, көч тә күп, тәҗрибә дә җитәрлек. Безнекеләр немецларга каршы бер километр, ягъни һәр 1000 метр арага 200 «ствол» куя. (Анда шулай сөйләшәләр иде). Бу инде һәр биш метр саен бер пушка дигән сүз. Шул пушкалар сәгать ярым чамасы дошман оборонасына атып тора. Кечкенә мәйданга меңәрләгән снарядлар төшеп шартлый. Ә һәр снаряд 20—30 квадрат җирне тетеп сала. Кыскасы, дошман оборонасы иңгә, буйга, тирәнлеккә берничә кат тетелә. Анда бер тере җан иясе калмаслык ителә. Фәкать шундый гамәлдән соң гына дошман чигенергә мәҗбүр. Нәкъ менә гранит тау-ташны чокып, шартлатып, китеп ала-ала алга барган шикелле инде. Курляндиядә сугыш әхвәле шундыйрак иде. Гаҗәп түгел, Берлин алынгач та әле бередәге фрицларның кикриге шиңми, сыннары сынмый.

Госпитальдән төзәлеп чыккач, безне һөҗүм алып бара торган шушындагы бер частька китерделәр. Минә минем кечкенә Кызыл армия кенәгәсендә: «Прибыл в 612 легкий артиллерийский полк, 5 батарея, 23 ноября, 1944 года», дип мөһер сугылган. Мин ноябрь башында килгән идем. Авырып санчастьтә ятып чыктым. Мине довольствиегә алырга, сугышчы итеп вакытында теркәргә җай булмады. Старшина рәтле яза белми икән. Ул барча язу-сызу эшләрен бер сержанттан эшләтә иде.

Яңа һөҗүмгә бик каударланып әзерлек бара торган чак иде. Безне шунда ук эшкә йөгертә башладылар. Безнең артиллерия часте үзебезнең алга урнашкан пехота батальонына беркетелгән. Без, пушкарьлар, пехотачылар белән бергә, бер йодрык булып хәрәкәтләнергә тиешбез икән. Пехотачылар иң алдагы траншеяларга килеп урнашканнар. Хәзер траншеяларны тирәнәйтә, озынайталар. Без дә аларның траншеяларыннан ун метр чамасы арттарак җайлы урын табып, күзәтү пункты ясадык. Бер накатлы гына кечерәк блиндаж. Ишегеннән траншея сузыла. Ул бер чокырга барып тоташа. Без шуңа көндезләрен дә кереп-чыгып йөри алабыз. Икенче төнне җәяүле гаскәр солдатлары да траншеяларының бер тармагын безнеке белән тоташтырдылар. Ләкин алар якты күздә бер адым хәрәкәтләнә алмыйлар. Чөнки немец снайперлары бик уяу сагалый. Ә безне алдагы куаклар ышыклап тора. Накат бүрәнәсенә стереотруба урнаштырылды, куакларның бер өлешен төнлә чапкалап, күзәтү өчен ачыклык ясадылар. Без төнлә бер элемтәче солдат белән батареядән алып күзәтү пунктына кадәр элемтә линиясе суздык. Өч-дүрт катушка чыбык китте.

Көнгә караңгы иңү белән алгы сызыкта хәрәкәт, ыгы-зыгы башлана. Сугыш кирәк-яраклары, минометлар, башка кораллар китереп урнаштыралар. Мотор гөрелтеләре ишетелеп китә. Немецлар тавышка бик сак, тавыш аулый торган приборлары бар, ди. Әз генә тавышны да сизеп алалар һәм авыр туплардан пешерергә тотыналар. Бу инде цельсез-сукыр ату, шулай да кайбер снарядлары байтак зарар китерә.

Рота командиры лейтенант Епифанов безнең янга телефоннан сөйләшергә кергәли. Ул — урта буйлы, озынча йөзле, нык ихтыяр иякле, йомык кыяфәтле кеше. Күптән түгел генә госпитальдән килгән икән. Күз чокырларындагы касмак төсле сарылык шуның билгеседер, мөгаен. Сөйләшкәндә тыныч, бер дә тавышын күтәрми. Аңардан ниндидер мәһабәтлек бөркелә. Гадәттә, язмышы белән килешеп, авыр шартлардан зарланмый торганнарда шундый чалым була. Телефоннан сөйләшкәндә өстәге командирларның аңа кычкыру, сүгүләренә дә артык исе китми шикелле иде. Ә менә рота замполиты бик кырыс һәм кискен күренә. Аның йөзендә үк сине нәрсәдәдер гаепләргә торган ачулы төсмер бар. Турганов фамилияле, үзе гарәп төсле кара-кучкыл чырайлы. Мин аны башка милләттән дип торам, ул чып-чын урыс икән. Кызык, Турганов фамилияле ничә чи татар кешесен очратканым булды. Ә бу — урыс. Татар фамилияле урысларның бик еш очравына гаҗәпләнми булмый.

Мин телефон трубкасын уң колагыма җайлап бәйләгән килеш җир сәкедә янтаеп утырам. Пехота командирлары эшләре беткәч, чыгып китәләр. Минем бик нык йокы килүдән күз кабаклары салына, һич күтәрер хәлем юк. Көн-төн йокы белән көрәшәм. Алгы сызыкта солдат ашау һәм йокы өчен иза чигә. Аз-маз ач тору берни түгел, әмма йокы тәтемәсә, бар нәрсәдән яман. Баш миңгерәүләнә, акны-караны аермый башлыйсың. Бар нәрсәгә битараф булып каласың. Пулялар-га баш имисең. Үлем куркынычыннан сакланырга башың-зиһенең тупайлана. Йокламау кешене тәмам сафтан чыгара.

Күзләремне ачсам, ротный яссы алюмин котелоктан кичке аш ашап утыра. Безнең блиндажда тычкан уты кадәр яктылык сибә торган лампа кисәге бар. Шуңа ул бездә ризыкланучан булып китте. Минем күз ихтыярымнан тыш аның йөзеннән шуып уза. Менә иртәгә-берсекөнгә ул ротасын һөҗүмгә алып барачак. Исән калырмы, юкмы? Лейтенантның эчен шул нәрсә кыра торгандыр мөгаен. Аның чырае бар нәрсәдән бизенгән, гарык булып тайчынган төстә. Минем йөрәк әллә нишләп китте. Берәр нәрсә сизенә микәнни?.. Әле бер атна элек кенә безнең батарея командиры һәлак булды. Соңгы күргәндә аның да йөзе котны алырлык, вәйранлык белән өретелгән иде. Бер өзмәс тәмәке төтәтте. Безне ашыктырып, батареяга кайтарып җибәрде. Үзе күзәтү пунктында калды. Бездән тизрәк аерыласы килә иде кебек. Без чыгып киткәч тә, блиндажга ерактан ата торган снаряд төшкән...

Алгы сызыкка аяк басуга, кешеләрнең холык-фигыле үзгәрә. Икенче эшелоннан иң алдагы траншеяга күчкәндә нык сизелә бу хәл. Шаулап-көлеп сөйләшүләр кинәт тына. Һәркем шыпырт була, ничектер бөрешеп, кечерәеп кала. Эчкә шом кереп оялый. Үзеңне ихтимал мишень итеп тоясың. Һәркемнең үзенеке үзендә. Эндәшсәң дә, җавап бирми. Җиңеннән тартканга да илтифат итми.

Нишләп лейтенатның йөзе шул тикле фаҗигале, кара сызыклар белән тулган? Эчендәге бар нәрсәсе йөзенә чыга икән...

Көндез пехотачылар — блиндажларда. Салкын, шушы көннәрдә генә тундырып җибәрде. Тышта 6—7 градус салкын. Әмма учак ягу ише нәрсәләр мөмкин түгел. Блиндажда бераз ышык. Замполит сәяси әңгәмә уздыра. Сүзне

хәзерге моментка китереп бәйли. Тиздән һөҗүм башланачак. Атака вакытында дошман траншеяларына беренче кергәннәргә «Дан» ордены биреләчәк. Икенчеләренә дә «Дан» ордены — ләкин өченче дәрәҗәдәгесе. Өченчеләргә — «Кызыл йолдыз»...

Ярты төн узгач, термослар белән ботка китерделәр. Сугышчылар тыз-быз йөренделәр. Һөҗүм алдыннан тиешле йөз грамм сырец аракы да өләшенде. Өшегән-күшеккән тәннәргә бераз җан җылысы кергән кебек булды. Ләкин беркемнең дә теле чишелмәде. Үз эчләренә ныграк йомылдылар. Күзгә күренеп килгән үлемне ничек хәйләләргә дип, эчтән генә баш ваталар төсле иде...

Төн караңгылыгы сыекланып, әйберләр шәйләнә башлаган эңгер-меңгердә кинәт җир дерт итеп китте һәм аяк асты чайкалып алгандай булды. Берьюлы бердәм кубып, бик күп пушкалар дошман позицияләренә ут яудырырга тотынды. Бу артәзерлек башлануы иде. «Катюша»лар җан суыра торган аваз чыгара-чыгара, каршы якка ут күперләрен сузалар. Әче дары исе һаваны куерта, борыннарны әчеттерә. Күктәге мотор тавышлары ишелеп-ишелеп җиргә төшкән шикелле. Бик күп самолетлар эскадрильясы немецлар ягына бомба ташлыйлар. Анда хәзер җирнең асты өскә килә. Балчык фонтаны, кап-кара сөрем каплаган. Берни шәйләп булырлык түгел.

Пушкалар, минометлар шашынып атканнан соң, ут нокталарын дошман оборонасының эченәрәк күчерделәр. Аяк астындагы җир дулкын өстендәге көймәдәй чайкала. Кайчак берәр нәрсәгә тотынып кына егылмый каласың. Безнекеләр материаль як белән алдыралар. Ягъни снаряд, бомбаларны кирәгеннән артык яудыралар. Сугыш техникасы да немецларныкыннан артык. Материаль өстенлек җинә. Шуңа солдатларның фидакарьлеге өстәлә...

Ниһаять, тәмам яктырды. Пушкалар һаман аталар әле. Безнең элемтә командиры блиндаж накатына стереотруба беркетеп куйды да, дошман ягын күзәтә башлады. Бераздан читкә тайпылып, пехотачылар ягына сузылып карады. «Күтәрелергә нәкъ вакыты, нәкъ вакыты, нигә сузалар?» — ди-ди мыгырданды. Ул арада пехота траншеяларында хәрәкәт башланды. Епифановның басынкы, властьлы тавышы ишетелде: «Сержант Проклов, уң флангтан сугышчыларны күтәр! Сержант фәлән сул флангтан... Ну, ну, ребятки, пошли, пошли!..» — Ул траншея буенча йөгерә-атлый чапкалап йөри, ләкин нигәдер траншеядан өскә күтәрелми. Проклов кычкыра, әшәке сүгенә: «Ут ноктаалары бетерелмәгән, әнә пуля янгыры сибеп тора. Ничек күрә торып үлем авызына керәсең? Пушкалар халтурит иткәннәр күрәсең...» «Разговоры! Ползком, давай, давай, ребятки!» Епифанов траншеяның бер очыннан икенче очына ашыга. Траншеяның ары очына җиткәч, ул кинәт: «За мной!» — дип команда бирде дә өскә күтәрелде. Ләкин нигәдер аңа иярүче булмады. Инде байтак вакыт узды. Безнең командир борчыла: моментны ычкындырдылар бит, аннары яман булачак, эх!..

Епифанов тагы бик нык нервылы тавыш белән кычкыра, һөҗүмгә күтәрелергә приказ әйтә-әйтә, абына-сөртенә йөгерә. Юк, сугышчылар башларын күтәрмиләр, траншея стеналарына сыланып катканнар. Нәрсә бу, мондый хәлнең очраганы, ишетелгәне юк иде. Моментны ычкындырдылар шикелле инде. Шулчак кинәт траншеяда батальон командиры һәм замполит пәйда булдылар. Комбат пистолетын кулына тотып, бер генә кычкырды, барча сугышчылар хәрәкәткә килде. «Замполит, ротаны һөҗүмгә алып бар!» — дип җикеренде. Шунда замполитның да рәхимсез приказы яңгырады һәм ул үзе беренче булып траншеядан атылып чыкты. Аның артыннан сугышчылар берәм-берәм алга ыргылдылар.

Бу көтелмәгән хәлдән Епифанов югалып калган иде. Комбатның килүе, рота белән җитәкчелек итүне Тургановка бирүе аны тәмам каушатты. Ул бруствергa сикереп менәргә, сугышчыларга ияреpгә итә иде. Әллә каян гына чыгып, аның каршына күк погонлы яшь кенә ике кеше килеп басты. Сержант погонлысы кулын сузып: «Оружие сюда!» — дип, лейтенантның пистолетын кулыннан тартып алды. Икенчесе куеныннан бер кәгазь чыгарып, лейтенантның күзләренә тераде. Епифановның болай да саргылт йөзе кәгазь кебек агарып китте, каны качты. Ул як-ягына каранып, батальон командирын эзләде. Әмма тапмады, өмете өзелгәндәй шиңеп калды. Мондый очракта беркемнең аңа ярдәм итә алмаганлыгы аңына барып җитте. Ул: «За что? Почему?» — дип тә әйтә алмады, телсез калды. Йөзендә зәһәрле, нинди дер җансыз елмаю иде. Үзенең кулга алынуы аңына барып җитми иде шикелле...

Нәкъ шушы мәлдә немецларның еракка ата торган пушкалары бу тирәгә снарядлар яудыра башлады. Епифановны безнең блиндажга алып керделәр. Командир стереотрубадан һөҗүмнең ничек барышын күзәтү белән мәшгуль иде. Аларны эчкә уздырып, үзе күзәтүен дәвам итте. Һөҗүмчеләрнең кая хәтле барып

житүләрен бер-ике сүз белән әйтеп ала иде. «Танклар киттеләр, танклар!» — диде ул шатланып. Ләкин особистлар моны ишетмәделәр. Епифановтан сорау алырга ашыктылар.

— Ни өчен ротаны атакага күтәрә алмадыгыз, кырык минут соңардыгыз? — дип, особист сержант бик катгый итеп аны стенага терәде...

— Ут нокталары юк ителеп бетерелмәгән иде, пулялар очып торганын үзегез дә шәйләгәнсездер? Шуңа күтәрелмәделәр, мөгаен? — диде ротный исенә килеп һәм үзенең хәлен аңлый башлап...

— Мең метрга ике йөз «ствол» куйганда ут нокталары бетмәве мөмкин түгел! — Особистның кинәт ачуы кабынды, чигә тамырлары бүртеп зәңгәрләнде. Ротный моңа каршы әйтергә дәлил тапмады. Особист теоретик яктан хак сөйли иде. Ул блокнотына тагы нәрсәләрдер сызгалады. Язуын танырлык түгел, стенографист билгеләре белән яза иде...

— Арада ризасызлык белдерүчеләр булдымы? — дип сорады икенче ефрейтор-особист...

— Ансыз булмый инде, ризасызлар һәрчак булып тора.

— Кемнәр? — дип, эш конкретлыкка килеп терәлгәч, ротный тукталып калды. «Фамилияләрен әйтергәме, юкмы?» — дигән каршылык белән эчтә көрәш бара иде.

— Юк, дәгъвачылар батыр, менә дигән сугышчылар, сез аларны каләмгә алмагыз, зинһар! — дип ялварды ротный...

— Фамилияләрен әйтергә теләмисез, димәк, сез алар белән теләктәш булгансыз? — Особист сорауны мәкерле итеп куя. Ротный тагы ык-мык итеп торды.

— Теләктәшме, түгелме, белмим, ләкин алар чын солдатлар! — диде.

— Димәк, сигналлар нигезле булган, — дип нәтиҗә чыгарды ефрейтор үзенчә борып. — Кемнәр беренче булып алга ыргылырга тиеш иде? — Особистның тавышында барысына да лейтенант гаепле дигән ышаныч чалымы сизелде.

— Уң флангта — Проклов, уртада — Тимиров, сул якта — Журба. Алар бер атна элек кенә госпитальдән килгәннәр. Бераз кыюлыклары төкәнү табигый. Тылда торып килгәч, шулай була. Алар барыбер үз бурычларын үтәрләр. Сез мине болай итеп ялгыштыгыз! — Ротный сүзен әйтеп бетерә алмады, особист тавышын күтәрде:

— Шуны бел һәм аңла: без ялгышмыйбыз! — Аның чыраенда дәһшәт сызыклары калыкты, йөзен ямьсез, шәкелсез иттерде. Әмма ротный үзендә хаклылык сизде:

— Юк, бик каты ялгыштыгыз, җавап бирергә туры килмәгәе, — диде. — Әллә сездән өстә бернинди көч юкмы? Һе! Һе!..

— Без җавап бирмибез, шпак, неужели жираф син? Бездән өстә бернинди көч була алмый! Төшендеңме? Шулай да кызык, нәрсәдә безнең ялгыш, ә? Ә? Әйтеп кал, без яхшы чакта, ә?

— Сезнең ялгыш шунда: ротаны һөҗүмгә Турганов алып китте, — дип сөйләнде Епифанов. — Турганов сугышчыларны харап итәчәк, чөнки аның тәҗрибәсе юк. Башкалар өстеннән әләкләү белән генә күтәрелгән. Башы начар эшли...

— Юк, юк, ул безнең кеше! — дип, сүзне бүлде ефрейтор...

— Шикләнмим, сезнең кешедер, әмма акылсыз, бушка кан коелачак. Менә шул...

— Ну бу синең үзеңне акларга тырышып, «почва зондировать» итәргә маташуың, аңлашыла...

— Беренче траншеяга барып җиттеләр! — дип, тышта кычкырды безнең командир. — Ах, безнең бер танкны яндырдылар, икенче кат траншеяда фаустник утырган шайтан. Аны пехотачылар күреп, дөмектерергә тиешләр иде. Эх!.

— Хәзер фрицлар артәзерлек вакытында артка чигенеп, яшеренгән җирләреннән чыгачаклар, — дип, Епифанов үз сугышчылары өчен кайгырды. — Бу минутта бик сизгер һәм хәйләкләр булырга кирәк. Ике-өч кеше бер булып хәрәкәт итәргә кирәк. Чөнки фриц белән ялгыз күзгә-күз килсәң, ул сине җиңә. Әйе, әйе!

— Менә антисоветчик икәнеңне үзең үк әйтеп торасың, — диде ефрейтор, нәрсәдер тапкандай шатлыклы тавыш белән.

— Куркытма, мин куркудан узган инде, — диде Епифанов батырая барып. — Менә сез ул антисоветчиклар! Әйе, әйе! Сезнең ялгыш аркасында ничә сугышчының гомере өзеләчәк! Сездән дә яман антисоветчикның булуы мөмкин түгел! Әй, Россия, кайчан арынырсың шундый халуйлардан!

Ротный сүзен әйтеп бетермәс борын, ефрейтор сикереп торды да аның түш изүеннән шатырдатып эләктереп алды һәм ишеккә таба өстерәргә тотынды.

Сугышның ерагайганы хәзер нык сизелә. Бу тирәдә инде адашкан пулялар да очмый диярлек. Окулярдан күзен алмый күзәткән безнең командир:

— Немец траншеяларында шартлаулар еш шәйләнә. Бик кискен граната сугышы бара, ахрысы,— дип сөйләнде, үкенечле тостә. Тагы бераздан шатлыклы тавышы ишетелде: —Танклар икенче траншеялар өстендә күренәләр...— Ул тынычлана төшкәндәй, күзәтүдән арып, блиндаж эченә керде, тизрәк папирос кабызды да җир сәкегә сузылды...— Прорыв булмады, шулай да 4—5 чакрым алга кителде,— дип сөйләнде ул. Немец бик нык утыра,— дип аны куәтләде элемтәче.— Әллә ничә эшелонлы ныгытма төзегән, шуңа прорыв була алмый...

Ул арада көнгә бик тиз караңгылык иңә башлады. Батареядан сержантны сорадылар. Мин трубканы аңа суздым. Ул байтак кына андагы командир белән бәхәсләште. Приказга тиз генә күнми, каршы төшеп үз дәлилләрен куярга ярата. Һәрвакыт шулай, командир белән бераз тел чарлап алгач кына күнә. Акыллырак булуын сиздерергә тырышуымы, әллә үзен тәҗрибәле итеп күрсәтергә теләүдәнме — каршы әйтмичә бер генә эшне дә башкармый. Бәлки саклык өчен шулай эшлидер? Эш барып чыкмаса, мин каршы килеп караган идем, дип, акланырга җай кала. Командирның акылына, логикасына ышанып җитмәү дә бар, ахрысы. Төрле командирларга туры килеп, бик нык авызы пешкән булса кирәк.

Сержант канәгатьсез тостә, кашларын җимереп, трубканы миңа бирде һәм әйтте:

— Малайка, давай кабельләреңне катушкага чорный башла, яңа позициягә күчәргә приказ...— Ул папиросын еш-еш суырып торды да төпчеген ыргытты, иелеп, блиндаж ишегенә таба юнәлде.— Тиз-тиз, хәзер машина килеп җитәр! — ди-ди чыгып китте. Мин тиз генә телефон аппараты булган яшел тартманы җыярга керештем. Икенче элемтәче чыбыкны катушкага чорный-чорный, тегеннән килүчегә каршы китте.

Күпме вакыт үткәндер, пушка таккан безнең студебеккерлар килеп җитте. Батарея позициягә шушы тирәләрдә урнашырга тиеш икән. Безгә исә пехотачылар янына алга барып күзәтү пункты төзергә боерык бирелде. Сержант анда машина белән барырга теләгән иде, ләкин батарея командиры рөхсәт итмәде. Ник дигәндә, минадан әрчелмәгән җирләргә юлыгуың бик ихтимал. Сержант моны үзе дә аңлый иде. Шуңа артык бәхәс корып, карулашып тормады. Без кухнядан кичке ашны алып ризыкландык та, аппарат һәм катушкаларны җилкәләргә асып, юлга ашыктык. Без карабинны үзебез белән йөртергә тиеш. Әмма ике катушка, аппарат өстенә карабин бик авырга туры килә. Карабин алмаганга командирлар ачулана. Тик хәлне аңлыйлар, күрмәмешкә салынулар. Анысы инде коралсыз алгы сызыкка бару үзебез өчен дә хәтәр. Иң курыкканым — әсирлеккә эләгү. Шуңа чалбар кесәсендә «лимонка» йөртәм. Ләкин лимонка авыр. Чалбарны төшерә, билдә чалбар тормый. Без әллә кайдан «дамский» дигән кечкенә пистолетлар юнәткән идек. Шуны фуфайканың эчке кесәсендә генә йөртәбез.

Алгы сызыкка ашыгуның хикмәте бар. Немецлардан калган берәр блиндаж эләктереп калып булмасмы. Чөнки салкын 6—7 градус булса да, җирне туңдырып җибәрде. Блиндаж төзү болай да мәшәкатьле, күп көч сорый торган эш.

Дегет кебек куе караңгы төн. Немецлар чигенеп урнашкан җирдән ракеталар чөяләр. Кечкенә ут йомгагы мөлдер-мөлдер килеп җирне яктырта. Ерактан ата торган пушкалар өзмәс төшереп кенә торалар. Снарядлар безне узып шартлыйлар. Без алга баруны дәвам итәбез. Тирәбездә узгынчы пулялар, тыз-быз килеп, сызгырып выжылдыйлар. Пуляларга әһәмият биреп вакланмыйбыз. Алар безнең баш очыннан, өстәнрәк үтәләр.

Мышкылдый-мышкылдый барып җиттек. Траншеяга яңа пехота частьләре килеп тулган. Кай арада диген. Һөҗүм вакытында ук яңа көчләрне китергәннәр, ахрысы. Без блиндажларны чамалыйбыз. Блиндаж ишегенә килеп җитәрәк, сержант: «Кто там?» — дип кычкыра бирә. Тегеннән тавыш килгәч кенә, алга атлый. Керә дә кесә фонаре белән эчен яктыртып карый. Кеше тулган булса, юк, дип кире чыга. Әмма без белгән пехотачылардан ник берсе очрасын. Әллә барысы да һәлак булганнармы? Епифанов гоман иткәнчә? Әллә алышынып өлгергәннәрме? Без караңгыда бик күп олаучыларның арба тавышын ишетеп бардык. Кайбер олаулар белән янәшә атладык.

Траншеяның тармакланып киткән чокыры бер тупикка барып чыкты. Куакларга ышыкланган блиндаж бар икән. Барып кердек, буй белән йөрерлек, үзе зур гына. Сержант яктыртмас борын, Тургановны тавышыннан танып алды. Кесә фонарен худка җибәргәч, күрдек: яфрак түшәлгән такта сәкедә яралы Турганов һәм тагы ике-өч сугышчы ята. Аларның берсе авыр яралы, мыгыр-мыгыр саташа. Калган икесе контужен булганнар шикелле. Сөйләшә алмыйлар, әйткәнне әллә

ишетмиләр, әллә ишетмәмешкә салышалар. Турганов шунда ук сержантны таныды һәм олау таләп итеп, кычкыра-сүгенә башлады. Ул байтак салмыш икән, янындагы термоста аракы булып чыкты. Ул сүгенде, карганды: «Безне бүре авызына ташладылар,— ди,— югары командирларны эттән алып эткә салды. Сержант аны тынычландырды: «Хәзер олау юнәтәм, зинһар әүчәләнмә,— диде.— Әнә күрәсең, немецлар бик каты аталар, тына төшкәч кузгалырбыз».

Блиндаж безнең өчен кулай иде. «Шушында төякләнергә кирәк»,— диде сержант. Турганов бераз тынычлана төште кебек. Таныш кешенең очравы өмет тудыра иде. Аның аягы яраланган, бик авыр түгел кебек күренә. Һәрхәлдә, сөяккә эләкмәгән булса кирәк. Сөяге яраланганнар болай кычкыра да, сөйләшә дә алмыйлар. Турганов торып утырды. Сержантка аракы салып бирде, үзе дә ярты кружка чамасы эчте. Турганов сизелерлек тынычланды. Тавышы әкрен-әкреләнде, сержантка дустанә шикелле карый иде. Хәл-әхвәл белешкәндә сержант Епифанов турында сүз кушты. Нәрсә булса ул хакта сөйләшүдән качар, дигәндәй, бик сагаеп әйтте. Әмма Турганов боргаланмады. Чөнки хәзер эш узган, ул яралы, моннан соң алгы сызыкка эләкмәячәк. Моңа нык ышанычы бар шикелле сөйли:

— Кемдер «сизгерлек» күрсәткән булырга тиеш,— диде.— Болай да аңа ышанмыйчарак карыйлар иде. Мине кисәттеләр, аңа бик ышанып бетмә, диделәр. Үзем абайламыйча, мин дә аны сатkалаганмындыр, дип уйлыйм хәзер. Беләсең, штабка барган саен бер особист сораштырырга тотына. Епифанов болай бит, тегеләй бит инде, ди-ди, минем авыздан сүзләрне тартып чыгара. Ул читләтеп-читләтеп, әллә кайларга кереп, сөйләнә, Епифанов турындадыр дип уйламыйсың да. Соңыннан ми тартмаңда шундагы әңгәмәне акыл бизмәненә салып анализлаганда гына эчке мәгънәләргә төшенәсең. Әмма эш узган була. Үзең дә аңлап җитмичә, иптәшеңне саткан буласың. Анда бит профессионаллар эшли. Безнең эше беркатлыларның эчен актарып чыгара алар. Епифановны яклап бер уңай сүз әйтсәм, юк, син аны белмисең генә, диләр. Кайбер сорауларына ым гына кагасың, үз файдаларына булса, шунда ук эләктереп алалар һәм күпертәләр. Әйтәм бит, иптәшеңне сатуыңны сизмисең, син белерлек, фикер төйнәрлек җай калдырмыйлар...

Турановның теле көрмәкләнә башлаган иде. Сержант тиз генә чыгып, бер олау табып килде. Без, җыйнаулашып, яралыларны бричкага төядек. Алар китеп тә бардылар. Юк, Турганов дурак түгел икән, Епифанов аны ачудан гына гаепләп маташкандыр...

Менә шул. Мин бу хәлләргә үзем шаһит булдым. Ул вакытта күп нәрсәләрне аңламаганмын, билгеле. Әмма төп вакыйга хәтер төбендә калган. Нык тәэсир иткәнгә күрәдер инде. Ул хәлнең хәтәрлеген сизеп, мин аны үземне-үзем мәҗбүр итеп оныттым. Куркудан белмәмешкә-күрмәмешкә салыштым. Сер түгел, без күпме еллар буе белмәмеш-күрмәмеш булып яшәдек. Исәпләсәң, исең китәр... Кеше ышанмастайны дөрес булса да сөйләмә, дигәннәр. Ләкин алгы сызыкта болай кешегә аңлавы кыен хәлләр адым саен булып тора иде. Аларны, гыйбрәт өчен булса да, хәл кадәри сөйләп, язып калырга кирәк. Еллар узу белән баштан кичкән күп нәрсәләр хәтердән коелып беттеләр. Ә Епифанов фамилиясе ничектер хәтердән җуелмады. Үзенең вакыйгасы белән истә торды. Гайре табигый булганга гына түгел, куркытканга күрәдер дә дип уйлыйм. Епифанов фамилиясе очраган саен кызыксына, сораштыра идем. Ләкин лейтенантны белүчеләр булмады.

Госпитальдә сөйлиләр иде: алгы сызыкта сугышчыларны һөҗүмгә күтәрә алмау очраклары булгалый, ди. Шуны алдан исәпләп, штаб тирәсендә бер-ике батыр, гаярь офицер тотыла. Була ди, алар нәрсә беләндер тапланган, салгаларга яратучы, ләкин гаҗәп аек акыллы фидакарь лейтенантлар... Сугышчыларны, алдан барып әйдәргә, атакага күтәрергә тиешләр. Ихтимал, Епифановны да әнә шундый максатта файдаланганнардыр, мөгаен. Булса да булыр, мин моңа ышанам, сугыш бит устав буенча гына бармый ул.

*Май, 1995*

# БУ ХАЛЫКТА — ТАУЛАР ГОРУРЛЫГЫ

(ЧЕЧЕН ПОЭЗИЯСЕННӘН ҮРНӘКЛӘР)

**Соңгы елларда Чеченстан (Ичкерия) дигән сүзләр телдән төшми. Моның сәбәбе барыбызга да мәгълүм: чечен халкы, гайрәт алып, инде ничә гасырлар барган азатлык көрәшенең яңа дулкынын кузгатты. Әмма империя бирешергә теләми: ут һәм кылыч белән горур халыкны тез чүктерергә, буйсындырырга, хәтта юк итәргә тели.**

**Без, татарлар, мондый шовинистик сәясәт белән килешә алмыйбыз, әлбәттә. Шагыйрь-әдипләр дә ил-халык белән, бердәм рәвештә, чечен халыкларына яклау белдерәбез. Журналыбызда чечен поэзиясеннән шигъри үрнәкләр бирү — безнең яктан теләктәшлек, дуслык билгесе булсын. Төрле елларда, төрле авторлар тарафыннан язылган шигырьләр булса да, аларда бүгенге көннәрнең кайнар сулышы сизелеп тора.**

## Мөхәммәт Мамакаев

### Без — таулар кешесе

Безнең дә бит яшәп яткан чаклар,
Без — кешеләр — сөю, нәфрәт гөле.
Гамь утында дөрләп янсак кына,
Хыялларга тугры калсак кына —
Юлдаш булыр безгә бәхет көне.

Буын арты буын алмашына,
Исәннәрдә тибә тере йөрәк.
Бәя биреп эше зурлыгына,
Ак-карага бүлеп тормый гына
Үлгәннәрне искә алу кирәк.

Хактан булсын кылган гамәлебез,
Көрәш хисе дәвам итә канда.
Нәсел җебен өзми саклар өчен,
Газиз Ватаныңны яклар өчен
Үлемсезлек яши безнең җанда.

## Рәисә Әхмәтова

* * *

Эчем поша, йөрәк яна бүген,
Бу болытлар гүя — таш дивар.
Шушы ташлар этә-төртә мине
Үткәннәргә илтеп ташлыйлар.

Сагышларны көннәр белән түгел,
Күз яшьләрем белән санадым.
Җилкәм белән этеп таш диварны,
Килер көнгә төбәп карадым.

Кояшлы юл алда төсмерләнә,
Күз яшьләре кибә берзаман.
Чык бөртеге тулган таңнарымны
Көтә-көтә яшим мин һаман.

* * *

Сентябрьдә гөлләр саргаядыр,
Яфрак шавы күмә урманны...
Көз!

Сентябрьдә — җил-яңгырлар туе,
Ак Кояшның сүрән нурлары.—
Көз!

Кайчак җәйнең уртасында нигә
Йөрәгенә кереп тула ул,—
Көз?!

## Алла Дудаева

* * *

Синең җанда күпме хәзинәләр
Посып ята!.. Әгәр шуларны
Мин белмичә китеп барам икән —
Кем кичерер ялгышуларны?

Юллар озын, гомер генә кыска,
Кем соң әйтер синең сүзләрең:
«Ай-кояшлы шушы дөньялыкта
Мин калдырам гомер эзләрем...»

## 1988 ел

Еллар арты еллар дәвам итте,
Көннәр арты көннәр йөгерде.
Һаман да шул таныш соры йөзләр,
Берни аңлатмаган соры сүзләр
Тырнап тора иде күңелне.

Кинәт кенә бер яңарыш булды!
Очты-китте кайбер маскалар.
Ялгышмаска вәгъдә бирә-бирә,
Яңа юлбашчылар
Яңа юлга аяк бастылар.

Менә без дә ерак юлга чыктык:
Пар яфрактай очып, җилкенеп.
Күләгәләр, кояш арасыннан
Узып китмәбезме җил кебек?

Әй, Россия! Шушы яңарышың
Бу юлы да чыкса ялганга,—
Елый-елый мин үкенер идем
Шулай сине сайлап алганга!

## Россиягә

Югарыдан фәрман төшергәннәр,
Җайлашканнар көнгә, вакытка.
Патшаларның гаҗәбенә каршы,
Миллионнар ята табутта.

Чокырларга шыплап тутырылган
Һәм түшәлгән алар канауга.
Бу урманнар, күлләр тиешмени
Кеше каны белән янарга?

Этне генә комлы туфрак белән
Ашык-пошык шулай күмгәннәр...
Судсыз-нисез, бары приказ белән
Кеше гомерен өзә түрәләр.

Күпләр әле, күпләр бер гөнаһсыз
Изге бәндә булып кылана.
Җиргә ятып җилләр елаганны
Сөйләп бирер идем мин аңа!

Ничек итеп канлы күз яшьләрен,
Яраларны йолып калырга...
Егерменче гасырда да инде
Җинаятьчел юлдан барырга?

Мин дә, син дә — һәркем гаепледер,
Әмерләрне сүзсез тыңлагач.

Ничек инде тыныч яшәү кирәк —
Күңелеңдә өмет булмагач...

* * *

Ажаган уйный күңелдә
Үткәннәр төсе булып.
Яшьлегем, төнге кош сыман,
Төште күктән убылып.

Йокламыйм: әнә, ал дивар —
Таң калкына каршымда.
Исемеңне язам дисәң,
Сәхифәләр бар шунда...

Рашат НИЗАМИЕВ *тәрҗемәләре.*

# Хаси Зибукаев

## Бөркетең булып калам

Бабам нигезе — Кавказ тауларым,
Бөркетләрең сине данлады.
Омтылганга һәрчак иреккә,
Очты алар биек-биеккә.

Кара болыт — дошман яулары,
Ятлар сине били алмады,
Урыс-патша үзе алданды —
Бөркетләрең җимне алмады,
Бабамнарның рухын санлады.

Теләделәр тоткын итәргә,
Динебезне мыскыл итәргә.
Сулар һавам тыгыз кысылды,
Тауларыма кереп сыенды...

Куердылар тагын болытлар,
Сынатмагыз, бөркет егетләр!
Тау йөрәген чукый Каракош,
Туган тауны саклап калаек.

Шул Каракош теге заманны
Бүлдергән бит бабам намазын,
Мәҗбүр иткән чит-ят җирләрдә
Мәхрүмлекләр яшен түгәргә...

Туган нигез — Кавказ тауларым,
Бөркетләр күк, исән-сау даның!
Синең улың булу — горурлык,
Бер бөркетең булып каламын.

## Көтмә минем һәлак булганны...

Очраттым мин сине, гүзәлем,
Кулларыңда иде гөлләрең.
Узып киттең, никтер күрмәдең,
Гөлләреңне миңа бирмәдең...

Сугышларда каткан күңеле
Аңлый алмас гөлне, дидеңме?
Аһ, фәрештәм, ач та күзеңне,
Күреп бакчы шагыйрь күңелен.

Мин көл түгел, гөлләр ятатам,
Дуслык кулы эзләп җан атам!
Ярату ул — ихлас хис, беләм,
Яулап булмый аны көч белән...

Санламыйча, күрми үтмәсәң,
Тиңең күрсәң, колың итмәсәң,
Күңелемне сиңа ачармын,
Хәзинәмне уртак ясармын...

Аңламаска теләп хисемне,
Янып бетсен җаны, дисеңме?!
Шул вакытта гөлләр куярмын
Кабренә аның, дисеңме?

Ул вакытта ачылыр күзләрең,
Тик соң булыр инде, гүзәлем.
Көтмә Сөю һәлак булганны,—
Бүген кирәк миңа гөлләрең...

Шамил МАННАП *тәрҗемәләре*

# ШИГЪРИЯТ



## Рифат Җамал

### Галәм очкыны

Малай чакта бик үсәсе килә —
Көннәр кыска, еллар озыннар.
Миннән алда үсеп ат булдылар
Миннән соңрак туган колыннар.

Малайлыктан чыгып бетмәс борын
Эзли идем тормыш токкасын...
Хәзер инде вакыт, әй, ашыга —
Чабуыннан килә тотасым.

Тотып булмый — ул йөгерә башлый,
Ә аннары сизәм очканын.
...Соңгы мизгелемдә күреп калам
Мин үземне — Галәм очкынын!

### Ачы матурлык

Көзнең дә үз бизәкләре:
Кып-кызыл миләш, балан.
Тәгәш-тәлгәш «утлар» белән
Гөлт итеп тора алан.

Көзнең сары сагышыннан
Алар күңелне саклар,—
Сөеп-сөелгән язлардан,
Әйтерсең, сәлам-хатлар.

---

[1] Рифат **ЖАМАЛ** (Корбанов) — *1951 елда Арча районының Мирҗәм авылында туган. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе профессоры. Шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә.*

Ерактан чакыра алар:
«Алчы,— дигәндәй,— алчы!»
Тик көзнең бу матурлыгы —
Татып карасаң, ачы!

* * *

Кемдер сөйли, кемдер хурлый:
«Ул — Алласыз!»
Дөрес түгел! Табынганым —
Бер Алма-кыз.

Мин инанам. Тик укымыйм
Намаз гына.
Бөтен җанны биләп алган
Гел наз гына —
Иреннәрем тибрәнү дә
«Гөлназ!» — була...

### Сүнгән йолдыз...

Синең белән минем ара якын,
Тик күңелең миннән еракта.
Ул күңелгә барып җитеп булмас,
Бу дөньяны урап-урап та.

«Сөю» дигән хисне минем яшьтә
Ходай бирми һәрбер адәмгә.
Газабын да, бәхетен дә бирмим
Башкаларга аны әрәмгә.

Йөрәк тынды, тынычланды күңел,
Төшләремә инде кермисең...
Синең күктә ялгыз йолдыз сүнде,—
Ә син шуны һаман күрмисең!

* * *

Көздә күрдем сине, тирә-ягым
Чәчәкләргә кинәт күмелде!
Бар дөньяга яз килгәндәй булды —
Син биләдең минем күңелне.

Кышларны мин синең белән уздым,
Тоймадым да карлар яуганын.
Син янымда чакта сизми идем
Җанга бозлы таулар ауганын.

Язлар килде... Синең күңел генә
Көзләр сыман салкын, битараф.

Җаным өши минем шул суыктан,
Алда — нинди фасыл, ни тараф?!

## Дүртъюллыклар

* * *

И Ходаем, мәрхәмәтең белән
Мәхрүм итмә мине бәхеттән,
Гөнаһларым күп булса да, кума
Шул «МӘХӘББӘТ» дигән тәхеттән!

* * *

Сөямен, көямен, янамын,
Ыргылам, егылам, каламын...
Көләсең, китәсең, сөймисең...
Минеке буласың — сизмисең!

* * *

Күктә оча акчарлаклар,
Суда йөзә ак чабаклар...
Сезләр — гөлдә, безләр — утта,
Сүндерергә юк болыт та!

* * *

Бер рәсемне ерттым урталай:
Ул сурәттә — Кояш белән Ай...
Яши алмый алар гел бергә —
Көн белән Төн аерым гомергә!

* * *

Елый белмим. «Ела, җиңеләер!» —
Диеп киңәш итә кайсылары.
Бәлкем, шигырьләрем — йөрәгемнән
Тамган кайнар яшем тамчылары?!

* * *

*«Бәхетнең тәхете юк, имеш».*
Равил Фәйзуллин

Бәхетлеләр шалашта да
Тоя үзен тәхеттә.
Бәхетсезләр тәхеттә дә
Тоя үзен ләхеттә.

* * *

«Энем!» — диеп дәшкәннәргә
Үпкәли идем элек.

«Абый!» — дигәч, сискәндем мин —
Картайганымны белеп.

* * *

«Яшь мәхәббәт келәт вата!» — диләр.
Карт мәхәббәт вата пулатны.
Ә мин кем соң? Яшьме, әллә картмы —
Мәхәббәтем нинди, ничаклы?!

* * *

Карлар эри. Синең эзләр анда
Карлар белән бергә югала...
Җанда кала сиңа булган хисләр.
Тик аларын, Тәңрем... юк, алма!

## ИГЪТИБАР!

### Алдан хәбәр итәбез

ГКЧП вакыйгалары...

Рәсәйнең ул чактагы Югары Советындагы киеренке хәлләр...

Һәм, ниһаять, 1993 елның 3—5 октябрь көннәре: Мәскәү урамнарындагы митинглар, милиция һәм ОМОНчыларның халыкны рәхимсез кыйнавы, президент Ельцинның Ак йортны, андагы депутатларны танк һәм туплардан аттыруы...

Әлеге канлы вакыйгалар хакында без инде телевизордан карап, газеталар укып үз вакытында байтак мәгълүматлар алган идек. Әмма шушы хәлләрнең шаһите — ул чакларда Рәсәйнең халык депутаты, РФ Югары Советы Президиумы әгъзасы, язучы Ринат Мөхәммәдиев язмалары кайнарлык һәм дөреслек җәһәтеннән аерым игътибарга лаек.

Алдагы саннарда Сезне, хөрмәтле укучыларыбыз, Р. Мөхәммәдиевнең «Утлы таба өстендә» дигән гыйбрәтле әсәре белән очрашу көтә!

**P. S. Кадерле укучыларыбыз! Исегезгә төшерәбез: икенче ярты еллыкка журналга язылу дәвам итә.**

**Ярты елга язылу бәясе чагыштырмача арзан: нибары 13 мең 200 сум.**

## Сәбахетдин Кодрәт Аксал

# КИЧКЕ ЭҢГЕР

ХИКӘЯ

**Шагыйрь, хикәяче, драматург һәм театр белгече Сәбахетдин Кодрәт Аксал 1920 елны Истанбулда туган. Шундагы университетның фәлсәфә факультетын тәмамлаганнан соң, муниципалитетта һәм хезмәт министрлыгында эшләп ала. Консерваториянең, аннары Истанбул театрының директоры булып тора.**

**1953 елны беренче хикәяләре дөнья күрә. Шуннан инде язучы буларак таныла: бере арты бере шигырь һәм хикәя җыентыклары чыга, сәхнә әсәрләре һәм тәнкыйть мәкаләләре язып, театр дөньясында активлашып китә.**

**Әдипнең «Газлы агач» дигән хикәяләр җыентыгы 1955 елны Сәет Фаик исемендәге бүләккә, «Җәрәхәтле җанвар» китабы 1956 елны төрек телчеләре җәмгыяте бүләгенә лаек була.**

Тауга үрмәләгән тыкрыкның яртысына җиткәч, Рәфикъ бәй ял итәргә туктады. Эштән кайтышлый ул һәркөн шунда туктап, бераз хәл җыеп ала торган иде. Тыкрыкның кыл уртасында — тузанлы тәрәзәләрен юлга төбәгән азык-төлек кибете. Аның каршысында янгын ялап алган, шәп-шәрә калдырган бушлык, аннан ары — диңгез. Әнә ул зәңгәрләнеп җәйрәп ята.

Азык-төлек кибетен узгач, тыкрык сулга борыла, шуннан инде Рәфикъ бәйнең өе дә күренә. Үз өен күргәч, җанына рәхәт булып китә, аяк атлаулары җиңеләя. Бу вакытта инде өйләренә кереп, ачык тәрәзә каршына йомшак мендәрләргә җайлап кына утырырга өлгергән мөхтәрәм күршеләренә, вак-төяк кибет тотучы агай-энегә сәлам бирә-бирә атлый торгач, Рәфикъ бәй кайтып җиткәнен дә сизми кала торган иде.

Ул буяусыз-нисез ян капканы төртеп ачты да бәләкәй генә ихатасына килеп керде. Аның аяк атлавына кадәр күнегеп беткән карчыгы каршы чыкты. Гадәтенчә, иренең кулыннан портфелен, башыннан эшләпәсен алды да:

— Исән-имин генә йөредеңме? Нинди яңалыклар бар? — диде.

Мондый сорауга Рәфикъ бәй дә һәрвакыттагыча:

— Ярый шикелле, Назимә. Урамда яман кыздыра,— дип җавап кайтара торган иде.

Бүген дә телендә шул ук сүзләр булды. Хәер, аның һава торышына кагылышлы билгеләмәсе елның фасылына карап үзгәрә: җәй көне — «эссе» булса, кыш көне — «суык». Җылымса көзге көннәрдә исә җилгә нисбәтле сүзләр әйтелә иде. Гәрчә Назимә ханым көннең нинди икәнен үзе үк тышка чыгып белә алса да, Рәфикъ бәй гадәтен үзгәртми, һаман шуны тукый иде.

Баскычтан югарыгы катка менделәр. Нишләптер бүген Рәфикъ бәйнең бер дә тавыш-тыны чыкмый әле. Бүтән көннәрдә дә гөрләп сөйләшә торган зат түгел анысы, өйдәгеләрнең бәхәсләшкәнен, шаян сүзләрен тыңлап кына утыручан. Мәгәр бүген бөтенләй ләм-мим дәшмәве карчыгын сагайта калды.

— Ни булды үзеңә? Әллә чирләп-нитеп киттеме? — диде ул.

— Юк ла инде... Син миңа кофе әзерләсәң иде.

Бүлмәдә ялгызы калгач, Рәфикъ бәй җиңел сулап куйды, аннары ишек янына килде. Ишекне биклисе дә, һичкемне кертмичә, ялгыз башың тәрәзә буенда яшьлегеңнән алып бүгенге көнгәчә башыннан үткәннәрне хәтереңә төшереп утырасы иде...

Ишектәге ачкычны борды да, өстеннән пинжәген салып куйды, муенындагы галстугын бераз бушата төшеп, тәрәзә янындагы кәнәфигә җайлап кына барып утырды. Тәрәзәдән әлеге дә баягы тыкрык уртасындагы бушлык күренә, бераз арырак диңгез җәйрәп ята. Ерактан өстендәге кораблар да акварель буяу белән ясаган рәсемдәге шикелле, хәрәкәтсез булып күренә иде. Мәгәр бүген Рәфикъ бәй үз уйларына чумган, күзенә диңгез күренми! Колагы чыңлый, күз алдыннан бере арты бере төрле күренешләр узып тора. Әнә ярәшкән кызы... Назимә ханым аның күз алдына шул чактагыча сылу гәүдәле, нәфис кенә бер кыз бала кыяфәтендә килеп баса. Үзгәрсә дә үзгәрер икән кеше дигәнең! Ул чәче, ул кулы... Моннан утыз дүрт ел элек, Рәфикъ бәй аны күрергә дип килгәндә, кыз бала бер почмакта үкси-үкси елап утыра иде. Елаудан күзләре шешенеп беткән иде. Ә бит иртәгә туй дигән көнне дә балавыз сыкмаса, күршекүлән ни әйтер? Елаудан туктатмакчы булып, Рәфикъ бәй ниләр генә әйтеп карамады кәләшенә! Сүзнең шифасы тимәгәнне абайлагач исә, кәләшенең кулын учларына алды егет. Назимәнең куллары хәзерге шикелле тупасланып, яргаланып бетмәгән иде, үзе ап-ак, үзе нәп-нәфис иде...

Хәер, ул чагында егете дә егет иде шул: буй-буй кара чалбар, күтәрмә якалы ак күлмәк. Менә ул эштән соң сөеклесен күрергә ашкына.... Менә аның Назимәсе ояла-ояла гына озакламый ишәяселәрен хәбәр итә. Шуны ишеткәч, Рәфикъ бәйнең сөенгәннәре, ул сөенгәннәре! Беренче бала булып кызлары Мөкаддәс туды. Өйләре шаулап-гөрләп тора башлады. Кем уйлаган шул шаян сабыйларының гомеркәе ике елдан да ким булыр дип? Дөнья шул бу, дөнья... Кызлары вафатыннан соң өч ел буена балалары булмый торды. Аннары кызлары Нуртән дөньяга килде. Янә биш елдан соң уллары Йылмаз туды. Бәхете белән туды шул малай: аңа бер атна тулган көнне Рәфикъ бәйне эшендә бер басмага югарырак күтәрделәр. Ул көннәрдә сәрви агачлары шау чәчәктә утыра, гүя агачлар да, аның шикелле үк, шатлык-куанычларыннан исерешеп, хуш ис бөркиләр иде. Күк йөзендәге болытлар да бөдрә-бөдрә булып, катламланып күренәләр. Балык базарына камбала китергәннәр, шуны бушатып яталар иде. Рәфикъ бәй шунда, шайтан коткысына бирелеп, базардагы шәраб кибетенә керде дә ике-өч касә эчеп чыкты. Аннары канатланып өенә очты. Кызык инде: аның бит урамдагы барча шау-шуны да, агачлар бөркегән хуш исләрне дә, агачларның үзләрен дә тамырлары белән йолкып, өенә алып кайтасы килде. Ян капканы тибеп кенә ачты — бичара капка, коймага бәрелгәч, ыңгырашып куйды. Баскычтан Рәфикъ бәй сикерә-сикерә менде. Хәтта әле Назимә ханымның бу хәлне бик үк өнәп бетермәвенә дә һич илтифат итмәде...

Ел арты ел уза торды. Нуртән мәктәпкә йөри башлады, Йылмаз исә тәпи басарга азапланды. Аннары улы да мәктәпкә керде. Аның беренчедә укыган чагында ничә каләм башына житкәнен беркем әйтә алмас иде...

Рәфикъ бәй исенә килгәндә, кемдер ишекне дөбердәтә иде. Йөрәге урыныннан кубарга житешеп, ишекне ачарга ыргылды. Чынаяк белән кофе тоткан Назимә ханымның чырае качкан, күзе зур булып ачылган иде. Ул авыр сулап:

— Нишләвең инде бу? — дип, ризасызлыгын белдерде. — Баядан бирле дөбердәтәм ләбаса, ачмыйсың да ачмыйсың. Акылдан яздырасың бугай инде мине...

Рәфикъ бәй дәшмәде. Якында гына кофе тарткан сыман, колагы шаулап тора иде аның. Җитмәсә тагын котлары алынган Назимә ханым нишләп бикләнеп утырганын төпченә бугай бит әле. Ни дип кенә җавап бирсен инде ул хатынына? Теге чакны салып кайтканымны исемә төшереп утырам әле, димәссең бит инде! Берни аңламас, акылга җиңеләя башлаган икән, дип кенә уйлар. Икенче берәүне түгел, үзебезне дә юньләп төшенеп җитә алмыйбыз бит әле. Ә инде бүтән кешенең күңелендә ниләр актарылганын аңлау һич мөмкин булмастай хәл ләбаса.

Карчыгы кулыннан чынаяк белән кофены алып, яңадан урынына барып утырды. Назимә ханым аның каршысына урнашты да, әлеге сәерлегенең серенә төшенергә өметләнеп, иренә төбәлде. Кофены бер-ике уртлагач та, ирнең кәефе әйбәтләнә төште. Каршысында япь-яшь кәләше түгел, бәлки олы яшьләрдәге ханым, аның карчыгы утырганны абайлагач, сәрви агачларының хуш исләре дә шундук таралды. Кофены тагын берәр уртлаганнан соң, йөрәге дә үз урынына утырган сыман тоелды. Сигарет кабызып, ныгытып төтен суырды да:

— Нуртән кайтмадымы әле? — дип сорар булды.

— Кайтмады шул әле. Тегүче янына киткән иде, аннары ахирәтен күрәсе бар икән, инде вакыты-мазар калган тәкъдирдә, теш врачына да сугылмакчы иде.

— Биләмдә йөрергә остарып китте бугай бу араларда. Әллә ничә көн буена... Әле тегүче, әле табибә, әле ахирәтләр, дигән булып...

— Тикмәгә бәйләнмәсәң иде ичмасам. Болай да таң тишегеннән машинкасы янында утыра. Бераз гына булса да кеше арасына чыгарга ярыйдыр лабаса инде. Болай да сабырлык бирсен ходай үзенә.

— Машинкага мин бәйләп куймадым бит аны. Ярар ла! Йылмаз кайда йөри?

— Клубына чакырып алдылар. Иртәгә ярышлары буласы, диме...

Иренә ни-нәрсә булганын ачыклый алмыйча, Назимә ханым урыныннан купты да кичкелеккә аш-су хәстәрен күрергә дип, кухняга төшеп китте. «Бигрәк картайды шул. Нишләгәнен дә белеп бетерми ләбаса. Эштән арып-талып кайткан, җитмәсә көне яман эссе. Бикләнгән дә ачмый гына бит, ишеген җимереп керерлек булдым. Ачканнан соң, берни булмагандай, балаларны сораштыра тагы...»

Ул арада Рәфикъ бәйнең уйлары да, ярларыннан чыккан диңгездәй, рәхим-шәфкать күрсәтмичә, өстенә ябырылды.

Аскы каттагы кухнядан көек исләре күтәрелде. Карчыгы баклажан кыздыра булыр. Диңгез өстендә күк йөзе карасулана башлады. Кәкре-бөкре тыкрыкта утырган агач йортлар эңгер эченә тәмам сеңеп бетте. Еракта берән-сәрән ут алганнары күзгә чалынды. Биш-ун минут узуга, караңгылык отыры куерды, берни күреп булмый башлады. Юл уңаенда көндезге буяуларны берәм-берәм йота-йота, шәһәр өстенә берзаман төн үзенең канатын җәйде. Эсседә әлсерәгән ирләр һәм хатыннарның эштән кайтканы күренде. Тәрәзә каршында утыручы Рәфикъ бәйгә алар елмаеп сәлам биреп уздылар. Әмма аның күзенә берәү дә күренмәде. Аның күз алдыннан үткәндәге хәлләр, төрле түрәләр, бергә эшләгән иптәшләре, кафедагы әшнәләре, туган-тумачалары, газетада портретлары басылып чыккан мәшһүр кордашлары-замандашлары, трамвай һәм автобус кондукторлары берәм-берәм уза торды.

Менә Кечексуга[1] барганнары хәтеренә төште. Күпер янында алар шыгрым тулы пароходка утырдылар. Буш урыннар булмагач, ашамлык салган пакетлар күтәргән килеш, аяк өсте барырга туры килде. Пароход

[1] Кечексу — Босфорның Азиягә кергән ярында ямьле бер болын. Истанбул халкы шунда чыгып, ял итәргә ярата.

Кечексуга житеп туктагач, пассажирлар тизрәк чыгу ягын карадылар. Хатыны белән күңелле генә сөйләшә-сөйләшә, ул да басмалар буйлап жиргә төште. Күксу инеше буендагы чирәмлеккә урнаштылар. Паласлар җәеп, кофе пешерделәр. Ул чагында Нуртән ундүрттә, Йылмаз тугызда иде бугай. Балалар шунда яр буенда бизәкле ташлар җыеп йөрделәр. Сәгать унбердә җыйнаулашып өйдән күтәреп килгән ризыкка ябырылдылар. Янә кофе эчтеләр. Аннары ул баш астына пинжәген бөкләп салды да бераз черем итеп алырга дип ятты. Шунда күргән сәер төшне һич онытасылары юк. Әйтерең бармы, гаиләсе тулаем үз янында булып, ял итеп ятканда — үзе белән бергә эшләүче, кәнсәләрдә кара-каршы өстәл янында утыручы Хандан килде дә керде төшенә. Исенә төшсә, әле дә оятыннан кая барырын белми...

Имештер, алар Хандан белән икәүдән-икәү генә яр буенда йөриләр; имештер, көймәгә утыралар. Ханданга тикмәгә генә чибәр дип сокланмыйлар икән: ул коңгырт чәче, ул нечкә биле дисеңме! Назлы сүзләр пышылдап, моңа сарыла ук башламасынмы!..

Шундый төш күрүдән кәефе кырылып, шактый вакыт тынычлана алмый азапланды. Хатыны китергән кофе да, кызының мәктәптә өйрәнгән җырларны шыңшып-җырлап йөрүе дә, улының үбүе дә кәефен элеккеге хәленә кайтара алмады. Алай гынамы соң — гаиләсендә хөкем сөргән ваемсыз канатлану хәтта әле отыры гайрәтен чигерде. Нишләп әле исәнме-саумыдан ары узмаган, атналар буена ләм-мим сүз катмаган хатын төшенә килеп керә? Сөйләшер сүзләре булса икән, ичмасам! Әнә шул асыл зат аның төшенә килеп керә, көймәгә утырып йөри, шашындыра, ә монда — хатыны, ике баласы... Ахырдан да моның сәбәбен ачыклау нияте белән уйлангалады: мәгънәсез төш күрүдән кәефе кырылдымы, әллә иртәрәк уянып китүенә ачуы килдеме, әллә инде Хандан белән хозурланып йөрүләре төшендә генә булганлыктан гайрәте чиктеме?..

Назимә ханым кереп, аны ашарга чакырды. Рәфикъ бәй, гүя әле генә уянып киткәндәй, тәрәзәгә күз салды: тышта утлар яна, бүлмәдә кап-караңгы иде. Төн житкәнне абайламыйчарак калган икән ләбаса.

— Балалар кайттылармы соң? — дип кызыксынып алды ул.

— Әллә кайчан кайттылар инде. Сине көтеп утыралар, табын янында.

— Вакыт күпме соң?

— Тугыз тулып килә инде. Бераз соңгарылды шул бүген.

— Назимә, бер дә ашыйсы килми бит минем.

— Син мине хафага саласың болай. Бер-бер хәл булмагандыр бит!

— Хафаланырлык нәрсә юк ла...

Рәфикъ бәй урыныннан купты, хатынына ияреп, аскы катка төште. Нуртән белән Йылмаз табын янында ашап-эчеп утыралар иде. Әти кеше, авызга су кабып торуның килешеп бетмәсен абайлап, Йылмазга сүз кушарга ниятләде:

— Өйгә кайтып та кермисең, — диде.

Йылмаз, кояшта янып тәмам каралган йөзен күтәреп:

— Клубта булдым. Иртәгә матчка сәфәр чыгасы, — дип җавап кайтарды.

— Кая инде ул, сәфәр дигәнең?

— Бурсага.

«Бурсага микән, әллә югыйсә әнкәң сөйләгән теге асыл зат янына микән?» — дигән уй Рәфикъ бәйнең миен көйдереп узды.

Улларының Бурса ягына ешлавы Назимәгә дә бик үк ошап бетми булса кирәк.

— Әллә йөрмисеңме, балакаем? — дип куйды әни кеше.

Йылмаз егетлеген күрсәтү нияте белән тавышына гайрәт өстәде:

— Нишләп? Бүтәннәргә барырга яраганны миңа ярамыймыни?

Нуртән дә сүзсез калмады:

— Әни, син кешегә комачау ясамасаң иде. Аны командадан кудыртасың килмидер бит? — дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Йылмазга шул җитә калды:

— Безнең командада һөҗүмчеләр миннән башка да икәү. Минем бармый калуымны гына көтәләр. Тик аларга тәтеми шул минем урын! — диде.

Табын янынннан кузгалгач, Рәфикъ бәй үз бүлмәсенә менеп, тәрәзә каршысындагы кәнәфигә утырды. Кызы аңа кофе китерде. Нуртән чынаякны җайлабрак куйган арада ата кеше аны күзәтеп утырды. Ярыйсы ук чибәр икән ләбаса аның кызы. Ул зифа буй дисеңме, ул зәңгәр күз, житен чәч дисеңме... Көлмәгендәге миләүшә чәчәкләре дә үзенә килешеп тора. Ә бит үзенә егерме сигез тулды, кияүгә чыгарга уенда да юк бугай. Хәер, хафаланырга урын юк. Теге чакны имзасыз хат алгач кына, борчылганы исендә. Нуртән олы яшьтәге, өйләнгән, хәлле генә кеше белән йөри, бай рестораннарда булгалый, сөяркәсе белән машинага утырып, шәһәр читенә чыккалый, диелгән иде ул яман хатта. Баштарак Рәфикъ бәй ул әләкне хатынына белгертмәскә дә уйлаган иде, әмма көннәрдән бер көнне, иртәнге биштә үк йөрәге әрнеп уянып китте дә, карчыгын уятып, чиште дә салды серне. Менә гаҗәп: Назимә ханымның артык исе китмәде. Кызыбызның дошманнары барын белмисеңмени соң? Көнчелек галәмәте, бүтән берни түгел, диде дә яңадан йоклап китте. Карчыгының шул сүзләрен ишеткәч, Рәфикъ бәй дә тынычлана төште...

Менә күрше бүлмәдән джаз музыкасы яңгырап ишетелде.

— Кызыбыз радио тыңлый бугай... — дип үзалдына әйтеп өлгермәде, берүзе сөйләнеп утыруыннан үзе үк көлемсерәп куйды.

Нуртән джаз музыкасын тыңлап утыра. Йылмаз караватында спорт журналларын актарып ята, каршы як капкасына тупны иң оста кертүче — футбол короле булырга хыялланып елмая. Назимә ханым кухняда савыт-саба юа...

Рәфикъ бәй һич кенә дә күңелен бимазалап торган нәрсәдән арына алмый азаплана. Күзе — диңгездә җемелдәгән утларда, ә күңеле — бүген булып узган вакыйгада. Хәлне хәзер үк сөйләп-аңлатып, җанына җиңеллек алсынмы, әллә югыйсә яткач сөйләү иплерәк булырмы? Ничегрәк башлыйсы бит әле аңлатуыңны? Бер дә инде менә кирәкле сүзе табылмый. Назимәгә иртәдән үк башлап ниләр булганын төкми-чәчми сөйләргә дә бирергә — шуннан да яхшысы булмас.

Рәфикъ бәй иртәгесен, гадәтенчә, кәнсәләренә эшкә килгәч, иптәшләренең үзенә җәлләбрәк, ничектер серлерәк карауларын абайлап алды, тик моның нилектән икәнен аңларга башы җитмәде. Өйлә вакытына таба өстенә афәт килүенә төгәен төшенде, мәгәр әлеге афәтнең кай тарафтан ябырылуын гына аныклый алмады. Аннары аны директор чакырттырды. Рәфикъ бәй кабинетка барып кергәч тә, директор аңа утырырга урын күрсәтте. Ә инде хезмәткәр утырмагач, үзе урыныннан торды да көчләп диярлек урындыкка утыртты. Беравык шулай сүзсез генә бер-беренә карашып утырганнан соң, директор калтыраган тавыш белән сүзен башлап җибәрде. Карусыз, намуслы хезмәт күрсәтүе белән олуг хөрмәткә ия булуын телгә алды, хәзер инде лаеклы ялга киткән тәкъдирдә дә, иптәшләре аны беркайчан онытмаячаклар икәнен әйтте...

Әйе, тотарга да шулай һәммәкиен сөйләп бирергә үзенә! Иртән ул аңламыйча аптырап торган кебек, хатыны да баштарак аңламастыр әле. Бигрәк әйбәт. Иренең бүтән эшләмәгәненә әкренләп күнегүе хәерле.

Әллә бөтенләй үк әйтмәскәме? Иртән элеккегечә, өйдән чыгып китәргә дә кибетләрне айкап йөрергә, дус-ишнең хәл-әхвәлен белергә, әңгәмә корып җибәрергә, биек агач ябалдашына сыенган кафега кереп утырырга да аннары кичен өйгә кайтыргамы? Юк, алай килешмәстер... Хатынына гомерендә ялган сөйләмәде. Нишләп хәзер борчак сипсен икән? Барыбер беленә лабаса. Иң дөресе таң атканны көтү булыр мөгаен. Төнлә белән ничек курыкмыйча сөйләмәк кирәк? Иртәгәсен, нурланып кояш чыккач, сөйләве-аңлатуы да ансатрак булыр...

Шундый катгый карарга килгәч, күңеле бераз тынычлана төшә. Колаклары тагын шауларга тотына, үткән-кичергән хәлләр, күргән-белгән кешеләр берәм-берәм күз алдыннан уза. Әле сөенечле,әле көенечле, бер үк вакытта газаплы да, ләззәтле дә хатирәләр өчсыз-кырыйсыз фильмдай агыла да агыла...

Ул кәнәфиеннән купканда, өй эче тынып калган иде инде. Бүлмәләрдә утлар сүнгән. Тәрәзәгә күз салса — анда да ут әсәре күренми. Фәкать диңгездә генә еракларда утлар җемелди иде. Сәгатькә бер карап алды — төнге ике тулып узган. Рәфикъ бәй ишегалдына чыкты. Сызык кына ачык калган ишектән улының тигез сулап йоклаганы ишетелә иде. Бернинди хатын-кызга бәйләнмәгән булырга тиеш, әнкәсе юкка хафалана. Уллары иртәгә Бурсага барыр, анда узасы ярышта катнашыр, каршы як капкасына бер-бер артлы әллә ничә туп кертер. Бүлмә аша Нуртән йоклап ята. Рәфикъ бәй кызының йоклаганын кереп карады. Кызы төшендә күлмәкләр, туфлиләр, хушбуйлар күреп ята булыр. Теге хаттагы яман сүзләр барысы да гайбәт кенә бит. Имзасыз хат җибәрү гадәте — иң зур этлек эшләү, адәм балалары шуннан һич арына алмыйлар лабаса... Рәфикъ бәй шыпырт кына йокы бүлмәсенә узды. Назимә ханым караватның кырыена ук ятып оеган. Хуҗа кеше йокы бүлмәсеннән кире чыгып, өйне янә бер тапкыр урады... Ябылмыйча калган тәрәзәләрне япты, газ плитәсенә килә торган кранны тикшерде, тәмәке савытына җыелган көлне түкте. Аннары озаклап караңгы тәрәзәгә карап торды. Үзалдына: «Димәк, иртәгә әйтәм булып чыга?..» — дип сөйләнде. Хатыны да, балалары да тыныч кына черем итәләр. Ул шыпырт кына аларның һәркайсына күз салды һәм хәвефсез-нисез йөзләрен күреп сөенде. Аннары кабат йокы бүлмәсенә керде дә, пинжәген салып, артсыз урындыкка утырды.

Менә берзаман күңел түреннән илаһи бер җылы дулкын күтәрелә башламасынмы! «Бәхет дигәнебез шул үзедер лабаса инде»,— дигән уй йөгереп узды. Хәзер менә хатыны, кызы, улы тыныч кына йоклап яткан йорт — бу бит инде төн диңгезен гизүче кораб лабаса! Диңгезнең очы да, кырые да күренми. Иртәгәсен, тәүге кояш нурлары уянганда, алар инде һәммәсе дә яңа пристаньгә җиткән булырлар...

Кыям МИҢЛЕБАЕВ *тәрҗемәсе.*

# ӘДӘБИ МИРАС

## Рәшит Әхмәтҗан

### СОҢГЫ ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН

*Бәхет диган бәйрәмнәрне көтәсезме? —*
*Бәхетсезнең күз яшьләрен сөртәсезме?*
*Китkән кеше кире монда кайтмый калса —*
*Аны эзләп эзләреннән үтәрсезме?*

* * *

Тургайларым кайтты менә, тургайларым,—
Боз куйнынна.і куптарганнар яз айларын.
Дөнья шул ук — урталайга бүленмәгән,
Чыннан да, җыр көчле икән үлемнәрдән...

Тукта, Рәшит, әйтер сүзең бүтән иде,
Тел очында тора ул сүз күптән инде:
Җыр — үлемнән көчле, ә без ни эшләрбез? —
Гомерегез узды, диләр, ишетәбез.

Каурый каләмемне һәр көн канга манам
Һәм җыр язам... Кошлар сыман канатланам.
Кан азая — озак яши алырбызмы? —
Бирербез дә җырыбызга җаныбызны,

Кошлар — җиргә, ә без күккә егылырбыз,
Очырырбыз — яши бирсен шул җырыбыз!

* * *

Үзәккә үттең инде, җил,
Үзәккә үттең инде,—
Фәхишә хатын шикелле
Ничә кат үптең инде.

Санадың инде, санадың
Илемдә ниләр барын,—
Яфраклар кебек өзелде
Дусларым, туганнарым.

Күзләргә яшьләр тутырдың,
Елмаер чакта гына,
Аккошларымны качырдың
Кара төн кочагына...

Төн буе кайда йөрисең
Ат караклары белән? —
Син үзең урлашмасаң да,
Булышканыңны беләм.

Үзәккә үттең инде, җил,
Үзәкне өздең инде,—
Чәчәкләрне төймә итеп
Муеныңа тездең инде.

Урадың инде биленә,
Урадың уйларымны,
Нараттай туры ир идем —
Нишләттең буйларымны?!

Йөрәкне чакырасың, җил,
Кайларга чакырасың? —
Ул канлы, яралы килеш
Сәфәргә чыгамы соң!

Юк, аны тота алмыйсың
Куркытып, калтыратып.
Ул әрни... Илдән җибәрми —
Илерә җиргә ятып.

Ияреп китәр идем дә,
Кем икәнеңне беләм,—
Бар, йөреп кайт берәр атна
Ат караклары белән...

* * *

Бар гөлләргә гомер биреп, әллә кайчан
Әйлән-бәйлән уйный-уйный яуды ләйсән.
Җәйләр килде... Сине эзләп йөри-йөри,
Гаҗәпләнмә, диванага мин әйләнсәм.

Җирдән эзлим, күктән эзлим, күптән эзлим,
Шуны белеп әйлән-бәйлән уйный гөлләр.
Көндезләрен ярый ла ул... көлә гөлләр,
Төнлә авыр. Төнлә елый әллә кемнәр?

Ул елаучы ялгыз калган юлаучымы? —
Белсәләр дә беркемгә дә әйтми җилләр.
Яна йөрәк, өзелә лә минем үзәк...
Син кайларда? Җаның бармы? Хәбәр җибәр.

Хәбәр җибәр: көләргәме, еларгамы?
Әллә күзне мәңгелеккә йомаргамы?

## Тауларына менсәң — җил бәрә

Сөйгәнемне төштә күргән идем,
Күргән идем — күреп туймадым.

Эзләп киттем, күзгә күренгәннең
Ераклыгы юк, дип уйладым.

Тауларына менсәң — җилләр бәрә,
Болыннарга төшсәң — сил бәрә.
Югалмасын икән сөйгән ярың,
Эзләп табулары мең бәла.

Күкләренә баксаң — әй, тулган ай,
Тулган айлар монда моңга бай.
Туган илдә йөрмәс иде болай:
Ул сандугач иде, мин — курай.

Болыннарга төшсәң — сил бәрә дә,
Тауларына менсәң — җил бәрә.
Кураемны кулга алыр хәл юк,
Сандугачым сайрап җибәрә.

## Мостай ага Кәримгә хат

Йолдызлардан — йодызларга күчеп,
Киләшкә дә иңгән бер әмер:
«Туфанлы да булгач, шигъриятькә
Мостаен да тудырыйк без хәзер.

Ауган егетләргә алмаш кирәк,
Алдан барыр өчен — байракчы!
Мең ел саклап килгән иманыңны,
Юкса, мордар тартып алмакчы!»

Империя этләренә бирми
Талатырга шушы иманны,—
Шигъриятнең азаматы булып,
Азат яшәттегез Сез аны.

Ә бу илдә һәрбер азаматны,
Адым саен коллык сагалый.
Һәм аннан соң... тарих буйлап сана:
Бер шагыйрьгә — йөзләп Шаһгали!

Ә азатлык әсир Туфанны да
Эзләп тапты әллә кайлардан,—
Башын алып балта асларыннан,
Итек биреп,
Илгә кайтарган.

Сулышыгыз белән җылыткансыз
Себерләрдә туңган Туфанны.
Туфан аша — безне. Әллә Сезнең
Җаныгызда кояш булганмы?

Кеше җанындагы кояшларны
Төннәр буе эзли бозлы Ай...
Дәшә сыман Туфан:

— Безнең дөнья
Җылындымы әле?..
Бер җылынып әле, и Мостай!

Телсез калган безнең сабыйларның
Ачылмадымәле телләре? —
Ак атыңда Казан якларыннан
Хәлләрен бер белеп кил әле!

Телгә, денгә кайтам, диючеләр
Илгә таба барыбер юл таба.
Шигъриятнең шәригатен тәгәл
Үтәсеннәр — булыш, Мостафа!»

...Истә, аны төнлә каршыларга
Казаннарга килгән чагыгыз.
Уяткансыз:
— Туфаныгыз кайта,
Исән кайта! Каршы алыгыз!

Уянган тик җиде-сигез татар,
Уйлангандыр уны-унбише...
«Күпме генә сиңа дан җырлама,
Барыбер дә куркак син, кеше!» —

Беркемгә дә түгел, мин үземнең
Татарыма әйтәм бу сүзне.
Ярты халкы телсез,
Ярты халкы
Сукырайганга сүгә ник Сезне?!

Шагыйрьләрне Себерләргә сөреп
Туймаганмы әллә бу Казан?!
Шигъриятнең шәригатен үтәп,
Менә бүген Сезгә хат язам.

Безнекеләр сезне гаепли дә,
Сезнекеләр безне гаепли:
Сезнең гамәлләрдә гаеп ни дә,
Безнең гамәлләрдә гаеп ни?

Туганнарча киңәшләшер өчен,
Туфан туган илгә килегез.
Сез элек тә аның түрендәге
Иң кадерле татар идегез...

Туфаннандыр әле, Туфаннандыр...
Күктән җанга иңде бер әмер:
— Бер-беребезне саклар, яклар өчен,
Алмаз кылыч булыйк без хәзер!

## Һай!

Кеше генә булу, һай, авыр шул —
Төн буена күзем йоммадым.

Өшеп йомарландым һәм урадым
Кайгылардан Кайгы йомгагын.

Тәгәрәде китте кара йомгак,
Ә эчендә мин дә тәгәрим.
Бер сүтелеп бетәр. Ни булганын
Бер сөйләрмен әле сезгә мин.

Һаваларда очкан бөркет кенә
Белсә белер кая киткәнне.
Иткәнменме? Аннан нинди давыл
Өзгәләгән минем җилкәнне?

Башкаларын Ходай язмаган шул,
Кеше генә булу, һай, авыр.—
Таулар җимерелсә — ташлар баса,
Һәм башыңа җитә бер давыл.

Дошман басып алса — дарга аса,
Ярың яратмаса — янасың,
Кара күмерләргә каласың да,
Кабат туып кара аннан соң!

Һай, шуларны кат-кат уйлый-уйлый,
Төн буена күзем йоммадым.
Дардан төшкәч, кабат тудым да мин —
Сүтәм менә кайгы йомгагын...

## Арыслан

*Үләр алдыннан, иртәгә шифаханәгә керәсе көнне «Карурман» җырын җырлады да елады, җырлады да елады...*

К. Т. Арсланова сөйләгәннәрдән

Гомер буена да «Карурман», әй,
Үләр алдыннан да «Карурман»,—
Күпләр әле саташып та ята,
Ярый шундый җыры табылган.

Урманнарга киттем синең эздән:
Әйтер сүзе юкмы гөлләрнең?
Сагыш ае монда,
мин сагышның
Нәкъ күзенә килеп кергәнмен.

Үрли сагыш сары елан сыман,
Имәннәргә үрли... Каенның
Һәр яфрагы саен ялтырый моң —
Яктысы шул сагыш аеның.

Сагыш яктысына ияреп мин,
Уртасына кердем урманның.
Карурманнар арысланнар өчен,
Ничек моннан кабат чыгармын?

Карурманда,
Сагыш яктысында
Шигырь сөйли безгә Арыслан!—
Кысан притон — кәрләләргә калган,
Кала — җырны малга алышсаң.

Димәк, җаны карурманда яши,
Каберләргә сыймый андыйлар.
Андыйларны исән чакларында
Баһадиршаһ итеп сайлыйлар.

Ул гамәлне башкаралмый калдык,
Денсез калган заман дәшмәде.
Ә татарның теле, карак сыман,
Карурманда качып яшәде.

Телсез калган Казан гөрләп яши.
Тәһарәтсез, мәнсез бәндәләр —
Сәхнәләрдә — патша саулыгына
Һаман әле азан әйтәләр...

Кабер — бишек. Бишек җыры итеп,
«Карурман»ны җырлый карурман.
Шагыйрьләргә бәхет табылганмы?—
Моңнарымнан учак кабынган.

Карурмандай кара чор булган да,
Шул кара чор — үлмәс җыр булган.
Тып-тын тора синең гүрне саклап,
Изге Туфан куйган чардуган.

Шаулый урман — горур җаннар иле,
Һәр имәне — шигъри бер мөнбәр.
Һай, урманга бер арыслан җитми,
Кермәс иде минем кебекләр...

* * *

Дүрт йөз елга чигенәм дә йөрим һаман да,
Күккә хәтле күтәрелеп янган Казанда.

Кабан күле — казан. Инде казан кайнаган,
Халык канга баткан, әле хәлдән таймаган.

Кыргый урда белән әле Казан көрәшә —
Ата-ана, улы-кызы баскан янәшә.

Казанның күге җирдәге каннан кызара,
Әүлияләр сөйләшәләр күктә узара:

— Күр, Казанны каплап алган кафер башлары,—
Тауларыннан нигә яумый икән ташлары?

Күгеннән ник каргыш яумый — нәҗес, яманга,
Карлыгачлар һәм тургайлар каргамаганга!

Имән урманы: Авам! Дип шауламаганга,
Таудагы кылганнар дөрләп яналмаганга.

Дошман басуга — таулары ярылмаганга,
Һәрбер түмгәгенә дошман абынмаганга...

Чокырларың дошманнарны нигә йотмады,
Яна дөрләп, яна көйрәп Казан йортлары.

Җайдагыннан инде күпме атлар ычкынган,
Янган утта кешни-кешни алар кычкырган.

Идел нигә сыңар тамчы каның тамуга —
Әйләнмәде дошман өчен кара агуга?!

Каеннарың ник дошманга каралмадылар,
Карагайлар сөңге булып кадалмадылар?

Аең нигә аермады берсеннән-берсен,
Ник кояшың баемады — адашып үлсен!..

Кайттым, кайттым канга батып бүгенге көнгә,
Мең кабат артып нәфрәтем җирдә үлемгә.

Кемнәрдә гаеп әле соң, кемнәрдә гаеп?—
Соңгы агачың утыра кочагын җәеп.

Кочагында исән калган соңгы умарта.
Кортлары бер очып китә, әйләнеп кайта.

Татарның иле шул инде — дошманнан калган,
Могҗизалар белән аны Алла коткарган.

Кагыла күрмә син аңа, үрчеп яңарсын,
Кагыла күрмә син аңа — үлем табарсың.

Балы гына түгел аның — агуы да бар,
Гасырлар буе җыелган... Кагылма. Чыгар!

* * *

Дуслык дигән бәхет тә бар — дуслашыгыз,
Уртагызда яшәмәсен дошманыгыз.
Уртада — җан. Җанда — телең, туган илең.
Җанны яклап янган утка ташланыгыз.

* * *

И пәйгамбәр шагыйрь, кичер Илне —
Хәбәр килде менә әле генә:
Соңгы китабыңның әҗеренә
Таш та куеп булмый кабереңә...

## ПУБЛИЦИСТИКА



**Батулла**

# АМЕРИКАНЫ МИН АЧТЫМ

СӘЯХӘТНАМӘ

«Америка, Әмеркә, Әмрик» сүзләрен мин иң башта биш яшемдә, 1943 елда ишеттем. Икенче Дөнья сугышы вакытында авылларда «Әмеркә паюгы, Әмрик күчтәнәче» тараталар иде: консервалар, киемнәр, уенчыклар. Ул әйберләрнең матурлыгы, ул консерва калаеның гүзәллеге сабыйларның гына түгел, олыларның да ушын ала иде. Америка — ул сыйфат билгесе, Америка — ул ятимнәр вә мохтаҗларга ярдәм итүче гадел ил икән, дигән уй һәр кеше зиһененә кергән иде.

Сугыш бетте. Әмерикә паюклары килми башлады; шуннан соң озак та узмастан, Америкага карата булган хөрмәт вә сокландуларны үҗәт рәвештә кырып-себереп чыгарырга тотындылар. Америка — ул гаделсез, капиталистик ил икән. Америка иң гадел ил — Советлар Берлегенә һөҗүм әзерли икән. Мәктәптә, дәресханәләрдә дисеңме, ул гәзитләрдә, «Чаян»ында дисеңме, Сэм агайны, Труменны, Эйзенхауэрны — җөмләсен эттән алып, эткә салып мыскыллау, сүгү сабыйларны аптырашта калдырды. Советлар яклы булып, Һитлерга каршы сугышкан Америка агайлары, күчтәнәчләре белән без сабыйларны куандырган миһербан иляләре әнә нинди юха еланнар икән ләбаса.

Совет идеологиясенең кавузыннан шундый юынтык су агып торса, икенче яктан Америка язучыларына тирән мәхәббәт әкренләп күңелләргә керә, чыкмаска керә торды.

Марк Твен, Генри Лонгфелло, Гарриет Бичер-Стоу, Фенимор Купер, Эдгар По, Теодор Драйзер, О. Генри, Джек Лондон, соңра Эрнст Хемингуэй, Артур Миллер, Эрскин Колдуэлл, Уильям Фолкнер һәм башка әдипләр, драматурглар Американы коммунистлар агызган нәҗес астыннан тартып чыгара тордылар. Алар иҗат иткән китаплардагы чын Американы без әнә шулай өйрәнә тордык.

Шулай итеп, сабый-үсмер татар баласы алдында Американың өч сурәте калыкты. Сыйфатлы, гүзәл мал житештерүче, ярдәмчел ил; комсыз эксплуататор һәм көне-төне СССРны яулап, бәхетле рәвештә яшәп ятучы совет халыкларын кол итеп, тагын да баерга маташучы агрессор-илбасар АКШ; һәм кантарлы әдәбият, техника барлыкка китерүче әдипләр, фикер иляләренең ватаны.

Икенчесе, СССР җимерелгәнче үк мин — сабый зиһенендә ишелеп төште, күңелдә могҗизалар иле, демократия учагы — бөек Америка торып калды.

Шулай да Американы, гомумән, капитал илләрен идеаллаштырудан мин һәрвакыт ерактарак була килдем. Тора-бара бу илнең, бу системаның да күңел кайтаргыч яклары аз түгеллеге ачыклана башлады. Һәм, әйтергә кирәк, Америкага булган сәфәрем, мин белгәннәргә, мин күз алдына китергәннәргә яңалык өстәмәде. Америкадан әйләнеп кайткач, таныш-белешләремнең:

— Йә, ничек соң Америка? Шәпме? — дигән сорауларына каршы мин юньлебашлы һични әйтәлмәдем.

— Америкада американнарча яшиләр! — дидем.

Аннан соң Американың ни бары бер шәһәрендә — Нью-Йоркта, нибары бер атна торып кына бу ил, аның катлаулы мәсьәләләре турында фәлсәфә куерту көчемнән килмәс. Американы күреп кайткач, Маяковский әйткәндәй, «Юлъязмаларымның максаты — ерак киләчәктә булачак сугыш-көрәшләрне көнелем сизенгәнгә, Американың зәгыйфь һәм көчле якларын өйрәнү-сөйләү» булмас. Бәс, сәфәремә кагылышлы кайбер өске тәэсирләрем белән генә уртаклашырмын.

Алдан ук әйтәп куямын: фәкыйрегез Америкага мие томаланган гашыйк түгел. Американы эттән алып эткә салып сүгә дә алмыймын. Мин: «Америка нәкъ америкача яши торган ил», — димен.

Нәрсә соң ул «Америкача яшәү»?

Күргәзмә: 1972 елда Америкадан Казанга техника әсбаплары күргәзмәсе килде. Күргәзмә олы стадионда урнашкан иде. Машиналар, авыл хуҗалыгында кулланыла торган техника, галәмгә җибәрелә торган иярченнәрнең үрнәкләре, станоклар, аш-су әзерләү өчен электрик савыт-саба, бушка өләшенә торган яхшы журналлар халыкны стадионга агылып килергә мәҗбүр итте. Күргәзмәдәге әсбапларга аңлатма бирүчеләр арасында Америкада яшәүче татар кызлары да бар икән, дигән хәбәр татарларны аеруча җәлеп итте. Кызлардан башка күргәзмә әһелләре белән бергә Америкада яшәүче Рокыя исемле бер ханымның килүе, аның фотоаппарат белән Казанның җимерегрәк урыннарын төшереп йөргәне турында да сүз таралды. Имеш, бу ханым ЦРУ җасусы икән дә, имеш, ул Советлар Татарстанының килешмәгән-җитешмәгән якларын гына төшереп алырга килгән.

Рокыя ханымны Илһам Шакир кунакка алдырды. Мәҗлес Татар ашлары йортында (ТАЙ) узды. Америка ягыннан Рокыя ханым, бер татар кызы белән бер җегет килгән иде. Чем-кара чәчле, каратут йөзле бу мәһабәт кунак җегетен Италиядән чыгышлы америкалы, диделәр. Сәер җегет иде ул: бер авыз татарча да, урысча да белми. Мин исә бер авыз сүз итальянча да, инглизчә дә белмим. Безнең «сөйләшү» бары тик елмаю вә күпләп аракы эчүдән гыйбарәт иде. Шулай «сөйләшә» торгач, Жозеф исемле бу җегетнең төягән йөге кыйгаеп, укшый башлагач, мин аны бәдрәфкә алып киттем. Ул шуннан кире чыгар дәрәҗәдә түгел иде инде. Соңыннан шагыйрь Зөлфәт минем турында:

— Батулла шул капиталист-буржуй малаен исерткәнче эчертергә КГБдан махсус йөкләмә алган икән, — дип шаяртып та йөрде.

Татар әдәбияты-сәнгате ягыннан бу табын янында Әлфия ханым Афзалова, Мөнирә ханым Булатова, оркестр җегетләре, берничә язучы-журналист — бөтенесе егерме бишләп кеше иде. Шулар арасында мин дә бар. Мине кунакка чакырган чакта Илһам:

— КГБ сине американнар белән очраштырырга теләми. Әллә ничә тапкыр КГБга барып, көчкә рөхсәт алдым, — диде.

Бу: син чит ил кешеләре алдында авызыңны чамалап ач, сәяси хата җибәрә күрмә, дигән сүз иде.

Чөнки Илһам бик яхшы белә: мине Чирек күлгә сорау алырга йөртәләр иде, хәтта өемдә тентүләп тә алганнар иде; советларга каршы яшерен әсәр эзләүләре. Ул чакта мине «идеологик диверсант» диеп, «антисоветик әсәрләрем», ярамаган сүзләрем өчен КГБ майоры Виктор Морозов хөкемгә тарттырырга кәгазьләр әзерләп йөри иде. Америка татарлары янында миңа йә дәшмичә генә утырырга, йәисә «антисоветчы түгел»легемне исбат итәргә кирәк иде.

Тәти булырга сүз биреп, мәҗлескә киттем. Табын мул, аракы — муеннан, һәр авызга бер литр «Посольский». Җырлашып, ашап-эчеп, сөйләшеп утырасы урында ике як та бер-беренә карашып, уңайсыз елмая, мәҗлес гөрләп китә алмый. Чөнки һәр сөйләнгән сүз яшерен рәвештә язылып бара булыр. Язылмаса да, монда ни әйтелгәне бәйнә-бәйнә Кул буена җиткереләчәк. Мин сөйли башласам, янымда утырганнар аякка баса, калыксам, итәктән тарта.

Рокыя ханым хуҗалардан җанлырак булып чыкты, ул сөйли, сораштыра. Ләкин ике сүзнең берендә: сез татарлар, монда ярлы яшисез, без, татарлар, Әмриктә яхшы торабыз, дигән мәгънә чыгара тора. Ара-тирә соңгы мода аппарат белән табындашларын рәсемгә ала. Аппарат әзер рәсемне шундук сыер теледәй чыгарып та бирә. Оркестр малайлары бу эшкә хәйран калып, фотоны кулдан-кулга йөртә, аһ-ух итә: «Вот это техника, а! Во блин, как здорово», диләр. Рокыя ханымга шул гына кирәктер: Америка техникасы белән шаккатыру, ушны алу. Минем ачу килә. Бер җай табып, җегетләргә ысылдадым:

— Сер бирмәгез! Исегез китмәсен! — дидем.

Рокыя ханым моны сиздә бугай, миңа шикчән карап алганнан соң, ул Илһам колагына нидер әйтте. Соңра билгеле булды:

— Бу карасакалыгыз КГБда эшлиме әллә? — диеп сораган икән.

Илһам, гадәтенчә, башын артка ташлап, соңра авызын учы белән каплап, нелеп көлә башлады.

— Бик эшләр иде дә, Батулланы КГБга алмыйлар шул, чөнки аның күкрәгендә сер, авызында сүз тормый! — дигән Илһам.

Бер-ике чәркәдән соң мәҗлес җанланып китте. Сөйләшү башында һаман Рокыя ханым.

— Нью-Йоркта, Уошингтонда татарлар бик бай яши,— дип башлады ул чираттагы сүзен.

Әйтерсең, андагы тормышның нинди икәнен без белмибез. Түзмәдем:

— Рокыя ханым, алай бик бай яшәгәч, сез анда, Уошингтонда йәки Нью-Йоркта татар гәзитәсе чыгарасыздыр, театрларыгыз да бардыр? — дим.

Кунак ханым уңайсызланып кына Америкада татарча гәзитә дә, театрлар да юклыгын әйтте. Мин, калай әтәч, килгән кунакны кыен хәлгә куячагымны белсәм дә, ач кеше алдында тук килеш мактанмасын, дигәндәй:

— Бездә татарча кырык гәзитә чыга, илле театрыбыз бар! — дип әйтеп салам.

Америка ягы авыз ачып кала, хуҗалар ягы каушый, шул чак янәшәмдәге хатын — Кояш Тимбикова уң аягыма тибә. Чөнки Татарстанда өч кенә гәзитә, дүрт кенә татар театры барын тегеләре дә, болары да бик яхшы белә. Өстәл астында аяк көрәше дәвам итсә дә, мин тагын да әтәчләнеберәк:

— Әйе! Кырык гәзитәбез, илле театрыбыз бар! — дип кабатлыйм һәм аптыраулы, гаҗәпләнүле чырайларга болай дип нәгъръә орам: — Дүрт гәзитә Казанда, калган утыз алтысы һәр төбәктә — район гәзитәләре!.. Дүрт театр: Әлмәт, Минзәлә, Кучмә, Камал, калган кырык алтысы — халык театрлары!

Совет ягы иркен сулап, ашарга тотына, Америка ягы: «Кара, без белмәгән идек», дигәндәй, баш селки.

Бу «батырлыгым», ягъни «буржуйларны төп башына утыртканым» өчен күп кеше соңра кулымны кысып котлады.

Мәҗлес дәвам итә. Җырлау, бию, уен, сөйләшү.

— Без,— ди Рокыя ханым,— дөньяда нинди мәшһүр татар бар — бөтенесен дә беләбез, аларны шәрәф дәфтәренә теркибез.

Калай әтәч тагын күкрәк кага:

— Алайса, Рокыя ханым, сезнең исемлектә Әсхәт Җиһаншин да бардыр?

Кунакбикә янә каушый, ике як ватандашына карап ала да:

— Ә, юк, без аны белмибез... Кем соң ул Әсхәт Җиһаншин? — дип сорый.

— Һәлакәткә очрап, кырык тугыз көн океанда ач йөргән совет диңгезчеләренең командиры Әсхәт Җиһаншин. Аларны Америка крейсеры «Силленжир» үз бортына алды, алар сезнең президент белән дә күреште, бу турыда бөтен дөнья гәзитәләре шаулады.

Рокыя ханым тагын кыен хәлдә иде.

Бүген боларның барысы да бала уены кебек көлке күренер, әмма ниндидер күләмдә мин үземне үзем коткарып калдым шикелле, янәсе, мин антисоветчы түгел, имеш, кирәге чыкса, ЦРУ шпиуннарын да кәкре каенга терәтә алам!

Чыннан да, икенче көнне күргәзмәгә килгәч, Рокыя ханым минем белән бик салкын исәнләште, дөресрәге, миннән качып китте.

— Синнән курка ул,— диде Илһам Шакир.— «Теге сакаллы КГБчыгызны күрәсем дә килми», ди.

Дөресе, мин хәтта кыгыбычыларның үзләреннән дә арттырып җибәрдем бугай.

Америкада яшәүче татарлар белән беренче очрашу әнә шулай «курку белән йолку» шартларында узды. Берәннең артында КГБ, икенчеңнең баш очында ЦРУ торганда рәхәтләнеп мәҗлес корып буламыни?

Әмма егерме өч ел узгач, без Рокыя ханым белән Нью-Йоркта, минем пьеса уйналган кичне Поляк клубында тагын очраштык. Сәхнәгә басып татар халкының аяныч язмышы һәм бүгенге Татарстан хәлләре турында сөйләгәннән соң Рокыя ханым үзе минем янга килде. Мин аны чак таныдым, элеккеге дәртле, гайрәт чәчеп күзгә төшкән, хәрәкәтчән ханым урынында тыйнак татар карчыгы басып тора иде. Мин дә теге чактагы кебек кара сакаллы түгел. Исәнләштек. Ләкин беребез дә 1972 елдагы очрашуны искә төшермәдек.

Сукмак башы. 1988 ел. Бу елны Казанга төрле илләрдә яшәүче татар яшьләре килгән иде. Аларның килүе алдан ук билгеле булса да, алар өчен көн

тәртибе тәфсилләп эшләнмәгән иде. Кунаклар Татарстан яшьләре белән иркенләп, якыннан аралаша-таныша алмадылар. Истәлекле бүләкләр алып китә алмадылар. «Чәй йорты»ндагы очрашу кунакларны мыскыл итәр өчен генә оештырылган иде кебек. Урыслашкан татар җегетләре кунакханәгә кереп аракы эчеп чыгалар да татарча җырлаган-биегән булалар, кунаклар аптырап утыра бирә. Моны күреп, Илдар Юзи сүз сөйләми кайтып китте. Рөстәм Мингалим белән икәү калдык. Шул мәҗлестә Америкада яшәүче Илдар Агиш исемле татар җегете белән таныштым. Илдар белән эч серләребезне сөйләргә шүрләп, күзгә күз карашып утырдык. Еллар ачыла төшкәч, Илдар бәй белән дусты Илхан Айдагөл тагын Казанга килде. Бу юлы инде чит ил кешеләрен өйгә кунакка алдыру мөмкин иде. Рәхәтләнеп, иркенләп сөйләшеп, җырлашып утырдык. Аерылышканда мин ике дустымны поездга озата төштем: хушлашканда кочаклаштык. Илдар сабыр, тыныч иде. Илхан мине кочаклап үксеп, ярсып җылый башлады, мин дә тыела алмыйм — җылыйм... Кабат күрешә алмабыз, юллар тагын ябылыр кебек тоелгандыр инде. Гасырлар буе күрешә алмаган бабаларыбызның сагышы, җирсүе булып, безнең күз яшьләре агадыр.

Шуннан соң Илхан да, Илдар да Казанга бик күп тапкырлар килде, хәзер аерылышканда җылашмыйбыз.

Илхан атасын, Ибраһим абзыйны да, хакыйкый ватанына — Мамадышка алып кайтты. Алар үз авылларында үз акчаларына мәчет салдыра. Афәрин! Йөз яшә, Илхан!

Мине Нью-Йоркка чакыручы да шул, Илхан Айдагөл булды.

Илхан «Капитал трэйдиң корпорэйшн» атлы сәүдә фирмасының президенты, аның ярдәмчесе — Илдар Агиш. Шулай итеп, мин Нью-Йоркка җыена башладым.

Виза мәшәкатьләре. Элегрәк чит илгә чыгу гадәттән тыш хәл иде. Хәзер инде күнегеп беттек; кемдер Америкасына да, Испаниясенә дә, Италиясенә дә, Япун-Һиндстанына да барып кайткан, читтә озаклап яшәгән, бәгъзеләре хәтта бөтенләйгә күчеп киткән. Кесәсе калыннар Җир шарының теләсә кайсы диңгезенә барып ял итә, сайфия (дача) сатып ала. Шулар өстенә киносы, телевидениесе, видеосы, китаплары бар: кара, күр, укы, бак. Шул сәбәпле, мин һичбер вакытта да чит илләргә чыгарга омтылмадым; барлы-юклы акчамны путевкалар, круизларга сарыф итмәдем. Җае чыгып, кунакка чакырсалар — барырмын, чакыручы булмаса, калган гомеремне шушында — Татарстанымда гына яшәп бетерермен, дидем. Юраганым юш килде, мине дусларым ике тапкыр Финляндиягә, өч тапкыр Төркиягә һәм, ниһаять, менә Нью-Йоркка да чакырдылар. Аларга олуг рәхмәтләрем!

Әлбәттә һәр сәяхәтемә дә иҗат эшләрем сәбәпче булды.

1995 елда Финляндиядә яшәүче татарларның һәвәскәр театры мин фәкыйрегезнең «Туйлар узгач, туннар тузгач» исемле җырлы-биюле кәмитен сәхнәгә куйган иде. Һельсинки шәһәрендәге Швед театры сәхнәсендә уйналып, ул спектакль уңыш казанган иде. Тамашачылар арасында Америкадан килгән Сәйдә ханым (Илдар Агишнең апасы) да була. Тамашадан бик канәгать булып, ул соңра:

Бу сәхнәне Нью-Йоркта яшәүче татарларга да күрсәтеш кирәк! — диеп сүз кузгата.

Шулай итеп, Һельсинкидәге һәвәскәр татар театры Америкага чакыртыла. Уйнаучылар белән бергә спектакльнең режиссеры Зөһрә Шакирҗан (Камал театры музееның мөдирәсе), пьесаның авторы — мин фәкыйрегез дә чакырулы идек.

Илхан Айдагөл, Нью-Йорк Татар җәмгыяте, аның рәисе Илдар Агиш; Финляндия Ислам җәмгыяте, аның рәисе Окан Даһер; Финляндия төрекләре (татарлары) җәмгыяте, аның рәисе Гөлтән ханым Бәдретдин вә Америкада яшәүче Хаҗил Сәйдә ханымнарның уртак эше иде бу.

Америкага кәтелмәгән юл әнә шуннан башланды.

Әле күптән түгел генә, өч-дүрт ел элек кенә чит илгә чыкканда КГБ чиновниклары куйган мең киртә, йөз чокыр вә энә күзе аша узарга кирәк иде. Шуларны, утны-суны, җиз торбаларны кичкәч кенә син барасы илнең илчелегенә кереп виза ала идең. Чит илчелекләр визаны биш-ун минутта эшләп бирәләр иде.

Гаҗәбемә күрә, хәзер гел киресе икән. Дөнья үзгәргән. Хәзер Русия: бар, чык, йөр, теләсәң, бөтенләйгә кал, дигәндәй синең җиде буын бабаңны да тикшерми, кәгазь артыннан кәгазь дә тутырттырмый; чит илгә чыгасы паспортыңны тотып, барасы илнең илчелегенә юнәләсең. Анда рөхсәт алсаң — китәсең, алмасаң — паспортыңны учлап каласың. Чит илләр хәзер Русиядән,

БДБдан чыгарга теләүчеләргә шәп бюрократия диварлары корып куйган. Чит илләр хәзер һәр теләгәнне үзенә кабул итми. Русиядән чыгармас өчен мең төрле хәйлә, сылтау таба. Чөнки Русиядән, элеккеге социалистик илләрдән чыккан килмешәкләр чит илләрдә еш кына тәртип боза, урлаша, эшсезләр һәм фахишәләр армиясен арттыра, шул мәмләкәт өчен өстәмә социаль, әхлакый, сәяси кыенлыкларны ишәйтә. Үз мәшәкатьләре дә муеннан.

Шуңа да карамастан, Америкага барып кайтырга яки бөтенләйгә күчеп китәргә теләүчеләр саны күбәйгәннән күбәя бара. Америка илчелеге бу эштән үзенчә бик яхшы акча эшләү җаен китереп чыгарган. Американың Мәскәүдәге илчелегенә керү өчен егерме доллар (100 000 сум) түләргә кирәк, сиңа виза бирәләрме, юкмы — һәр кеше акчасын түли. Дүрт-биш сәгать урамда чират торганнан соң, консул офицеры хозурына килеп керәсең. Кабат керәсең булса, син тагын шул ук сукмак буйлап, яңадан акча түләп узарга мәҗбүрсең. Бәхет төшеп, визаңа рөхсәт алгач, тагын 100 доллар (500 000 сум) чыгарып саласың, бөтенесе 120 доллар (600 000 сум) калдыргач кына синең паспортыңа мөһер сугыла. Ләкин бу бәхеткә ирешер өчен шактый борчулы, мәшәкатьле юл узарга кирәк. Күз, чәч, тән төсләре, буй-гәүдә турында мәгълүмат язып тутырганнан соң, озын чиратка басасың, иртәнге биштә килеп бассаң да, йөзенче кеше буласың. Ул көнне сиңа чират җитмәсә, иртәгә таң тишегеннән такси яллап,— чөнки метро әле эшләми,— илчелеккә элдертәсең.

Без, бер көнне чама белән ике меңгә якын кеше, кәгазь-гариза тапшырдык. Шуларның алтмышлабы гына виза алу бәхетенә иреште. Мин шәхсән, бу сөрешне узар өчен сигез көн сарыф иттем. Һәм, ниһаять, консул ярдәмчесе каршысына барып ирештем.

Консул офицеры белән әңгәмә мондыйрак мохиттә бара. Миннән алдарак торучылар белән сөйләшкән ачык ишетелә. Офицер тәрәзәсе каршында олы яшьтәге бер хатын. Консул ярдәмчесе:

— Сезнең Америкада булганыгыз бармы?

Хатын:

— Ике тапкыр кызым янында булдым.

— Кызыгыз анда нишли?

— Кияүдә.

— Ике тапкыр булгансыз бит инде, ни өчен тагын барасыз?

— Сагындым.

— Сагынганыгыз өчен генә без Сезгә виза бирә алмыйбыз.

— Ни өчен?

— Чөнки Сез бу юлы Америкада калырга барасыз!

Хатын ык итте, мык итте, нидер әйтергә теләде, тәрәз капкачы шартлап ябылды. Эчтән җавап булмагач, хатын еламсырап китеп барды. Ул китүгә үк тәрәзә ачылды. Офицер бер ир белән сөйләшә:

— Сез Америкага ни өчен барасыз?

— Тәҗрибә уртаклашырга.

— Сез кем?

— Мин кече предприятие директоры.

— Юл чыгымнарын, кунакханә өчен түләүне кем күтәрә?

— Үзем.

— Сезне кем чакырды?

— Анда, кәгазьдә барысы да язылган.

— Сезгә виза бирә алмыйбыз.

— Ни өчен?

— Чөнки Сезне чакыручы мондый фирма Америкада юк һәм Сез Америкада калырга барасыз, дип уйлыйм.

Җегет һич сүз әйтмәстән, паспортын алып, тиз генә чыгып китте.

Чират миндә.

— Ни өчен Сез Америкага барасыз?

— Чакыру илә.

— Кем чакыруы илә?

— Капитал трэйдиң корпорэйшн.

— Аның президенты кем?

— Илхан Айдагөл.

— Монда гаиләгез, балаларыгыз бармы?

— Бар.

— Сез Америкада калырга уйламыйсызмы?

— Юк!

— Айдагөл белән кайда таныштыгыз?
— Казанда.
— Кайчан?
— 1988 елда.
— Ул Сезне ни өчен чакыра?
— Анда, Нью-Йоркта, минем пьесам уйналачак.
— Уйналса соң! Алар Сездән башка гына уйный алмыймыни?
— Уенчыларга минем ярдәмем кирәк, чөнки алар профессиональ артистлар түгел.
— Пьесагыз кайсы бинада уйнала?
— Анысын белмим.
— Менә шуны белгәч, тагын килерсез.
— Аның өчен Америкага тикле шылтыратырга кирәк бит.
— Анысы Сезнең мәшәкать!

Шулай итеп, мин дә паспортымны учлап, илчелектән чыгып киттем. Америкага шылтыратып, пьеса уйнала торган урынның тулы атамасын, адресын, телефоннарын соратып алганчы тагын бер атна узып китте.

— Ярый,— диде офицер.— Ләкин «Капитан трәйдиң корпорәйшн»ның Сезнең пьесага ни катнашы бар? Ул бит сәүдә оешмасы.

— Бу сәүдә оешмасы сәнгатьчеләргә химаячелек итә, ягъни акча белән ярдәм күрсәтә,— дидем.

— Сезнең юл, кунакханә, ашау-эчү чыгымнарыгызны кем каплый?
— «Капитал трәйдиң корпорәйшн».
— Яхшы! — диде офицер.— Без Сезгә виза бирәбез!

Виза артыннан чаба торгач, Мәскәүдән Нью-Йоркка туры бара торган очкычка билетлар беткән иде. Фин һава юллары очкычына менеп, башта Һельсинкига, аннан башка очкычка күчеп, Америкага очарга туры килде.

Һавада. Очкычка кергәндә үк фин кызлары — стюардессалар каршы ала. Бу кызларны гүзәлләр гүзәле дип булмый. Әмма алар пөхтә-чиста киенгән, бизәнгәннәре бик сирәк, бизәнгәннәре дә сизелер-сизелмәс кенә сөрмә тарткан; алар бик мөлаем, йомшак тавышлы, ярдәмчел, аларны кочасы килә башлый. Очкычта унлап шундый кыз хезмәт күрсәтә. Аларның елмаюы дежур елмаю түгел, һәр кешегә алар һәр мәртәбәсендә дә ихлас елмая. Үз эшләрен сөеп башкаруы, кешеләргә хөрмәт вә сөю тәрбия иткәннәре күренеп тора. Андый хатын-кызларга син дә сөю вә хөрмәт аша карыйсың. Аларның матур мөгамәләсе вазифа кушканнан гына түгел, аларның гадәт-йоласында кешегә миһербанлы булу ята булыр.

Өйлә вакыты җитте. Һәр кешегә өйлә ризыкларының исемлеген өләшеп чыктылар. Атамалар исемлегендә «Тунататар» дигән сүз күреп, мин шул тунататарны ашап карарга булдым. Мин белмәгән ул нинди татар ашы икән? Ләкин бу аш мин көткән ит ризыгы булмады, диңгез кәбестәсеннән ясалган салат иде ул; әмма бик тә тәмле иде; аның янына кыздырылган чебеш күкрәге, гөмбә салаты, крем-брюле, сыра, теләгән кешегә фин аракысы, шәраб, виски, төрле җимеш сулары. Кайнар суда чылатылган тастымал белән бит-кулны сөннәтләгәннән соң, кешеләр тәгамга тотынды. Аштан соң янә кайнар-дымлы тастымал бирелә. Аш табагында бер кулланырлык борыч, шикәр, тоз янчыклары янында теш арасына кысылган ризык кисәкләрен чыгарыр өчен очланган шырпы (мисвак та) бар. Гомумән, мин булган илләрдә табынга һәрвакыт мисвак куела. Бу — кагыйдә.

Һавадагы фәрештәләр — очкыч кызлары һәр кеше белән инглизчә сөйләшә, фин, юлчылары белән — финчә, шведлар белән — шведча; аш атамалары да өч телдә язылган: инглизчә, финчә, шведча. Минем сыманнар бу телләрнең берсен дә белми. Шәраб, аш сайлау, эчәргә теләгән саен су, җимеш суты китерттерерлек булса да инглизчә белү юлчыга зарур нәрсә.

Сәгать ярымнан соң очкыч Һельсинкидәге очкычлар аланына килеп кунды. Очкычтан чыкканда һава фәрештәләре, кадерле кунак озатып калучы хуҗабикәләрдәй, рәхмәт әйтеп, хәерле юл теләп калды. Ярты сәгатьтән соң Һельсинки— Нью-Йорк юлы белән очучы тимеркошыбыз күккә күтәрелде. Очкычның эче театр кебек. Һәр кеше каршысында телевизор. Экранда очкычыбызның кайсы географик нокта өстеннән: диңгез, тау, илләр аша очканын карап барабыз. Маршрутны күрсәтеп алганнан соң экранда маҗаралы фильм карый аласың. Теләсәң, янында гына радио колакчыннары. Терсәк астындагы сәдәфкә басып, үзең теләгән музыканы тыңлый аласың. Ике тапкыр ныклап ашау вә теләгән саен, теләгәнең кадәр салкын су, җимеш суты, шәраб, виски, сыра эчеп, ара-тирә черем иткәләп бара торгач, сигез сәгать узганны сизмисең дә.

Очкычыбыз төгәл вакытында очкан иде, төгәл вакытында Нью-Йоркның очкычлар аланына килеп төште. Америкага барганда исерткечне күпләп эчүче булмады. Әмма кире кайтканда Русия кешеләре аракысын да, вискиен да, шәрабын да, сырасын да күпләп чөмерде (түләнгән бит!). Мәскәүгә килеп төшкәндә кайтучыларның яртысыннан күбесе ләх иде.

Нью-Йоркның очкычлар мәйданыннан чыкканда мине дусларым Илхан Айдагәл белән Илдар Агиш каршылады.

Кунакханә. Мин Финляндиядән килгән дусларым белән бер кунакханәдә, аерым бер номерда яшим. Чисталык, нечкәлекләренә кадәр уйланган шартлары турында язып тормыйм, кыскача гына әйтәмен ки: Русия, Татарстан кунакханәсендә син кунак түгел, син анда хуҗа да түгел, син килмешәк сыйфатында яшисен. Кунакханәнең администрациясе, җыештыручы, дежур хатыннар сиңа баш. Чит илләрдәге кунакханәдә син хуҗа, син боеручы, шул ук вакытта син кадерле кунак та. Бар да синең көйсезлегеңә түзәргә, син теләгәнне үтәргә әзер.

Тамаша. Финляндиядән Нью-Йоркка спектакльдә катнашучы җиде уенчы белән бергә бөтенесе кырык татар килгән иде. Һельсинкидә караган тамашаны тагын бер карарга Америка тикле Америкага, океан аръягына йөрү бер караганда гаҗәпләндерә дә кебек.

— Бу — тарихи бер бәйрәм бит, Батулла әфәнде,— диде Тинәт ханым.— Бәйрәмдә катнашу үзе бер бәхет.

Туганнарны бер күрү, яңа танышлар табу, бергәләп кунакка йөрү, театрга бару һәм тагын бер тапкыр сөекле артистларының уенын Нью-Йоркта карау — аларның рәхәте.

Поляк клубына олы яшьтәге кардәшләребез белән бала-чага җыелган. Яшьләр аз. Алар бүген Төркия көнен бәйрәм итә икән. Урамнарда олы нәмаеш (демонстрация) буласы икән. Яшьләр шунда, имеш.

Шушы мәҗлескә, «Туйлар узгач»ны карарга махсус килгән Талип әфәнде Күдәки Канадада яши икән. Арабызда саф татар теле. Бу кардәшне Татарстанга, татар милләтенә кагылышлы бөтен нәрсә кызыксындыра. Ул бүген тамаша карый да Канадага кайтып та китә, эш кешесе.

Кыска буйлы, алтмыш яшьләрдәге бер абзый Талип әфәнде белән сөйләшеп бетергәнемне сабыр гына көтә. Талип әфәнде китүгә үк, әлеге агай саф үзебезчә:

Мин Гайсә абыең Мәҗит буламын,— диде.— Чистайдан мин, Баганалы авылында туып үскән кеше.

Шаян сүзле, хәйләкәр күзле, хәрәкәтчән Гайсә абзый алтмышта түгел, сиксән икене тутырган кеше булып чыкты. Ул сугыш башында ук Сталинград янында алманнарга әсир төшкән. Без әле аның белән алга таба да очрашкаларбыз.

Габдулла ага Вафалы Себердә туган. Икенче Ярман сугышында әсир калган. Габдулла ага белән дә аның үз өендә күрешәчәкбез.

Шәмсия ханым Апакай Сан-Францискода яши. Ул Камчатканың Петропавловск шәһәрендә туган. 1924 елда Кытайга күчеп китәргә мәҗбүр булган. 1951 елда Төркиягә килгән. 1961 елдан бирле Америкада яши. Мәгълүматы ягыннан Шәмсия ханым «Татар халкының тере энциклопедиясе» диеп әйтерлек шәхес.

Гомумән, Америкада төрле язмышлы татар кешеләре яши. Аларның бер өше революциягә чаклы ук чит илләргә киткән буын вәкилләре. Икенчеләре революциядән качкан кешеләрнең нәселе. Өченчеләре Беренче-Икенче Дөнья сугышларында әсир калган кардәшләребез. Дүртенчеләре моннан йөз-йөз илле ел чамасы Финләндиягә ирекле күчеп, сәүдә итеп, шунда төпләнеп калган татарлар. Бу кешеләр арасыннан берсенең генә язмышын алып, китап язсаң да, татар халкының фаҗигале язмышы гәүдәләнер иде.

Бу бинага өч йөзләп кеше сыя торгандыр шәт. Янда бай буфет: салкын эчемлекләр. Икенче янда кайнар ризык өстәлләре.

Сәхнәдә тамаша җиһазлары. Алдарак — Финляндия һәвәскәр Татар театрының оркестры. Оркестрда Бату Алкара, Сабит Насретдин, Кәрим Шакир әфәнделәр музыка коралларын көйли.

Сәхнәдә Нью-Йорк Татарлары җәмгыятенең рәисе Илдар Агиш әфәнде. Илдар бәй үзе Кытайда туып үскән малтабар.

— 1927 елның 15 мартында татарлар тарафыннан Нью-Йоркта Америка мөселманнары җәмгыяте корыла,— дип башлады Илдар Агиш.— 1945 елдан соң сугышта әсир төшкәннәр: үзбәкләр, казакълар, башка мөселман кешеләре Америкага күпләп килә башлый һәм 1962 елда оешмабыз «Америка ислам җәмгыяте» булып аерылып чыга. Хәзер инде ул «Америка татарлары җәмгыяте» диеп атала.

Сәхнәдә Финляндия ислам җәмгыятенең рәисе Окан әфәнде Даһер:

— Бабаларыбыз йөз егерме ел әүвәл Финляндиягә килеп урнашкан. Качкын булып түгел, рәсми рәвештә күченгәннәр бабаларыбыз. 1927 елда Финляндия ислам җәмгыяте корыла. 1935 елда Финляндия төрекләре (татарлары) берлеге оеша. 1945 елда Финляндиядә Татар спорт җәмгыяте «Йолдыз» корыла. Хәзерге көндә аның рәисе Акиф Али әфәнде. 1948—66 еллар арасында татар балалары өчен мәктәп эшләп килде. Балалар аз булу сәбәпле, ул мәктәбебез 1969 елда ябылды. Хәзер татар балалары өчен җәйге мәктәп эшли. Алар бу дәресханәләрдә бер сәгать ана теле, бер сәгать дин белеме ала. Менә театрыбызны яңадан торгыздык. Элеккеге театрыбыз да көчле иде. Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», «Асылъяр» пьесаларын, Гаяз Исхакыйның әсәрләрен уйный идек заманасында. Яңа театрыбыз да инде дүрт пьесаны сәхнәгә куеп өлгерде. Ике тапкыр Казанга гастрольләргә барды театрыбыз. Шушылай ук оркестрыбыз, җырчыларыбыз да Казанга берничә тапкыр гастрольләргә барды, уңыш казанды. Менә, Аллаһ насыйп итте, инде Америкада да сезнең белән күрешү бәхетенә ирештек. Сезгә Батулланың «Туйлар узгач, туннар тузгач» дигән тамашасын алып килдек! Мәрхабә, туганнар!

Тамаша башланды.

1973 елда Тинчура театрында беренче тапкыр куелып, халык театрларында озак еллар дәвамында уйналган бу кәмитне Америкада яшәүче татарлар аңлармы, Казандагы гаилә (кайнана, килен, кияү) мәсьәләләре аларның күңелен кузгатырмы? — дигән шикләр белән киткән идем Нью-Йоркка.

Беренче күренештә Йосыф (Акиф Али) белән Таһирның (Харис Бәдретдин) сәхнәгә чыгуы ук шик-шөбһәләремне таратты. Һәр сүзне, һәр хәрәкәтне тамашачы дәррәү алкышлый башлады. Һәм тамаша азагынача шул мохит хөкем сөрде Поляк клубында. Бу, әлбәттә, спектакльнең режиссеры Зөһрә Шакирҗанның һәм Финляндиядә яшәүче кардәшләребезнең тырышлыгы — уңышы иде.

Йосыфны уйнаучы Акиф Али бик тә кызыклы шәхес. Ул тормышта гаять житди, аның көлгәнен түгел, елмайганын да сирәк күрәсең. Әмма сәхнәдә ул («Асылъяр»да) Шәрәфетдинне уйнап Һельсинки һәм Казан тамашачысын әсир итеп, рәхәтләндергән иде. Менә ул тагын көлке остасы булып, бер тамашада капма-каршы холыклы ике рольне башкара. Мәхәббәт каһарманы Йосыфтан соң ул сәрхүш Сиражетдинны уйный, янә Йосыф булып сәхнәгә чыга. Сиражетдин ролендә мин аны һич кенә танымадым. Кыяфәте, рәвеше, тавышы шулкадәр үзгәргән, Акиф образга кергән, ул чын Сиражи булып әверелгән иде. Соңыннан гына мин Сиражины Акиф Али уйнаганын белдем. Бер тамашада аерым-аерым ике образ иҗат итү, әйтергә бурычлымын, профессиональ актерлар арасында да бик еш булмый.

Усал кайнана Бибиасма (Билгә ханым Вафин) үз өендәгедәй сәхнәдә яши. Йөгәнсез Зәйнәп (Сайнур Садыйк) сәхнәгә чыга-чыгышлый алкышларга күмелә. Мәҗнүн (Раиф Низаметдин) көчле, моңлы тавышы белән җырлый һәм Ләйләсе (Гүлин туташ Хәйрулла) белән ярашкан-ярәшкән пар булып тамашачы күңеленә керә, сәхнә гизә.

Шәрифҗан (Зирәк Туганай әфәнде) белән Фәсхетдиннәр (Ариф Хәмидулла әфәнде) дә тамашачы хәтерендә калыр.

Халык канәгать. Уенчылар шат. Миңа ни кала? Авторның кәефе уенчыларга, тамашачыга бәйле: барысына да олуг рәхмәт!

Шау-шулы тамашадан соң сәхнәгә мине дә чакырдылар.

Тәнәфес. Чәйле, ризыклы табыннан соң килгән кунаклар, Нью-Йоркта яшәүче татар балалары катнашында концерт булды. Соңра, үзенә күрә, туй мәҗлесе кебек табын корылды.

Бу кичәгә Рөстәм Камский да килгән иде.

— Кичерегез, — диде Рөстәм. — Гата килә алмады. Ул ярышка хәзерләнә.

Без Рөстәм Камский белән байтак кына сөйләшеп тордык, сүз арасында ата кеше углы Гата каршында көндәшләре корган ясалма кыенлыклар турында да әйтте:

— Татарга кайда да кыенлык күп! — диде Рөстәм Камский.

Биюләр, әңгәмәләр, танышулар, озакка сузылды. Бәйрәм дими, ни диярсең!

Театрда. Бродвейдагы күпләгән театрлар арасында «Шуберт театры» да бар. Ул 1913 елда ук корылган. Без «Сиңа үлеп гашыйк булдым» дигән музыкалы кәмит карыйбыз. Билет бәясе 48 доллар тора. Бу — уртача бәя. Әсәр көненә ике тапкыр уйнала, унынчы ел инде шулай дәвам итә, тамашачы бу спектакльгә йөрүдән туктамый. Мине сокландырганы — сәхнә техникасы. Җиһазларның, кү-

ренешләрнең тавышсыз, тиз алмашынуы — барысы да электроникага корылган. Нью-Йорк манзаралары, күз алдында, күз ачып йомганчы пәйда була, автомобильләрнең кеше тояп сәхнә уртасына атылып чыгулары кинодагы кебек җиңел эшләнә. Шартлап, шаулап торган ШОУ, дәртле, җитез, ялгышсыз биюләр, вокаль сәнгате һәм актерларның спортсменнар, йогалар, каратэчылар кебек трюклар эшләве, кирәк булса, сальто мортале сикереп, кирәк булса, «үлем элмәге» ясап, каһарманның биек баскычтан тәгәрәп төшеп, тамашачы кырыенда «үлүләре» могҗиза кебек. Шушы хикмәтләр өстенә театрда Сүз Сәнгате хакимлек итә. Актерның тамашачыга аңлашылмаган, ишетелмәгән бер генә сүзе дә булмаска тиеш һәм бу шулай да.

Телевидение. Экранда кытайча, итальянча, испанча, япунча тапшырулар, кинолар бик еш күрсәтелә. Американың җирле халыклары (индеецлар) турында нәфис фильмнар күп. Бу фильмнарда индеецлар бик тә миһербанлы, горур, чибәр, каһарман итеп сурәтләнә. Ләкин чынбарлыкта җирле халык, татар халкы кебек үк, үз ватанында хокуксыз.

Бер атна эчендә экранда урыслар турында Америкада төшерелгән бер нәфис фильм бирделәр. Себерне яулап алу турындагы бу фильмда урыс баскынчыларына каршы «канга — кан, үлемгә — үлем» диеп көрәшүче татарлар Себер җирләренең чын хуҗалары итеп сурәтләнгән. Фильмның исеме «Михаил Строгов» иде булса кирәк. Татарлар монда карикатур шәкелдә түгел, батыр, мәһабәт итеп бирелгән, алар үз ватанын дошманга бирмәс өчен соң тамчы кангача сугышып үлә.

Мәскәү урыс булмаган милләтләргә шулкадәр телевидение каналлары, вакыт бирә алыр идеме икән?

Телевидение аш-су әзерләү тапшыруларына бик күп вакыт бирә. Атаклы ашчылар нинди ашның ничек әзерләнгәнен пәрәме тамашачы каршысында әзерләп, татытып күрсәтә. Бу өстәге максат кына. Төп максат табак-савыт, табын әсбапларын рекламалау. Ул уңайлы казаннар, табаларны, электр, газ плитәләренең гүзәллеген, җайлылыгын күреп, шундук кибеткә чыгып йөгерәсе килә башлый. Экранда спорт хакимияте. Спортта күбрәк негрлар алда бара.

Кунакта. Илхан Айдагөл әфәнде үз өендә кунак җыйды. Бу йортның матурлыгы, уңайлыгы, яшеллеккә, чәчәккә күмелеп утырулары турында тәфсилләп язып тормыймын. Шулай да мондагы кунак кабул итү, кеше сыйлау йолалары турында күзәткәнемне әйтеп узыйм.

Әйе, татар — кунакчыл халык. Татар халкының табын янындагы әдәбе, культурасы, чамасы күпләргә үрнәк булган. Ләкин соңгы ун-егерме ел эчендә без инде табын янындагы йолаларыбызны да оныттык, ташладык. Ямьсезрәкләрен алдык. Мин аракыны чамасыз күп эчертүнең төп максатка әверелүе турында гына әйтмимен. Кыстау мәсьәләсе турында гына бер авыз сүзем бар. Артык кыстау татарда элек булмаган. Үтереп кыстау бары тик ачлык елларда башланып китә. Хуҗаларның үзләренә дә аз булган ризыгын кунак кыстамыйча ашамаган. Табынга муллык килгәч тә әнә шул үтереп кыстау гадәткә кереп калды. Хәзер табын янында сөйләшеп, җырлашып утыру түгел, төп максат — кунакны екканчы эчертү: авызыннан кире килгәнче ашату, согындыру. Чит илләрдән килгән татарлар миңа күп мәртәбәләр зарландылар:

— Батулла әфәнде, нигә сездәге татарлар шулкадәр ямьсез кысташалар? — диделәр. — Эчәргә, ашарга кыстамасаң гына кунакка барам, дигәннәре дә булды.

Артык кыстау — ул ирексезләү, көчләү. Ашап утырган кешене кыстау, ашама дигәндәй, мәгънәсезлек. Эчәргә кыстау — ул инде җинаять.

Нишләтәсең, безнең матур йолаларыбызның байтак өлеше кайчандыр моннан күчеп киткән татарларда сакланган.

Илхан Айдагөл өендә дә әнә шулай иркен, матур мәҗлес булды. Бакчада корылган табын янында илледән артык кунак. Әзер ризыклар: кайнары, салкыны, шулпасы, салаты шунда — бакчадагы өстәлләрдә. Шешәдәге эчемлекләр (җаның ниндиен тели!) бөтенесе дә бозлы кисмәкләргә батырылган. Күрше өстәлдә табак-савыт: кашык, чәнечке, пычак, тустаган. Һәркем кайчан тели, ни тели, күпме тели, үзе барып, хаҗәтенчә ризык ала, бөтенесен төпсәгә куеп, үзе теләгән кешесе янына барып ашый, эчә, гел урын күчеп, бакча буйлап йөри, сөйләшә, аралаша.

— Җәгез кунаклар, тәгамнан җитешегез! — дип әйтүдән башка һичкем сине кыстамый, ирексезләми, «аны эч, моны аша», диеп өстеңдә балта белән тормый. «Эчмәсәң, үпкәлим, димәк, син мине хөрмәт итмисең», дими. Рәхәт!

Мәҗлес таңгача сузылды.

Шәхсән мин үзем кыстасалар, ач булсам да ашый алмыйм. Мондагы мәҗлес нәкъ мин теләгәнчә узды.

Илхан Айдагәл сүзе:

— Алманың орлыгын Алманиягә яки Америкага күчереп утыртканнан соң, ни үсеп чыга?.. Каен үсми бит... Татарлар да шулай. Кайда гына булса да ул татар булып кала.



Батулла Нью-Йорктагы дуслары арасында. Сулдан уңга: «Капитал трейдинг карпорэйшн» фирмасының рәисе Илхан Айдагәл, Америка татарлар җәмгыятенең рәисе Илдар Агиш хатыны һәм әнисе уртасында.

1995.

Чыннан да, Илхан рәислек итә торган тәшкиләттә гел татарлар гына эшли. Ләкин Илхан әфәнде урыслар белән дә, башкалар белән дә хезмәттәшлек яклы. Өч ел инде ул Русия, Татарстан белән сәүдә эшләрен рәткә салырга йөри.

— Казый торгач, адәм чишмә чыгара,— дип дәвам итә Айдагәл әфәнде.— Чишмә тапкач, иң башта бу чишмәнең суын тапкан кеше үзе эчеп бага. Аннан соң сусаганнарга тәкъдим итә. Чишмәне ачкан кеше үзе күчеп китсә дә, вафат итсә дә, чишмә юлчыларга су бирүдән туктамый, халыкка хезмәт итә. Сәүдә дә шулай булырга тиеш, әфәндем. Сәүдә чишмәсе сәүдәгәрнең сусавын да, тагын күпләрнең сусавын да басарга тиеш. Безнең фирманың йөз кешесе Русиядә, Татарстанда эшли. Аларның һәрберсе бер генә кешегә бер генә файда эшләсә дә, һәр гаиләдә бишәр кеше генә хисаплаганда да, биш йөз кешегә ашарга әпәй, эчәргә чәй бирә, дигән сүз. Бер кешенең эшен кисү, биш кешенең икмәген кисү. Син бер кешенең малын сатып алып, үзеңә файда эшлисең. Сатучыга да файда эшлисең бит. Русиядә әнә шундый, үзенә дә, кешегә дә файда эшләүчеләрне кистеләр. Алар беткәч, күпләр мохтаҗлыкта калды... Безнең максатыбыз, әфәндем, Татарстан кешеләренә файда эшләп, аларны алыш-биреш ясарга, малтабарлыкка өйрәтү һәм үзебезгә дә мал табу. Юкса, мин ул малны Америкада җиңелрәк тапкан булыр идем. Безне ата-баба туфрагы тарта. Без дә татар дигән бер милләтнең ерактагы балалары. Америкада эшләгәнгә караганда кимрәк табыш алсак та, без Татарстан белән эшләргә телибез. Татарстанда хатын-кызның эше бик тә авыр. Ирләре күп мал казанса, хатыннарга җиңелрәк булыр иде...

Иртән Илханның улы Кәримне (унынчы сыйныф укучысы), кызы Ясминне (дүртенче сыйныф укучысы) мәктәп автобусы килеп, дәрескә алып китте. Кәрим компьютер, спорт белән мавыга, Ясмин музыка-театрга тартыла. Автобус һәр иртә аларны капка төбеннән алып китә, дәресләрдән соң китереп куя. Ике-өч минутка соңга калулар булгалый икән. «Капка төбеннән» дигәнем сүз җае өчен генә әйтелде, монда капка, капканың төбе юк, өй ишеге турыдан-туры урамга чыга.

Кичәге мәҗлестән соң калган буш шешәләр, кулланылган табак-савыт, тапланган келәмнәрне җыештырырга ике хатын килде. Өй хуҗалары чыгып китте. Әлеге ике хатын өйдә калды. Алар ишекләрне үзләре бикләп чыгачак. Өйдә кыйммәтле вазалар, табак-савыт (сервиз), диварда мәшһүр рәссамнарның иҗаты: кыйбатлы рәсемнәр, манзаралар, натюрмортлар. Мин ирексездән сорап куйдым:

— Әйберләр югалгаламыймы? — дидем.

— Андый нәрсә монда булалмый! — диде Илхан әфәнде.— Бу эш аларның уена да килми. Була калса, ул гомерендә дә Америкада эш табалмый үләчәк.

Хуҗаның «Мерседес-Бенс»ендә барабыз. Һич көтмәгәндә Илхан әйтә куйды:

— Син аптырагансыңдыр инде, ни өчен Илханның хатыны өй җыештырмыйча эшкә китте, акча биреп, ике хатын чакыртып эшләтәләр, дисеңдер. Аның җае бар, дустым Батулла... Хатыным ике сәгать өй җыештырса, ул арый. Чит кешегә акча түләп эшләтү безгә отышлырак, арзангарак төшә. Армаган хатыным эшендә яхшырак эшләячәк. Боларга түләгәннән күбрәк акча казаначак...

Илханның хатыны Түркән ханым физиотерапевт булып эшли. Америкада табиплар иң күп акча ала торган һөнәр ияләренең берсе.

— Буш шешәләрне җыеп, юып, илтеп тапшырырга бер сәгать вакыт узачак. Бу эштән ун доллар акча килер. Шешәләрне бу хатыннарга калдырып, эшенә барып, бер сәгать эчендә минем хатын унике доллар алачак. Ике доллар янга кала.

Бу Америка тормышын аңлап бетермәссең, билләһикәем. Бер генә мәртәбә кулланылган яхшы, матур бизәлгән тустаганнар, чәнечкеләр, кашыкларны чүп савытына ыргытканда сыкрап куясың: боларны күп тапкырлар файдаланып булыр иде бит әле, дисең. Әмма бәрәкәтле Америка бәйрәм табынына куярлык бу әсбапларны чүплеккә ата. Чөнки пластмасс тустаганнарны, чәнечкеләрне юуга караганда, аларны чыгарып ату, яңасын сатып алу арзангарак төшә. Бәрәкәтлелекнең имәнгеч бер мантыйгы.

Юлда электрон хәбәрләр тактасы бар: алда машиналар тыгылышы, фәлән юлдан әйләнеп узыгыз; фәләненче чакрымда машиналар бәрелешкән, төгән юлга чыгыгыз.

Юлларда полис юк, тизлекне арттырсаң, иртәгә өеңә ясак кәгазе килә, чөнки юл буе электрон күзләр синең кагыйдә бозганыңны, машина номерыңны күзәтә, яза, хәбәр итә. Мине күрмиләр әле, диеп син юл кырында печ тә итә алмыйсың.

Язмышлар. Габдулла ага Вафалы белән Рокыя апа өендә утырабыз.

Озын, төз гәүдәле Габдулла аганы бер күрүдә аның борынгы зыялы токымнан икәнен чамалыйсың. Бу мәһабәт картка сиксән яшь.

Габдулла аганың бабасы Вафа Ишбай хәзрәт Шиһап Мәрҗани белән бик якын дус булган. Аның улы Кәрим Вафа Казанда туган. Кәрим Вафа Габдулла аганың атасы була инде.

— Бабаем егерме җиде яшендә Сөембикә манарасындагы хачны каерып төшерә,— дип сөйли Габдулла ага Вафалы.— Казан губернаторы аны җүләрләр хастаханәсенә яптыра. Аны хастаханәдән, төрмәдән халык коткара, азат иттертә.

Шуннан соң Вафа хәзрәт шикаять язып, Питербурга китә. Патша янына керү бик озак-кыен юл булганга, ул патша хәзрәтләрен сагалап, Летний Садта көннәр озын йөренеп тора һәм, ниһаять, ул бакчада патшаны күреп, үзен кабул итүен үтенә. Патша Вафа хәзрәтне кабул итә.

— Сез, Ишбаев хәзрәт, кайтыгыз! — ди патша.— Язганнарыгыз дөрескә чыкса, чаралар күрелер!

Хәзрәтнең Питербурга жалоба белән киткәнлеген Казан губернаторы белгән була, Казанга кайтуга ук Вафа хәзрәтне ул зинданга утырта.

— Әниемнең әнисе Шәмсиҗамал төрмәгә әйбер ташый. Камырга хат төреп, ипи итеп пешереп, бабаем белән язышалар. Ләкин бабаем язган шикаятьләр патша хәзрәтләренә барып җитми. Бер ел төрмәдә утырганнан соң бабаемны Томскига сөрәләр. Гаиләсе бабам артыннан сөргенгә китәргә мәҗбүр була. Андагы татар мәхәлләсе бабама йорт салып бирә. Бабам янә Питербурга юнәлә. Тагын патша белән күрешә.

— Казан губернаторы мине зинданга утыртты, сөргенгә куды. Сезнең әмерегез аңа барып җитмәде,— диеп бабай шикаятьнамәсен тагын патшага калдыра.

Патша указ чыгара. Указны бабайның үз кулына тоттыра. Бабам указны алып кайтып губернаторга тапшыра. Губернатор аңа сөргеннән кайтырга рөхсәт бирә. Бабам гаиләсен Казанга алып кайтырга диеп, Себергә китә, ләкин барып җитә алмый, ике ыстанса кала Мишкин дигән җирдә, бабам юлда вафат итә. Шулай итеп, безнең нәсел Себердә торып кала. Мин 1915 елда шунда Себердә туганмын.

Габдулла абый әбисез-бабасыз, әнисез кала. Әтисез дә кала, чөнки Кәрим Ишбайның чүплегеннән егерме ике кул бомбасы табып, аны төрмәгә алып китәләр. Күрәсең, бу провокация, юри ташланган гранаталар булгандыр. Төрмәдән чыккач, Кәрим абзый яшь хатынга өйләнә. Үги малай Габдулла артык кашыкка әйләнә.

— Ибраһим җизни Чиләбе ягында мәдрәсә мөдире иде. Бер атна бардым җизнине эзләп. Чиләбедән утыз тугыз чакрымдагы Токтыбай авылында икән җизни. Токтыбайга барып җитәр өчен Полетаево ыстансасында төшәргә. Ыстансадан кар ерып ике сәгать бардым. Ниһаять, килеп җитеп, җизниләрнең ишегенә егылдым. Ачлык еллары бит, хәл юк, арылган. Җизни дигәнем бик кырыс кеше булып чыкты. Сәләмә киенгән, ач, хәлсез сукбай малайны күрүгә ул:

— Кем син, ник килдең монда? — диде.

Мин җылап җибәрдем.

— Атаң кем? — ди җизни.

— Кәрим,— дим.

— Анаң кем? — ди.

— Анам үлде,— дим.

— Кемнәрең бар тагын? — ди.

— Рауза апа, Фатыйма апам, Кәшшаф җизни, Зәйнәп апам, Ибраһим җизнәм,— дип бар туганнарны санап киттем.

Җизнинең кулындагы комганы төшеп китте.

— Улыбыз килгән! Зәйнәп, анасы, улыбыз бар безнең! — дип кочаклап алды җизни.

Аллаһ Тәгалә аларга бала бирмәде, шуңа күрә, миңа алар үз уллары кебек карады. Дүрт ел аларда рәхәт яшәдем. Ибраһим җизнәм шул авылда имам иде. Ишегалды тулы мал. Шуннан калхузлашу башланды. Беркөнне җизни әйтте:

— Монда калсаң, харап булырсың,— диде.— Син калада укырга тырыш.

Аннан соң мине аулак урынга алып китеп:

— Тегеләр халыкны харап итәчәкләр, Габдулла кайниш. Син алга таба укы. Вакыты җиткәч, халыкка дөресен сөйләрсең. Укы! — диде.

Златоустка киттем. Укырга керә алмадым. Ашчы ярдәмчесе булып эшләдем. Аннан Җиденче мәктәпкә кердем. Ул арада җизнәм Токтыбай авылыннан күчеп китәргә мәҗбүр булган. 1931 елда Чиләбегә күчкән икән, диделәр. Зират сакчысы булып урнашкан, диделәр. Ятакханәдә торып, 1933 елда мәктәпне тәмам иттем. Менә шуннан соң мин Ибраһим җизнәмне югалттым. Ул чирләп үлгән икән. Шулай авыр елларда апам Зәйнәп белән, Ибраһим җизнәм мине ач үлемнән алып калды. Урыннары җәннәттә булсын!

Шуннан соң Габдулла ага артиллерия офицеры булып китә. Җиде ел Армиядә хезмәт итә. 1941 елда әсир төшә. Өч ел ярым тоткынлыкта яши. 1952 елда АКШка күчә. Кара эшләрдә күп эшли. Әмма укуын дәвам итә. 1965 елда Рокыя ханым белән таныша, алар өйләнешәләр. Күперләр салучы инженер-консультант булып, озак еллар эшләп, 1980 елда Габдулла ага Вафалы пенсиягә чыга.

— Ил булса, иблис табыла! — ди Габдулла ага.— Җизнәмнең тормышын, атамның тормышын иблисләр бозды.

Рокыя ханым сөйли:

— Мин Ишмәкевләр нәселеннән. Ата-бабамнар эшкуар булганнар. Мәшһүр Акчура мануфактурасының алга китүендә Ишмәкләрнең дә өлеше бик олы. Акчура фабрикаларын йон белән тәэмин итүче Ишмәкләр була... Соңгы Акчура заманасында фабрикада олы янгын чыга, өч эшче маржа янып үлә... Моның гаугасы бик олыга китә башлый. Имеш, татар фабрикасында интегүче урысларны яндырганнар... Эш башында йөрүче Ишмәк бабамны судка тарттыралар. Шуннан соң Ишмәк: эшне зурга җибәрмәгез, мин моның өчен урыска яхшы чиркәү салдырам, диеп котыла. Һәм вәгъдәсен үти дә. Бесштановка дигән теге хатыннар авылында ул чиркәү хәзер дә тора.

Ишмәк сүзе:

— Мин фабрикамның, йортымның беренче нигез ташын ничек салдым — беләм, ничек төзеп бетердем — беләм, әмма камунистларга кайчан бирдем — белмим.

Бу сүзләрне: мин үз теләгем белән малымны бирмәдем, аны миннән талап алдылар, диеп аңларга була.

Мәҗлестәшем Гайса ага Мәҗит сүзе:

— Татарга бер ирек килерме икән ул?

Гайсә ага бу сүзне миннән җавап алыр өчен кузгатмады кебек, үзалдына сөйләгәндәй генә әйтте бугай. Минем җавабымны да көтмәенчә, Гайсә ага җыр башлады:

— Сандугачым, син сайрап кал,
Кисәләр талларыңны;
Янарсың да, көярсең дә,
Сөйсәләр ярларыңны.

— Чистайның Баганалы авылында мөртәтләр зираты бар иде. Өсләрендә таш та юк, кемнәр күмелгән анда, хәтерләми халык. Әмма «Мөртәтләр зираты» буларак беләләр. Ни гаҗәп, мөртәтләр зиратына кереп тәрәт иткән кеше юк, каберләрне мыскыл иткән кеше юк...

Шунда Рәшит Әхмәтҗанның: «Туган җирдә дошман каберләре, каберләрдән ирләр үч алмый», дигәне искә төшә.

Гайсә абый тагын җырлый:

Уйлый күңлем, уйлый күңлем,
Уйлый күңлем файдага;
Уйсыз гына рәхәт көннәр
Булмас ул беркайда да.

— Безгә бер генә юл,— ди Гайсә ага.— Урыс богавыннан котылу. Алман, төрек кулына керү түгел. Украина, Мажарстан, Румыйния сугыш вакытында Адольф кул астында рәхәт яшәде. Һитлер килеп җиткән булса, татарга да шул муллык тияр идеме?

Ага кеше бу сөальне дә җавап өчен әйтмәде сыман. Бәлки ул минем бу сорауга җавап бирмәячәгемне сизенгәндер, чөнки минем җавапның аның фикере белән тәңгәл килүе бар яки аның фикеренә бөтенләй рас килмәве дә ихтимал.

Бу мәсьәләне Фәнзаман Баттал куерта башлаган иде дә, күпме каргыш, күпме ямьсез хатлар алды. Гәрчә, мин дә пышылдап кына әйтер идем: бүгенгедән дә хуҗе булмас иде шәт.

Сандугачкай икәнсең лә,
Җитә күзләр, китәрсең;
Җан теләгән яр булмасаң,
Ни хәлкәйләр итәрсең?

Рокыя ханым Кытайда яшәгәндә үк туплаган бай архивын ача. Монда революциягә чаклы, утызынчы елларда чыккан китаплар белән бергә Кытайда чыккан «Ерак Шәрык» журналлары бар; Габдрахман Сәгъдинең 1926 елда басылган «Татар әдәбияты тарихы» дәреслеге, Гаяз Исхакыйның әсәрләре саклана икән. Саубуллашканда хуҗабикә миңа Исхакыйның «Солдат» романын, баягы дәреслекне һәм Кытай татарлары арасында мәшһүр шагыйрь булып танылган Акбирдиннең шигырьләре тупламасын, Габделбари Баттал-Таймасның «Төрек-татар тарихы»н бүләк итте.

— Әхмәт Гәрәй исемле кеше Икенче Дөнья сугышында Алманиядә кала. Муса Бигине фәкыйрьләр зиратына җирләгәннәрен ишеткәч, Әхмәт әфәнде артыннан йөреп, Каһирәнең байлар зиратына Биги бабамызның җәсәден күчертә. Һәм Мисыр дәүләтен Муса Бигигә һәйкәл куйдырта.

Илхан Айдагәл сүзе:

— Бабамны мәчеткә намазга барганда коммунистлар җибәргән катил чәнчеп үтерә. Аның мәетен җирләргә рөхсәт итмиләр. Ике атна ул җир өстендә аунап яткан. Кыюрак картлар яшерен рәвештә аның гәүдәсен алып, мәчетнең мәет кабыклары куела торган катына куялар. Бабамның колак-борыннарын күселәр ашап бетерә. Соңра яшереп җирлиләр. Бабамның исеме Зыятдин. Ул Мамадыш төбәгенең Шәтче авылы кешесе.

Менә шул кешенең улы Ибраһим ага әле дә булса исән, ул заманында Кытайга китеп, хәзерендә Төркиядә яши. Ибраһим аганың улы Илхан Айдагәл АКШта тора. Шәтче авылында ул үз акчасына мәчет кордырды. Нью-Йорктагы аның офисында гел татарлар гына эшли, дигән идем инде. Эш бүлмәләрендә Татарстанга кагылышлы әсбаплар бик күп. Президентыбызның ат сөеп төшкән рәсеме, Татарстан байраклары, Татарстан харитасы, Татарстан туграсы, Казан, Болгар күренешләре, Бакый Урманче, Усман Абдулов, Риф Фәхретдиннәрнең эшләре, Сөембикә манарасының сурәте — кыскасы, монда татар рухы.

Рифат Таби Кырымда туган, Кырымны ярман басып алгач, җиде балалы Шакир абзый гаиләсе дә Алманиягә җибәрелә, ләкин бик күп туганнары бу якта, Советлар ягында да кала.

Рифат әфәнде АКШның Нью-Йорк технология институты профессоры. Аның бер гектар җире урман эчендә, йорты бик күп бүлмәле, ишегалдында егерме биш

метрга унбиш метрлы йөзү кавузы бар. Һәр гаилә әгъзасына машина: гадәти күренеш.

Рифат Таби сүзе:

— Коммунистик режим җимерелмәгән булса, татар нишләр иде икән? Татар үзен-үзе коткара алырмы?

Габдулла Вафалы сүзе:

— Бары тик үз эчендәге көчкә генә таянырга тиеш татар! Аңа һичкем ярдәм итмәс!

Рестораннар. «Үлеп гашыйк» спектакленнән соң без төнге рестораннарның берсенә киттек. Бу ресторан үзе «Җәкилл һайд клубы» диеп атала. Аны «Җәһәннәм рестораны» диеп мин атадым. Бу клуб 1931 елда корылган. Мөштәриләр (клиентларны) тартыр өчен монда җәһәннәм тишеге ясаганнар. Урам якта, ишек төбендә кечкә кара кәчтүн кигән бер сөлдә (кеше скелеты) ыржаеп басып тора. Шул сөлдә узып барганнарны җәһәннәм тишегенә керергә өндәп, чакырып тора. Бу сөлдә янында узып, керү ишеген ачуга мөштәрине кара киемгә чорналган, күзе генә ачык калган бер җәһәннәм хатыны каршы ала. Шулчак дивар куышы кинәт ачылып китә; анда йөзе күгелҗем күгәрек белән капланган, җыерчыклар, төзәлеп бетмәгән чи җәрәхәтләр белән ермачланган тәнле, котчыккыч ямьсез бер мәет телгә килә. Ул карлыккан тавыш белән сине сүгә, сиңа яный башлый. Кинәт ут сүнә, җан өшеткеч авазлар, җен кочкан хатын чинаганы яңгырый. Инде беттем дигәндә генә баягы җәһәннәм хатыны түр ишекне ача. Аралыкка килеп керәсең, андагы зобаныйлар, әрвахлар, ярым шәрә ирләр, ялангач хатыннар, сине кочарга теләгәндәй, якынаялар, ирексездән син кача башлыйсың һәм аягүрә басып торучы мәетләргә, кеше баш сөякләренә бәрелә-бәрелә, йөгерә торгач, ресторан залына килеп эләгәсең. Өч катлы бу ресторанның диварларында китап шүрлекләре, бу — сихер-тылсым-магия китапханәсе икән; диварларга майлы буяу белән эшләнгән кеше сурәтләре эленгән, бер карасаң, гап-гади портретлар, игътибары төшкән кеше күрер һәм имәнеп китәр: бу портретларның күз алмалары сине күзәтә, аларның керфекле күз кабаклары хәрәкәтләнә, син кая барсаң, шул якка борыла. Кара киемле ике егет безгә аулаграк куыш табып, урынлаштырдылар. Һәр кешенең өстәлендә төймә, шул төймәгә бассаң ут бары синең алны гына яктырта. Шуңа күрә, ресторанда караңгы. Дөньяда нинди исерткеч бар — барысын да шушында татып була икән, янәсе. Мин Бельгия сырасы китерттем һәм гел шуны гына эчтем, кабарга өстәлгә ни килсә, шуны ала бардым. Диңгез җәнлекләре, җылан койрыклары, «маймыл күзе» диеп аталган салатлар ашап утырганда кинәт нидер шартлады, чинап ярдәмгә чакыручы хатын авазы ишетелә башлады; ресторан эче ялкын-төтен белән тулды. Җир тетриме, атом бомбасы шартладымы, белгән юк: ресторан түбәсеннән, түшәмнән бер утлы тартма аерылды. Шул тартмага Вельзевуль (Иблис) утырган. Урта катта туктап, бу шәйтани зат мәхәббәт, гөнаһ вә шәраб турында нотык сөйли. Тагын караңгылык, тагын шартлау, кемнедер көчлиләр сыман, суялармы — акырыш. Акрын гына яктыра. Тартмада бер тере мәет кеби зат бер яшь, гүзәл хатын белән әвәрә килә.

Алга таба күпме генә шартлатсалар да, күпме генә чинасалар да, миңа кызык түгел иде инде. Бу җиргә Нью-Йорк халкы үзе йөрми икән. Күбесенчә килмешәкләр генә йөри, чөнки бу шактый примитив балаган уены. Чынлыклап курыкмыйсың, ләззәт тә алмыйсың.

Нью-Йоркка килгән кичне үк без кырыклап кеше мәшһүр «Һард Рокк» ресторанында җыелдык. Нью-Йоркка килгән һәр кеше, аеруча яшьләр, шушы ресторанга эләгергә тырыша икән. Бу ресторанның мәшһүрлеге шунда ки, хуҗа кеше рок музыканың беренче музыкантларының киемнәрен, уен коралларын, кайчандыр җырланган җырларның ноталарын туплап, үзенә күрә рок музыкасы музее ясаган да шундук ресторан ачкан. Шушы шөгыль гаять куәтле рекламага әверелгән. Ресторанннан кеше өзелми, алдан ук заказлар кабул ителә.

«Һард Рокк» сүзен «Авыр рок музыкасы» диеп тәрҗемә итәргә була. Ресторанда өзлексез авыр рок яңгырап тора.

Яшермим, кан басымлы кеше өчен бу бигүк рәхәт нәрсә түгел иде.

Без, татарлар, икенче катны бөтенләе белән биләп утырабыз. Ашау-эчү мул. Авыр рок аркасында сөйләшә алмыйча бер-беребезгә багып, елмаешып утырабыз. Шау-шу, тавыш. Шулар өстенә күрше өстәл янындагы татарлар барысы да кычкырып торып татарча сөйләшәләр. Ресторанннан киткәндә һәр кешегә «Һард Рокк»ның түшкә тага торган калаен бүләк иттеләр. Бу да реклама.

**Төрек рестораны.** Егермеләп кеше төрек ресторанына әбәт ашарга киттек. Нью-Йоркта төрек рестораннары бик күп. Һәрберсендә дә бары тик төрекләр генә эшли; бары тик төрек милли ашлары гына әзерләнә.

Ишектән керүгә үк сине талгын гына төрек музыкасы каршы ала.

Тамакай буларак, мин һәр ризыкны тәмләп ашыйм. Шуңа күрә, кайда ни ашатканнарын тәфсилләп язып барам. Бу сәяхәтнамәмне бастырырга алынучы мөхәррир ашау өлешен кисеп ташлармы, юкмы, миннән калмасын — языйм әле.

Иң башта, аш сайлый башлаганчы ук, сап-салкын саф су вә җимеш сутлары китереп куйдылар; эссе көнне шуннан да кирәк, шуннан да татлы нәрсә юктыр. Тәмле су эчә-эчә сөйләшәбез. Табын янында Канададан, Финляндиядән, Төркиядән, Татарстаннан килгән татарлар.

Төрек җегетләре әбәт китерде. Ике төрле казы, ике төрле пәйнир (сыйр), бәрәңге, борчак, салат, памидур, тагын бик тәмле кызган ит, сыйр өстенә кызыл уылдык сыланган.

Бу тәгамны ялтыраттык та сөйләшәбез, салмак кына татарча җырлыйбыз.

Җегетләр янә ризык китерде. Салат, аның эчендә туралган кишер, кәбестә, кызыл торма, яшел яфрак, төрле тәмләткеч үләннәр, яшел кыяр, тозлы кыяр. Бу салат та тоткарлыксыз карынга үтте.

Мин Татарстан турындагы сорауларга җавап бирәм. Ул арада өстәлдә өченче тәгам пәйда булды. Әстерхан чикләвеге хәтле дүрт йомарлак ит. Ит янында салҗага (соус) манчып пешерелгән тана ите. Шунда ук эремчекле бөрәк (пирог) телеме.

Бу аш та йөрәккә май булып ятты, шөкер.

Йылмаз әфәнде Төркиядә торганнарын, төрек ашлары, төрек халкының гореф-гадәтләре турында сөйли.

Табынга кыздырылган тавык белән дөге китерделәр. Бу аш та бик тәмле иде.

Төрек җыры тыңлыйбыз. Төркиядән килгәннәр җырга кушыла. Җыр ләззәтеннән соң үзгә аш ләззәте көтә. Алда җимеш белән тулы табак: әфлисун, мандарин, ике төрле алма, банан, нар (гранат) җимеше. Җиләк-җимештән соң каһвә, кемдер чәй, кемдер су эчә.

Тәгам җыю тәмам.

Әлхәмдулиллаһи әлләзи әтгамәнә вә сәканә вә җәгаләнә мин әл мөслимин, амин!

**Кытай ашлары.** Монда да бары тик кытай кешеләре генә хезмәт итә. Алда тәгам алыр өчен пар таякчыклар ята. Нинди ризык китергәннәрен санап, язып бетереп булмас, ахрысы. Итле ризыклар биш төрле, ит янында мул яшелчә. Кузаклы яшел борчак, керән, суган, әче торма, төче торма; пылау, ботка, өч төрле гөмбә ашы, креветка белән салма, ул гаҗәеп тәмле салҗага буталган; кытай сырасы, җимеш сулары — бар да бар. Барыбыз да таякчыклар белән ашыйбыз; йодрык хәтле ит кисәген дә, ялгыз дөге бөртеген дә шул таякчыклар илә алабыз. Таяк тота белмәгәннәргә чәнечкә, пычак, кашык бирелә. Әмма бу табын янында таяк идарә итә белмәгән кеше юк: күбесе Кытайда яшәгән татар балалары, башкалары да дөнья күргән — Кытайда, Япониядә булган. Ә мин исә Казанда артыштан үзем ясаган таяклар белән ашарга өйрәнгән идем.

**Италия ашлары.** Нью-Йоркта Италия ашлары әзерләнә торган рестораннар бик күп. Италия табыны да бик мул, шәп иде. Американнар Италиянең һәр ризыгына мөкиббән. Эш урыннарында да төшке ашка Италия ризыклары китертәләр. Бигрәк тә Италия ләвәше йөрештә. Табага җәеп пешерелгән ләвәш, ләвәш өстенә мул итеп памидур измәсе сыланган, суган, борыч, тоз бутап салынган, измә өстенә пәйнир (сыйр) җәелгән, төрле тәмләткечләр сибелгән. Койган да куйган — үзебезнең дучмак (дурычмак, шәңге) инде, бары тик бәрәңге измәсе урынына памидур боламыгы, күкәй урынына сыйр. Бу ризык хәзер Мәскәүдә дә әйләнешкә кереп бара: почмак саен Мәскәүдә шуны пешереп саталар. Бик яхшы үтә.

Нигә без дә татар ашларын шулай йөрешкә кертеп, мәшһүрләштермибез икән ул?

Нью-Йорктагы рестораннар типтерү урыннары булудан битәр ашау урыны, көрәшү мәйданы.

Шәһәр буйлап йөреп, арып, соңга калып кайткач, янә кечкенә ресторанга, тамак ялгап алырга киттек. Финляндия ватандашлары Акиф әфәнде Али, аның хатыны (Татарстан кызы) Нурания ханым, Атик әфәнде Али, аның хатыны (Татарстан кызы) Әлфия ханым белән бишәү төнге аш ашыйбыз. Буйвол итеннән әзерләнгән

ризык бирделәр, ит янында кукуруз оныннан пешерелгән кәтермәч, күп яшелчә куелган; җиңелчә-затлы шәраб белән тамак ялгаганнан соң, төнге урамга чыктык. Урамда телефон-автоматларның берсенә Атик Али кереп китте дә, бер-ике минуттан соң;

— Батулла әфәнде, сине Рузия ханым телефонга чакыра! — дип кычкырды.

Мин ышаныр-ышанмастан йөгереп килеп Атик кулыннан телефон колаксасын алдым, телефонда хатыным Рузия тавышы, аннан соң улым Нурбәк авазы ишетелә.

— Исәнме, әти, син кайдан? Бик яхшы ишетелә.

Казанда иртәнге сәгать сигез икән. Хатын әйтә:

— Шулкадәр якын, әллә кайтып та төштеңме? — ди.

— Кайтып төшкән булсам, болай яхшы ишетелмәс иде! — дим.

Шулай итеп, әби әйткәндәй, эт багана төбенә печ иткәнче өйдәгеләр белән дә хәбәрләшеп алдык.

Бродвей. Мин дә бардым Питербурга, дегет чиләге дә, дигәндәй, без дә Нью-Йоркны килеп күрдек, урамнарында йөрдек, ресторганнарга кердек, театрында да утырдык, кунакханәсендә дә тордык, дусларның өйләрендә дә кунак булдык. Барысы да кызык, әлбәттә.

Нью-Йорк йөз-йөз ун катлы йортлар — күктерәрләр шәһәре. Йөз ел элек салынган бу йортлар, бүген салынгандай, чиста күренә, кирпечнең төсе үзгәрми. Урамнарда сөрем-тузан томаны күренми, мультфильмнардәге кебек күп төсле утлар, буяулар-рекламалар, тавыш-тәтен чыгармый торган машиналар, һәр җирдә сервис — кешегә яхшы хезмәт күрсәтү, акчаңны түләсәң, синең өчен өзелеп-үлеп торучы хезмәтчеләр — бар да безнеңчә түгел. Нәкъ Америкача һәм моның шулай икәне беркемгә дә сер түгел. Америкада шулай булмаса, сәер булыр иде.

Нью-Йорк урамнары буйлап ялгыз йөрим. Байлык, бизнес шәһәре минем ушымны алмады. Минем дикъкатьне байлыктан, бизнестан читтәрәк торучы халык җәлеп итте. Олы күпер янында, пәрәме кеше йөри торган юлга гәзит җәеп йоклап ятучы карт кешене күрәм. Янында биштәре тора. Кырынмаган, өс-башының элә-танагы калмаган, кырык эт талаган чабулы яңгырлык бөркәнгән. Узгынчылар аның биштәрен атлап чыга, гәүдәсен әйләнеп узалар.

Кем ул? Нигә ул урамда йоклый? Юкса, күләгәле урыннар да Нью-Йоркта җитәрлек, аулаграк урыннар да бар. Нигә аны полисмен алып китми? Ни өчен бу ир кеше бу хәлгә төшкән? Үземе гаепле? Балаларымы? Нинди көчләр аннан бичара ясаган? Әллә ул үзен гарипләндергән шушы җәмгыять кешеләренә үч итеп, сез мине инкарь итсәгез дә, барыбер мин сезнең юлда ятам, дип шулай эшлиме? Бу сорауларга Илдар Агиш та туры-тулы җавап бирә алмады:

— Шушы күперне саклый ул! — диде Илдар ниндидер киная илә.

— Кемнән? — дим.

— Урыс шпиуннары килеп, күперне шартлатмасын, дип...

Мин Илдар бәйнең шаяртуын кабул иттем. Көлдем. Әмма сузылып ятып калган бичараны кызганып:

— Их, язмышлар диң, — дидем.

— Кызганма! — диде Илдар. — Ялкаулар монда шулай яшәргә дучар.

Чыннан да, урамда йоклаучыларга бер генә кеше дә игътибар итми, анда әллә ертык чүпрәк аунап ята, әллә кеше йоклый — һичкемнең гаме юк.

Ә үзебезнең урамнарда аунаучыларга игътибарлымы соң без? Юк бит! Сәрхүш! Исерек! Алкоголик! Аунасын! Аларга ярдәм итеп бетерерлекмени?

Кичләрен урамнарда йөргәнемдә андый йортсызларны күпләп-күпләп күрдем. Бәгъзеләре катыргы тартмадан башына каплавыч оя ясап йоклый; кояштан, җилдән саклана. Арада кара тәнлеләр дә, ак тиреләләр дә җитәрлек, җирле халык индеецлар гына күренмәде.

Монда, Америкада, бездәге кебек, туры мәгънәсендә хәер сорашу юк. Кул сузып, ялварып торучылар күренми. Әмма ике төрле фәкыйрь адым саен күзгә ташлана. Америкада тора салып хәер-сәдака өләшмиләр. Тора салып, хәйләләп акча таләп итмиләр, андыйларга монда урын юк.

Азатлык һәйкәленә бара торган юл кырында бер негр быргы уйнап тора. Алдында кечкенә телевизордан бушаган катыргы тартма. Акча салыр өчен ярык ясалган. Тартмага «РӘХМӘТ» диеп язылган. Ягъни акча салган кешегә аталган рәхмәт сүзе, чөнки рәхмәт әйтергә, негр авызы буш түгел, ул быргы уйный. Ул көне буе шушында төрле көйләр уйнап, акча җыя. Бик еш булмаса да, ара-тирә акча салып китүчеләр бар. Ничә доллар салганнарын күз элдерми, әмма кәгазь долларлар да, вак акча да салалар. Хәер җыюның бу төре хуплана, чөнки бу

музыкант эшләп ашый, эсседә, көне буе быргы уйнау хөрмәткә лаек хезмәт. Бирелгән акча хәер-сәдака түгел, хезмәт хакы. Америкада хәерче дә эшләп ашарга тиеш. Безнең урамнардагы чегәннәр, «без үзбәк—таҗик» диеп алдалап-йолдалап, хәйләләп йөрүчеләр Америкада сорана алмый, андыйлар әрәм тамак саналачак.

Икенче төр хәерче бар. Монысы чүп савытларына ташланган икмәк сыныклары, җимеш калдыклары, эчелеп бетмәгән сыраларны, суларны җыя. Хәерче сыеклыкны шундук эчә, җимешне ашый башлый, тамагы туйгач, артыгын янчыгына сала. Бу төр хәерчеләрнең күбесе сәләмә киенгән, йолкыш кыяфәтле, араларында акылга таманнар да бик еш очрый. Әмма гаҗәпкә калдым. Бер урамда бөтенләй башка төр хәерчене күрдем. Бу—олы яшьтәге негр яхшы киенгән, өстендәге тузанлык-яңгырлык чикмәне өр-яңа, кояштан-яңгырдан сакланырга кулына яхшы кулчатыр тоткан. Боларына да шаккатмас идем, хәерченең муенында берсе алтын, икенчесе көмеш ике чылбыр уйнаклый, һәр бармагында алтын йөзек, балдаклар. Үзе чүплектән ризык калдыклары эзли, таба, ашый, артыгын биштәренә сала. Узып баручы берәү туңдырмасын асфальтка төшереп җибәрде дә кул селтәп үтеп китте. Әлеге бай хәерче туңдырманы алды, юри генә өргән булды да бик тәмләп ашый да башлады. Ул беркемгә игътибар итми, минем бу кылмышымны кеше күрер диеп уфтанмый, ана да беркем дә бакмый. Ул әллә бар, әллә юк. Меңләгән кеше арасында ул япа-ялгыз. Хәерче шулай салмак кына йөреп, тамак туйдырып, бераз мая туплап, күләгәлерәк җиргә йокларга ятты...

Җан иясе яшәми торган чит-ят күк җисемендәге япа-ялгыз калган кеше сыман күренде ул миңа.

— Бер дә Казаннан артык җире юк икән бу Нью-Йоркның! — диде Зәһрә Шакирҗан.

Американың күзендә—Бродвейда татар артисткасының татар язучысына әйткән бу сүзендә бик күп мәгънә ята иде.

Шаярумы бу? Әйдә, шаяру булсын. Чокырлы-чакырлы тар урамнары, тупас сатучылары белән өтек кибетләре, адым саен кәфер сүз белән сүгенүче Казан; «ә» дигәнгә «җә» диеп торучы хезмәтчеләре, сокланудан күз бәбәгең атылып чыгардай бай кибетләре, һәр кешегә уңай-кулай булсын, дигән системага корылган илнең иң мәшһүр шәһәре Нью-Йоркның Казаннан артык җире юк икән ләбаса. Бу шаяру гына түгел—сатира. Казанга да, Нью-Йоркка да әче сатира. Әмма бу сүзләрдә тирән яшерелгән бер хакыйкатьне сиземләмәү мөмкин түгелдер. Шәһәрләрнең барысының да бер уртаклыгы бар. Таш йортлар урманы ешлыгында кешеләрнең күплеге; кеше күбәйгән саен, кешенең кадере бетә, шул байлык эчендә яшәүче бәндәләр бер-берсенә чит-ят, битараф, гамьсез. Чыннан да, мин Мәскәүдә дә, Истанбулда да, Нью-Йоркта да, мөмкин булса, хәтта Казанда да тормас идем. Тынычлыкка тарта күңел. Авылда ичмасам һәр очраган кешегә сәлам биреп, сәлам алып узасың, йомышың булмаса да, хәл-әхвәл сорашасың. Без—авылдан качып, шәһәргә оялап, яшәп арганнан соң, авылны идеаллаштырып, сагынып, җирсеп, шәһәрнең эссе чакта эссе, кышын суык бетоны арасында җан бирәбез.

Бродвейда адым саен театр. Адым саен ресторан, казино. Адым саен яшьләр. Яшь җегет белән бер гүзәл кыз үбешеп тора. Аларга һичкем игътибар итми. Алар да: ай-һай, кеше күрер дими—озаклап үбешә.

Нью-Йорк хәрәкәтле-утлы рекламалар шәһәре. Рекламага котчыккыч күп акча тотыла. Рекламага киткән акча җәл түгел. Димәк, реклама файда китерә, керем бирә. Адым саен кока-кола рекламалары.

Шәһәрнең мәркәзе Манхаттан утравына салынган йөз-йөз ун катлы йортлардан тора. Бу—рәсми шәһәр, эш үзәге: кунакханәләр, эш урыннары, кибетләр. Нью-Йоркның үз халкы монда яшәми. Алар Манхаттаннан читтә бер-ике катлы үз йортларында тора. Шәһәрнең ул өлешен татарлар «авыл» ди: без авылда торабыз, әйдәгез безнең авылга киттек, дип сөйләшә алар. Чынлап та, авыл дими, ни диярсең: һәр йорт тирәсе агач, чәчәк, чирәм белән уратылган. Көпшәләр су сиптереп тора, чип-чиста урамнар, хәрәкәт аз, шәһәрнең тонык гүләве монда ишетелми. Монда тынычлык, салмак хозурлык хөкем сөрә.

Нью-Йорк сары төстәге таксилар шәһәре. Һәр ун машинаның сигезе такси. Таксичыларның күбесе килмешәк: чалмалы индус, хач таккан урыс, кара гарәп, шәрык кешеләре. Таксисыз бу шәһәр яши алмас иде. Тәүлек әйләнә урамда такси өзелми. Чөнки төне буе шәһәрдә хәрәкәт туктамый. Көндез йоклап арганнар рестораннарга, урамга, кафеларга, театрларга китә, төнге клублар, казинолар шыгрым тулы була.

Гадәттә, урамдагы кешеләрнең карашлары сиңа тукталмый, шуып уза. Үзләренә мөштәри (клиент) эзләүчеләр генә кеше күзенә туры карый, сине күрә. Чөнки син аңа кирәк. Урам буйлап барганда берәрсе каршына чыгып:

— Кызлар кирәк түгелме? — диеп эндәшсә, гаҗәпләнергә кирәкми, бу адәм түләүле кызларга мөштәри эзли чыккан.

— Акча юк бит, нигыр дус, мин читтән килгән кеше,— дисәң, ул үзенчә сөйләнә-сөйләнә бәя төшерәчәк, син уңайсыз елмаеп китсәң, ул артыңнан калмый озак барыр. Андыйлардан тиз котылуның бер генә чарасы бар:

— Аем рашен! Мин — Русиядән, мин — урыс,— дисәң, кодалаучы шундук яныңнан таяр.

Спидтән курыкмасаң, кесәңдә долларлар булса, тәвәккәллә. Акчасыз калырсың, аның каравы хатыныңа «океан арты күчтәнәче» алып кайтырсың. Чөнки профессиональ тәтәйләр йортына баягы негр кебек урамнан чакырмыйлар.

Акчасызлык күпләрне әхлаксызлыктан саклап кала. Ирексездән саф әхлак иясе булу да ярап куя хет.

Юлым-йомышым төшмәсә дә, Нью-Йорк метросына төштем. Керү бәясе 1,2 доллар, безнеңчә алты мең сум. Мәскәүдә метро җиде йөз сум.

Бездәге чама белән Америкада бәяләр бик югары. Ләкин аларның хезмәт хакы да югары. Әйтик, Гайсә абзыйның айлык пенсиясе мең доллар, ягъни биш миллион сум. Татарстанда уртача пенсия йөз мең сум.

Урамнарда тәгәрмәчле каталар киеп машиналар белән рәттән чабышучы егетләр еш күренә. Бу ысул белән эшкә, укуга, кыз белән күрешергә дә баралар.

Күзәтүем вә фаразларым буенча Америкада өч төрле халык яши: нормаль кешеләр — 80 процент, җинаятьчеләр — 10 процент, корбаннар — 10 процент.

Русиядә ике төрле генә халык яши, минемчә: җинаятьчеләр — 40 процент, корбаннар — 60 процент.

Урамнарда гауга, сугыш, кеше кыйнаш кебек күренешләргә тап булмадым. Тәүлекнең кайсы вакытында булса да йөрү куркыныч түгел. Ресторан ишеге төбендә кеше кыйнауга очрамадым. Әмма полис машиналарының җан өшеткеч кычкыртып урам буйлап каядыр чабышулары бик еш булып тора.

Өемне басып чыгарлар, машинамны урларлар, дип курыкмыйлар американнар, әмма машиналар нык сак астына куела, сәпидләр, матайлар урамдагы баганаларга юан-юан чылбырлар, комган хәтле йозаклар белән бикләнә.

Хушлашу. Америкада алган тәэсирләр арасында иң олысы татар кешеләре белән халкыбызның язмышы турында сөйләшү мизгелләре булгандыр мөгаен.

Казанга кайткач дуслар сорар:

— Азатлык һәйкәленә бардыңмы?

— Бардым,— диярмен.

— Клинтонның кулын кыстыңмы? — диярләр.

— Кыстым,— диярмен.

— Йөз дә ун катлы йортларга кереп йөрдеңме?

— Йөрдем.

— Театрда булдыңмы?

— Булдым.

— Нигә бер дә исең китмәгәндәй кыланасың, әйтерсең лә, Америка синең өчен абзар арты.

Шулай, дөрес, исем китмәде. Индеец кабиләләрен алдап-йолдап егерме алты долларга сатып алынган Манхаттан атавына салынган Нью-Йоркның күктерәр йортлары мине шаккатырмый. Җирле халыкны начар туфраклы резервацияләргә куып тутырып, Азатлык һәйкәле салып куйган, әнә шул ялган азатлыкка табынган халыкка соклана алмыймын.

«Азатлык» диеп аталган хатын һәйкәленә менү сәяхәтчеләр өчен дәрәҗә икән. Ләкин аның өчен өч сәгать чират торырга кирәк.

Америкада бер генә җирдә чират бар, әнә шул хатын һәйкәле өстенә менәр өчен. Үзебезнең илдә дә чиратлардан туйган инде, чират тора-тора таш хатын өстенә менәсем килми, дидем.

Мине иярттә йөрүчеләр рәхәтләнеп көлә башладылар. Шулай итеп, мин аларны чират торудан, үземне таш хатын өстенә менүдән коткарып калдым. Азатлык хатынын таш итәге астыннан гына караштырып йөрдек тә киттек.

Кайтып киткәндә мин, очкычка утырып һавага күтәрелгәч, аска — Америка, Канада җирләренә карап уйга калдым.

Күптән түгел генә, ике ел әүвәл булса кирәк, АКШның Мәскәүдәге консулының ике ярдәмчесе Казанга килгән иде. Алар биш-алты татар язучысы белән дә очрашты. Аларны Татарстандагы милләтләрнең үзара мөнәсәбәте кызыксындыра иде. Сүз иярә сүз чыккач, мин әйттем:

— Дөньяда кара язмышлы, әче тәкъдирле ике генә халык бар: Американың җирле халкы — индеецлар һәм татарлар. Бу халыкларның фаҗигасе өчен кем җавап бирер? — дидем.

Бүген мин сүзләремә тагын: «чечен халкының ике тапкыр масса-күләм кырылышы өчен кем җавап бирер?» — дип өстәгән булыр идем.

1978 елда мин Югары әдәби курсларда Виктор Розов җитәкчелегендә драматурглар бүлегендә укыдым. Колумбның Американы ничек ачканлыгы һәм җирле халыкларга ул культура түгел, кырылыш алып килгәнлеге турында «Мин Америка ачтым» дигән трагипамфлет язган идем. Бу пьесаны укып чыккач, сөекле остазым болай диде:

— Дөрес, Американы яулап алганда индеецлар күпләп кырыла. Хәзер генә без моның вәхшилек икәнен аңлыйбыз. Әмма Колумб та, Писсаро да, Кортес та яхшылык эшлибез дип уйлаганнар, мотлак. Без бит бүген чебен-черкиләрне кырабыз. Килер заман, черки белән чебеннең дә табигать өчен бик кирәкле җаннар икәне ачыкланыр, шуннан соң синең белән мине судка тарттырырлармы?

Шуннан соң мин Розов семинарларына йөрми башладым.

Шундый ярымкүзаллау, ярымтөш халәтендә мин Мәскәүгә кайтып төштем.

Каршы алырга килгән дусларым:

— Бер-ике көнгә кунак булып Мәскәүдә кал! — дигән иде.

Мин:

— Рәхмәт. Тизрәк «Татарстан» поездына утыртыгыз, зинһар! — дидем.

Үз ватанымда, ягъни Татарстанда, мине, Русия индеецын, ни-нәрсә көтә икән?

*1995 ел.*

## Авторларыбыз игътибарына!

**«Казан утлары» журналына үз язмаларын, әдәби әсәрләрен, хатларын җибәрергә теләгән авторларның исләренә төшерәбез: безгә исем-фамилиягезне, әтиегезнең исемен, тулы адресыгызны (почта индексын да күрсәтеп) ачык итеп язсагыз иде. Бер үк вакытта паспорттагы тулы мәгълүматларыгыз да кирәк (паспортның сериясе, номеры, кайчан һәм кайда бирелүе, тору урыны күрсәтелергә тиеш). Болардан тыш, үзегезнең саклык кассасындагы исәп-хисап номерларын да төгәл күрсәтергә онытмасагыз иде. Болары гонорар түләгәндә һәм салым полициясенә мәгълүматлар җибәрү өчен кирәк.**

**Журнал редакциясе.**

# ТУКАЙ ГОМЕРЕНЕҢ БЕР ЕЛЫ

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты инде күптәннән өйрәнелә. Әдәбият галимнәре бу проблеманы игътибар үзәгенә куеп күп кенә китаплар, монографик хезмәтләр яздылар. Берничә мәртәбә шагыйрь әсәрләренең күп томлы тупламалары да басылып, киң катлам укучыларга җиткерелде.

Тукайга багышланган мемуар әдәбият тә шактый бай. Шуларның кайберләре архивта гына сакланса, күбесе матбугатта дөнья күргән.

Ләкин Тукайның тәрҗемәи хәле тарихи эзлеклелектә өйрәнелгән дип булмый. Шагыйрь тормышына караган аерым вакыйгалар һәм иҗаты белән бәйле фактлар, бәхәсле детальләр хроникаль яктан җентекләп ачыклауны сорый. Шуңа да аның иҗат һәм тормыш елъязмасын төзү мөһим мәсьәлә булып кала бирде. Бу ихтыяҗны истә тотып, 80 нче елларда ук Г. Ибраһимов исемендәге институтта бу мәсьәлә каралып, шушы эшне башкарып чыгу бер төркем хезмәткәрләргә йөкләнелде. Моның нәтиҗәсе буларак, «Габдулла Тукай: иҗат һәм тормыш елъязмасы» дигән хезмәт барлыкка килде. Һәм ул 12 басма табак күләмендә Татарстан китап нәшриятында быел басылачак.

Шулай ук, соңгы елларда Тел, әдәбият һәм тарих институтының кульязмалар һәм текстология бүлегендә Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты Нил Юзеев җитәкчелегендә «Тукай энциклопедик сүзлеге» эшләнә башлады. Шагыйрьнең иҗат һәм тормыш хроникасы бу зур күләмле хезмәттә дә урын алачак.

Биредә укучылар игътибарына шушы елъязманың 1912 елга караган өлеше тәкъдим ителә.

Китерелгән фактларның кайберләре тарихи яктан төгәл үк булмаска да мөмкин, шуңа күрә бәхәсле моментларның чыганаклары да күрсәтелде. Бер үк вакытта берничә чыганакка таяну исә фикернең нәрсәгә нигезләнүен күрсәтә.

«Елъязма» белән танышу Тукайны безгә тагын да якынайта төшәр, аның шәхесен ачыграк күрергә, иҗатын тулырак аңларга ярдәм итәр.

Әнисә АЛИЕВА,
*филология фәннәре кандидаты.*

## 1912 ЕЛ

Яңа 1912 нче елны Г. Тукай Өчиле авылында каршылый.

1 январь.

Г. Тукай язган «Былтырның хисабы» исемле фельетон «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Еллык отчет рәвешендә язылган бу фельетонда: **«Былтыр Петербургта «В мире мусульманства» дигән әллә нинди рус исемендә бер чын**

**мөселман пәйда булды. Ул әллә ниләр эшли... Багана-багана хәдисләр дәреж итә. Мусульманин, ди, панисламизм, ди, единоверцы, ди. Әл-хасыйль, бигрәк җете кызыл мөэмин булып кылана. Мөселманнар: «Ай-һай, тиз узмаса ярар иде»,— дип, шиктә торалар»**, дип яза.

Үзен политик, дип атаган Тукайның сизгерлегенә гаҗәпләнми мөмкин түгел: шагыйрь үлеп, ике-өч ел да үтми, әлеге басманың мөхәррире М. Хаҗи-Теләшинең провокатор һәм авантюрист булганлыгы фаш ителә.

«Ялт-йолт», 31 нче сан; Нуруллин И. Габдулла Тукай. Казан, 1979, 242 б; Лаисов Н. Габдулла Тукай. Казан, 1985, 68 б.

Шул ук көнне Өчиледән Казанга «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиевка хат яза. Үзенең авылдагы тормышыннан ризалыгын, канәгать икәнлеген белдерә. Ләкин ул анда ял итеп, дәваланып кына ятмый, туктаусыз эшли, яза. Үзенең яраткан журналы «Ялт-йолт» турында кайгыртудан туктамый: **«Ялт-йолт» чыккач, миңа җибәрерсез әле. Русча көлке журналлары җибәрегез. Иншалла, рәсем мәүзугълары[1] вә мәкаләләр җибәрсәм кирәк. Түбәндә адресым булыр. Фатихтан, бер дә ялыкмыйча, «Ялт-йолт»ка язгалаштыруын просить ит. Колагын тондырганнан соң гаҗиз калып, бер-ике нәрсә язса да файда. Габди[2] тавышы ахыры ни булып калды? Ул бер көн, бик шәбәеп, «Ялт-йолт»ның соңгы номерын эзләп йөридер иде... Берәр җирдә журналга бәйләнеп язарга йөрми микән...»** дип сорый һәм киңәшләр бирә. Шунда ук тулы адресын яза, ләкин кем сораса да бирмәгез, дип кисәтеп тә куя.

«Совет әдәбияты», 1961, 4 сан, 28 б.; Биштомлы «Әсәрләр», 5 т., 113 б.

Шул ук көнне Өчиледән Казанга «Мәгариф» матбагасының хуҗасы Гыйльметдин Шәрәфкә хат яза. Тукай үз әсәрләренең шактый өлешен шушы матбагада бастыртанга, алар якын мөнәсәбәттә булалар. **«Ниһаять, авылга кайтып җиттем. Сандык шикелле кечкенә генә, нараттан салынган ак өй үземнеке. Көненә ике ягылганга, бик җылы, тәмам чишенеп йоклыйм, иртә белән яңа сауган җылы сөт эчәм. Хәзер үк үземдә бераз яхшыру вә хәлләнү сизә башладым. Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм. Эшләр болай барса, бер-ике айдан сихәтләнермен кебек...»** дип, Тукай үзенең хәле турында яза.

Г. Тукай. «Мәҗмугаи асарь», 1914, 5 б.; Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 111 б.

Ел башында «Яшен ташлары» исемле китабы (икенче җөзьэ. Авторы: Шүрәле. Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы) басылып чыга. 24 биттән гыйбарәт бу китапның эчтәлегендә түбәндәге әсәрләр бар: «Борын», «Граммафонда татар җырлары», «Тормыш», «Өйләнү түгел сөйләнү», «Кайда? Кем?», «Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә», «Гаилә тынычлыгы», «Сөбханалла», «Зур бәшарәт», «Йокы», «Бер кайгы көнендә», «Тотса Мәскәүләр якан», «Бозау кадәрле зур фәлсәфә», «Төрекчәдән», «Исемнәребез хакында».

ТҮДА, 420 ф., 1 тасв.; Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 306 б.

12 январь.

Өчиле авылыннан Ф. Әмирханга хат яза. Хат үзе сакланмаган, бары тик конверты гына исән. Анда түбәндәге адрес язылган:

(заказное)
Казань, Евангелистовская,
Контора Б-р Шарафь
от Абдуллы Тукаева (дер. Малый Верезей[3] Казанск.
губ. и уезда, Ново-Кишитской вол.).
аста (Фатих Әмирханга тиз генә тапшырыгыз) дип язылган.

---

[1] Мәүзугълары — темалары.
[2] Г. Ибраһимов турында сүз бара.
[3] М. Верезей — Өчиленең русча исеме.

Конвертка Арча почта бүлегенең печате сугылган. Дата шуннан алып куелды.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Мирасханәсе[1] 9 ф., 2 тасв., 20 эш.

Январь.

Бераз тернәкләнүгә Тукай дәртләнеп эшкә керешә: **«...көне буе йоклап, төне буе язып утыра башлады. Язган язуларын Габдулла һәрвакыт миңа биреп куя иде. Арчага барганда, ирем аның язуларын почтага алып барып сала иде».** (Җиңгәсе Рабига истәлегеннән.)

Өчиледән Казанга Әхмәт Урманчиевка хат яза[2]. Хатта үзенең авылдагы тормышы, сәламәтлеген хәбәр итә: сөт эчүен әйтә, шулай ук күп эшләгәнлеге дә сизелеп тора: **«Миңа «Горе от ума» белән Лермонтов Полное Собрание сочинениесен җибәрә күр әле, кирәк.** (И. Нуруллин бу юлларны, Г. Шәрәфкә язган хаттан, дип раслый. Кара: «Истәлекләр», 253 б.)

**Теге рәкымнәр[3] астында языла торган нәрсә 20 рәкымнән артты.** (Син күргәндә 7 рәкым иде.) **Әгәр хөсне хатимә[4] белән тәмам булса исемен дә «Рәкымнәр астында» куярмыз. «Рәкымнәр астында» пессимистический рух белән башланган иде, монда бөтенләй оптимистландым, ахры»,**— дип, ике атна эчендә унөчтән артык эреле-ваклы шигырьләр язуын әйтә.

Хатта киләчәк тормышы турында уйланулары да чагылыш тапкан: **«Казанга апрель башларысыз кайтмаска дип торам. Чөнки «Болгар» белән «Шәрекътән өмид өздем... салкын булыр кебек... Әле авыл хатирәсе булыр дип бер йөргән, ике мендәр эшләтеп алдым. Моннан соңра мин фатирда гына торачак булганга, боннар тормышта да әһәмиятле нәрсәләр...»**

Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 114 б.; Рәбига Әмирова-Мөхәммәтжанова. Тукай Өчиле авылында. «Истәлекләр», 1986, 163 бит; И. Нуруллин. Габдулла Тукай, Казан, 1979, 246—247 бб.

20 январь.

Оренбургта «Вакыт» газетасы үз укучыларына Тукайның шигырь җыентыклары басылып чыгуын хәбәр итә: «Соң көннәрдә нәшер ителгән шигырь мәҗмугалары: М. Гафуриның «Моң вә зар», «Тәэссоратым». Г. Тукай: «Күңел җимешләре», «Яшен ташлары» (1), «Яшен ташлары». (Икенче җөзьэ.)

«Вакыт», 910 нчы сан.

21 январь.

«Мич башы кыйссасы» исемле юмористик очеркы «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

«Ялт-йолт», 32 нче сан.

Истәлекләрдән укып белгәнебезчә, аның Өчиледә авыл крестьяннары белән аралашып-сөйләшеп утырган чаклары да була. Ара-тирә ишек алдындагы мәдрәсәгә кереп, хәлфәнең дәрес биргәнен тыңлап утыруын һәм чатнама суыкта яланаяк мәдрәсәгә йөргән бер малайга Казаннан киеп кайткан киез итеген бүләк иткәнлеген дә, һәм, әлбәттә, мулла агасының кечкенә кызы Нурания һәм песи белән рәхәтләнеп, ихластан уйнавын да күз алдына китерәбез.

Рәсулева З. «Тукай эзләреннән». Казан, 1985, 60 бит; Нуруллин И. «Габдулла Тукай». Казан, 1979, 248 бит.

---

[1] Алга таба «Мирасханә» диеп кенә күрсәтеләчәк.

[2] Бу Әхмәт Урманчиевка 1 январьда язган хатның дәвамы булуы ихтимал. (Биштомлы «Әсәрләр», 5 т., 114, 286 бб.)

[3] Рәкым — цифр.

[4] Хөсне хатимә — яхшы нәтиҗә.

11 февраль.

«Балалар күңеле» китабы (икенче кыйсем. Казан, «Өмид» матбагасы) басылып чыга.

«Яшен ташлары» исемле китабы (беренче җөзьэ, 2 нче басма. Авторы: Шүрәле. Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы) басыла. Беренче басмасы белән әлеге икенче басма арасында үзгәреш юк.

ТҮДА, 420 ф., 1 тасв.; Биштомлы «Әсәрләр». 5 том, 306 бит.

27 февраль.

«Сабитның укырга өйрәнүе» исемле шигырен яза. Шигырь И. Н. Харитонов чыгарган «Татар әлифбасы» дигән китапка кушымта итеп, рәсемнәр белән басылган.

«Татар әлифбасы». Казан. 1912, 17 май; Биштомлы «Әсәрләр», 2 том, 373 бит; Мирасханә, 9-ф., 1 тасв. 17 эш.

Февраль азагы, март башы.

Туганнарының «Тагын бераз тор әле», дип кыстауларына да карамастан Тукай февраль азагында Өчиледән Казанга кайткан. «Казанга кайтыш» исемле автобиографик очеркыннан (11 нче мартта басылган) күренгәнчә, ул Казанга кайткач тыныч, аулак җирдән фатир табып, шау-шулы иптәшләреннән читтәрәк яшәргә карар бирә. Һәм ул квартирада бер атна чамасы торып та чыга.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Өчиледән киткәндә ул инде рухи һәм физик яктан да ныгый төшкән, озак-озак утырып яза, эшли башлаган.

Казанга аны Хәбир абыйсы ат белән илтеп куя. Рабига җиңгәсе шагыйрьгә ике мамык мендәр бүләк итеп биреп җибәрә.

«Ялт-йолт», 35 сан, Рабига Әмирова-Мөхәммәтҗанова. Тукай Өчиле авылында. «Истәлекләр», 163, 249 бб.

11 март.

«Казанга кайтыш» очеркы «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Бу биш өлешкә бүленгән очеркның беренче өлешендә авыл тормышы, халыкның уй-фикере тасвирлана. Авыллардагы ачлык хәлләрен сөйли, наданлык турында искәртә.

Очеркның икенче өлешендә иртәнге сәгать алтыдан кичке сәгать җидегә чаклы Өчиледән Казанга кадәр булган юлда күргәннәре, төрле исемдәге авылларны үтү, Тимерче, Чыпчык, Киндерле..., шуларга нисбәтән уй-фикерләре тасвирлана.

III, IV, V нче бүлекләрдә исә Казанга килеп урнашкандагы маҗараларын яза. Тыныч квартирада торып, ялгызы эшләргә, укырга-язарга план корса да, фатир хуҗалары — мещанкалар белән килешә алмыйча тагын номерга урнаша. «Свет» кунакханәсенең (хәзерге Чернышевский урамы) бик матур якты бер паркет идәнле бүлмәсенә урнаша. Әмма дөньяда бер нәрсә дә камил булмый, яхшының да начар ягы табыла икән. Бу мактаулы номер да күсе оясы булып чыга. Шуннан мәче эзләп тә таба алмыйча йөрүе һәм төнлә үзенең песи булып мияулавы искиткеч юмор белән тасвирлана.

31 март.

«Ялт-йолт» журналының 36 нчы саны дөнья күрә. Бу санда Тукайның «Америкадан Вәли муллага телеграм», «Вәли мулладан Америкага», «Көлеп язмыйбыз, көлеп әйтмибез» исемле фельетоннары «Гөмберт» имзасы белән басылган («Ялт-йолт»ның 26 нчы санында басылган «Өч баш» исемле мәкаләнең дәвамнары). Шул ук номерда «Яз галәмәтләре» исемле шигыре «Городской ломбард» дигән рәсем асты итеп имзасыз басылган һәм «Мәкальле киңәшләр» мәкаләсе дә «Гөмберт» имзасы белән кертелгән.

Март ахыры, апрель башы.

Истәлек өчен фотога төшә. (Ак күлмәк, бант бәйләп костюмнан төшкән рәсем). Аның бу фоторәсеме «Гасыр» нәшриятында почта открыткаы формасында эшләнеп таратылган.

Габдулла Тукай. Альбом. Казан, 1978, 126 б.

Апрель башы.

Фатирда яшәү шартларыннан канәгать булмыйча, Тукай «Свет» кунакханәсенең бер матур, якты номерына урнашып яши башлый. **«Иптәшләрнең: «Синдә чахотка бар»,— дию ләреннән гаҗиз булып, алардан читтәрәк бу номерга күчкән идем»,**— ди үзе Габдулла Гыйсмәтигә (1883—1939) монда күчүенең сәбәбен аңлатып.

Габдулла Гыйсмәти. Ике елдан соң бер хисап. «Замандашлары», 159 б.

Апрель башы (бәлки элегрәк тә).

Петербург мулласы, дин галиме, җәмәгать эшлеклесе Муса Бигиевтән Петербургка килергә чакырып бер-бер артлы ике хат ала.

И. Нуруллин. «Габдулла Тукай». Казан, 1989, 255 б.

Апрель башы.

Дусты Габдулла Гыйсмәти белән очраша. Ул, «авыру» сүзен кулланмыйча гына, Тукайны Казаннан китеп, һавасы әйбәт булган җиргә барып хәл җыярга өнди һәм шуңа күндерә. Сөйләшү вакытында Кырымга баруның яраганлыгы исбат ителә. Ләкин Тукай ялгызы ул якларга чыгып китәсе килмәвен әйтә. «Син барсаң гына, ул якка барам...» ди.

Габдулла Гыйсмәти. Ике елдан соң бер хисап. «Истәлекләр». 168 бит.

7 апрель.

«Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» исемле шигырен яза.

«Ялт-йолт», 37 нче сан, 15 апрель.

14 апрель.

Җәй буе кыргыз даласында кымыз белән дәвалануны күздә тотып (Троицк мулласы Габдерахман Рахманкулов та чакырып киткән була), Троицкига барырга, беразсәламәтләнгәч, көз көнендә Петербургка барып докторга күренергә ниятләп, «Фултон» пароходында Казаннан Самарага юнәлә[1]. Аны пристаньга дусты, «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиев озатып төшкән.

«Йолдыз», 17 апрель, 820 нче сан; «Ялт-йолт», 40 нчы сан.

15 апрель.

«Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигыре басылып чыга. Әсәр Тукайның якын дусты Хөсәен Ямашевның (1882—1912) вакытсыз үлеме мөнәсәбәте белән язылган.

«Ялт-йолт», 37 нче сан; «Йолдыз», 817 нче сан.

---

[1] Р. Гайнанов Тукайның Самарага китү көнен 4 апрель дип күрсәтә. (Биштомлы «Әсәрләр», 5 т., 270 б.)

«Шыер» әсәре «Айнюк Самакай малае» дигән имза белән басылган.
Хөсәен Ямашев үлгәч, Казандагы бер төркем иптәшләре аңа багышлап «Йолдыз» газетасына кушымта бит чыгаралар. Шул кушымтага басар өчен, журналист, язучы Фәхрелислам Агиев (1887—1938) Лермонтовның «Ангел» исемле шигыренә охшатып бер шигырь язып җибәрә. Шигырь «мишәрчәрәк» килеп чыкканга, Тукай аңа пародия рәвешендә шушы шигырен яза.

«Ялт-йолт», 37 нче сан; Биштомлы «Әсәрләр», 2 т., 375 бит.

«Һазиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа» шигыре «Кыйссасел-әнбия (Рабгузи)» имзасы белән басылып чыга. Шигырь Әстерханда чыккан «Бөрһане тәрәккъый» газетасы мөхәррире, алдынгы фикерле кешеләргә, революцион демократларга матбугат аша һөҗүмнәр ясаучы, татар телен төрекләштерергә чакыручы Мостафа Лотфи Исмәгыйлев-Ширванскийга каршы язылган.

«Ялт-йолт», 37 нче сан; Биштомлы «Әсәрләр». 2 т., 371 б.

15 апрель, кич.
Пароход белән Самарага килеп төшә («...икенче көнендә бугай, төнгә табарак Самарага җиттем»). Анда бик мәһабәт бинага урнашкан «Бристоль» кунакханәсенә туктый. Шул көнне үк Самараның мулласы, «Икътисад» журналы мөхәррире Фатих Мортазин белән очрашып, озаклап сөйләшеп утыралар.

Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 47—48 бб.

16 апрель.Сәяхәтен дәвам итеп, Самарадан поезд белән Уфага китә. Аны вокзалга Фатих Мортазин җибәргән шәкерт резиналы фәйтүн белән озатып куя.

«Ялт-йолт», 41 нче сан.

Самарадан Уфага барып җитә. Уфада Тукай «Сабах» көтепханәсенә туктала. Биредә ул шагыйрь Мәҗит Гафури белән очраша. Моңарчы М. Гафури белән танышлыклары язылган әсәрләре аркылы гына һәм Тукайның Гафури әсәрләренә үткен тәнкыйть рецензияләре дә язганын уйласак, бу очрашу аларның икесен дә дулкынландырган. Әмма алар рухи берлек һәм бик тиз уртак тел табалар. Сөйләшеп, фикер алышып ике көн бергә үткәргәннән соң, ул аңа үзенең Петербургка чакырылганын һәм анда барып кайтырга теләвен белдерә. Чөнки кымыз сезоны башланмаган, әле иртәрәк була.
Тукай Петербургка барачагын хәбәр итеп телеграмма суга. Уфада Тукай бик гади генә итеп «Сабах» көтепханәсенең бер буш бүлмәсенә генә урнаша да, көннәре күңелсез үтми: **«Квартир гомумән күңелле. Кеше күп килә. Эч пошырлык түгел. Монда һәр көнне мөхәтдисе кәбир[1] Әхмәтфәиз Даутов белән күрешәбез. Ул скрипкәдә маташтыра, әлегә яхшы уйный алмый. Ләкин җырласа, мин андый җыруны бөтен гомеремә тыңлар идем. Аның гади сөйләшүдә дә металлический вә музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вә голүвиятен[2] изһар итә[3]»,** дип язып, татар-башкорт көйләрен тыңлап рәхәтләнгәнен әйтә.

Мәҗит Гафури. Габдулла Тукай Уфада. «Истәлекләр», 1986, 175—176 бб.; Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 53 б.

17 апрель.
Тукайның сәфәре хакында хәбәр басылып чыга: «Г. Тукай 14 апрель Самарага китте, аннан озак вакытка кымызга чыга».

«Йолдыз», 820 нче сан.

---

[1] Мөхәтдисе кәбир — хәдисләрне (пәйгамбәр сүзләрен) әйбәт белүче.
[2] Голүвият — бөеклек.
[3] Изһар итү — ачып бирү.

18 апрель.

Х. Зәбири алып биргән билет белән поездда Тукай Уфадан Петербургка китә.

20 апрель.

Иртәнге сәгать сигездә поезд белән Николаевский вокзалга килеп төшә. Үзен чакырып хат язучы Муса Бигиевкә телеграмма җибәргән булса да, аны каршылаучы булмый. Ул, извозчикка утырып, М. Бигиевнең өенә бара (Сергеевская, 81). М. Бигиев аны кабул итә һәм үз өендә, үзенең бүлмәсенә урнаштыра. Тукай биредә үзенең элекке танышлары, иптәшләре белән дә күрешә алмаган хәлдә 5 көн яши.

Муса Бигиев белән бергә Петербург имамы, җәмгыяте хәйрия мәктәбенең мөдире Лотфулла Исхаковларда кунакта була. Шагыйрь белән күрешергә курсистка кызлар киләләр. Ләкин, авыруын сылтау итеп, Тукай аларны кабул итмәгән.

Петербург бае, Муса Бигиевләр партиясе тарафдары Галим Максудов үзенең Истанбул дарелфөнүнен тәмамлап кайткан улы Кәрим белән күрешер вә танышыр өчен, үзләренә кунакка чакырып Тукай янына киләләр.

Биштомлы «Әсәрләр» 5 т., 57 б.; И. Нуруллин. Габдулла Тукай. Казан, 1979, 261—262 бб.; Әхмәтҗанов Шәриф. Искә төшерү, «Хатирәләр», 166 б.

24 апрель.

(Петербургта бишенче көне.) «Нур» газетасы редакторы Сафа Баязитов студент Шәриф Әхмәтҗанов (Манатов) аркылы Тукайга дәгъватнамә җибәрә. Кичен Кәбир Бәкер (1883—1939) дә Тукай белән очрашуга бара.

«Ялт-йолт», 45 нче сан; Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта. «Истәлекләр», 179 б.

25 апрель.

Тукай «Нур» газетасы идарәсенә бара. Анда ул элекке иптәшләре Кәбир Бәкер, Габделкәрим Сәгыйтевләр белән күрешә. Сафа Баязитов, студент Шакир Мөхәммәдьяров белән очраша. Ул Муса Бигиев өендә яшәп ятудан кыенсынуын һәм аерым номер алып торасы килүен әйтә.

Иптәшләре белән бергәләп карап, Невский проспектка якын «Казанская» исемле кунакханәнең (хәзерге Плеханов урамы, 5 нче йорт) бер номерында урнаша. Монда Тукай үзе хуҗа, тулы ирек. Таныш-белеш һәркайсы килә, теләгәнчә утыра. Шагыйрь үзе: **«Тагын үземнең мөкатдәс ялгызлыгыма кайттым...»** дип сөйли бу турыда, ягъни үзе хуҗа, үзе теләгән кешеләр белән аралаша: **«Менә Шакир әфәнде Мөхәммәдьяров килеп чыкты. Менә укучы яшьләр, мөгаллимнәр, менә Габделкәрим Сәгыйтов. Инде монда күңелсезләнергә урын калмады. Чөнки минем бүлмәм чирек сәгать тә кешесез тормый».**

Сафа Баязитовның чакыруы буенча аның өенә кунакка бара. Анда граммофонда Пушкин, Лермонтов әсәрләрен, «Евгений Онегин» арияләрен яратып тыңлый.

Опера һәм балет театрына барып «Евгений Онегин» операсын тыңларга планлаштырып билетлар да алына, ләкин Тукай, авыруы сәбәпле (көннең яңгырлы, юеш, салкын булуы Тукайда бизгәкне көчәйтә), операга бара алмый калалар.

«Мәкаләи махсуса» «Ялт-йолт», 45 нче сан; Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта. «Истәлекләр», 192 б.

26 апрель.

«Ялгыш уйланмасын» исеме белән «Ялт-йолт»ның 37 нче санында басылган һәм «Йолдыз» газетасына күчерелгән «Хөрмәтле Хәсәен ядькяре» исемле шигырендә «Йолдыз» идарәсенең «әүлиялар» дигән сүзгә ялгыш аңлатма бирүе турында искәрмәсен яза.

**«...Минем шигыремдәге «әүлиялар» сүзе үзенең чын-дөрест мәгънәсе белән «изгеләр» мәгънәсендә генә аңланырга тиеш...»**

«Ялт-йолт», 39 нчы сан, 1 июнь.

Апрель ахыры (6 майга кадәр).

Ш. Әхмәтҗанов Тукайга Петербургта чыга торган большевистик «Звезда» газетасында басылган Хөсәен Ямашев турындагы мәкаләсен күрсәтә. Шагыйрь укый да: **«Менә заман. Безнең хакта пайтәхеттәге рус газеталары да сөйли башладылар бит. Күптән кирәк иде... Мин Хөсәен мәрхүмне тәкъдир вә ихтирам итәм һәм аны бик сагынам... Мин үзем социалист түгелмен, шуның өчен дә ул мәсләктәге кешеләр хакында артык сүз сөйли алмыйм. Фәкать, һәркем үз мәсләген гүзәл аңлап, чыннан халыкка, ватанга хезмәт итсен иде»**,— ди.

Әхмәтҗанов Шәриф. Искә төшерү. «Хатирәләр», 168 б.

Дуслары Тукайны докторга күренергә үгетлиләр һәм, ризалыгын алгач, Ш. Мөхәммәдьяров аны университет докторы Александр Робертович Поль әфәндегә күрсәтә.

**«Петербургта университет докторына күрендем, кыяфәте белән пәйгамбәр төсле кеше икән. Ул кымыз белән дәваланырга кушты. Аны Шакир Мөхәммәдьяров минем номерыма алып килгән иде»**,— дип яза ул турыда Ә. Урманчиевка.

Доктор Тукайның иптәшләренә: «Туберкулезның соңгы дәвере... тын ала торган әгъзаларының дүрттән бере белән генә сулап тора»,— ди. Тукайга Петербургтан тизрәк китәргә, санаторийга барып дәваланырга киңәш итә.

Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 115 бит; Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта, «Истәлекләр», 192 б.

«Нур» идарәсенә ул яңадан да килеп йөри. Яңа килгән татар гәзитләрен укып, танышып бара, алардан аерым мәкаләләрне кисеп алып, «Нур»да басарга тәкъдим итә. Петербургка килгәндә аның янында бер җирдә дә басылмаган берничә яңа шигыре була. Кәбир Бәкер истәлегенә караганда, ул «Нур» газетасында шуларның берсен — «Дин вә гавам» исемле шигырен бастырырга риза була: **«Ләкин соңыннан аның да «Нур» мәсләгенә муафикъ булып бетмәгәнлеге аңлашылды. Бу шигырьдә Тукай хәзерге дин башында торучыларны «каргалар» дип атый. «Нур» исә мулла вә мөәззиннәр «органы» булганлыктан, дин башында торучыларга ул тарызда[1] тел тидерергә разый түгел».**

Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта «Замандашлары», 180 б.

«Нур» газетасы мөхәррире Сафа Баязитовка «Йолдыз»да Садыйк мулла Иманкуловның Муса әфәндегә каршы язган «Ифрат» исемле мәкаләсе барлыгын һәм шуны алып «Нур»да басарга тәкъдим итә. С. Баязитов, Муса әфәндегә каршы язарга кушмыйлар бит дисә дә, Тукай: **«Аның мәкаләсенә әһәмият бирерлек бар»**,— ди. Һәм «Нур»ның 208 нче номерында «Ифрат» басылып та чыга.

Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта Оренбург, 1914 ел, 63 б.

«Нур» газетасы идарәсендә утырып, идарәгә килгән хатларны, мәкаләләрне, шигырьләрне караштыра. Тоз-түбәдән бер мөгаллим Хәбибрахман Әлмөхәммәдевнең җибәргән шигырьләреннән берсен азрак төзәтеп газетада бастырырга киңәш бирә[2]. К. Бәкер аны пессимистик рухта язылган дисә дә, Тукай: **«Бер нәрсә дә юк бит инде... Шулай да әһәмияте бар. Пусть халык башымыздан кичердекемез**

---

[1] Тарыз — рәвеш сурәт.

[2] «Тормыш» исемле шигырь «Нур»ның 1912 елгы 208 нче санында басылган. Сүз шул турыда бара.

**көннәрнең өмедсез — кара көннәр икәнен белеп калсын... Аның характерный ягы шул: бүген кулына чак каләм тота белгән татар балаларының бары да шул өмедсезлек җырларын җырларга мәҗбүрләр.. Менә шул хәзер матбугатта бик нык сизелеп калырга тиеш...»**

Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта. Оренбург, 1914, 38 б.

4—5 май.

Петербургтан китәсе көннең алдагысында мәктәп балаларының шагыйрь белән очрашасылары килгәнен хәбәр итәләр, һәм мәктәптә укыган ир вә кыз балалар исеменнән Тукайга (номерына) алты кешелек делегация җибәрелә. Вәкилләрдән өчесе кыз, икесе ир бала, берсе мөгаллим Мәхмүт Сипаев була.

Кыз балалар чәчәк букеты, ир балалар бик матур карасавыт бүләк итәләр. Карасавытта бронзадан бер ау эте белән сумка сурәте төшерелгән эмблема була. Истәлекләргә караганда, Тукай бу шәкертләргә дә һәм бүләкләргә дә бик куанып кала. «Шәкертләр киткәч... бик озак карасавыт өстендәге эт белән сабыйлар кебек шаярып ятты»,— ди К. Бәкер.

«Хатирәләр», 160 б.

5—6 май.

Тукайның Петербургтан китәсе тәгаен билгеле булгач, иртән Сафа әфәнде Баязитовның Мойкадагы квартирында шагыйрь хөрмәтенә иртәнге аш мәҗлесе ясала. Кич белән зур бер сәүдә оешмасында хезмәт итүче Мөхәмматша Җиһаншин фатирасында Тукай хөрмәтенә озату мәҗлесе үткәрелә. Биредә приказчик вә сәүдәгәрләрдән башка, яшьләрдән Шакир Мөхәммәдъяров, Кәрим Сәгыйдев, Кәбир Бәкер, берничә Петербург мөгаллиме, Муса Бигиев, Петербург имамнарыннан Сафа ахун Баязитов, Лотфулла Исхаков катнаша. Кунакка чакыручы күп булса да, Тукай ул дәгъваларны кире каккан. Хикмәт авыруында һәм һаваның салкын юеш булуында гына түгел, әлбәттә. Шуңа күрә сәүдә хезмәткәрләре һәм приказчиклардан торган 30—40 лап кеше, шагыйрьне бер генә мәртәбә «мәшәкатьләргә» теләп уртак мәҗлес оештыралар. Мәҗлескә җыйналган халык Тукайны бик яратып, җылы кабул итәләр. Чөнки,— дип яза К. Бәкер,— кайсының углы, кайсының кызы бар. Боларның мәктәптә иң яратып укыган китаплары Тукаев әсәрләре, Тукаев шигырьләре идеке мәгълүм. Мәҗлестә булганнарның берсе үзенең ун яшьлек бер баласының Тукайны белгәнлеген сөйләде. Тукаев килгән дигәч, бу бала анасына Тукайны шулай тәгъриф кылган: «Ул минем шикелле кечкенә бер Апуш булган, шуннан соң «зуп-зур Тукай булган».

Мәҗлес күңелле генә үтә. Мәҗлестә сөйләнгән сүзләрнең күбесе Тукайга ихтирам һәм хөрмәтне белдереп, аның сәламәтләнеп, яңадан матур бер вакытта Петербургка килеп кунак булырга чакыру була. Ахырдан мәҗлесне ясаучылар исеменнән Тукайга адрес тәкъдим ителә һәм акчалата бүләк тапшырыла.

Үз чиратында Тукай мәҗлесне оештыручыларга һәм үзен хөрмәт итеп очрашуга килүче милләттәшләренә рәхмәтен белдерә. Петербургның юешсалкын һавасы сәламәтлегенә начар тәэсир итүен һәм тизрәк моннан китеп, кымыз эчеп дәвалану нияте белән Уфа вә Троицк якларына сәфәр кылачагын әйтә.

Шәриф Әхмәтҗанов. Искә төшерү. «Истәлекләр», 205 б.

Әлбәттә, авыру шагыйрь тиктән генә ерак юлга сәфәргә чыгып китмәгән. Ул, башкалага баргач, күп нәрсәне белергә, күрергә, танышырга хыялланган була. Ләкин авыруы көчәю аркасында, теләкләре үтәлми кала. «Мәкаләи махсуса» әсәрендә үзе болай яза: **«Мин дә Петербургка бардым, дегет чиләге дә! Никадәр мөмкин була торып, Думага керә алмадым. Финляндиягә чакырдылар, анда бара алмадым. Бер театрга, бер музейга вә, гомумән, бер достопримечательный җиргә булсын йөреп булмады: әлеге хәстәлек!**

**Тик Сафа әфәндегә барганда гына бер җан рәхәте була иде».**

«Нур» газетасы редакторы Сафа Баязитовның искиткеч бай граммофон язмалары (пластинкалар) фондыннан төрле арияләр тыңлап, илаһи музыка белән ләззәтләнгән Тукай.

Бирдә ул А. С. Пушкинның «Евгений Онегин» романы буенча П. И. Чайковский язган операны да беренче мәртәбә буларак ишетә. Киләчәктә опералар тыңларга йөрермен дип күңеленә беркетә.

«Мәкаләи махсуса», «Ялт-йолт» 45 нче сан (5 ноябрь).

6 май төне.

Петербургның Николаевский вокзалыннан Тукай поезд белән Уфага китә. Вокзалда аны озатырга дуслары һәм фикердәшләре Кәбир Бәкер, Шәриф Әхмәтжанов, Шакир Мөхәммәдъяров, Кәрим Сәгыйдев һәм башкалар белән бергә, имамнардан Сафа ахун Баязитов, Лотфи әфәнде Исхаков, зыялы мөгаллимнәр, байлар, төрле сәүдә йортларында хезмәт итүче мөселман приказчиклары, төрле мәктәпләрдә укучы яшьләр, студентлардан торган 30 лап кеше җыйнала. Һәммәсен дә, сыйнфый аерымлыкларны куеп торып, бөек шагыйрьне ихтирам белән озатып калу теләге берләштергән һәм бирегә китергән, әлбәттә.

Үзе бу турыда: **«13 көн Петербург ризыгын ашагач тагы Уфага таба сәфәр иттем»**— дип яза «Мәкаләи махсуса» дигән әсәрендә.

Өченче класстан плацкарт белән билет алына һәм Кәбир Бәкер Тукайны Мәскәүгә кадәр озата бара.

Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта. «Истәлекләр». 200 бит; Биштомлы «Әсәрләр». 5 том. 62 б.

7 май, иртәнге сәгать 10 нарда.

Петербургтан Мәскәүгә килеп җитәләр һәм озак тормыйча Тукай Уфага юнәлә.

Кәбир Бәкер истәлегендә болай яза: «Иртәгесе көн сәгать 10 нарда Мәскәүгә җиттек. Анда Николаевский вокзалдан Рязанский вокзалга күчеп, аш (обед) ашап, чәй эчүгә поезд килде. Бик сайлап бер урын алып, Тукайны утыртып озатып калдым. Ялгыз китәргә булгач бик уңайсызланган кебек иде. Уфадан язган хатында бик яхшы кайтканлыгын белдерде.

Кәбир Бәкер. Тукай Петербургта. «Истәлекләр» 200 б.

8—9 май.

Петербургка сәяхәтендә унбиш көн чамасы йөреп, яңадан Уфага кайта. Бу сәфәрдән ул гаять йончып, арып кайта. Бу вакытта инде Уфа яшәргән, агачлар яфрак ярган, җир өсте яшел мамык кебек яшь үләннәр белән капланган, кымызлар әзерләнгән була. Тукай Уфаның саф һавасын, матур бакчаларын ярата, кымыз эчә. «Сәламәтлек һавасы эчәм»,— дип сөйли иде Тукай, ди Мәҗит Гафури үзенең истәлегендә.

Мәҗит Гафури. Габдулла Тукай Уфада. «Замандашлары», 164 б.

8—9 майдан соң.

Тукай Уфада яши.

«Уфа Тукайның дәрәҗәсенә мөнасип һичбер хәрәкәт күрсәтә алмады. Тукайның Уфага килү хөрмәтенә һичбер мәҗлес-фәлән тәртип кылынмады. Аның Уфага килгәнен күп кеше белми дә калгандыр.

Тукайның Уфада үткәргән ун-унбиш көн гомере «Сабах» көтепханәсенең артындагы бүлмәдә үтте»,— дип яза М. Гафури.

Истәлекләргә караганда, Уфада Тукай Себер якларында мөгаллимлек кылучы Мөбарәк Әмиров белән очраша. Ул аннан Себергә кайчан баруы, анда нинди шартларда эшләве һәм кемнәрне укытуы турында гаять кызыксынып сораша.

Уфада яңадан докторга күренә. Бу турыда 12 майда Кәбир Бәкергә язган хаттан укыйбыз: «Уфа докторына кан тәхлиле тугърысында бардым... Җүтәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә кушты».

«Замандашлары», 164 б.; Тукай Башкортстанда. Уфа, 1966, 44 бит; Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 117 б.

11 май.

Уфадан Казанга Әхмәт Урманчиевка хат яза. Анда ул үзенең Уфадан Петербургка баруын һәм аннан кире кайтуын хәбәр итә. Бу сәфәрдән канәгатьсезлеген белдерә. Андагы суыклыктан һәм шуның аркасында килеп чыккан бизгәк авыруыннан зарланып, шул шәһәрдә үткәргән 12—13 көн гомерен кызганып искә ала. Уфада гына торган булсам, хат түгел, мәкаләләр дә язган булыр идем, ди... «Ялт-йолт»ның үзе Казаннан киткәч чыккан 37—39 саннары хакында фикере белән уртаклаша. «37 нче санның беренче сәхифә рәсемен Галиәсгар[1] бозып чыгарган»,— дип ачына. Бөтенләй Тукай катнашыннан тыш эшләнгән 38 нче сан (29 апрель) турында: «38 «Ялт-йолт» гомумән яхшы чыккан. Мәскәү мулласының лекциясен әүвәлге биткә басарга кирәк иде. Бу номерда да әдәпсез сүзләр бар. Шундый сүзләргә юл киселсен иде»,— ди.

Тиздән Троицкига китәсен хәбәр итеп: «...минем корзинкада онытылып калган кара тышлы дәфтәрне дә җибәрсәңез иде, зинһар. Ул дәфтәрдә минем «Җан азыклары» дигән почти шул мәҗмугалек шигырьләрем бар»,— дип сорый, «Хәзер Уфада булсам да, сезнең өчен адрес: «Троицк (Оренбург. губ.) Абдрахману Рахманкулову. Передать А. Тукаеву»— дип яза. Димәк, ул тәгаенләп үзен чакырган Габдрахман хәзрәткә бара һәм Троицкийда яшәгән вакытта аның белән элемтәдә торачагы аңлашыла.

Биштомлы «Әсәрләр». 5 т., 115, 288 битләр.

12 нче майга кадәр.

Уфадан Петербургка «Нур» газетасы редакторы Сафа Баязитовка хат яза (тексты табылмаган).

Кәбир Бәкер. «Тукай Петербургта», Оренбург, 1914, 11 б.

12 май.

Уфадан Петербургка дусты Кәбир Бәкергә хат яза. Петербургтан Уфага кайту уңайлы, җайлы булды дип хәбәр итә. Петербургта күрешкән, аралашкан иптәшләре Кәрим Сәгыйдов, Шәриф Әхмәтҗанов (Манатов) ка сәлам тапшыруны үтенә. Шакир Мөхәммәдъяровка «пәйгамбәр» төсле кешесе өчен» (доктор) аеруча рәхмәтен белдерә.

Петербургтан кайткач, Тукай Уфада бер атналап тора. Монда шагыйрь күбрәк вакытын М. Гафури белән уздырган. Кымыз сатыла торган бакчага чыгып, яшел чирәм өстендә кымыз эчәләр, Агыйдел буендагы бакчага чыгып биек ярдан баржа, буксир, салларны күзәтәләр... Бер атнадан соң әүвәлге карары буенча, кымыз эчәр өчен Троицкига китәргә карар кыла.

Уфада журналист һәм әдәбиятчы Габделбари Батталов (1874—1959) белән очраша.

Май урталары.

Габделбари Баттал аны поезд белән Троицкига озатып җибәрә. Ләкин билет алганда, ялгышлык килеп чыга. Тукайга Полетаевкага барырга кирәк, ә поезд анда туктамый, туры Чиләбегә бара икән. Тукай Чиләбедән ат яллап кире Полетаевкага кайтырга карар итә.

Г. Баттал Тукайны каршы алырга кушып Чиләбегә уртакул сәүдәгәр А. Галиевкә телеграмма җибәрә.

«Мәкаләи махсуса», Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 63 б.

Чиләбе вокзалында Тукайны Галиев каршылый. Аның өенә барып чәй эчеп, хәл җыйганнан соң Тукайны извозчикка утыртып озатып җибәрәләр: «Чәй янында хата билет алганлыкны сөйләп, Троицкига барырга бирәр иптәш юкмылыгын сораштым. Бу мөхтәрәм әфәнделәр, мин аштан соң ятып хәл җыеп торганчы, иптәш тә тапканнар. Ат та киләчәк булган.

---

[1] Галиәсгар Камал турында сүз бара.

Бераздан атлар килеп, Троицкига бара торган бер приказчик юлдаш булып, Полетаевкага юнәлдек»,— дип яза үзе.

Төнлә поездга утырып, иртән Троицкига килеп тә җитә. Ул бирегә мулла Габдрахман Рахманкуловның икенче кат чакыруы буенча кымыз белән дәваланырга килә. Габдрахман мулла Рахманкулов, кеше җибәреп, аны поездан каршы алдыра: **«Габдрахман хәзрәткә барып кердем... наконец, гакыйбәт авызга кымыз тиде. Мине кымыз өчен Уфага бару фикереннән кайтаручы вә андагы кымызның җәгълилеген (искусственный) сөйләүче вә яз көне кымыз эчәргә үзенә чакырган вәгъдә алып китүче ошбу Габдрахман хәзрәт иде».**

Троицкида Габдрахман Рахманкулов өендә берничә кич куна.

Истәлекләргә караганда, Троицкига килеп төшкәч, Тукайны каршыларга «Сөембикә» мәктәбендә укучы кыз балалар килгән була. Алар шагыйрьне тимер юл станциясендә чәчәкләр биреп каршы алалар. Тукайны каршылаучы кеше мулла Г. Рахманкуловның кодасы Хәкимҗан Бакиров була.

Истәлекләрдә Тукайның Троицк яшьләре көн дә җыела торган урында— театр һәм музыка һәвәскәрләре җәмгыяте урнашкан Васильевский тыкрыгындагы 5 нче йортта Хәкимҗан Бакировларда булуы, Х. Бакиров белән Троицкиның мәшһүр бае Яушевларның өлкән туганы Муллагали Яушевларга чәйгә баруы да сөйләнә.

Бишгомлы «Әсәрләр», 5 том, 64 б.; Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, Казан,; 1986, 106 бит; Һилалов Ибраһим. Тукай Троицкига килгәч. Тукай Башкортстанда. Уфа, 1966, 45, 48, 79 бб.

15 май.

Г. Тукайның Петербургта булып китүе турында Кәбир Бәкернең «Тукаев вә Петербург мөселманнары» дигән мәкаләсе басылып чыга. Анда Тукайның апрель азакларында 13 көн Петербургта кунак булуы әйтелә: «Петербург мөселманнары авыру шагыйрьне яхшы тәкъдир иттеләр».

«Йолдыз», 832 нче сан.

17 май.

«Сабитның укырга өйрәнүе» шигыре «Татар әлифбасы» исемле китапка кушымта итеп чыгарылган «Бүләк» дигән китапта (Казан, И. Н. Харитонов матбагасы) басылып чыга. Китапчыкта берничә рәсем һәм шушы шигырь урнаштырылган. Харитонов, татар хәрефләре эшләткәч, беренче итеп бу китапны бастырып чыгара.

ТҮДА. 420-ф., 1-тасв., Мирасханә. 9-ф., 1-тасв.; Бишгомлы «Әсәрләр», 5 том, 307 б.

20 май алдыннан.

«Ялт-йолт» редакторы Ә. Урманчиевтан хат ала. «Казаннан киткәнеңә икенче ай инде, бернәрсә дә язмыйсың, идарәгә бер мәкалә дә җибәрмисең»,— диелгән була ул хатта.

20 май.

«Мәкаләи махсуса»ның беренче бүлеген яза, һәм Казанга «Ялт-йолт» журналы идарәсенә җибәрә. Бу сәфәргә үзен озатып җибәргән дусты «Ялт-йолт» журналы мөхәррире Әхмәт Урманчиевка адреслап болай ди: **«Мөхәррир әфәнде! Әле минем авырудан башка эшем юк, бик зур эш эшләгән шикелле, әллә кайларга барып авырып йөрим. Авылда авырдым, Казанда авырдым, Самарада авырдым. Ахирләмер, патша тора торган шәһәргә — Петербургка барып авырдым. Троицк халкы да күрми калмасын дип, монда да авырыйм. Ләкин монда эш шәп. Терелермен кебек. Терелсәм, әллә нәрсәләр язармын кебек».**

«Ялт-йолт», 40 нчы сан.

Май азагы.

Берничә көннән Хәкимҗан Бакиров Тукайны кымызга Габдрахман Рахманкуловның дачасына илтеп куя.

Совет власте елларында бу урыннарда кымыз белән дәвалану санаторийлары ачыла.

Шагыйрь исә: **«Троицкида берничә көн торгач, сахрага, шәһәрдән егерме биш чакрым җиргә киттем... Анда хәзрәт тарафыннан ялланган казакълар аның йөзәр баш биясен савып, бүтән малларын көтеп торалар. Ике киез өйдән гыйбарәт шул казакъ авылына өченчегә миңа махсус чатыр тегелде. Шәһәр смрадыннан, завод агуыннан, бозык һавадан качып чыгып, арбадан пароходка, пароходтан поездга күчә-күчә эштән чыккан мин бичара ахры бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым... Бу — сахра... коры степь һавасы... Бөтен нәрсә табигый...»** Бу казакъ даласына барган беренче көнне үк күңел күтәренкелеге белән табигатьнең матурлыгына, киңлегенә рухланып шигырь дә яза:

«Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!
Ак күмәч белән ашарлык саф һава;
Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!
Ак болыт, күчмә казаклардай күчеп,
Бер куньшлык җирне сайлый, валлаһи!
Аз гына бер җил исү белән үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Иштә бу — сахрада беренче көнемдә язылып ташлаган бер кәгазьдән алынган җырулар! — ди.

И б р а һ и м  Һ и л а л о в. Тукай Троицкига килгәч. Тукай Башкортстанда. Уфа, 1966, 47 б.; «Мәкаләи махсуса», «Ялт-йолт», 45 нче сан. 5 ноябрь.

25 май.

«Халык моңнары» (Икенче табгы. Җыючысы: Шүрәле, Казан, «Сабах» көтепханәсе) басылып чыга.

«Халык әдәбияты» (Икенче табгы. Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Өмид» матбагасы) басыла.

ТҮДА. 420-ф., 1-тасв.; Биштомлы «Әсәрләр». 5 том, 307 б.

1 июнь.

«Мәкаләи махсуса» исемле әсәрнең 1 нче кисәге «Хәкыйрь Шүрәле» имзасы белән басылып чыга[1].

«Ялт-йолт», 40 нчы сан.

11 июнь.

Троицкидан Казанга, Гыйльметдин Шәрәфкә хат яза. Сәламәтлеге арулануын, хәле һәм кәефе әйбәтлеген, ләкин ялгызлык ялыктыруын хәбәр итә: **«Урыным Троицкидан 25 чакрым җирдә. Һәр тараф сахра. Ике казак өеннән башка бернәрсә дә күренми, күңелсез, эч поша. Шунысы изә...**

**Авыруым, тагын яңалары башланмаса, бетә инде. Ләкин терелеп нәрсә бар? — дип карыйм каравын. Ач кеше вакытның соң икәнен белсә дә ята, «Торып нәрсә бар?» — ди. Мин дә шулай, өмидем юк».**

Биштомлы «Әсәрләр», 5 том, 118 б.

15 июль.

«Ялт-йолт» журналының 41 нче саны дөнья күрә. Бу санда «Мәкаләи махсуса» әсәренең икенче кисәге (I—V бүлекләре) «Сәяхәте көбралар ясаучы: «Шүрәле» имзасы белән, «Бәндәләр» шигыре имзасыз[2] басылган.

---

[1] Журналда «1 июнь» дип ялгыш басылган; 1 июньдә 39 нчы сан чыккан.

[2] Бу шигырьнең Тукайныкы икәнен әдип һәм галим Нәкый Исәнбәт тә раслады («Казан утлары» 1966, 4 нче сан).

Май азагы — июльнең 20 ләренә кадәр.

Казакъ даласында ике ай-ике ай ярым вакыт яши. Бередә ул «Мәкаләи махсуса»ның икенче кисәген язып (5 бүлекчә) почта белән Казанга җибәрә. «Хәзер җиләк-җимеш вакыты» фельетоны да җәйләүдә язылган булуы мөмкин.

Шәһәрдән аның янына килгәләп йөргәннәр. Үзе дә берничә мәртәбә, чакыруларга җавап йөзеннән, Троицкига барып кайткан. Кайбер истәлекләргә караганда, Тукай ял иткән вакытта тагын бүтән җирләргә дә барган. Үзе кымыз эчеп дәваланган казакъ авылыннан ерак түгел Кушкүл авылына килә. Халыкка яңа шигырьләрен укый. Күлдә көймәдә йөри, болындагы чәчкәләр белән хозурлана.

Нуруллин И. «Габдулла Тукай». Казан, 1979, 270 б.; Бикбулатов Мөхәммәт. Ике кечкенә хәтирә. Тукай Башкортстанда. Уфа, 1966, 49 б.

Июльнең 20 ләре.

Ялы ял төсле булды дигән фикергә килгәч, үзендә азмы-күпме хәлләнү дә сизгәч, Тукай кайтыр юлга чыга. Июльнең егерменләрендә, ниһаять, Казанга, «Свет» кунакханәсендәге номерына кайтып керә. Ис алып, хәл җыеп тормастан, «Ялт-йолт»тагы вазифасын башкарырга керешә. «Җан азыклары» җыентыгын матбугатка әзерләргә тотына.

Нуруллин И. «Габдулла Тукай». Казан, 1979, 270, 283 бб.

Троицкидан кайтып бер-ике көн үтүгә, Фатыйх Әмирхан белән икәүләп фоторәсемгә төшәләр.

Нуруллин И. «Габдулла Тукай». 1979, 286 б.; Габдулла Тукай. Альбом. Казан, 1979, 19 б.

21 июль.

Календарьчы Шәрәф Шәһидуллин тарафыннан 1913 ел өчен чыгарылган «Заман календаре»нда Тукайның фоторәсеме һәм кыскача тәрҗемәи хәле урнаштырылган. «Идел» редакциясе биргән реклама, «Календарь»ны төрле яклап мактаганнан соң, түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Һәр төрле киңәшләр, статистика мәгълүматлары бирү өстенә милли яшь мөхәррир, әдип вә шагыйрьләремезнең рәсем вә тәрҗемәи хәлләре һәрбер укый белгән мөселманның игътибарын тарта.

Без бит әле яшь мөхәррир вә әдипләремезнең рәсемнәрен дә күргәнемез юк... «Заман календаре» исә укучыларын шул мөхәррирләр белән таныштыра. Бу мәртәбәдә Тукаев, Гафури, Бәшири, Думави, Әмирхан вә башкаларның рәсемнәре бар...»

«Идел», 473 нче сан.

26 июль.

Казанда Евангелистовлар урамындагы Хөсәеновлар йортында татар яшьләренең әдәби түгәрәге җыйнала. Бу утырышта журнал чыгарырга карар бирелә. Русларның әдәби журналлары кебек күләмле булуы күздә тотылып, аның татар яшьләрен оештыручы, берләштерүче үзәк булырга тиешлеге искәртелә.

Җыелышта бу мәсьәлә Гәрәй һәм Бари Хәсәновлар... Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, укытучы Гафур Колахметовларның актив катнашы белән хәл ителә һәм әдәби-мәдәни «Аң» журналы чыгарырга карар бирелә. Исемне Тукай тәкъдим иткән.

Саратов Өлкә Дәүләт архивы, 55 ф., 1 тасв., 44 эш, 59 к.; Абдуллин И. Архивные документы о Г. Кулахметове. «Гафур Кулахметов» Казан, 1983, 198 стр.

Г. Тукай әдәби түгәрәккә җыелган яшьләр, үзенең дуслары һәм фикердәшләре белән бергәләп фотога төшә. Ләкин бу фоторәсем тулы килеш, бөтен

нөсхәсе бүгенге көнгә кадәр табылганы юк. Аның ике яктан да киселгән урта бер өлеше генә саклана. Китапларга, альбомнарга да шул урта өлеше (биредә: Г. Тукай, Ф. Әмирхан утырганнар, Г. Колахметов, К. Колахметов артка басканнар) генә урнаштырылып килә. Фотограф Зөфәр Бәширов фикеренчә: «Фотографиядә кабул ителгән стандарт буенча аның иңе 27,5 биеклеге 22,5 см булырга тиеш. Әгәр дә Г. Тукай уртада утырган дип исәпләсәк, бөтен фоторәсемдә шагыйрьнең даирәсеннән тагын 6 кеше булырга тиеш дип уйларга урын бар».

Алар кемнәр — билгесез. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсенең Тукай фондында фотосурәтнең бердәнбер нөсхәсе саклана. Иңе — 7, биеклеге 22,5 см. Фоторәсем ике ягыннан да пычак белән кисеп алынган, аның эзләре ап-ачык күренеп тора.

Габдулла Тукай. Альбом. Казан, 1978, 89 бит.; Зөфәр Бәширов. Киселгән язмышлар. «Шәһри Казан», 1995, 25 апрель.

Тукай фотога төшә. Үзе генә профиль белән утырган. Чәче кыска итеп кистерелгән. Буйлы күлмәк кигән, галстук һәм костюмнан.

«Аң», 1913 ел, 8 нче сан, 10 апрель; Габдулла Тукай. Альбом, Казан, 1989, 136 бит.

31 июль.

Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы провокаторның 26 июльдәге җыелыш турындагы доносын Идел буе охранкасы башлыгына җибәрә һәм бу кешеләрнең жандарм идарәсенә билгеле булуы, алар артыннан яшерен күзәтү дәвам иттерелүе турында хәбәр итә.

Бу «бик яшерен» тамгасы салынган документның «Урында кулланылган чаралар» дигән графасында Казан жандарм идарәсе болай дип язган: «Монда исемнәре аталган кешеләрнең кайберләре (арада Г. Тукай да бар — төзүче) Идарәгә үзләренең элекке политик эшчәнлекләре буенча билгеле. Алар артыннан күзәтү дәвам итә».

Саратов Өлкә Дәүләт архивы, 55 ф., 44 эш, 60 бит.

5 август.

«Гасыр» нәшриятында почта открыткасы формасында басылган рәсеменә (1911 елда алынган, ялан баш, буйлы күлмәк белән бант таккан, костюмнан) шагыйрь үз кулы белән:

**«Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй вә Габдрахман әфәнделәргә ядкарем. 5 август, 1912 ел Г. Тукай»** дигән автограф язып бүләк итә.

Мирасханә. 9 ф., 3 тасв., 49 эш.

Татарстан Дәүләт музее хезмәткәре Дания Баһаутдинова фикеренчә, бу рәсемен Тукай үзен Троицкига, казах даласына кымыз белән дәваланырга чакыручы Габдрахман хәзрәт Рахманкулов һәм аның ир туганы, әдәбиятчы һәм сәхнә әсәрләре дә язган кеше — Әхмәтгәрәйгә бүләк иткән булырга мөмкин.

Д. Баһаутдинова. Тукайның яңа табылган автографы. «Социалистик Татарстан», 1978, 28 апрель.

Көз башы.

Казанга килгән шагыйрь һәм мөгаллим С. Сүнчәләй Тукай белән очрашып тора. Мәгълүм истәлегендә ул болай дип яза: «Бу вакыт Тукайның хәле тәмам беткән, нервлары какшаган. Кечкенә генә нәрсәгә дә кәефе китә, бик тиз ачулана, юк-бар нәрсәдән дә шикләнә, курка, берәүне дә күрәсе килми иде».

Сүнчәләй, авылына китәр алдыннан, саубуллашырга да кергән. Тукай шунда аңа: «Менә, сиңа бүләгем булсын», — дип үзенең көмеш сәгатен бүләк итә. Бу аларның соңгы мәртәбә очрашулары була.

Тукай «Свет» номерларыннан яңадан «Болгар»га күчә.

Сәгыйть Сүнчәләй. Тукай турында истәлек. «Истәлекләр», 141 бит.

Көз.

Журналист Шиһап Әхмәров истәлегенә караганда, Тукай, үзенең барлык шигырьләрен мәҗмуга итеп бастыру хокукын Г. Шәрәфкә биреп, аның белән килешү төзи һәм шул җыентык («Мәҗмугаи асарь»[1]) өстендә бик басылып эшкә керешә. Г. Шәрәфнең бу килешүгә нинди шартлар куюы билгеле булмаса да, Тукайга якын кешеләр, Тукай өчен бу килешүнең «кабальный» булуын сөйлиләр.

Мирасханә. 9 ф., 4 тасв., 14 эш.

20 сентябрь.

«Динчеләр куаныштылар» мәкаләсе «Гөмберт» имзасы белән басылып чыга. Динчеләрдән һәм Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» журналыннан, аның нашире Вәли мулла Хөсәеновтан көлеп язылган сатирик мәкалә.

«Ялт-йолт», 43 нче сан.

3 октябрь.

Дусты революционер Мәхмүт Дулат-Алиевка үзенең фоторәсемен бүләк итә (Казанда И. Якобсон фотоательесында Тукайның профильдән төшкән рәсеме). Рәсем артына: **«Иптәшем Мәхмүткә ядкарь, Г. Тукай, 3 октябрь, 1912 сәнә»,** дип автограф язылган. Бу фото Кырлай музеенда саклана. Анда аны М. Дулат-Алиевның олы кызы Ләлә Дулат-Алиева тапшырган.

«Әти белән Тукайның дуслыгы гомере буе дәвам итте»,— дип яза бу турыда истәлек авторы Ләлә Дулат-Алиева.

Г. Әпсәләмов. Тукайның тагын бер рәсеме. Казан утлары. 1970, 1 сан, 156 б.; Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. Казан, 1985, 124 б.

Октябрь.

Авыруы каләм тотарга комачаулый башлый. Бу вакыт ул, «Ялт-йолт»ны чыгаруга хезмәт куюдан тыш, «Җан азыклары» җыентыгын матбугатка әзерли.

Нуруллин И. «Габдулла Тукай». Казан. 1979, 283 б.

11 октябрь.

«Йолдыз» газетасы укучыларына заманның танылган шәхесләре турында хәбәр итә: **«Ачык хат. Иң соң алынган рәсемнәрдән: Исмәгыйль Гаспринский, Йосыф Акчура, фотоларыннан эшләнгән открыткалар Мөхәммәдгаяз Исхакый, Габдулла Тукаев яңа гына заграницадан эшләтеп китерелеп сатыла башлады».**

«Йолдыз», 892 нче б.

13 октябрь.

«Балканда» шигыре рәсем-карикатура асты итеп имзасыз басылган. Бу икеюллык Төркия белән Балкан дәүләтләре арасындагы сугыш мөнәсәбәте белән язылган.

---

[1] 1914 елның октябрендә дөньяга чыккан, «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре» (Җәмалетдин Вәлиди тарафыннан язылган Тукайның тәрҗемәи хәле һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә. Казан «Мәгариф» көтепханәсе.) әсәрен Тукай үзе исән вакытта нигездә төзеп бетереп калдыра. Дусларыннан Ш. Әхмәров әйтүенчә: «Бу Мәҗмуганең күп өлешен мәрхүм үз кулы белән төзеп калдырды. Ул үзенең ахыр көннәренә кадәр, хәтта шифаханәгә кергәч тә шуның өстендә эшләвен туктатмады... Мәҗмуга Тукайның үзе исән вакытында басыла башлап, Тукай үлгәч... дөньяга чыкты». Кара: Тукай турында замандашлары», Казан, 1960, 193 б.

Шул ук санда «Иң соңгы хәбәр» исеме белән кечкенә информациясе имзасыз басылып чыга.

«Ялт-йолт», 44 нче сан; Биштомлы «Әсәрләр», 4 том, 342 б.

5 ноябрь.
«Ялт-йолт» журналының 45 нче саны дөнья күрә. Биредә «Шүрәле» имзасы белән «Мәкаләи махсуса» әсәренең VI—IX нчы бүлекләре, шунда ук «Валлаһи» шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Хаксызлыктан котылдык» исемле мәкаләсе урнаштырылган. Анда сәүдәгәрләр, муллалар булышлыгы белән Дүртенче дәүләт думасына депутатлыкка сайланырга тырышса да, актык минутта сайланмый калган Шаехгаттар Иманаевтан көлен ә. Шушы вакыйга уңае белән тагын «Казан мулласы һәм булачак депутат» дигән сатирик шигыре рәсем асты итеп «Шүрәле» имзасы белән басылган.

«Ялт-йолт», 45 нче сан.

Көз.
Тукай яраткан һәм мәхәббәт турындагы шигырьләренең күбесен аңа мөнәсәбәттә язган Зәйтүнә туташның Казаннан Чистайга китүен Тукай бик авыр кичерә. Аңа кинәт кояш сүнгән, дөньяның яме киткән кебек тоела. Бу мәхәббәтен күпләрдән яшерсә дә, дусларыннан берсенә Зәйтүнәне һаман яратуын, онытa алмавы, сагынуы турында сөйли.

Нуруллин И. «Габдулла Тукай». Казан, 1979, 152 б.

10 декабрь.
Казанда «Кояш» исемле демократик юнәлештәге газета чыга башлый. «1912 елда караңгы Казан өстенә «Кояш» чыгып «Йолдыз»ны сүндерде»,— дип яза Тукай бу вакыйгага рухланып. Газетаның җаваплы секретаре итеп Ф. Әмирхан билгеләнә. Тукайны, 40 сум айлык хезмәт хакы биреп, газетага язышучы итеп билгелиләр. Яңа газетаның идарәсе «Амур» кунакханәсенә (хәзерге Киров урамы, 70 нче йорт) урнаша. Ф. Әмирхан да, Тукай да «Амур»га күчеп (Тукай — тугызынчы бүлмәдә, Ф. Әмирхан — унберенчедә) тора башлыйлар. Хәзер инде алар көн саен очрашып яшиләр.

Нуруллин И. «Габдулла Тукай». Казан, 1979, 285 бит; Исмәгыйль Рәми. Ул сагышланды, күрә алмады. «Истәлекләр», 214 б.

15 декабрь.
Казанда «Аң» исемле әдәби-иҗтимагый журнал чыга башлый. Редакторы һәм нашире «Гасыр» китап ширкәте башлыкларыннан берсе — Әхмәтгәрәй Хәсәни. Киңәшү-сөйләшүдә, булачак журналның идея-политик һәм әдәби-эстетик юнәлешен билгеләүдә һәм Хәсәнине бу эшкә күндерүдә Тукай якыннан катнашкан. Журналга исемне дә Тукай тәкъдим итә. Беренче санында журнал чыгу уңае белән язылган «Аң» шигыре урнаштырылган.

«Аң», 1 нче сан.

22 декабрь.
«Ялт-йолт»ның 48 нче санында «Журнал өчен материаллар «Амур» кунакханәсенең 9 нчы бүлмәсенә җибәрелсен»,— дигән игълан басылган, күрәсең, беркадәр вакыт «Ялт-йолт»ның редакциясе дә шагыйрь яшәгән бүлмәгә күчеп торган.

«Ялт-йолт», 48 нче сан.

23 декабрь.
«Балкан» шигыре басылып чыга. (Төркия сугышы мөнәсәбәте белән язылган.)

«Кояш», 7 нче сан.

«Балкан көйләре» исемле шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шигырь Балкан дәүләтләре (Болгария, Сербия, Греция һәм Черногория) белән Төркия арасында барган сугыш һәм Төркиянең шушы елның октябрендә җиңелүе хакында язылган.

«Кояш», 7 нче сан.

29 декабрь.
«Җан азыклары» исемле шигырь җыентыгы басылып чыгу турында «Яңа басылып чыккан иң мөһим әсәрләр...» дип игълан бастыра.

«Вакыт», 1078, 4 нче сан.

# ТУКАЙНЫҢ АЧЫК
# ҺӘМ
# ЯШЕРЕН ИМЗАЛАРЫ

Шагыйрь үзе исән чакта ук ун төрле имза белән газета һәм журналларда күренгән әсәрләрен китапларына кертеп калдырган. Аның имзаларының ачылу тарихы шул вакытларда ук башлана. Соңрак бу эшкә аның күптомлы басмаларын әзерләүчеләр зур өлеш керттеләр. Без аларга: шагыйрьнең Өчтомлыгын (1929—1931) төзүче Фатих Сәйфи-Казанлыга, ике томлы Академик басманы (1943—1948) һәм Беренче дүрттомлыкны (1955—1956) төзүче Хәй Хисмәтуллин белән Якуб Агишевларга, Икенче дүрттомлыкны (1975—1977) һәм Биштомлыкны (1985—1986) төзүче Рәшат Гайнановка (аның «Билгесезлектән — яна томга» дигән мәкаләсендә дә сүз псевдонимнар турысында бара. «Соц. Татарстан», 1976 ел, 20 май) рәхмәтле булырга тиешлебез. Шулай ук Г. Халит, Р. Башкуров, Р. Нәфыйков, И. Нуруллин, М. Мәһдиев, Н. Юзиев, М. Гайнетдинов, Ф. Ибраһимова, Р. Якуповларның да Тукай имзалары мәсьәләсенә караган кыйммәтле фикерләре бар.

Минемчә, Тукай имзаларын беренче мәртәбә исемлек рәвешенә китереп М. Бурнашева бастырды (Беренче дүрттомлык, 4 нче том, 257 бит). М. Һадиның (М. Бәдәйлинен) «Псевдонимнар сүзлеге»ндә исә («Казан утлары», 1969 ел, 1 нче сан) Тукайның 24 имзасы саналган, ләкин ике хәреф хатасы булу аркасында, алар 22 генә булып күренә. Ү. Гыймадиевның «Сила сатирического слова» дигән китабы ахырындагы (1987) исемлектә — 26 имза (М. Һадиныкыннан 7 се төшерелгән 9 имза өстәлгән).

Мин, Тукай әсәрләре басмаларын һәм күптомлыкларын әзерләүчеләрдән булмасам да, имзаларның исемлеген төзеп карарга уйладым. Нәтиҗәдә ул мондыйрак рәвеш алды.

## I. Тукайнын ачылган имзалары (аларның иясе Тукай булуны инкяр итәрлек мәгълүматлар күренми):

1. Адвокат. «Яңа дәгъва» исемле һәҗүви (сатирик) парча «Уклар» журналында (1906 ел, 3 нче сан) шул имза белән чыккан. Беренче мәртәбә Биштомлыкта басыла.

2. Айнук Самакай малае. «Шыер» пародиясе «Ялт-йолт» журналында (1912, 37 нче сан) шул имза белән бирелә. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кереш сүзе төшерелеп, «Бәет» дип исемләнеп кертелә. М. Һади исемлегендә ялгыш «Аннур Самакай малае» диелгән.

3. Берничә кешеләрнең үтенече буенча вәкил — Уральск кешесе. «Шәһәремездәге зур тәмгылы муллаларга бер-ике сүз» исемле публицистик чыгышы «Фикер» газетасында (1906 ел, 21 июль) шул имза белән бирелгән. Шунда ук «Уральск кешесе» имзалы мәкалә дә бар. Беренче тапкыр Беренче дүрттомлыкка кертелгән.

4. Бер фикерче. «Һәркимиң кәндинчә вардыр ля мәхаль әндишәси» исемле публицистик мәкалә «Фикер»дә (1906 ел, 31 август) шул имза белән чыга. Аның Тукайныкы булуын И. Нуруллин дәлилләп күрсәтте (Тукай иҗаты. Казан, 1964 ел, 73 бит). Беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелә.

5. Биик усал. «Алай-болай» фельетоны «Фикер»дә (1906 ел, 3 июль) шул имза белән чыга, ә дәвамы — 21 июль санында, имзасыз. Беренче мәртәбә Беренче дүрттомлыкка кертелгән.

6. Гъ. (Габдулладан кыскартылган). «Кечкенә генә бер көйле хикәя» поэмасы «Фикер»дә (1906 ел, 17 май) шушы имза белән чыга. Беренче мәртәбә Өчтомлыкта басылган.

7. Гъ. Т. Г. Тукайның инициалларыннан ясалган бу имза белән «Әль-ислах» газетасында, «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» һәм «Шура» журналларында егермедән артык шигъри һәм чәчмә әсәре басылган.

8. Габдулла Тукаев (Г. Тукаев). Шагыйрьнең туганда кушылган исеменнән (метрикә кәгазендә — Габдуллаҗан) һәм фамилиясеннән ясалган әлеге ачык имза белән күпсанлы шигырьләре, публицистик чыгышлары, игъланнары, аңлатмалары һәм искәрмәләре басылган, махсус кәгазьләре (бланклары) булган. Русчасы — Абдулла Тукаев (А. Тукаев, А. М. Тукаев, А. М.-Г. Тукаев). Исән чакта чыккан күпчелек китапларының авторы итеп тә Габдулла Тукаев (Г. Тукаев) күрсәтелә.

Тукаев фамилиясенең кайдан килүе әлегәчә билгесез. Ярулла Муради үзенең истәлегендә Уральскидә рус-татар мәктәбендә укып йөргәндә Тукайның Гарипов фамилияле булуын, бераздан әтисе язуларын табып, чын фамилиясенең Тукаев булуын белеп, «Тукаев» дип яза башлавын хәбәр итә. 1903 елның 30 июнендә апасы Сәҗидәгә җибәргән хатында да имза — Габдулла бине Мөхәммәтгариф Тукаев. Х. Зәбиров — әнисе Газизәнең дә «кыз чагындагы фамилиясе Тукаева» дип язып чыккан иде. М. Мәһдиевнең фикере кызыклы. Ул бер мәкаләсендә (1973) болай ди: «Тукай «Габдулла Мөхәммәтгариф улы», яки һичъюгында «Габдулла Гарипов» булырга тиеш иде. Ләкин ул үзенең иң беренче публикациясенә үк «Габдулла Тукаев» дип имза куя. Тукайның нәсел-нәсебеннән дә, замандашларыннан да бу псевдонимның каян килгәнен әйтеп калдыручы булмаган. Тукайның ерак нәселендә дә андый кешенең барлыгы искә алынмый. Каян килгән бу? Габдулла Гарипов аны очраклы рәвештә алмагандыр бит? «Тукай» сүзенең мәгънәсен, бәлки, гарәп-фарсы сүзләреннән чыгып эзләргә кирәктер. Гарәп-фарсы телләренең белгечләре моны ачыкларга ярдәм итәрләр.» З. Рәсулеваның «Тукай эзләреннән» китабының (1985) фәнни редакторы һәм бит асты төшермәләрен язучы Р. Якупов Тукайның әтисен «Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалимов» дип күрсәтә. «Тукаев»ның кайдан килүе, шулай итеп, ачыкланмаган хәлдә кала. З. Рәсулева китабында Мөхәммәтгарифның бабасының бабасы Туктулы булуы да әйтелә. Бәлкем, шуннан киләдер. Тукаев фамилиясе татарлар арасында шактый еш очрый, ул үз телебез җирлегендә ясалган булса кирәк. Моңа Г. Саттаров кебек галимнәребез дә игътибар итәләр. И. Нуруллин «Габдулла Тукай» исемле китабында (1979), риваятьләргә таянып, шагыйрьнең ерак бабаларыннан булган Туктаргалинең Тукай дип йөртелгәнен яза.

9. Габдулла Тукай (Г. Тукай; Тукай). Шагыйрь үзе бу имза белән бик аз эш иткән. Аны куллануга бер мисал — «Гомер юлына керүчеләргә» шигыренең (1910) соңгы ике юлы:

Нигә, дим, изге мәктәптән, сабый чаклардан айрылдым?
Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зуп-зур Тукай булдым?

Аның турында башкалар язганда шагыйрь исән чакта ук бу имза инде телгә кергән була.

10. Гөмберррт (өч «р» белән!). Тукайның Шүрәледән кала иң яратып кулланган имзаларыннан (М. Мәһдиев әйткәнчә, ни өчен халыкны Шүрәле булып кытыкламаска, ни өчен берәр кадимчегә «Гөмберррт» итеп китереп сукмаска?). Беренче мәртәбә «Тотса мәскәүләр якаң» һөҗүви шигыре «Яшен»дә (1908 ел, 1 нче сан) шул имза белән дөнья күрә, соңгы мәртәбә Клячкин шифаханәсеннән җибәргән «Матбугатымызның фәсахәт нәмүнәләре» фельетоны «Ялт-йолт»та (1913 ел, 53 нче сан, 15 март) басылганда кулланылган. Бу имза күбесенчә «Яшен» һәм «Ялт-йолт» журналларындагы парчалары һәм фельетоннары ахырында күренә. Шагыйрь үзе үк чыгарган җыентыкларына кертелү сәбәпле, имза иясе ул заман укучыларына мәгълүм булган.

11. Догачы: Шүрәле. «Яшен» мәрхүм» исемле язмасы «Ялт-йолт» та (1910 ел, 2 нче сан) шул имза белән бирелә (текстта дога образы кулланылган). Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән.

12. Дугъры. «Уклар» журналының 1906 ел, 1 нче (июнь) санында журналның программ мәкаләсе — «Сүз башы» шул имза белән чыккан. Беренче мәртәбә биштомлыкта басылды.

13. Идарә. «Уральск имамнарына ачык хат» һәм «Өлфәт»кә хат» «Фикер» газетасында (1906 ел, 10 июль, 18 август) шул имза белән укучыга тәкъдим ителгән. Әүвәлге мәртәбә беренчесе — Икенче дүрттомлыкка, икенче хат — Биштомлыкка кертелгән.

14. Имам хатиб. Тукай бу имза белән «Керешү хотбәсе»н «Ялт-йолт»та (1910, 5 нче сан) бастыра, аннары «Яшен ташлары»на кертә. Беренче мәртәбә Биштомлыкта басылган.

15. Имзасыз да Яраретдинов. «Толстой хакында мәшһүр татарларның фикерләре» «Ялт-йолт» журналында (1910 ел, 12 нче сан) шул имза белән чыккан. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән.

16. Имза: Шәп кеше. Бу имзаны «Исемнәремез хакында» дигән мәкаләсен «Ялт-йолт» журналында (1911 ел, 23 нче сан) бастырганда кулланган. Текст «Шүрәле» имзасы белән чыгарылган «Яшен ташлары»ның икенче басмасында очрый. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән.

17. Имза: Фәйләсүфләр. «Фәлсәфи сүзләр» исемле сатирик язманың беренче кисәге «Ялт-йолт»та (1910 ел, 8 нче сан) шул имза белән басылган (икенче кисәге «Фәйләсүф» имзасы белән). Беренче тапкыр Өчтомлыкка кертелгән.

18. Ишан мөнкире. Биштомлыкта (1 том) урнаштырылган «Уклар» журналында мөхбир уланлара тәнбиһ» шигыренә искәрмәдә «Ишан мөнкире дә — Тукай псевдонимы» диелгән. Ләкин Тукай җыентыкларында бу имзалы бер генә әсәр дә очрамый.

19. Кыйссасел-әнбия. Рабгузи. «Һәзиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа» (Мостафаны мактау турында көйле әсәр бу) сатирик шигырен Тукай шул имза белән «Ялт-йолт»та (1912 ел, 37 нче сан) бастыра. Текст беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән. Р. Гайнанов фикеренчә, моны имза-псевдоним дип тә, Рабгузи китабыннан бер өзек дип тә уйларга мөмкин; Тукай анлы рәвештә шундый эффект тудыра. (Биштомлык, 2 нче том, 375 бит).

20. Кырмыска. «Нәрсәдән?» шигыре «Яшен»дә (1908 ел, 5 нче сан) шул имза белән чыга һәм Өчтомлыкта беренче мәртәбә дөнья күрә. Ике һөҗүви парчасы «Уклар»да (1906 ел, 3 нче сан) басылып, соңыннан Академик басмага кертелгән.

21. Милләтче. «Мин шулар илә милләтче» һөҗүви парчасы «Яшен»дә (1908 ел, 4 нче сан) бу имза белән басылган. Беренче мәртәбә Беренче дүрттомлыкка кертелгән.

22. Мин язмадым. Бу имза белән ике әсәрен — «Гучков» һөҗүви парчасын һәм «Матбугат каһарманнары» исемле фельетонын «Яшен»дә (1909 ел, 6 нчы сан; 8 нче сан) бастырган. Соңгысы «Яшен ташлары»ның икенче басмасында күренә. Икесе дә Академик басмада бар.

23. Мылтык. «Билгесезлектән — яңа томга» дигән мәкаләсендә («Соц. Татарстан, 1976 ел, 20 май) Р. Гайнанов, Тукай бу имзаны «Уклар»да кулланган, дип язды.

24. Мәкәрҗәдә булучы. «Сырой егет» дигән әсәре «Фикер»дә (1906 ел, 1 октябрь) шул имза белән басыла. Аның Тукайныкы булуы Р. Гайнанов мәкалә-

сендә әйтелә. «Сырой егет» беренче мәртәбә Биштомлыкның 3 нче томында «Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр» арасында бирелгән.

25. Мәхүп прахут конторщигы. Р. Гайнанов мәкаләсендә Тукайның бу имзалы әсәрләре «Уклар»да басылганлыгы әйтелә.

26. Мәҗнүн. «Кызык гыйшык» шигыре «Әльислах»та (1908 ел, 17 июнь) шул имза белән басылган. Аны Тукай Казанда Купеческое собрание залында (хәзерге: ТЮЗ) ислахчы яшьләрнең әдәби кичәсендә укый. «Г. Тукаев диване»нда бар. Беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелгән.

27. Мөсафир. «Дәхи ниләр күрермез икән?» мәкаләсе «Фикер»дә (1906 ел, 15 октябрь) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелгән.

28. Мөтәрҗим Г. Тукаев. Иң беренче әсәрләреннән «Мужик йокысы» шигыре «Фикер»дә (1905 ел, 26 ноябрь), «Аю һәм Ссыльный» чәчмә мәсәле әлеге газетаның 1906 елгы 5 ноябрь санында шул имза белән бирелгән. Беренчесе «Габдулла Тукаев шигырьләре» китабында (1908 ел) ук күренә. Мәсәл исә беренче мәртәбә Академик басмага кертелгән.

29. Мөхәррир мин түгел. «Хикәя язарга теләүче яңа әдипләргә үрнәкләр» «Ялт-йолт»та (1910 ел, 23 нче сан) бу имза белән басылган. Беренче тапкыр Икенче дүрттомлыкка кертелгән.

30. Олуг Фәйләсүф. «Фәлсәфә» дигән парчасы «Ялт-йолт»та (1910 ел, 14 нче сан) шул имза белән бирелгән. Беренче мәртәбә Өчтомлыкта басылган.

31. Партия. «Уральск хәбәрләре»нең ахыры «Фикер»дә (1906 ел, 3 декабрь) шул имза белән дөнья күргән (башы Ш. имзасы белән). Беренче мәртәбә Биштомлыкта күренә.

32. Салам Торхан. «Ир, хатын» һәм «Хатыннарның русча, татарча кушаматлары» дигән әсәрләре «Ялт-йолт»та (1911 ел, 27 нче сан) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Икенче дүрттомлыкка кертелгәннәр. (Салам Торхан имзасы журналның Тукай үлгәннән соң чыккан саннарында да очрый).

33. Счет төймәсе. «1912 елның онытылганнан калган гына хисабы» шул имза белән «Ялт-йолт»та (1913 ел, 49 нчы сан) басылган. Беренче тапкыр Академик басмага кертелгән.

34. Сәгыйд. Сәгыйд Рәмиевнең «Йокы» шигыренә пародия рәвешендә язылган «Йокы» шигырен «Яшен»дә (1908 ел, 3 нче сан) Тукай шул имза белән урнаштырган, аннары «Яшен ташлары» китабына да керткән. Барлык күптомлыкларында урын алган.

35. Сәяхәте көбралар ясаучы Шүрәле. «Мәкаләи махсуса»ның икенче кисәгеннән I—V бүлекләре «Ялт-йолт»та (1912 ел, 41 нче сан) шул имза белән басылган (баштагы өлеше — Хәкыйрь Шүрәле, ахыры Шүрәле имзасы белән). Беренче тапкыр Өчтомлыкка кертелгән.

36. Сөемсез. «Фикер» газетасында һәм «Әлгасрелҗәдид» журналында берничә мәкалә һәм фельетон шул имза белән басылган. М. Һадиның «Псевдонимнар сүзлеге»ндә Тукайныкы итеп күрсәтелсә дә, Биштомлыкка кертелмәгәннәр. Ф. Яхинның «Сөемсез» имзасы белән кем язган?» дигән мәкаләсендә (Язучы биографиясенә яна чыганаклар, Казан, 1989, 30—33 битләр) бу имзаның Тукайныкы булуына ышанычлы дәлилләр китерелгән.

37. Сөенче Алаев. Сәгыйд Сөнчәләй (Сөнчәләев) шигырьләрендә чагылган кайбер җитешсез якларны тәнкыйтьләгән «Шигърият һәм нәсер» һәҗүви шигырен Тукай «Ялт-йолт»та (1911 ел, 22 нче сан) шул имза белән бастыра. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән.

38. Сөңге. Р. Гайнанов мәкаләсендә бу имза белән «Уклар» журналында басылган әсәрләрнең Тукайныкы икәнлеге әйтелә. Сөңге имзалы әсәрләр «Ялт-йолт»ның 1910 елгы 1, 4 һәм 6 нчы саннарында да очрый (Тукай ?).

39. Т. (Тукайдан). «Күгәрчен» шигырен «Йолдыз» газетасында (1910 ел, 15 август) Тукай шул имза белән чыгарган, «Күңел җимешләре» китабына да керткән. Барлык күптомлыкларында бар.

40. Тиктормас. «Кызыкка очрау» мәкаләсе «Фикер»дә (1906 ел, 19 ноябрь) шул имза белән басыла. Беренче мәртәбә Беренче дүрттомлыкка кертелә.

Тиктормас имзалы берәү «Ялт-йолт»ның 1914 елгы 71 нче санында «Тукайда көлү кабилияте» исемле мәкалә бастыра (аның сүзе: «Иртәгә танышырга тиеш идем, ләкин шул көнне Клячкин шифаханәсенә керде»).

41. Тиле. Тукайның төрле имзалы һәм имзасыз әсәрләре «Ялт-йолт»та, гадәттә, бер-бер артлы бирелә торган булган. Журналның 2 нче санында, мәсәлән, шундый хәлгә тап булабыз: башта «Яшен «мәрхүм» мәкаләсе (Догачы: Шүрәле имзалы), аннары Тиле имзалы «Ихтар» (искәртмә), аннан соң Шүрәле

имзалы «Авыл җырлары» урнаштырылган. Үзе үк сәркәтибе булган журналда икс әсәре арасына башка берәүнең биш-алты юллык кына текстын кертеп җибәрмәс иде Тукай. Безнең фикеребезгә «Ихтар» — һичшиксез, аныкы. Тиле имзасы текстның эчтәлегеннән чыгып куелган (һәм шунда гына кулланылган кебек).

42. Түнтәреф. «Кушмый ишәк җырлый» дигән сатирик шигыре «Ялт-йолт»та (1911 ел, 20 нче сан) шул имза белән басылган. Тукай Ишми ишанның уй-теләкләрен үзеннән сөйләтә һәм «шуның өчен дә имзаны Ишми (Түнтәр авылы ишаны) исеменнән «Түнтәреф» дип куя» (Р. Гайнанов). Текст беренче мәртәбә Икенче дүрттомлыкка кертелгән.

43. Тәртә башы. Р. Гайнанов мәкаләсендә «Уклар» журналында бу имза белән басылган тугыз әсәрнең барысы да Тукайныкы итеп күрсәтелә. Ләкин андый имзалы әсәрләрдән «Мөхәммәдия» көе» шигыре һәм «Казан хәбәрләре» беренче мәртәбә Биштомлыкның төп өлешендә, ә «Идел буендагы шәһәрдә» дигән һәҗүви парча, ни сәбәпледер, Биштомлыкның «Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр» арасында басылган.

44. «Төрек» газитәсеннән татарлар хәленә борыбрак мөтәрҗим Г. Тукаев. «Җәмгыяте хәйрия» мәкаләсе «Фикер»дә (1906 ел, 17 декабрь, 31 декабрь) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән.

45. «Уклар»ның лөгать тәфтише. «Сәдәхә» исемле һәҗүви парча «Уклар»да (1906 ел, 6 нчы сан) шул имза белән чыккан. Беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелгән.

46. Уральскидә Габдулла Тукаев. «Хәзерге халемезә даир» исемле шигыре «Әлгасрелҗәдид»тә (1906 ел, 1 нче сан) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Икенче дүрттомлыкка кертелгән. Имза бер генә мәртәбә кулланыла.

47. Уральск кешесе. «Погром» һәм «Хакны белеп инкяр кыйлу» фельетоннары «Фикер»дә (1906 ел, 10 июль һәм 21 июль) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Беренче дүрттомлыкка кертелә.

48. Уральск җәмгыяте хәйриясенең бик усал бер члены. «Уральскидә җәмгыяте хәйрия башлануы» фельетоны «Фикер»дә (1906 ел, 15 октябрь, шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелә.

49. Феакут. «Фөрьяд» шигыре «Әль-ислах»та (1908 ел, 1 январь) шул имза белән басылган. Барлык күптомлыкларына кертелә.

Феакут — анаграмма, Тукаевны гарәп хәрефләре белән язылышында сулдан уңга укыганда килеп чыга торган хәрефләр тезмәсе. Ул елларда очраган анаграммалардан: Фираз — Зариф (Бәшири), Фобикар — Рәкыйбов, Йәкәнеч — Ченәкәй, Шадлуй — Юлдаш (К. Юлдашев ?), Ласуа — Усал (Ф. Туктаров).

50. Фәйләсүф. «Фәлсәфи сүзләр»нең икенче кисәге «Ялт-йолт»та (1910 ел, 9 нчы сан) шул имза белән басылган. Беренче тапкыр Өчтомлыкка кертелгән. Беренче кисәге «Имза: Фәйләсүфләр» дип имзаланган.

51. Хәйләсез. Р. Гайнанов мәкаләсендә бу имза белән «Уклар»да басылган әсәрләрнең авторы Тукай булуы әйтелә.

52. Хәкыйрь Шүрәле. «Мәкаләи махсуса» очеркының баштагы өлеше «Ялт-йолт»та (1912 ел, 40 нчы сан) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән.

53. Хәсрәт. «Куркынычлы хәбәр. Кыямәт» исемле һәҗүви парча «Уклар»да (1906 ел, 5 нче сан) шул имза белән басылган. Р. Гайнанов мәкаләсендә аның Тукайныкы булуы әйтелә. Текст беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелгән.

54. «Хәятел-хәйван»нан күчерүче. «Төрле хәйваннар тугърысында бераз мәгълүмат» исемле язмасы «Яшен»дә (1908 ел, 4 нче сан) шул имза белән чыккан. Беренче тапкыр Беренче дүрттомлыкка кертелгән.

55. Чапансыз. Р. Гайнанов фикеренчә, бу имза белән «Уклар»да басылган мәкалә — Тукайныкы.

56. Ш. (Шүрәледән.) Әлеге имза белән шагыйрьнең «Фикер» газетасында (1906 ел, 3 декабрь) «Янә «Тәрҗеман»га һәм «Уральск хәбәрләре» исемле мәкаләләре басылган. Беренчесе — Беренче дүрттомлыкка, икенчесе — Биштомлыкка кертелгән (беренче мәртәбә).

57. Шәкерт угы. «Ахун хәзрәтләрнең сатылулары», «Тиешсез эш», «Казый кем була?», «Яңа камустан берничә лөгать» дигән һәҗүви парчалар «Уклар»да (1906 ел, 3 нче сан) шул имза белән басылган. Р. Гайнанов мәкаләсендә бу имзаны Тукайныкы итеп күрсәтә.

58. Шүрәле. Бу — Тукайның яратып һәм бик еш кулланган имзасы. Беренче мәртәбә «Фикер»нең 1906 елгы 8 май санында күренә. Хәтта китаплары да,

мәсәлән, «Яшен ташлары»ның өч басмасы, шул имза белән чыккан. Ф. Сәйфи-Казанлы Өчтомлыкка искәрмәләрдә: «Аның «Шүрәле» имзаы псевдонимлыктан чыккан иде дип әйтергә ярый, шулай да ул үзе үлгәнче «Шүрәле» исемен ташламый»,— дип язды.

Шүрәле имзалы әсәрләренең саны 80 гә җыела. Алар арасында житди шигырьләр дә, һәҗүви әсәрләр дә , юлъязмалар да бар.

59. Шүрәле дию белгәйсез. «Гыйшык» уты» һәҗүви язмасы «Ялт-йолт»та (1910 ел, 9 нчы сан) шул имза белән басылган. «Яшен ташлары»нда бар. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка кертелгән.

60. Җен. «Ишан кәрамәте», «Яңа камустан берничә лөгать» (ахыргы өлеше) дигән һәҗүви парчалар «Уклар»да (1906 ел, 3 нче сан) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелеп, искәрмәсендә «Тукай бу псевдонимын «Уклар»да берничә тапкыр куллана» диелгән.

61. Җыючысы: Шүрәле. «Халык моңнары» (Казан, 1910 ел) китабы шул имза белән чыккан.

62. Һөд-һөд. «Алырга ашыгыңыз» һәҗүви парчасы «Уклар»да (1906 ел, 3 нче сан) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Академик басмага кертелгән.

Һөд-һөд (русча: удод) — әзербәйҗан шагыйре Г. Сабирның (1862—1911) яшерен имзасы.

63. Һәйъәте идарә. «Фикер» газетасында «Гүзәл бер хакыйкать», «Алданмаңыз», «Уральскидә Думага сайлаулар» дигән публицистик чыгышлары шул имза белән бирелгән (1906 елның 11 август, 11 сентябрь, 1907 елның 18 февраль саннарында). Барысы да беренче мәртәбә Биштомлыкка кертелгәннәр (соңгы текст «Тукайныкы булуы ихтимал проза әсәрләре» арасында).

## II. Тукайныкы булуы ихтимал имзалар һәм әлегә кире кагылганнары:

1. Без. «Үрдәк бирсәң, каз алырсың» һәҗүви мәкаләсе «Фикер» дә (1906 ел, 21 июнь) шул имза белән басылган. Р. Гайнанов мәкаләсендә Тукайныкы диелә. Беренче мәртәбә Биштомлыкта «...Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр» арасында бирелгән.

2. Бичура. Тукай исән чакта бу имза белән биш текст басылган. Барысы да шагыйрь җигелеп эшләгән матбугат органнарында. «Нәҗип Ломовой шигырьләре» исемле рецензия һәм «Җавап» (реплика) «Яшен» журналында (1908 ел, 3 һәм 5 нче саннар) чыкса, «Авыл җырлары (Алтынланган чабатаның...)», «Доносчы колагына хор белән әйтелер», һәм «Йолдыз» һәм «Кояш» дигән һәҗүви шигырьләр «Ялт-йолт»та (1910 ел, 16 нчы сан; 1912 ел, 38 нче, 47 нче саннар) күренә. Болар («Җавап»тан башкалары) беренче мәртәбә Беренче дүрттомлыкка кертелгәннәр иде. Бу басманың соңгы томына бирелгән «Г. Тукай әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның кыскача библиографиясе»нә керештә М. Бурнашева «хәзергә билгеле булмаган псевдонимнары» арасында «Бичура» имзасын да телгә ала. Шул IV том чыккан елны ук Р. Башкуров «Нәҗип Ломовой шигырьләре»нең томга кертелүен «игътибарга лаеклы факт дип» санаган хәлдә, анда авторлыкны дәлилләү булмавын күреп булса кирәк, әлеге рецензиянең Тукайныкы булуын расларга омтыла («Совет әдәбияты», 1956 ел, 4 нче сан, 102—104 битләр). Аныңча, төп факт — рецензиядә китерелгән өч җырның икесе Тукай тарафыннан җыелып, 1910 елда «Халык моңнары» исемендә чыгарылган китабының «Пешми калган җырларның нәмунәләре» бүлекчәсендә бар; берсе исә (эпиграмма) Тукайның «Халык әдәбияты» лекциясендәге бер җырга бик охшаш. Соңрак Н. Исәнбәт «Бичура — Тукай псевдонимы булу хәтлесен Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре ачыклагандыр дип беләм»,— дип язды («Казан утлары», 1966 ел, 4 нче сан, 125 бит). М. Һадиның «Псевдонимнар сүзлеге»ндә Тукайныкылар рәтендә саналган. Ләкин Икенче Дүрттомлыкта һәм Биштомлыкта бу әсәрләр урын алмадылар һәм томнарны төзүче Р. Гайнанов беркайда да аларны читләштерү сәбәпләрен язып чыкмады. Күптән түгел Ф. Ибраһимова, М. Бурнашева исемлегенә, Р. Башкуров фикерләренә таянып, аларны Тукайныкы итеп каравын белдерде. Аның тагын бер дәлиле: Тукай вафатыннан соң чыккан 1913—14 елгы саннарда («Ялт-йолт»та) Бичура имзасы очрамый (кара: «Мирас», 1994 ел, 4 нче сан, 22 бит). Ләкин соңгы факт дөреслеккә туры килеп

бетми. «Ялт-йолт»ның 1913 елның 20 маенда чыккан 56 нчы санында Бичураның «Карт үпкәләр» рецензиясе бар. Р. Нәфыйков «Доносчы колагына хор белән әйтелер»не Тукайныкы түгел дип саный («Тукай и его окружение». 1986, 194 бит). Кыскасы, Бичура имзасын Тукай имзалары арасына кертер өчен дәлилләр ышандырып бетерми әле. Н. Юзиевнең «Тукай шигырьләреме?» мәкаләсенә кушылып, «әлеге имзаны ачыклау өчен уйланасы, эзләнәсе бар» диясе килә.

3. Болгар. «Кайгырту» шигыре «Фикер»дә (1907 ел, 22 февраль) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкта «Тукайга нисбәт ителгән һәм өйрәнчек шигырьләр» арасында бирелә.

4. Бән. «Интересный тормыш» фельетоны «Фикер»дә (1906 ел, 29 октябрь) басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкта «Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр» арасында бирелә.

5. Догачы. «Куркынычлы эш» исемле һөҗүви язмасы «Уклар»да (1906 ел, 3 нче сан) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкта «Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр» арасында бирелә.

6. Каз. «Әйтелгән сүз кире кайтмас» мәкаләсе «Фикер»дә (1906 ел, 21 июль) шушы имза белән басылган. Р. Гайнанов мәкаләсендә аны Тукайныкы итеп санавын әйтсә дә, ул Биштомлыкта «Тукайныкы булу ихтимал әсәрләр» арасында гына бирелгән.

7. Кәфәштәтыюш. 1912 елгы кульязмалары арасында очраугa таянып, бу имзалы «Казаннан Думага телеграмм» әсәре («Уклар», 1906 ел, 2 нче сан) башта Академик басмага кертелгән була. Беренче дүрттомлыкта да шул ук дәлил кабатлана һәм заманасында әлеге имза белән «Ялт-йолт»та (1913 ел, 53, 54 нче саннар) чыккан «Хәйран булып калдык» һәм «Татар мәҗлесе» фельетоннары да урнаштырыла. Ләкин соңрак Икенче дүрттомлыкка һәм Биштомлыкка кертми калдырыла. Аларны төзүче Р. Гайнанов моның сәбәпләрен язып чыкмады. Аны 1912 елгы кульязмаларның төрле куллар белән күчерелүе һәм «Татар мәҗлесе»ндә авторның (Кәфәштәтыюшның) Казанда 1913 елның 27 мартында булган бер җыелышта сөйләгәннәрне үзе катнашкан кебек тасвирлавы шикләндергән булса кирәк (Тукайның соңгы көннәре!). Тагын бер нәрсә. «Ялт-йолт»ның шул ук елгы 53 һәм 56 саннарында ике шигырь чыга, имзалары — Кәфәштәтыюш — Имрелкайс.

8. Мөәррих. «Ахырзаман галәмәте» шигыре «Фикер»дә (1907 ел, 12 гыйнвар) шушы имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкның 1-томында «Тукайга нисбәт ителгән әсәрләр» рәтендә китерелә.

9. Мәхәллә карты. Р. Нәфыйков бу имзалы бер мәкаләне («Әль-ислах»та) Тукайныкы булуы мөмкин, ачыклау эшен дәвам итәргә кирәк, дип саный («Тайны революционного подполья». Казан, 1981, 106 б.)

10. Тәнкыйть сөюче. Бу имза белән «Әль-ислах»та (1908 ел, 13, 31 нче саннар) чыккан «Корымлы мунчалар» һәм «Бичара Бибиҗиһан» исемле рецензияләр Академик басмага һәм Беренче дүрттомлыкка кертелгәннәр иде. М. Һади исемлегендә бу имза бар. 1978 елда И. Нуруллин бер җыелышта «Бичара Бибиҗиһан»ның, тирән эчтәлекле әсәр булса да, Тукайныкы түгеллеген әйтте. Икенче дүрттомлыкта һәм Биштомлыкта күренми. «Корымлы мунчалар», А. Сайганов төзегән «Фатих Әмирхан» дигән библиографик күрсәткечтә булуга нигезләнеп, Ф. Әмирханның дүрттомлыгына кертелгән, ләкин аңлатмаларда имзаның тагын да аныклауга мохтаҗлыгы искәртелгән.

«Бичара Бибиҗиһан» — шигырь белән язылган рецензия. Ә Ф. Әмирханның бу елларда исә тезмә әсәрләр язуы мәгълүм түгел. «Тәнкыйть сөюче» имзасы Тукайныкы булуы да ихтимал. Элегрәк «Әль-ислах»та «Тәнкыйть кирәкле шәйдер» дип чыккан иде бит әле ул... «Корымлы мунчалар» «Әль-ислах»та (13 нче сан) Тукайның Гъ. Т. һәм Феакут имзалары белән басылган ике шигыре арасына куеп бирелгән. Бу да имза иясе Тукай булуга ишарә итә кебек.

11. Ул. «Хәсәнҗан бине Әхмәтҗан әл-Хөсәениненң хиҗаб хакында улан мәзһәбе» дигән фельетоны «Фикер»дә (1907 ел, 22 февраль) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкта «Тукайныкы булуы ихтимал проза әсәрләре» рәтендә бирелгән (Р. Гайнанов мәкаләсендә бу имзалы әсәрләрнең Тукай каләме белән язылуы әйтелсә дә).

12. Шагыйре мәшһүр Якыйф Җәмали. «Ялгызлыкта» исемле шигъри пародиясе «Ялт-йолт»та (1913 ел, 54 нче сан, 3 апрель) шул имза белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкта «Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр» арасында китерелгән. Пародиядә шагыйрь Вакыйф Җәлал иҗаты тәнкыйтьләнә.

**Зөфәр РӘМИ**

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ МӘХӘББӘТЕ

*Тукайның әниемә булган мәхәббәте кайнар, сәер һәм яшерен була.*

Атилла Расих. «Ишан оныгы».

Зәйтүнә, Зәйтүнә...

Габдулла Тукайның төш күрүе турында үз кулы белән язылган әсәрләре дә бар. Ләкин ул һәрбер күргән төшен дә әдәби әсәр итеп яза бармаган. Ә менә бу юлы, Ходайның хикмәте, ничәнче тапкыр инде ап-ачык итеп, менә мондый төш күрде ул.

«Әль-ислах» гәзите редакциясе, имеш. Әкрен генә, тирә-ягына карангалап ала да, Зәйтүнә аның янына сак кына килә, ә аңардан ниндидер җылылык бөркелеп тора. Иң башта «үзе кул биреп» исәнләште, аның йомшак кына, кечкенә кулының җылысы бөтен тәнгә тарала. Ә күңеле һаман уяу тоела, ничек инде бер кечкенә кул, җылылыкка туймаган, өшеп йөргән Габдулланы эретеп ташлавына хәйран калды. Зәйтүнә якынайган саен аның җылысы күкрәкләрне йомшартты, ниһаять, тирләтә башлады. Мунчадагы кебек, җылылыктан тын алуы читенләште, еш-еш тын ала башлады. Ә күңел үзенекен итә: Зәйтүнә аның каушап, оялып, еш-еш тын алуын сизеп, уңайсызлана. Габдулла горур, имеш: «үзе кул бирде», аның сулышын да тойгандай була кебек.

Эсселектән тыны куырылып уянып киткәч, беләкләренә кадәр тирләп чыккан, июнь аеның кызу кояш нурлары тәрәзәдән төшеп бүлмәне кыздыра икән. Бераз төш тәэсиреннән кымшанмый гына яткач, Зәйтүнә Мәүлүдованың күзләрен, кыйгач кашларын, никадәр үпсәң дә туялмаслык иреннәрен күз алдына китерде. Күңеле күтәрелеп, чатнап киткәндәй булды һәм, үз хәлемне үзем беләм дигәндәй, убылып та төште. «Ничәмә мәртәбә керәсең төшләремә, йөзең күркәм, буең зифа банкаларда үскән кынадай...» дигән уйлар йөгереп үтте. Чү, бу җырны Гөләнвәрнең үзенең өзелеп сөйгән егете Фазылга язган хатында миннән яздырган иде бит. Ул хатны язганда аның кечкенә йөрәге и типте, и типте! Хәтеремдә, Гөләнвәр хатны язганда да, язылып бетеп, укып чыкканда да бер сүз әйтә алмады. Бераз иреннәрен җылап җибәргәндәй мимылдатып торды, күзләренә килеп тулган яшьләрен яшерә алмыйча сөртте һәм Габдулланы җылы, йомшак күкрәкләренә китереп кысты һәм бик нык итеп үбеп алды. Аны үз гомерендә башка беркем дә болай кочаклап үпкәне булмады...

Зәйтүнә, Зәйтүнә! Иренмә, еш кына көзгегә бак!
Күр йөзеңне: нинди нурлы, нинди алсу, нинди ак!

Тукта, урыс шагыйре Лермонтовның нәкъ шундый бер шигыре бар иде бит әле. Илһам килгәндә бер шигырь багышлыйм үзеңә, Зәйтүнә.

Ул күзең йолдызлыгын һәм ул кашың кыйгачлыгын,
Ул авызың никадәр үпсәң дә туелмаслыгын
Күр дә: бу шагыйрь мине бигрәк белеп мактый, диген,
Бу шигырь мәгънәсе хәзер бик ачык, якты, диген.
Ихтыярсыз, күңлең уйлар: миннән артык юк, диеп:
Сизми калып, син суларсың: мин матурмын, уф! диеп.
Үз-үзеннән разый булыр, яшь күңел дулкынланыр
Һәм диер: ай-һай, матур мин, кем алыр, тик кем алыр?
Шунда уйларсың: бу шагыйрь бушка аһ ормый, диеп:
Аһлары, фәрьядлары чынлап та урынлы, диеп.
Йә, җанашым, син дә бу хәлдә минем яклы бит, ә?
Гыйшкың юлында һәлак булсам да мин хаклы бит, ә?

Нинди шигырьләр генә язмый ул үзенең яшерен сөю хисләре турында. «Мин шундый малай инде, алма бакчасында бакчачы үзе биргән алманы, урлаган алманы ашап торган малайлар алдында: «Менә үзе бирде!» — дип, горурланып ашыйм, ә мәхәббәт бакчасында кыз үзе танышырга теләп, миңа яучы җибәрмәсә, мин һичвакыт танышырга эзләп, ваксынып йөрмим. Әмма үзе кул бирсә, тагы да «үзе бирде» дип горурланам, кадерлим ул кулны! Әмма, минем гәүдәм,

физик булмышым кызлар каратырлык мени, язам шунда, язам да ялган имзалар астына сыгынам, керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле. Ярабби, ятимләкләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан авылга сатылып йөрүләр, татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдекем булдыклылык очкыны шушы исереклекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?»

Ләкин чын-чынлап уйлап караганда, ул үзенең сөйгәнен бәхетле итә алмавын аңлый, сызлана, җәфалана. Яшь йөрәк түзми, күзе төшкән, ятраткан кызларга багышлаган шигырьләрен яза бирә. «Мәҗнүн» имзасы белән Зәйтүнәгә мәхәббәте тәэсирендә тагын бер шигырь Тукайның шәхси үз хәлен ачып сала.

Тирләп, эссе көндә койнырга теләп,
Бер кеше салкын су алды бер чиләк...
Суны җилкә аркылы читкә сибеп
Куйды да...
«Әл дә тәнгә тимәде»,— дип шатлана.

Кунакханәнең салкын бүлмәсендә күңелсез уйлардан калтыранып куйды ул. Өстәл тартмасыннан алып аспирин капты һәм эчеп куярга теләде. Бүлмәдә су юк иде, дару авызда шул көе эреп, таралып бетте. Бераз ябынып яткач, уйлары «җилкә аркылы читкә сибелгән салкын суны» хәтерләтте, үзенең яшерен мәхәббәте белән чагыштырды.

Мин моны яздым, бу гыйшкым миследер;
Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.
Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам —
Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам.
Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим, имеш;
Ут йотып янсам да, ялган кул куям,
Мин сөйгәнне белмәсен дип куркуда.
Тугры килсәм, сүз сөйлим салкын гына,
Булса да күкрәк тулы ялкын гына.

Татлы мәхәббәт хыялларына бирелгәнлектәндер инде, сүзләр үзеннән-үзе рифмалашырга гына торган кебек. Күңеле бер яктан яшерен яну белән янса, икенче яктан сәер кичерешләре белән барысын пыр туздырып, таратып ташлый. Әй, Аллаһым, дөньялыкларда үзең кебек һәм үзеңә тиң хәләл җефет белән гөрләшеп, чөкердәшеп пар күгәрченнәр кебек, гомер кичерүләргә ни җитә!

Артык дулкынланып китеп, өстәл артыннан тора һәм тәрәзәгә таба килә. Урамда тынычлык. Еракта утлар җемелдәп күренеп ала. Ә йолдызлар шулкадәр күп, аларның төрлелегенә карап, исең китмәле. Терсәкләре белән тәрәзә төбенә таянып уйга кала.

## Тукай Бишендегә ни өчен килмәгән?

*Моңлы бала түгел идем,*
*Моңнар төште башыма.*

Халык җырыннан.

Безнең Бишенде авыллары Златоуст — Оренбург, Казан — Уфа тракты дип йөртелгән олы юлдан бик ерак урнашмаган. Шулай ук ерак түгел Атнагол, Турай авыллары ярминкәләре дә ел саен гөрләп торганнар. Димәк, заманына күрә укымышлылары, алдынгы карашлылары сәяси яктан да, иҗтимагый яктан да хәбәрдар булганнар дияргә кирәк, аралашып торганнар. Әмма Ходай язмаган инде, адәм рәтле каләм тибрәтүчесе дә булмаган, ничәмә-ничә Бишенде авылларының данын күтәрердәй бер кеше дә табылмаган. Борын астыннан гына: Бишенде, Би-шенде-е-е...» дип, тавык моңы белән генә аяк өсте моңланучылары булса да, әллә ни аның даны еракларга ишетелми шул. Болай, уйлабрак карасаң, табигать тә бик кыерсытмаган үзләрен, бик матур боргаланып аккан елгалары, челтерәп аккан салкын сулы чишмәләре, зур-зур ташлары һавага ашкан таулары, җиләк-җимешкә, киек-җәнлекләргә бай урманнары кеше сокланып туя алмаслык. Шунда шүрәлеләр чыккалап, кешеләрне кытыклап, көлдереп йөрсәләр дә тирәякларда ишетмәгән-белмәгән кешеләр булмас иде.

Ичмаса, татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай килгән булса да, бишенделеләрнең күңелләрендә бер сагынып сөйләрлек хәтирә булырдае. Күплэрегез, ничек инде ул, дип елмаеп куярсыз. Ә шулай да бишенделеләр аеруча яраталар Габдулла Тукайны. Менә Югары Бишенде авылы колхозлаштыру чорларыннан бүгенгәчә Тукай исемен ташлаганы юк. Башта Балашов исемендәге колхоз оеша. Ул бер таралып оеша, өстәвенә ул кеше, югарыдан җибәрелүенә карамастан, «халык дошманы» булып чыга, шуңа күрә халыкны сөйгән, янып көйгән данлыклы кеше Габдулла Тукай бу колхоз исемен ала һәм бүген дә сынатмый, әлбәттә.

Ул вакытларда Каран Бишенде авылы Югары Бишенде авылыннан дүрт адым тыкрык белән генә аерылып торган. Тыкрыкта үскән ике авыл «арасындагы» тал тирәкләре бүген дә үсеп утыралар, кемнәргә шуннан үтәргә туры килә, дикъкать белән карагыз әле. Менә шушы авылда 1901 нче елда кирпечтән салынган мәдрәсә ачыла. Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, авыл бае Зиннәтулла улы Мөхәммәтша, аның хуҗасы була. Үзе белән бергә укыган шәкертләрдән мөгаллимнәр чакырта, араларында Зөләйха исемле мөгаллимә дә була. Мәдрәсәгә урам аша гына мулла Мөхәммәтшаның ихатасы: үзе гаиләсе белән торган йорт, хезмәтчеләр өчен йорт, мөгаллимә торган йорт һәм келәтләр, абзарлар...

Язгы кояш кыздыра башлаган чак. Өй эшләрен бетергәннән соң ун-унбер яшьлек Кәфия исемле кыз бала биек күтәрмә өстенә чыгып утырды. Шунда челтерәп кыңгырау тавышы ишетелә һәм ат җигелгән кошовка капка төбенә килеп туктый. Җитез генә сикереп төшкән кыска сакаллы кеше мөлаем гына сорады:

— Сөбханалла, кызым, хуҗалар өйдәме?

— Әйдүк, бабакай, әйдә, әйдә,— дип көйләде кыз бала. Әллә ничек, көйләп, җыру әйткәндәй булды.

— Әллә җырлый да беләсең, кызым? — дип, көлемсерәде бабай һәм тыңларга әзерләнеп, көтеп калды. Нишләргә дә белми Кәфия кулбашларын җыерды. Кыюланып, туп-туры итеп басты да өздереп җырлап җибәрде:

— Без барасы җулларның ике чаты канаулы;
Без моңаймый кем монайсын — калган гомер санаулы.
Кычкырма, күке, каршымда, кычкыр агач башында;
Моңлы бала түгел идем, моңнар төште башыма.
Менәр идем — тау биек, төшәр идем — җул кыек;
Җыен туган арасында минем күңелем боек.

Бабай кеше, тагын кемнәр ишетте икән, дигән кебек шомлы гына каранып ала һәм атлары янындагы кеше белән пышылдап сөйләште. Аннары, кызның башыннан сыйпады һәм бер төргәк тоттырды. Анда бер бик матур чәчкәле яулык һәм төргәге белән аллы-гөлле кәгазьләргә төрелгән кәнфитләр иде.

Икенче көнне бәләкәй абыстай белән уртанчы абыстай сөйләшүеннән Кәфия аңлавынча болай булган: теге кыска сакаллы бабай аның иң яраткан мөгаллимә абыстае — Зөләйханы Уфага алып киткән икән, чөнки аны Габдулла Тукайга ярәшкән булганнар, ди. Зөләйха абыстай китүгә, мондагы бәләкәй абыстай әй сөенгән иде! Олы абыстай орышкач кына туктады. Шулай итеп, Мөхәммәтша мулла дүртенче абыстайдан колак какты, күзе бик тә кызган иде. Ә чынында менә ничек булган: Зөләйханың әнисе бу турыда ишетү белән: «Баланы авылда калдырасыбыз юк. Әнә, Тукай Гафури янына килгән, ала диген, ярәштек диген, ал да кайт, атасы!» — дип, эшне бик каты һәм кыска тоткан.

Менә шул. Ходай насыйп итмәгән. Ни өчен ул Бишендегә килсен ди инде?

## Мәхәббәт — шигъри илһам бирүче булган. Әминәм минем...

Син дисең, имеш ки, шагыйрьгә барам;
Барма, барма — син әрәм аңгар, әрәм.
Үз уеңча, шагыйрь ул җырлый дисең,
Җыр исә тыңларга күңелле дисең.
Син алай иткәнче, и кашың һилал!
Бар да бер кош кибеттән былбыл ал.
Ал да читлеккә куеп сайрат аны;
Максатын хөснеңне — син саргайт аны.

«Әльислах»ның 1908 нче ел 3 июнь (32) санында «...гә (Мәслихәт)» исемендә «Шүрәле» имзасы белән басылган «Диван»да «...гә» — «...га»га алмаштырылган. Бу шигырьне багышлауда һәм басылганда авторны яшерү Тукайның кызларга карата мәхәббәте ифрат оялчан, яшерен, сәер һәм кайнар икәнлеген укучы чамалый торгандыр.

Ул... Әминәнең онытып калдырган перчаткаларын үбә, редакциядә күнелләре йомшап, җылап җибәрердәй була. Ә үзе аның белән очрашудан качып йөри. Тукай үзенең чиксез көчле, горур сөю белән янганлыгы турында Галиасгар Камалга гына сөйли. Ә Әминәгә белдерергә тартына, ул мине аңламас ди, һәм ин изге хисләрем мәсхәрәләнер ди, аяк астына салынып тапталыр, дип курка. Менә минем кебек бер йолкыш шәкертнең ана ни кирәге бар. Аның миннән өстенрәк, баерак һәм көчлерәк табынучылары аздыр дисеңмени. Тик мин аны шулай да яратачакмын...

Әминә авыл укытучысы булып Казаннан китә. Габдулла Тукай нык кайгыра, уйлана, ни эшләргә белми... үз-үзенә кул салмакчы була. Ул бу турыда үзе Хөсәен Ямашевка да сөйли. Аннары Әминәгә багышлап нинди генә шигырьләр язмый ул!

Әгәр җәннәттә күрсәм мин йөзеңне,
Күрермен ай йөзеңдә үз йөземне.
Табигый, синең күркәмлегең күкнегә
Һәм һәрбер әгъзаң нәфис, мактаулы.
Беләм инде: мине әсир итәрсең,
Сихерләрсең, мине әфсүн итәрсең.
Сөярмен мин сине дә, бик сөярмен,
Яратырмын, янармын да көярмен.
Синең һәрбер сүзең җанга рәхәт,
Синең һәрбер сүзеңнән күңел ял итә.
Тавышың сандугач тавышыннан матуррак,
Кем теләр соң синнән аерылырга?
Син үзең һәрвакыт изге, хөрмәтле,—
Без гөнаһлыларга кагылырга да ярәм.
Гүзәлсең син, матурсың син, матурсың;
Матурларның матурыннан матурсың.
Гүзәлсең син, зәбәрҗәтсең, асыл ташсың,
Ләкин җир кызы төсле түгелсең.

Табигать адәми затны шундый итеп яраткан, күрәсең, Габдулла Тукай яшендә күпләребез үзенең ихтыяҗларын йөгәнләп, киләчәк өчен олы юлдан алып китә алмый ялгышларга дучар була. Парлап гомер кичерүдәге берсе игәү, берсе тимер булып яшәү дә шул чаклардан башланадыр. Ә Габдулла Тукайда нинди олы тотанаклылык булган.

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас — төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.
Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре,— әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Шагыйрьнең мәхәббәте ни дәрәҗәдә көчле булуы турында һәрвакыт исеннән чыгып тормаган. Ул җаны белән, уй-акылы белән сөйгәненә зарыккан, ләкин үз йөрәген сөйгәненең йөрәгенә бәйләргә батырчылык итмәгән.

Мин төш күрдем. Гүя мин бер зур шаһ, имеш,
Таҗыма тезгән энҗе, мәрҗән, ахак, имеш;
Сине сөеп, шигырь сөйләп, шагыйрь булып
Йөрүләрем бөтенләй үк нахак, имеш.

Таҗлы башым хозурыңда иям, имеш,
«Җанашым, мин сине сөям»,— диям, имеш;
Нәрсә генә әйтер инде сөйгәнем дип,
Эчемнән бик янам, имеш, көям, имеш.

Сөю һәм мәхәббәт җимеше булган кеше дөнья яратылганнан бирле асылда бер үк табигать законы белән бара. Ул закон — мәхәббәт. Һәм һәр йөрәк аны үзенчә яңарта. Шулай булмаса, яшәүнең кызыгы да, мәгънәсе дә булмас, төшләргә кереп тә йөдәтмәс иде.

**Әнвәр НИЗАМЕТДИНОВ,**
*Башкортстан, Туймазы районы,*
*Югары Бишенде авылы.*



**Булат Хәмидуллин,**

Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре, аспирант

# ТАТАРЛАРНЫҢ ЭТНИК ТАРИХЫ

## турында уйланулар

Һәр яңа заман тарихи вакыйгаларны башкачарак күзалларга, ниндидер бер ачышка таянып, аларга үзгәрәк бәһа бирергә тырыша. Тарих өлкәсендәге андый ачышлар бигрәк тә соңгы егерме-утыз елда нык күзгә ташлана. Бу елларда узган гасырлар тормышына яңача бәя бирүче галимнәрнең алгы сафына Лев Николаевич Гумилев чыкты дисәк, берәү дә каршы килмәстер, мөгаен. Бигрәк тә аның этноска, этногенез мәсьәләләренә караган хезмәтләрен һәм СССР дип аталган зур империянең төп халыкларын тәшкил итүче славян-руслар белән төрки халыкларының үзара яшәешенә багышланган эзләнүләрен әйтергә була. Дөрес, Гумилевның этнослар үсешенә һәм этник тарихны барлауга багышланган теориясен идеаллаштыру, аны һәр очрак өчен үрнәк итеп карау бик үк дөрес түгелдер. Әмма ул теория нигезендә «иске» тарихка яңача карау ысулы үзен бик аклый.

Шушы ук яссылыкта эшләүче Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев уңышларын да билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Мөхтәрәм академигыбызның соңгы зур хезмәте моңа мисал булып тора. Л. Гумилев кебек ул да бүгенге көн тарих фәнендә өстенлек итүче концепцияләргә канәгатьсезлек белдерә, ул карашларны гомуми тарихи процесска да, этносларның барлыкка килү мәсьәләләренә дә ачыклык кертүгә комачау итүләрен билгеләп үтә.

Алда әйтелгәннәргә мисал рәвешендә, гомуми тарихка караган заманча хезмәтләрдән Л. Гумилевның «Древняя Русь и Великая степь» (***Мәскәү, 1993***), М. Зәкиевнең «Татары: проблемы истории и языка» (***Казан, 1995***), С. Алишевның «Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV—XVI вв.» (***Казан, 1995***) китапларын китерергә була. Ә этнос, этногенез мәсьәләләренә багышланган олы хезмәтләрдән Л. Гумилевның «Этногенез и биосфера земли», Ю. Бромлейның «Этносоциальные процессы: теория, история, современность» (***Мәскәү, 1987***) китаплары аерым атап үтәргә лаеклыдыр.

Бүген этносларның килеп чыгышы күпләрне кызыксындыра. Чөнки җир йөзендә яшәгән һәр этносның, күпме кешене берләштерүенә, зурмы, кечеме булуына карамастан, үз тарихы бар. Хәзерге чорга аяк басканчы ул этносларның бабалары бик-бик катлаулы яшәеш дәверләрен кичергәннәр. Әнә шул озын тормыш юлының сикәлтәләрендә кайчандыр зур-зур мәмләкәтләр тудырган кайбер этнослар бүген бик аз санда гына калганнар, яисә бөтенләй юкка да чыкканнар. Шуңа күрә һәр аерым этносның үткән тарихын барлау эше гаять тә катлаулы эш, аңа берничә буын галим вә тикшеренүчеләрнең хезмәт итүе кирәк.

Аерым этносларның тарихи үткәне бүгенгә чаклы ныклап өйрәнелмәве — әнә шул кыенлыклар нәтиҗәсе дә. Бигрәк тә кайбер халыкларның борынгы оешу чорын барлау, аларның кайсы этнослар белән кушылу нәтиҗәсендә туганлыгын ачыклау бик катлаулы. Теге яисә бу халыкның үз табигатенә салынган үсү, алга

китү процессларының чит бер йогынты нәтиҗәсендә төптән үзгәреш кичерү очраклары да еш кабатланып тора.

Гадәттә теге яисә бу халыкның килеп чыгышын төрле этносларның бергә кушыла башлау вакытыннан гына өйрәнергә керешәләр. Болай эшләү, минемчә, тикшерелә торган этносның үсеш тарихын тулы чагылдырмый. Фәндә теркәлгән һәр очракны барлый-барлый төп этносның ерак тамырына кадәр төшү, шул дәвердә аңа нинди холык-гадәтләрнең хас булуын ачыклау гына түгел, ә аны тудырышкан аерым этносларның да җиде бабасына җитү зарур. Шулай эшләгәндә генә, ягъни бер халыкны тудыруга булышкан һәр этносның генезисын җентекләп барлаган очракта гына чын дөреслеккә ирешеп була, минемчә. Шулай ук төп этностан аерылып чыгып, башка бер халыкны тудыруга катнашкан кардәш кан тармакларын да барлау бик-бик зарур булачак.

Югарыда бәян ителгәннәрнең барысын да истә тотып, Идел буе татарларының килеп чыгышына бәйле булган тарихи вакыйгаларны, этник үзгәреш-аралашуларны кыскача гына итеп тагын бер мәртәбә күз алдыннан уздырасы килә. Дөресен әйткәндә, бу язма алда күрсәтеп кителгән, тарихи чынбарлыкка яңача караш уяткан олы хезмәтләр белән танышу барышында туган уй-фикерләр белән уртаклашу хасиятеннән килеп туды. Элегрәк тә — Азак һәм Кара диңгезләрнең төньяк тарафларындагы иркенлекләрдә борынгы дәверләрдән бирле көн күргән күчле күчмә кабилә-этносларга багышланган гыйльми китаплар укыганда да — ул скиф, сармат кебек этносларның тормыш-көнкүреш рәвешләренең безнең халыкның төп нигезен тәзүче хазар, болгар һәм кыпчаклар яшәешенә охшаш булганлыгына әһәмият иткән идем. Димәк ки, егерменче гасырның күренекле галимнәреннән А. П. Смирнов; К. Ф. Смирнов, М. И. Артамонов, И. Б. Брашинский, С. А. Плетнева, М. В. Агубнов, С. С. Черников һәм башкаларның ул иркен далаларда яшәгән күчмәләр тормышын тасвир иткән хезмәтләре дә шушы язма туугa бер этәргеч булгандыр.

* * *

Төрки халыкларның, шул исәптән Идел буе төрки-татарларының да тарихта мәгълүм иң ерак бабалары «киммериләр» дип аталган ыру-кабиләләр берләшмәсенә кергән булса кирәк. Күчмә тормышлы киммериләр әлеге иркен дала һәм ярымдала төбәгендә безнең эрага кадәр сигез-тугыз гасыр элек яшәгәннәр. Биләмәләренең көнбатыш чиге Дунай елгасының Кара диңгезгә койган урынынача җитеп, көньяк чикләре Азак һәм Кара диңгез ярлары буйлап сузылганлыгы мәгълүм. Бу күчмәләрнең төньяк һәм көнчыгыш тарафларга күпмегә җәелеп яшәүләре анык ук түгел. Мәсәлән, кайбер авторлар аларның биләмә чигенең көнчыгыш өлешен Идел-су буенча билгеләсә, икенчеләре ул чикне тагын да арырак күчереп күрсәтергә телиләр.

Киммериләр тел үрнәге итәрдәй бертөрле дә язма калдырмаганнар дип уйланыла әлегә. Мәдәни күршеләре тарафыннан бары тик аларның аерым сүзләре яисә исем-атамалары гына теркәп калдырылган. Алар яшәгән чорга нисбәтләнгән зур археологик табышлар да алай ук күп түгел, чөнки тарихта эз калдырырлык зур уртак-калалары әле бик аз санда булгандыр, күрәсең. Шулай да бөтенләй үк эзсез дә югалмаганнар, әлеге киң далада алар чорына караган кайбер калдыклар, каберлекләр очраштыргалап тора.


Аннары шул ук җир-төбәкләрдә киммериләр урынын күчмә тормышлы скифлар биләгән дип исәпләнелә. Күпчелек галимнәр ул скифларны бөтенләй дә яңа бер этнослар дип, алар элекке киммериләр берләшмәсен бу җирләрдән куып чыгарганнар дип исәпли. Әмма ләкин чынлыкта шулай ук булганлыкны тәгаен белүе читен. Тарихи вакыйгаларга сабыррак карашлы галимнәрнең фикере исә үзгәрәк: элекке ыру-кабиләләр берләшмәсенә исем бирүче этносның көчсезләнүе нәтиҗәсендә икенче бер этносның өскә калкып чыгуы һәм үз атамасын илгә-җиргә танытуы да бик ихтимал. Күчмәләр тормышындагы мондый үзгәреш мисаллары соңгырак заманнарда да еш кабатланып тора бит.

Яңа эра туганчы биш гасырдан артыграк хөкемлек иткән скифлар дәверен галимнәр, Евразиядә яшәүче киләчәк буынга карата уңай йогынты үрнәге булачак, борынгы греклар һәм римлеләрдән соң өченче урында тора дип билгелиләр. (*Кара: А. П. Смирнов, «Скифлар», 7 б.*). Скифларда сәнгать бик югары дәрәҗәгә ирешкән була, ил белән идарә итү һәм хәрби тәртип буенча да алар алдынгылыкка ирешкән дип саналалар.

Мондагы ыру-кабиләләр берләшмәсенә караган мәгълүматлар башлыча шул грек һәм латин телле авторлар хезмәтендә сакланган. Аларга багышланган әзмекүпме мәгълүматны Кече Азия илләренә бәйле чыганакларда да очратып була. Әйтик, безнең эрага кадәр 673 елны Ассириядә теркәлгән бер язмада, «Ишкуза иле» дип, шул чорда скифләр яшәгән төбәкнең аталганы хәбәр ителә. Әмма бу күчмәләр тормышын тәфсиллап бәян кылган кеше — тарих гыйлеменең атасы саналган грек Геродот. Шул халыкларга ул чордаш булган (безнең эрага кадәр 484—425 елларда яшәгән), кайбер галимнәр фикеренчә, скифләр иленә сәяхәт тә иткән булса кирәк. Геродоттан ике-өч гасырга соңрак яшәгән, атаклы яугир Александр Македонскийның елъязмачылары булган грек тарихчылары язмаларында да скифләр телгә алына. Мәсәлән, Македонскийдан йөз еллар соңрак яшәгән Курций Руф грек гаскәрләренең Урта Азия төбәгендәге бер бәрелештә «сакаллы скиф»ләрдән җиңелү очрагын тасвирлый.

Асылда кемнәр булганнар соң ул скифләр? Күпчелек галимнәр аларның төрле-төрле ыру-кабиләләрне берләштерүен язалар. Мәгәр баш халык, шул берләшмәгә исем биргән кешеләр турысында юраулар, бәхәсләр әле дә тынмый дияргә була. Геродот аларны Кара диңгез буйларындагы бай табигатьле урыннарга килеп төпләнгәнче Азия төбәгендә яшәгәннәр дип гоман итә. Аның әйтүенчә, скифләр килгәннәр дә, моннан киммери кешеләрен кысрыклап чыгарганнар. Бу хәбәрләргә фәннең бүгенге карашыннан чыгып тукталып үтик. Беренчедән, скифләр чынлап та элек Азиядә яшәгәннәрме? Аларның төп илен кайсы төбәктәнрәк эзләргә? Кайбер галимнәр аларны Көнчыгыш Европага ерактагы Үзәк Азия өлкәләреннән үк күченеп килгәннәр дип исәплиләр. Әмма әле берәүнең дә бу хакта ышандыргыч дәлил китерә алганы юк диярлек. Дөрес, шушы гасыр башындарак Улан-Удэ шәһәреннән ерак түгел бер урында «скиф ханы»ның борынгы бер каберлеген тапканнар иде. Ләкин, шул чорга караган каберлек булса да, Кара диңгез буенда яшәгән скифләргә ни рәвешле бәйләргә? Алтай төбәгендә табылган бай каберлекләр дә — шул чор каберлекләре. Күмү йоласы, күмүдә кулланылган бай хәзинәләр дә — уртак. Ләкин бит ул төбәкләрдә элек-электән скифләргә тугандаш күчмә халыклар яшәгән, гореф-гадәтләр уртак булган. Шуңа күрә киммериләр җирендә төпләнгәннәренең кайсы төбәктәнрәк булуларын дәлилләүдә әлегә уртак бер фикер юк. Аннары ул заманнарда Европа белән Азияне «бүлү»дә бүгенге бүленешкә тәңгәл килми. Геродот яшәгән чорда ул бүленеш, башлыча, Танаис (хәзерге Дон елгасы) чигеннән үткән. Димәк, скифләрнең Идел буеннан гына күченеп килеп тә (андый күченү булса әле) «Азиядән килүчеләр» атын алган булулары бик тә ихтимал.

Геродотның: «алар киммери халкын куып таратып, шулар җирен биләгәннәр», дип белдерүе белән дә тулаем килешеп булмый. Дөресрәге монда конверсация күренешенә хас хәл, ягъни мәсәлән, скифләргә гореф-гадәтләре белән охшаш киммериләрнең үзара кушылып китүе хас булгандыр кебек.




Безнең гасырга кадәр 1 мең ел элек Скифиянең якынча чикләре. *(Кара: А. П. Смирнов. Скифы. М., «Наука», 1966. С. 50; История Европы (в 8 томах). Т. I. М., «Наука». 1988. С. 674.)*

Дөрес, төрле чыганакларда теркәлгән мәгълүматларга караганда, скифләр элек бик тә хәрәкәтчән һәм сугышчан халык булганнар бугай. Үзәк Азиядә алар катнашында берничә зур бәрелеш булган дип санала. Шуннан соң бу күчмәләрнең зур бер төркеме көньякка, икенчесе көнбатыш тарафка таба ябырыла булса кирәк. Кайбер мәгълүматларга нигезләнеп галимнәр, көньякка ябырылган «дул-

кын» безнең эрага кадәрге җиденче гасырның җитмешенче елларында Якын Көнчыгышка барып чыккан дип исәпли. Анда алар мидиялеләр һәм тагын кемнәр беләндер берләшеп, Азиянең ул өлешендәге иң зур, иң көчле дәүләтләрнең берсе булган Ассирия белән көч сынашалар. Аннары ул яу ташкыны, көньяк-көнбатышкарак юлын дәвам итеп, Фәләстин Сириясе аша үтә, борынгы Мисыр чикләренә үк барып чыга. Фараон Псаметих Беренче алар явыннан бай бүләкләр җибәреп кенә котылып кала, дип бәян ителә.

Көнбатышка таба ургылган ташкынның исә Европа үзәгенә юл тотканлыгы мәгълүм. Тарихчылар шул күчеш вакытында скифләрнең элек-электән монда яшәгән славяннарны урыннарыннан кузгатуга сәбәпче булган дип уйлыйлар. Шул вакыйгалардан соң славяннар көнчыгыш тарафка тайпылып, Карпат таулары тирәләренә килеп тупланалар икән.

Безнең эрага кадәр җиденче гасыр ахырларында бер зур төркем скифләрнең Италия ярымутравының төньяк төбәгенә барып төпләнүе хакында да хәбәрләр бар. Бу хакта әлегәчә бик серле тарихлы саналган этрусклар язмышын ачыклауга багышланган хезмәтләрендә В. Брандштейн, А. Пиганьоль, Гадилә Айда һ. б. галимнәр язалар.

Шулай итеп, Кара диңгез буе далаларына һәм ярымдалаларына килеп төпләнгәнче скифләрнең бөтен Евразия буйлап йөреп чыкканлыклары да ачыклана.

Заманына күрә шактый югары культурага һәм дәүләтчелеккә ия булган киммериләр дә, тарих сәхифәсендә аларны алыштырган скифләр дә күпсанлы ыру-кабиләләрне берләштергән берләшмә булганнар дип уйланыла. Скифләр хакимлек иткән берләшмәгә, мәсәлән, төрки, фарсы, угро-фин телләрендә, хәтта ки славян телендә сөйләшүчеләр дә кергәндер, дип фараз кылына. Ләкин кайсы тел уртак, аралашу теле саналган соң? Бу мәсьәләдә әлегә бертөрлелек юк диярлек. Күп кенә галимнәр бу ыру-кабиләләр арасында «патша скифләр»нең өстенлек иткәнен раслыйлар. Мәрхүм галимебез Җәвад Алмазның «патша скифләр»нең төрки телдә сөйләшүен дәлилләп язган хезмәтләре барлыгы мәгълүм. Үкенечкә, алар әле киң җәмәгатьчелеккә җиткерелмәгән, аның белән чикләнгән даирәләр генә таныш (алар Дәүләт музееның кульязмалар бүлегендә саклана).

Европа һәм рус галимнәреннән дә шул ук фикерне яклаучылар бар, алар скифләрнең үзара аралашу теле дә төрки булган дип белдерәләр. Рус галимнәреннән скифләргә багышланган беренче хезмәт авторы А. Лызлов (XVII гасыр) белән XVIII гасыр авторы В. Татищев та шул фикердә булалар. Исеме югарыда аталган зур хезмәтендә академик М. Зәкиев тә дөреслектә эшнең шулай булганлыгын күптөрле мисаллар һәм борынгы авторларның язмалары ярдәмендә дәлилли.

Әмма кайбер авторлар, бигрәк тә совет чоры галимнәре, «скифләр башлыча иран-фарсы сөйләмендә сөйләшкәннәр» дигәнрәк нәтиҗә чыгармакчылар. Болай дәлилләүнең үзенә күрә «кечкенә» генә сере дә бар бугай: европалылар үз телләрен (шул исәптән руслар да) иран-фарсы теленә нисбәтле дип исәплиләр. Шунлыктан, бер яктан: яшәү рәвешләре һәм гореф-гадәтләре белән башка төрки күчмәләрдән аерылмаган, ә икенче яктан: тормыш иткән җирлекләрендә бөтенләй үзгә дин тотучы һәм үзгәчәрәк яшәүче иранлыларга мөнәсәбәтле һичнинди тарихи эз калдырмаган киммериләр белән скифләрне (аннары шул ук җирлектә көн күргән сармат һәм аланнарны да) аларга хас булмаган тел дөньясына «бәйләү» — фәнни караштан бигрәк, сәяси карашларга мөнәсәбәтледер кебек кабул ителә. Дөреслекне, ягъни ул халыкларның борын-борыннан оешканлык, дәүләтчелек үрнәкләре күрсәтүен тану — аларның варислары булган төркиләрнең дәрәҗәсен бик нык күтәрәчәк бит. Шуннан соң аларны баскын итергә сәбәп булган «килмешәк»лек теориясенә таяныр нокта да калмаячак иң...

* * *

Безнең эрага кадәр икенче гасырда элек скифләр биләгән иркен төбәктә, Евразиянең зур бер мәйданында, сармат дигән этнос калкып чыга, скифләр исеме әкренләп тарихи язмалардан югала башлый. Дөрес, скифләрнең элекке якын күршеләре византиялеләр әле бу вакыйгалардан соң берничә гасыр үткәч тә шул ул Кара диңгез буйларында Бөек Болгар дәүләтен оештырган Кубрат ханны һәм аның варисларын ара-тирә «скиф патшасы» дип атаган булалар. (Кубрат ханның бай итеп җиһазланган кабер-курганы безнең гасырның утызынчы елларында Полтава өлкәсендә табыла һәм казыла. Ләкин ул ачышка багышланган җитди хезмәтләр әле юк.)

Ґалимнәр бу очракта да күчмәләр яшәешенә хас бер хәл — көчсезләнгән җитәкче кабиләне икенчесе алыштырган булса кирәк дип уйлыйдыр. Тарихта ул алыштырган кабиләнең ике исеме сакланган — савромат һәм сармат рәвешендәге исемнәре. Кайберәүләр алдан савроматлар, аннары сарматлар хөкемлек иткән дип уйлаеа, алар икесе ике төбәктә һәм бер үк чорда хөкемдар булганнар дип фараз кылучылар да бар. Бу ике исемнең бер үк этноска мөнәсәбәтле булуын дәлилләүчеләр дә җитәрлек. Хәтта скифләр белән сарматларның бер үк этнос булганлыгын раслаучыларның дәлиле дә ышандырырлык, минемчә.

Академик М. Зәкиев бишенче гасырда яшәгән автор Феофан Византиецның һуннарны да скифләр белән тиңләгәнлеген белдерә. Византиец: «Скиф Атилла... скифләргә өстенлек итә... Фракиягә һөҗүм башлады», дип яза икән.

Греклар язуында «скит», русча язмада «скиф» рәвешендә теркәлгән исемнең безнең эрага хәтле тугызынчы-җиденче гасырларда яшәгән төрки кавем «эске-ле»гә якын әйтелештә булуына нигезләнеп, академик М. Зәкиев югарыда исемнәре һәм эш-гамәлләре тасвир ителгән барлык этносларның да бер үк тамырдан булу ихтималын фараз кыла.

Тарихи чыганаклар һәм археологлар тасвир иткәнчә, киммериләр дә, скифләр дә, аларның варисы булып теркәлгән сарматлар да малчылык белән генә көн күрмичә, җир эшкәртүгә дә җитди әһәмият биргәннәр. Алар арасында, мөгаен, эш бүлешү тәртибе болайрак булгандыр: кемнәрдер җир эшкәртә, кемнәрдер мал бага, ә икенче бер кабиләләр бу кабиләрне чит-ят яудан саклый, яисә, кирәккәндә, яуга чыга. Геродот язмаларында да мондый бүленеш үрнәкләре китерелә.

Сарматлар дәверендә игенчелек һәм бакчачылык эшләре башлыча Төньяк Кавказ һәм Түбән Идел буйларында алга киткән була. Һөнәрчелек белән дә башлыча шушы төбәкләрдә шөгыльләнәләр. Кубан һәм Дон елгалары буенда, һәм Идел белән Дон аралыгында җитештерелгән икмәк һәм башка төр нигъмәтләр барлык бүтән өлкәләргә озатыла.

* * *

Безнең эраның дүртенче гасырында, Идел белән Дон аралыгында һәм Төньяк Кавказ җирләрендә бер гасыр чамасы төрки алан кабиләсе өстенлек иткәннән соң, Азия тарафыннан бу төбәкләргә хәрби яктан нык оешкан, элек яшәгән өлкәләрендәге көрәшләрдә зур яугирлек тәҗрибәсе туплаган яңа төрки күчмәләр — һуннар килеп төпләнәләр. (Һәрхәлдә, византиялеләр һуннар белән әнә шул тирәләрдә беренче мәртәбә очрашканнар дип санала.)


Ләкин һуннарның шул чорда гына Европаның көнчыгыш тарафларына «яу чабу» фаразы белән кайберәүләр килешми. Мирфатыйх Зәкиев тә «күчмәләрнең дала буйлап очтан очка чабып йөрү» теориясен галимнәр уйлап чыгарган дип белдерә. Төрле язмаларда теркәлеп калган, скифләр берләшмәсенә кергән һәм авторлар тарафыннан «унн»ар язылышында бирелгән кешеләр — шул ук һуннар булырга тиеш, ди ул. Беренче, икенче гасыр авторлары Дионисий, Птоломей хезмәтләрендә алар «унн» дип тә, «һун» дип тә теркәлгәннәр икән.

Болардан чыгып, бер үк исем белән аталган этносның бер үк вакытта көнчыгышта — Үзәк Азия төбәкләрендә — Кытайларга күрше булып, аларның елъязмаларында теркәлеп калган кебек үк, шул ук этносның бер өлешенең көнбатыш төрки берләшмәләре берәмлегенә дә керү факты белән килешергә тиеш булабыз. Һәм ул һуннарның дүртенче-бишенче гасырларда Кара диңгез буе күчмәләре берләшмәсендә алгы сафка чыкканлыкларын чамалыйбыз.

Һуннарның иң күренекле җитәкчесе Атилла заманында бу төркиләр берләшмәсенә Төньяк Кавказ һәм Кара диңгез буе биләмәләреннән тыш Урта Идел һәм Урал төбәкләренең дә кергәнлеге мәгълүм. Атилла, үз империясен тагын да киңәйтү һәм биләмә чикләренә якын ук килеп төпләнә башлаган Көнбатыш Европа халыкларын үз тарафларына таба кысрыклау ниятеннән чыгып булса кирәк, зур гаскәр туплап шул тарафка таба юнәлә. Ул Европаның үзәгенә үк үтеп керә, бернинчә өлкәне үз биләмәсенә кушуга да ирешә. Ләкин 451 елда, Рим империясенең көчле гаскәре белән чираттагы бәрелештә, җиңелүгә дучар ителә. Шуннан соң Атилла озак яшәми — 453 елда үлә һәм аның үлеме белән һуннарның өстенлеге дә әкренләп бетә башлый. Атилланың төп ватанында калган күчмәләр арасында таркаулык сизелә, анда хазар, болгар, акацир кебек кабилә берләшмәләре һәм аерым этнослар өстенлек алырга тырышалар.

Әйе, зур империяләр таркалгач, һәрвакыт бернинчә яңа ил-дәүләт баш калкытучан шул. Монда да башта аварлар каганаты баш калкыта, Төрки каганат

оештырыла. Бер гасыр да үтмәстән аның җирлегендә нытыган ике кабилә берләшмәсе әкренләп Хазар һәм Бөек Болгар ханлыкларына нигез салалар. Хазарларга элекке империянең Идел аръягынача булган көнчыгыш өлеше, Бөек Болгар ханлыгына исә Азак диңгезе буйлары һәм Дон елгасының түбән агымы өлешләре «бүленә» дип белдерәләр тарихчы галимнәр. Бөек Болгарның биләмәләре, мөгаен, Днепр буйларын да үз эченә алгандыр. Ләкин тарихчылар арасында бу хакта бердәм фикер юк. Соңгы дәвердә хәтта ки ул биләмәне мөмкин кадәр чикләргә омтылу күренеше үзен сиздерә. Кубрат ханның Днепрга якын бер төбәктә җирләнгәнен, борынгы төркиләр йоласы буенча аның төп утрак, кышлау урынында җир куенына тапшырылырга тиеш икәнлеген истә тотсак, бу төбәкнең дә Бөек Болгар биләмәсенә кергәнлеген фараз кыла алабыз.




Көнбатыш төркиләрнең 10 гасырда таралу мәйданы.

Тарих сәхифәләрендә Хазарларның тормыш-көнкүрешенә караган язма хатирәләр чагыштырмача күп, Бөек Болгарның исә Кубрат хан чорына караган ядкәрләре азрак яктыртылган. Ә бәлки аларның максатчан рәвештә өйрәнелмәве моңа сәбәптер. Хазар каганаты күтәрелеш кичергән чорга гарәпләрнең якынтирәдәге халыкларны халифәт кочагына алырга омтылган дәвере туры килә. Төньяк Кавказ чикләрендә хазарлар алар белән байтак еллар якага-яка килеп сугышалар. Һәм шул тиңсез көрәш Хазар иленең тәмам җелеген суыра, ханлыкның таркалуына китергән сәбәпләрнең берсе була. Шул ук вакытта бу вакыйгалар Хазар каганлыгының тарих сәхифәләрендә киңрәк урын алуына да сәбәпче булган, минемчә. Гарәп авторлары аны еш телгә алалар.

Хазар һәм болгарларның скифлар дәвереннән бирле җир эшкәртү белән шөгыльләнүче төбәкләрдә ил тотуы да эзсез калмаган. Аларны, бигрәк тә хазарларны, телгә алганда грек, әрмән, фарсы, гарәп елъязмачылары игенчелек белән бакчачылыкның алга киткәнлеген билгеләп үтәләр.

Тарихчылар фаразлавынча, Бөек Болгар ханлыгы күп очракта Хазар каганатына ярым буйсыну дәрәҗәсендә булган. Ягъни бу ханлыкларда яшәгән кардәш халыкларның кендеге бергә бәйләнгәнрәк булган. Хәер, Кубрат ханның зур мөстәкыйльлеккә ирешкән чаклары да тарихчыларга мәгълүм. Мәгәр, алда әйтелгәнчә, Бөек Болгар ханлыгының тарихы әлегәчә җитәрлек дәрәҗәдә барланмаган, өйрәнелмәгән булуы сәбәпле, бу ике зур ыру-кабилә берләшмәләренең үзара мөнәсәбәтләрен тогаенләү дә читенрәк. Бөек Болгар иленең тарихын ачыклау, ул төбәкләргә хәзер хуҗа булган рус һәм украин халкы вәкилләреннән дә бигрәк, безнең галимнәр бурычы дип уйларга нигез бар. Әлегә исә безгә шул бөек бабаларыбызның икенче тармагы булган Дунай буе болгарларына мәгълүм

фактлар да билгеле түгел бит. Чөнки ул ил галимнәре ачкан ачышлар белән тотрыклы рәвештә танышу мөмкинлегебез юк. Аларда дөнья күргән җитди хезмәтләр белән күпчелегебез таныша алмыйбыз, безнең илдә басылган очракта да алар вак иләкләр аша иләнеп, кат-кат редакцияләнгән рәвештә генә килеп ирешә.

Кубрат хан оештырган ил-дәүләт тә аның үлеменнән соң, җиденче гасырның икенче яртысында, таркала башлый. Бер яктан аңа көч-куәт туплап өлгергән кардәш хазарлар басым ясаса, көньяк тарафтан исә Византия дәүләте тынгылык бирми. Шунлыктан болгарлар бердәмлеген тәшкил иткән бер төркем Кубратның улы Аспарух җитәкчелегендә Дунай елгасына табарак күченә һәм Византия белән сугыша-сугыша шунда мөстәкыйль төрки дәүләткә нигез сала. Икенче төркем кардәш-ыру саналган Идел-Кама елгалары буе төркиләре арасына барып кушыла һәм озакламыйча Идел буе болгарлары ханлыгын оештырып җибәрә. Бу төркемгә Кубрат ханның икенче бер улы Кодрак җитәкчелек итә. (Ханның улы Батбайга буйсынган халкы төп урында кала.)

Галимнәрнең күпчелеге раслаганча, бу зур төркем күченеп килгәнче дә Идел-Кама буйларында төрки телдә сөйләшүче кабиләләр яшәгән инде. Алар угро-фин кабиләләре белән аралашып көн күргәннәр, аучылык һәм мал асраучылык белән тормыш иткәннәр. Болгарлар да килгәч исә монда иген игү җирләре киңрәк мәйдан ала барган. Көньяк өлкәләр белән сәүдә итү эше җәеллдереп җибәрелгән.

Мондагы болгар кавемнәре сәяси һәм икътисади яктан күпмедер дәрәҗәдә Хазар иле белән бәйләнешләрен дә өзмиләр. Идел-Кама буе халкы үз дәүләтчелеген булдыргач та Хазарга йөз тотудан, аңа буйсынудан арынмый. Бу хәлгә, әлбәттә, шушы ике «ил»дә яшәүче халыкларның башлыча бер үк нигездән булулары, бер-берсенә якын бер телдә сөйләшүләре дә ярдәм иткән. Унынчы гасыр авторы Истаһри, мәсәлән, «болгар һәм хазар телләре икесе бер», дигән. Болгар илендә берничә ай яшәп киткән Багдад кешесе Әхмәт бине Фазлан: «Болгар патшасы Хазар иле башлыгына салым түли: илендәге һәр йорт исәбеннән бер кеш тиресе», дип белдерә.

X—XIII гасырларда Идел буе болгарларының икътисади һәм мәдәни үсеше ныгый, күрше кардәш халыклардан тыш ераграк мәмләкәт кешеләре белән дә ныклы сәүдә элемтәләре урнаштырыла. Мөстәкыйль кенәзлекләр буларак оеша башлаган славяннар белән дә якын арадашлык мөнәсәбәтләре җайга салына.


1135—1136 елларда Болгар илендә яшәп алган испанияле гарәп Әбү Хәмид әл-Гарнати монда язма әдәбият һәм язма тарихи хезмәтләр булуын хәбәр итә, Якуб бине Ногман дигән зыялының «Болгар тарихы» китабы белән танышканлыгын яза. Бу ил халкының мәдәни үсешенә, билгеле, ул чор өчен бик тә прогрессив бер дин буларак кабул ителгән мөселман диненең үтеп керүе дә хәлиткеч булгандыр. Бу хәл мондагы этник берәмлекләрне уртак бер язма тәртип һәм уртак дин ярдәмендә бер-берсенә тагын да якынайтуга китергәндер, әлбәттә. Унынчы гасыр башында Идел-Кама буйларында булганда Әхмәт бине Фазлан ил башлыгына буйсынган этнос-кабиләләрнең берничәсен атап китә: суваз (сувар), эскел һ. б. Кайбер тарихчылар кыпчакларның да болгарлар белән бер язмышта булганлыкларын белдерәләр, аларның бер өлешенең Азак диңгезе тирәләреннән үк болгарлар белән бергә килеп төпләнүен фараз кылалар. Кыпчакларның икенче зур төркеме монда монголлар явыннан соң, XIII гасыр урталарында күченеп килгән булса кирәк. Ул вакытта инде Идел-Кама буендагы барлык төрки кабиләләр дә диярлек бер этнос рәвешен алган, уртак бер телдә сөйләшкән, язма телдә «болгари» исемендә таныла башлаган булалар. Һәм алар Идел-Кама төбәген үзләренең төп ватаннары буларак таныганнар.

* * *

Кыпчаклар тарихи чыганакларда безнең эрага кадәр өченче гасырда телгә алына башлыйлар. Аларның Көнбатыш Төрки каганат һәм Уйгыр каганатлары чорында көчле бер кабилә буларак яшәгәнлекләре мәгълүм. Академик Зәкиев аларның соңгы скиф һәм сармат кабиләләре берләшмәләре арасында да телгә алынуларын бәян итә. Башлыча аксыл кыяфәтле булган бу кешеләрне күршеләре «сары», «аксыл йөзле» мәгънәләренә туры килгән атамалар белән атап йөрткәннәр, соңрак дәвердә аралаша башлаган славяннар да аларны шул сыйфатларыннан чыгып «половец» дип, ягъни салам төсенәрәк тиңләп, башкалардан аерганнар.

Шулай итеп, кыпчакларның борынгы тарихи эзләрен монголлар яшәгән көнчыгыш өлкәләрдән башлап Кара диңгез буйларының дала чикләренә чаклы

зур аралыкта табып була икән. Унынчы гасырда хәзерге Иртеш елгасы белән Урал таулары арасында «Йәмәкләр каганаты» оеша һәм ул ил-дәүләтнең дә төп этносларыннан берсе кыпчаклар санала. Шул дәүләтнең көнчыгыш тарафларын биләгән кабилә исә татар атамасы белән мәгълүм булган. Тарихчылар шушы чорда бу халыклар биләгән җирләрдә аерым шәһәрләрнең дөньяга таныла башлавын һәм каганат кешеләреннән бер өлешенең утрак тормыш коруга җайлана барганлыкларын билгеләп үтәләр. Мәсәлән, шул чор авторы Гардизига таянып В. В. Бартольд бу ил халкының терлекчелек, сунарчылык, балыкчылык һәм җир эшкәртү белән шөгыльләнгәнлекләрен әйтә. «Государство кимаков» дигән китап авторы Б. Е. Кумеков (1972) башка бер чыганак нигезендә «татар, байандур...» кабиләләренең йәмәкләр биләменә Уйгырлар каганаты таралганнан соң күчешүләрен белдерә. Әмма ләкин бу чыганакларның берсендә дә бу ил-дәүләткә караган кайсы этнос-кабилә кешеләренең күбрәк җир эшкәртеп, иген игү белән көн күрүен ачыкламыйлар. Мөгаен, ул илгә тупланган һәр халыкның бер өлеше шулай көн күрүгә җайлашкан булгандыр.




Казан ханлыгы харитасе. Шартлы билгеләр: ▭ М. Кудяков фикере буенча ханлыкның чикләре; ... А. Ролих фикеренчә: ▨ Татарстан Республикасының хәзер биләгән мәйданы.

*Хариталәрне Булат Хәмидуллин төзеде.*

XI гасыр башларында, Йәмәк каганатының көнбатыш күршесе булган Хазар каганаты тарих арбасыннан төшеп калган бер вакытта, башлыча элек хазарлар биләгән биләмәләрдә яңа бер ярым күчмә дәүләт — Кыпчак ханлыклары берләшмәсе барлыкка килә. Бу очракта да әле тарих анык җавап бирми — бу яңа берләшмә элек Йәмәк каганатына караган кыпчаклар исәбенә, аларның көнбатыш тарафка яу чабулары нәтиҗәсендә туганмы? Яисә элек Хазар каганатына караган кыпчык кабиләләре, көч-куәт туплап, элекке иияләре арасыннан өстен чыгып, яңа берләшмәгә үз исемнәрен биргәннәрме? Рус тарихчылары нигездә

кыпчакларны Идел артыннан, хәзерге Казагыстан далаларыннан күчеп килгәннәр дип исәплиләр. Ләкин ул очракта андагы элекке кыпчаклар яшәгән урындагы халыкның хәзер дә үзен «кыпчак кабиләсе вәкиле» дип атавын ничек аңларга? Боларга әле анык җавап юк. Күчмәләр булгач, Кара диңгез һәм Азак диңгезе буйларында ике гасыр чамасы шанлы тормыш кичергән ул кыпчакларның бер өлешенең чынлап та Арал диңгезе, Сыр-Дәрья елгалары буйларына күзгалып, яңа җирләрне үз итүләре булгандыр. Шул рәвешле алар элек монда яшәгән кардәшләре белән уртак ватанда көчле бер берләшмәгә нигез салганнардыр.

Кайбер авторлар, әйтик С. А. Плетнева — хазар һәм кыпчакларга багышлап махсус хезмәтләр язган галим — кыпчаклар яңа урында зур үзгәреш кичерәләр дип белдерәләр. Әйе, Идел, Дон, Днепр кебек елгалар аралыгындагы элек-электән бай тормыш кичергән, үсештә булган болгар, хазар, уз, бәҗәнәк, аланнар белән якыннан аралашу уңай йогынтысыз калмагандыр, билгеле. (Болгарларның Батбай җитәкчелегендәге бер өлеше Төньяк Кавказ төбәгендә калуын яздык, аларның варисы бүген балкар, карачай халыклары исәпләнә.) Дөрес, әлегә бу халыклар арасында кайсысының күпчелекне тәшкил иткәнлеген ачыклау катлаулы. «Килмешәк» кыпчакларның чагыштырмача аз санлы булган очрагында гына мондагы этносларның уңай йогынтысы хакында сүз кузгатып булыр иде. Шунысы хак, галим Л. Гумилев тәкъдим иткән җыелма сүзне кулланeasak, бу дәвердә кыпчакларның пассионарияләре өстен була, исемнәре алда аталган тел кардәшләреннән өстен чыгалар һәм бу мөһим төбәктә оешкан дәүләтчелек алар атамасына бәйле рәвештә туа. Борынгы скифләр җирлегендә кыпчакларның яңа ватаны барлыкка килә.

Кыпчакларның бер өлеше Иделдән көнчыгыш тарафларда көн күрүне дәвам иттерәләр. Ә җиденче гасырда Идел-Кама буйларына күчеп утырганнары исә шул төбәктәге башка кардәш кавемнәр белән аралашып, төп этноска бәйле рәвештә болгар исемен алдылар бит инде.

* * *

Алдарак без кыпчакларга кардәш һәм илдәш булган татарлар хакында берничә сүз әйткән идек. Татар исеменең тарихта еш кабатлана башлаган чоры — V гасырларга карый. Шул дәвердән башлап аларның «тугыз татар», аннары «утыз татар» дип аталган ыру-кабилә берлекләре көньяк чиктәшләре булган кытай, көнчыгыш арадашчылары саналган монгол, маньчжур халыклары тарихына бәйле рәвештә еш телгә алыналар. Моңа кадәр күп гасырлык дәүләтчелек тарихы булган, мәдәни яктан алдынгы саналган кытайлылар төньяк чикбиләмәләрен еш борчый башлаган бу күчмә төркиләргә кимсетеп карап, имеш, тәртип-тәрбиясез бер халык, варварлар димәктән, татар исемен кушканнар дип фараз кылына фәндә.

VII гасырда бу татарларның зур өлеше Көнчыгыш Төрки каганатының төп этносларының берсе була. 745 елда исә уйгырлар җитәкчесе Моюн Чурой Көнчыгыш Төрки каганат язмышына чик куеп, Уйгыр каганатын оештыра. Татарлар яңа оешкан шул төркиләр бердәмлегенең бер вәкиле буларак яши башлыйлар. Аннары бу каганат та таркала, татарлар кардәш йәмәк-кимәкләр җитәкчелек иткән ханлыкка буйсындырылалар. Бу татарларның бер өлеше элегрәк Йәмәк каганатын оештыруда да төп кабиләләрнең берсе рәвешендә катнашкан була. Төркия тарихчысы Әхмәт Тәмир фараз кылганча, кыпчакларның зур бер өлеше көнбатыш тарафка, Идел-Дон төбәкләренә тартылганда, алар белән бергә әлеге татарларның да бер төркеме шунда күченеп китә. Ә элек-электән үк Көньяк Себернең көнчыгыш тарафларында күрше монголлар белән чиктәш булган татарларның төп өлешен исә XII гасыр соңнарында аянычлы язмыш көтә: Чыңгыз хан гаскәрләре ул җирләрне беренче булып басып алалар.

Тарихи вакыйгаларда элек бераз күләгәдәрәк кала килгән монголларның кинәт күтәрелеп китүен Л. Гумилев пассионар сикереш кичерү, акматик фазага керү кебек яңарак кулланышка кергән фәнни төшенчәләр ярдәмендә аңлата. Бу очракта, һичшиксез, әлегәчә аерым төбәкләргә бүленеп, таркаурак яшәгән монгол этносын бер максатка юнәлдерә алган, бергә туплаган шәхес Чыңгыз ханның үз вакытында тууы да кирәк булгандыр. Зур тарихи үзгәрешләр һәрвакыт олы максатларга хезмәт итәрдәй олуг шәхесләр исеменә бәйле рәвештә барлыкка килгәннәр бит. Төрки күчмәләр язмышында да ул һәрвакыт шулай булып килгән. Атилла, Кубрат хан һәм башка бик күп ил башлыклары язмышы шуны раслап тора. Чыңгыз хан исә шул исемнәрнең дә алгы сафында аталырга хаклыдыр, мөгаен.

Әйе, монголлар акматик фазада — көчле, гайрәтле. Беренче булып алар татарның ыру-кабилә башлыкларын юк итәләр һәм ат уйнатып сугыша белгән элекке күршеләрен үз гаскәрләренең алгы сафына тезеп, көнбатыш тарафка карап яу чабуларын дәвам иттерәләр. Шуның нигезендә XVIII гасыр башы Европа тарихчылары фән теленә «татар-монгол явы» төшенчәсен кертеп җибәрәләр. Шушы ике этнос атамасын синоним рәвешендә куллана башлыйлар. Чыңгыз хан житәкчелегендәге гаскәрләр 1207 елда Көнчыгыш Себер өлкәләрен, 1209 елда элекке Уйгырстанны буйсындыралар. Шуннан соң яу Үзәк Төркестан төбәкләренә күчә, 1219 елда «җиңелмәс» саналган Харәзм дәүләте гаскәрләре җиңелү ачысын татыйлар. 1220 елда монгол атлылары, Урта Азия ханлык-солтанлыкларын буйсындырып, Һиндстан чикләренә бәреп керәләр. Чыңгыз ханның көнбатыш тарафка юнәлдерелгән, яугирлек даны алган гаскәр башлыклары Җәбәдәй нойон белән Сүбәдәй баһадир житәкләгән сугышчылары исә Азак диңгезе буе далаларына ук барып чыгалар. 1223 елның җәендә, Калка елгасы буендагы сугышта, алар кыпчакларның җыелма көчен җиңүгә ирешәләр һәм көнчыгыш авторлары зурлап Дәшти кыпчак дип атап йөрткән чиксез Кыпчак иленә баш булалар. Бу зур бәрелештә татар сугышчысы җиңә, кыпчак чигенә, буйсына. Аннары инде күмәк көч белән Идел Болгарстанына һөҗүм итәләр. 1236 елда, яңа көч туплап, икенче мәртәбә һөҗүм ителгәннең соңында, Болгар иленең зур шәһәрләре дә буйсынуга мәҗбүр ителәләр.

Борынгы тарихи җирлектә яңа бер этнос хакимлек итә башлый. Чагыштырмача аз санлы монголлар кул астында татар, кыпчак, болгарлардан башка элекке Харәзм иленә караган күп санлы төрки халыклар да, Себер төбәгендә көн күргән башка төркиләр дә күп була.

Шунысы да игътибарга лаек: хәзерге заман монгол галимнәре — ерак чорлардан калган, иске монгол телендә язылган манускриптларны укыган кешеләр — Чыңгыз ханның яугирлыгын болайрак аңлатмакчылар. Янәсе ул, борынгы бабалары кебек, Евразия киңлекләрендә яшәгән барлык күчмәләрне бер кул астына тупларга ниятләгән булган һәм максатына ирешкән — бер-берсенә кардәш-ыру булган бу халыкларны берләштергән икән. (Тарихчы Ю. Трифоновның Монголия галимнәре белән әңгәмәсе.) Истәлек язмаларында шул ук фикерне мәгълүм европалы сәяхәтче, үз заманында Чыңгыз ханның варисы Мэнгу каган һәм Бату хан белән аралашкан Вильгельм Рубрук та куәтли: «алар Дунайдан алып кояш чыгышына чаклы сузылган Скифия җирләрен бүлешеп алганнар», дип яза.

* * *

Чыңгыз хан барлык күчмәләрне үз кулына алуга һәм буйсындыруга ирешсә дә, алар белән бер үзәктән идарә итүгә ирешә алмый. 1227 елның февралендә «бөек каган»ның үлеменнән соң, ул оештырган галәмәт зур империя нигезендә берничә ил-дәүләт хасил була. Шуларның иң көнбатышта урнашканында — тарихта Алтын Урда дәүләте исеме алганында — башлыча кыпчак төркичәсендә сөйләшүчеләр теркәлгән була: кыпчак, татар, болгар, алан. Шунлыктан дәүләтнең рәсми теле дә тиздән тәмам төркиләшә. Бату хан хакимлек иткән чорда, ягъни 1266 елларгача бу ил халкы арасында бердәм дин булмый әле: монголлар һәм аларга электән якын кабиләләрнең бер өлеше мәҗүси, икенчеләре нәсәрә динендә була. Кыпчакларның шулай ук бер өлеше мәҗүси, ә Киев Русе һәм Төньяк Кавказ төбәкләрендә яшәүче кайберләре көнчыгыш нәсәрә яки «әрмән дине»н үз итәләр. Хазар ханлыгына элек кергән халыкларның да бер өлеше яһүдилектә булса, икенчеләре мөселманлыкны өстен күргәннәр. Элекке Болгар илендә дә мөселманнар белән бергә мәҗүси диндәгеләр дә ишле була әле. Риваятьләр Бату ханның мөселман белән христиан нәсәрә диннәрен тиң күрүен, хөрмәт иткәнлеген сөйлиләр. Мәгәр аның онықлары, элекке мәдәни Харәзм һәм Үзәк Төркестаннан чыккан зыялылар йогынтысын тоючылар, чагыштырмача мәдәни булган мөселман иле Болгар үрнәген күреп торучылар, тиздән бөтен Алтын Урда өчен уртак саналган мөселман динен кабул иткәннәр. Бер дин, бер дәүләт, бер тел. Тора-бара бу ил-дәүләт «татар иле» буларак, анда яшәүче күптөрле халыкларның теле, нигездә, «татар теле» буларак дөньяга таныла. Алтын Урда империясенең төньяк тарафларында көн күргән угро-фин кабиләләре һәм Төньяк Кавказ төбәгендә яшәгән, «кырык тел»дә сөйләшкән халыклар өчен дә татар теле уртак аралашу теле буларак кабул ителгән. (Бу традиция XX гасыр урталарынача дәвам иткән дияргә була: утызынчы-кырыгынчы елларда әле төрки-татар теленең кавказлы грузин, авар, осетин, әрмәннәр өчен дә, Идел,

Урал төбәгендәге мукшы, мари, удмуртлар өчен дә уртак аралашу вазифасын үтәгәнлеге мәгълүм.)

Ә ул «татар теле»нең нигезен исә Алтын Урда ил-дәүләтендә күпчелек саналган кыпчаклар һәм аларга якын яисә бер үк сөйләм үзенчәлегенә ия булган татар, болгар, хазарлар теле хасил иткән. Һәм шушы укмаш бер тел Алтын Урда империясе җимерекләре урынында барлыкка килгән Казан, Әстерхан, Касыйм, Кырым һ. б. ханлыкларның да дәүләт теле булып киткән. Бу мөстәкыйль ил-дәүләтләрнең барысы да диярлек «татар ханлыклары», «татар дәүләтләре» буларак дөньяга танылалар.

Бу очракта да без скифләр заманыннан ук килгән бер үзенчәлекне күзәтәбез: кардәш этнослар бер җирлектә, бер ил-берәмлеккә тупланып яшәгәннән соң берәр ничек өстенлек алган бер генә этнос исеме белән атала башлыйлар. Безнең очракта инде бу татар этносы — соңгы империяләргә җитәкче булган монголлларга беренче нәүбәттә буйсынган һәм тора-бара шул империянең түрәләре катламын тудырган көчле рухлы бер этнос. Тарих фәнендә берничә этнос кушылудан соң яңа этнос, яңа бер халык барлыкка килүе генезис дип атала. Димәк ки, Чыңгыз хан яуларыннан соң оешкан Алтын Урда империясе татар генезисы барлыкка килүгә сәбәпче булган. Ә ул империягә нигез салган монголлар исә үзләреннән күпчелекне тәшкил итүче төрки этнослар арасында йотылып, юкка чыкканнар.

Алтын Урда империясенең чәчәк ату чорларыннан башлап ике-өч гасыр дәвамында татар исеме мактаулы, абруйлы исем була, аның йогынтысы бу империягә буйсындырылмаган ил-дәүләтләрдә дә сизелә. Ә инде күпмедер күләмдә салым түләп торган, Олуг кенәзләре хан ярлыкларыннан башка кенәзлек вазифасын да үти алмаган руслар илендә ул исемнең дәрәҗәсе турында әйтеп тә торасы юк! Шул дан-дәрәҗәнең чагылышы буларак Рәсәйдә XIX гасыргача «татардан чыккан кенәз», «татардан чыккан зыялы» рәвешендә уңай караш сакланган. Рус дворяннарының бер өлеше ерак бабаларының татардан булуы белән мактанышканнар. Мисалга, русның мәшһүр зыялысы саналган А. Н. Радищев шундыйлардан булган. Егерменче йөзгә йөз тотканда гына «татар» атамасының абруе юкка чыккан.

Алтын Урда ханлыгы чорында ана телләре төркичә булмаган кайбер кавемнәрнең якыннан аралашуы нәтиҗәсендә, үзләре өчен чит-ят саналган төрки-татар телен үзләштерү күренешләре дә сизелерлек көчәя. Ярым буйсыну хәлендәге славяннар арасында да бу күренеш күзәтелә. Ирекле рәвештә тел алмашу бигрәк тә Идел белән Урал төбәкләрендә көн күрүче, сөйләм үзенчәлекләрендә төркиләр белән уртаклык булган угро-фин кавемнәренә хасрак санала.

* * *

Казан ханлыгы чорында (XV гасырдан башлап бер гасыр чамасы дәвам итә) бер-берсенә ят телдә сөйләшүче этносларның үзара тагын да якынаюы күзәтелә. Әгәр соңыннан үзләрен чуваш дип таныган этнос вәкилләре төрки телдә сөйләшүче кабиләләр белән VII гасырда оеша башлаган Идел буе Болгарына чаклы ук аралашса һәм шул дәвердән үк төрки тел үзенчәлекләрен үзләштерә башласалар, фин-угор тел төркеменә караган башка этнослар мондый аралашуга соңрак керешәләр. Болгар иленең төп халкын тәшкил итүче төркиләрнең байтак өлеше монголлар 1229 елда беренче һөҗүм иткәннән һәм 1236 елда Болгарны тәмам яулап алганнан соң авыллары-авыллары белән Кама елгасының аръягына — Казан, Мишә елгалары буена, Зөя елгасының түбән агымындагы урманлы җирләргә качып китә башлыйлар. Чыңгыз хан яулары Идел буена якынлашкан бер вакытта Болгар иленә Кама елгасының урта һәм югары агымы төбәкләрендә көн күргән эсегелләрнең бер өлеше дә килеп кушылган була. Ят яу чирүләре борчый башлагач аларның да бер өлеше Каманы кичеп, Нократ һәм Чипсә елгалары тирәсенә барып утыра. Шулай итеп, элекке Болгар иле чикләре буйлап яшәгән мари, удмуртлар һәм Болгар иле оешканчыга хәтле үк килеп төпләнгән төрки кавемнәр яңа дулкын төркиләре белән тыгыз элемтәгә керергә мәҗбүр булалар. Шул рәвешле, Казан ханлыгы чорында ук инде Нократ, Чипсә буе төркиләреннән «нократ татарлары», Каманың урта өлешенең төньягындарак урнашканнарыннан «гайнә татарлары» оеша.

Болгар иленең көнбатыш чикләре монголлар явына хәтле Сура елгасы буйларынача сузылган була. Казан ханлыгы оешкан дәвердә исә анда инде төрки утраклар саны кимегәнлеген күрәбез. Алар монда аерым-аерым төркемнәр генә хасил итәләр. Бу төркиләрнең үзәк каласы булган урынга соңыннан русларның Юлов шәһәрчеге төзелә. Галимнәр элек бу тирәләрдә яшәгән төрки болгарлар-

ның ул вакытта яу чирүе җитмәслек саналган тыныч җирләргә — Мукша, Вада, Выш елгалары буендагы урманнарга сыенуларын фаразлыйлар. Шунда ук үзенә бер үзәк — Наровчат шәһәре дә күтәрелә (башлангыч чордагы исеме — Мукша).

Элекке Болгар иленең бушап калган җирләренә үз ояларында таркатылган кыпчаклар һәм элек алар берләшмәсенә тупланган башка кабиләләр, шул исәптән яңа биләмәләрне үзләштерә башлаган монгол, татар кавемнәре дә килеп утыра башлыйлар. Дөрес, булачак Казан ханлыгы биләмәсенә килеп төпләнүче саф монголлар бик тә аз санда гына була, алары да башлыча идарәче төркемгә карыйлар. Ә менә көнчыгыштан, Себер якларыннан алар ташкыны белән кузгатылган күчмә төркиләрнең монда уртакланып калуы ишлерәк булган. Шундый килүчеләр арасында мәрхүм археолог А. Х. Халиков Урта Азия һәм Кавказ кешеләренең дә булуын фараз кыла. Алар, башлыча, морзалар, бәкләр яисә дин әһелләре сословиесен тәшкил иткәннәрдер, мөгаен.

Билгеле инде, Казан ханлыгы чорында болгарлар белән фин кабиләләренең яңа арадашлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа төрки этнослар да туганнар. Бик аз күләмдә булса да, андый төркемнәр арасында славян-руслар этносыннан төркиләшүчеләр дә булган. Мондый генезис Алтын Урда ханлыгы чорында башланып, Казан ханлыгы чорында кимрәк күләмдә булса да дәвам иткән. Славяннарның ирекле рәвештә башка этносның, бу очракта әле дан-шөһрәтле империянең төп этносының, гореф-гадәтләрен кабул итү очраклары да, төрле сугыш-бәрелешләр вакытында әсир төшеп, мондый юлга мәҗбүри этәрелүчеләре дә булгандыр.

Менә шул рәвешле Идел-Кама төбәгенең элекке төп этносы булган болгарлар, монда күчеп килгән яисә яу-сугыш вакытында торып калган яңа төркиләр һәм яңарак кына төркиләшкән халыклар белән «куертылалар» да, булачак Казан ханлыгының төп халкы барлыкка килә. Баштарак чорда әле алар еш кына элеккечә болгар дип тә, яшәү төбәкләренә бәйле рәвештә дә аталып йөртеләләр. Үзләрен дингә бәйле рәвештә мөслимин-мөселман дип тә таныталар. Ләкин инде бу вакытта күрше халыклар да, үзләренең дә күпчелеге «татар, татарлар» дип атау һәм аталуны өстенрәк күрә башлыйлар.

Мондый үзгәрешне болгарларга килеп кушылган чагыштырмача аз санлы урдачыларның ул вакытта югары пассионарлыкка ия булулары белән аңлатырга мөмкин. Өстәвенә ул яңа кушылган төркемнең эчке күтәренкелек халәтен тирәюньгә таралган абруйлылык хисе дә тулыландырып торган. Аннары ул югары пассинарлыкка ия этносның уңай йогынтысы нәтиҗәсендә җирле этносларның да пассионар мөмкинлекләре арта һәм шул сәбәпле монда тотрыклы сәясәтле бер дәүләтчелеккә — Казан ханлыгына нигез салына. Үз көч-куәтен арттыра барган бу ханлык Алтын Урда чорында да данын һәм күпмедер дәрәҗәдә мөстәкыйльлеген саклап кала алган Идел буе Болгарстанының үсеш юлын дәвам иттерүче варис сыйфатында кабул ителә.

Казан ханнары үз биләмәләрен элекке Болгарстан чикләренә тиңләп билгеләргә һәм аны хәтта киңәйтергә тырышалар. Бу җәһәттән алар рус кенәзләренең элеккечә үк төрле яклап басымчылык итәргә теләүләренә кискен каршы торалар, алар белән даими рәвештә аяусыз көрәш алып баралар. Һәм шул сәбәпле баштагы дәвердә зур сәяси абруйга ирешәләр. Ләкин дошман да көннәнкөн көч-куәт ала бара, элек аерым булган кардәш халыкларны бергә туплауга ирешә. Казан ханлыгы оешуның йөз еллыгы якынлашып килгән вакытта бу төбәктә сәяси һәм икътисади хәлләр нык үзгәрә. Шуның чагылышы буларак җирле халыкның пассионерие кимүгә йөз тота башлый. Менә шушы хәлләр инде тиздән ханлыкның тәмам җимерелүенә китерә.

Шул чорга караган тарихи чыганакларга нигезләнеп, академик В. Ключевский һәм замандаш галимебез Р. Кузеев: «Казан ханлыгы һәлакәтенә дистә ел чамасы калганда, 1540 елларда, Идел белән Урал аралыгындагы табигатьтә котычкыч үзгәрешләр башлана — бу төбәктә элек күрелмәгәнчә корылык хөкемлек итә, ачлык, төрле авырулар баш күтәрә», дип белдерәләр. Чума авыруыннан мал-туар һәм кешеләр күпләп кырыла. Ә аннары инде Иван патша явы башлана һәм 1552 елда Казан ханлыгы җимерелә.

Тик әлегә Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында татар исемен алган, борынгы күчмә төркиләрнең төп варисларының берсе саналган халык, еллар узган саен азая-азая барып булса да, яшәвен дәвам иттерә. Ул халыкның пассионарие кайчан да бер тагын күтәрелерме? Ул халык эчке бер күтәрелеш, үсеш юлына басармы соң? Монысы инде тирә-як мохиткә генә бәйле түгел, шул халыкның үз теләгенә, үз омтылышларына да бик-бик бәйле.

# МИШӘР ТАТАРЛАРЫНЫҢ ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Идел буе төркиләре арасында, казан татарларыннан кала, сан ягыннан икенче зур этник төркем булып мишәр татарлары тора. Алар күбесенчә Иделнең уң як яр буйларына — Татарстан, Чувашстан, Мордва республикаларына, аннары Түбән Новгород, Пенза, Сембер, Самара, Рязань өлкәләренә чәчелеп утырганнар. Мишәр татарларының бер өлеше Башкортстан, Оренбург якларына да барып төпләнгән. Рәсәйнең байтак кына шәһәрләрендә дә эшле яшиләр.

Мишәр татарларының теле татар теленең көнбатыш диалектына карый. Шулай ук тормыш-көнкүрештәге, гореф-гадәтләрдәге үзенчәлекләре белән дә алар казан татарларыннан шактый аерылып торалар. Аларны казан татарлары белән берләштергән-туганлаштырган уртак төрки башлангыч булуга да карамастан, генетик тамырлар һәм тарихи тормыш шартларының аерымлыгы матди һәм рухи яктан үз йогынтысын ясамый калмаган. Шулай итеп, мишәрләрнең үзләренә генә хас җирле культурасы формалашкан. Ул бигрәк тә җыр-музыка өлкәсендә ачык чагыла. Моның, әлбәттә, социаль сәбәпләре дә бар: казан татарларының борын-борыннан авыл халкы да, шәһәр халкы да булган, ә мишәр татарлары, нигездә, күбрәк авыл җирләрендә яшәгәннәр. Шунлыктан, аларның тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә ислам дине азрак үтеп кергән, азрак тәэсир иткән булса кирәк. Бу күренеш, үз чиратында, мишәр культурасында мәҗүсилек йолаларын саклап калу белән бергә, аларны Идел буенда аралашып яшәүче күрше чуваш, мордва, урыс халыклары белән дә якынайткан. Болар барысы да мишәр татарларының үзенчәлекле рухи дөньясын тудырган.

Без бүген шул рухи байлыкның бер өлешенә — мишәр татарларының халык җырларына тукталырбыз. Бигрәк тә Мордва, Пенза, Түбән Новгород (нижгар мишәрләре) төбәкләрендә яшәүче мишәрләрнең халык җырлары күп кенә музыка белгечләре тарафыннан тәфсилләп өйрәнелгән, язып алынган, аерым китаплар итеп бастырып чыгарылган. Шундыйлардан түбәндәге басмаларны әйтеп үтәргә кирәк: М. Нигъмәтҗановның «Татарские народные песни» (Мәскәү, 1970), «Татар халык җырлары» (Казан, 1976), «Народные песни волжских татар» (Мәскәү, 1982), «Татарские народные песни» (Казан, 1984), З. Сәйдәшева белән Х. Ярминең «Татарско-мишарские песни» (Мәскәү, 1979), Р. Исхакова-Вамбаның «Татарские народные песни» (Мәскәү, 1981) китаплары.

Бу мәкаләдә файдаланылган, телгә алынган җырларның күбесенең ноталы үрнәкләрен шул басмалардан эзләп табарга мөмкин.

Халык авыз иҗатының иң борынгы башлангычлары, шул исәптән, җырлар да, мәҗүсилеккә нигезләнгән йолаларга барып тоташа. Әйтик, игенчелекнең ел фасылларына бәйле йолалары, тормыш-көнкүреш, гаилә җырлары әнә шундыйлардан санала ала. Егерменче гасырда ул йолалар инде зур үзгәрешләр кичергәннәр һәм күбесе хәзерге көннәргә кадәр килеп тә җитә алмаган. Шулай да кайберләре әле халык арасында һаман да яшәп килә.

Идел буе халыкларының байтагында ел фасылларына бәйле н а р д у г а н бәйрәме бар. Ул, гадәттә, җәйге һәм кышкы чилләнең беренче атнасында (елына ике тапкыр) үткәрелә: һәртөрле сынамышлар, тынга йөрүләр, кияү юраулар һәм башка шундый ырым-йолалар белән үзенчәлекле. Нар — төрки сүз, ул ут, ялкын, кояш дигәнне аңлата. Дуган — туган. Ягъни, ут-кояш туган вакыт. Кышын бу бәйрәм кояшның офыктан иң түбән торган чакларына (иң кыска көн — 22 декабрьдә), ә җәен исә иң югары чагына туры китереп (иң озын көн — 22 июньдә)

үткәрелә. Мишәрләрдә һәм керәшеннәрдә ул кышын урысларның да изге бәйрәме — святки көннәренә (25 декабрьдән 5 гыйнварга кадәр) туры килә. Шунысы кызык: мари, удмуртларда ул шулай ук «нардуган», мордваларда «нардуван», чувашларда «нартван, нарту» дип аталып йөртелә.

Нардуган бәйрәме йолаларын урыс миссионерлары үз вакытында керәшеннәрдән шактый тулы итеп язып алганнар, нәшер иткәннәр; мишәрләрдә исә кайбер аерым җырлар гына сакланып калган. Мисалга мишәр кызларының Яңа ел кичендә кияү юрау җырын китерергә була:

Нардуганым нар булсын,
Эче тулы нур булсын;
«Нардуган» кевен кем куләсә,
Шул дәүләтле, бай булсын.

Бу җырда кешеләрнең үзаңындагы мәҗүсилек чаткылары ачык чагыла: табигать көчләрен сүз белән ырымлап, ялварып буйсындырып була, дип уйлаганнар алар. Җырның көе исә ялварулы әфсеннәргә хас кабатлаулар белән баетылган, ритмик яктан ул казан татарларының мөнәҗәтләренә, аерым алганда, «Мөхәммәдия»гә шактый тартым. Соңгырак текстларда инде, мәҗүсилек чалымнары сакланып калса да, күбрәк кешенең рухи кичерешләре өстенлек ала:

Нардуганым нарына, ди,
Бакма кеше ярына:
Кеше яры яр булмас, ди,
Үз яр гынаң ят булмас.

Кара тавык кытныйдыр, ди,
Мая салма келидер.

Күрше кызын мактыйлар, ди,
Агай алма келидер.

Ай, ындырчы, ындырчы, ди.
Сугып ботын сындырчы.
Үдән үгә йөрегәнче, ди,
Мыекларың кырдырчы.

Кызларның юрау җырларыннан тагын берсе — нижгар мишәрләреннән язып алынган «Төймә такмаклары»:

Тәрәз төпләрендә бер кеше бар,
Кулларында тутый кошы бар;
Тутый кошын бирми, сүзен әтми,
Әллә инде хаҗәт йомшы бар?

Чыршы да гына нарат, әй, бүрәнә,
Чаналарга салсаң, сүрәлә.
Акылы да камил, үзе сабыр,
Кусалар, торадыр тирәдә.

Такмак дип аталса да, бу җыр казан татарларына хас такмаклардан эчтәлеге белән дә, көе белән дә шактый аерылып тора һәм мишәр җырлары үзенчәлеген саклап кала. Шуны гына әйтү дә җитә: казан татарлары такмаклары, нигездә, 7—8 иҗекле булсалар, болар 9—10 иҗекле шигъри юллардан торалар.

Ел фасылларына багышланган йолалар арасында, язгы ташулар җиткәч, кышны озату йоласы да булган. Нижгар мишәрләре яр буйларында учак яккannар, әйлән-бәйлән уеннар уйнаганнар, «Җимчәчәк» җыры җырлаганнар. Җимчәчәк үзе, умырзая чәчәгенең бер төре булып, җиләк-җимешләрнең, игеннәрнең муллыгын теләүне аңлаткан. Бу да шулай ук мәҗүсилек күренеше. Әйлән-бәйлән җырының борынгы тексты исә кыз яучылау мотивлары белән бәйләнгән. Бу җырларны кызлар-егетләр кара-каршы басып җырлаганнар. Шундый бер җыр — «Караңгы базар» җыры Х. Гатина тарафыннан Мордва республикасының Пурдашан районында язып алынган. Р. Мөхәммәдева исә сергач мишәрләрендә пасхадан соң җиденче атнада кызларның өйдә җырлы мәҗлесләр, кыр-басуларда биюле уеннар үткәргәннәрен хәбәр итә. Ә төн белән көннең тигезләнгән вакытында — 21 мартта балалар төркем-төркем булып өйдән-өйгә йөргәннәр, «келәү келәгәннәр». Бу йола «чип-чип» дип аталган. «Келәү»ләрендә такмаклап хуҗаларга байлык-муллык сораганнар:

Чип-чип, чибәрүк,
Йомыркасы югарук.
Ак тавык, күк тавык,
Ходай бирсен күп тавык.

*(МУХАМЕДОВА Р. Татары-мишари. М., 1972)*

«Келәүче»ләрнең, йорт хуҗасы никадәр юмарт булса, аңа байлык-муллык та шул кадәр күбрәк килә дип, йола ырымнарына ышанулары бик көчле була. Шунлыктан, саранрак хуҗаларны куркыту-өркетү дә «келәү җырлары»нда чагылыш тапкан:

Кодый-кодый, ак тавык,
Мая сала карт тавык.
Әби-бабай үдәме?
Бер йомырка бирәме?
Бер йомырка бирмәсә,
Тимерчегә барырмын,
Тимер тукмак алырмын,
Сугып башын ярырмын.

Сембер мишәрләре исә пасхада йорттан-йортка йөреп җыйган йомыркалар белән кызыклы уеннар уйнаганнар: алдан казып куелган чокырга йомырканы йомшак чүпрәк туп белән бәреп кертергә кирәк булган. Бу уен «кызыл йомырка көне» дип аталып йөртелгән. Вакытлар узу белән андый уеннарның ырымлы йолалары онытыла барган, алар яшьләрнең күңел ачу уеннарына әйләнеп калганнар. Хәзерге чорда мишәрләрнең уен җырлары казан татарларының җырлары йогынтысында зур үзгәрешләр кичерә, шулай да әле үзенчәлекләрен бөтенләй үк югалтып бетерми. Мәсәлән, Мордва республикасының Ләмбер районында яшьләрдән язып алынган җырлар шундый:

Колхозниклар эшкә йөри,
Һич пырагул ясамый;
Безнең закун шундый закун:
Эшләмәгән ашамый.
Әй, таулары, таулары,
Тау асты елгалары;
Анда «Шамилә»гә бии
Матур Пенза кызлары.

Мондый җырларның («Әй, таулары, таулары», «Дубая», «Бәйләнә баулары» һ. б.) көенә казан татарларының уен җырларына хас такмаклык килеп керсә дә, башлам җыр белән кушымтасы арасында тизлек аермасы юк диярлек.

Йола җырларының иң күбесе, мөгаен, туй йолаларына караган җырлардыр. Казан татарларындагы шикелле үк, мишәр татарларында да башлы-күзле булуның өч төре яшәп килгән: кызны яучылап алу, кыз урлау, кияүгә нияреп чыгу. Билгеле инде, кыз ярәшү, кыз яучылау йолалары иң дәрәҗәлеләрдән саналган. Әмма, казан татарларыннан аермалы буларак, мишәрләрдә кыз урлау, иярттеп алу күренешләре ешрак очрап, озаграк сакланып калган. Бу җәһәттән караганда, аларның керәшен йолаларына охшашлыклары да күренә. Бигрәк тә кыз елату җырларында ачык чагыла мондый охшашлыклар.

Кайбер очракларда, байлыкка кызыгып, җиткән кызны үсмер малайга да кияүгә биргәннәр.

Кодача яккан мунчаның гына
Уты әйләнә күмергә генә.
Мине бирдегез, биш йөз алдыгыз,
Кунакка түгел, гомергә генә.
Кызлар бәйлиләр айлы шәл генә,
Яшьтин малайга буй кыз җәл генә.

Йорт уртасында, келәт алдында
Кайнигәчләрем җепләр ашлыйдыр.
Газиз киявем унөч яшендә,
Кочакласам да елый башлыйдыр.
Кызлар бәйлиләр айлы шәл генә,
Яшьтин малайга буй кыз җәл генә.

Мишәрләрдә, гадәттә, өйләндерәсе улларына кәләш сайлау ата-ананың изге бурычы санала. Алар кызның әти-әнисе йортына үзләренең телгә оста берәр туганын яки авылда танылган башка берәр кешене баш кода итеп җибәрәләр. Баш кода кызның әти-әниләренә читләтеп кенә үзенең гозерен әйтә:

Сезнең алтыныгыз бар,
Безнең көмешебез бар —
Бергә кушыйк шуларны,— ди.

Ризалашу-килешү булса, килешү билгесе итеп, баш кодага сөлге бирелә һәм кыз килешенгән-«билгеләнгән» санала. Аннары кияү ягыннан кәләш өчен түләнәсе калым күләме хәл ителә, ризалашкан очракта, калымның бер өлеше шунда ук түләнә. Инде соралган калым бик зур булып, егет ягы аны күтәрә алмаса, күзе төшеп йөргән кызны ычкындырмас өчен, егет читкә — акча эшләргә чыгып китә. Бу күренеш «Малы юк егет җыры»нда бик ачык чагыла:

Карадин урманнын урталарында
Кырау сукмасмы яшел миләшне?
Үзебез яшьләр, йөрибез сәфәр,
Ятлар сөймәсме безнең кәләшне?

Безнең артларда түгәрәк күлләр лә,
Мукшы асларыннан сары су ага.
Безнең сөйгәннәр тәрәзәдән бага,
Малым юк — инде ятларга кала.

Калымның калган өлеше ярәшү туенда (ул калым түләнеп бетү хөрмәтенә үткәрелә) азык-төлек һәм кием-салым белән түләнә. Бу көнне кәләш үзенең дус кызлары белән чыбылдык астында гына утыра, аны кияүнең туганнарына гына күрсәтеп алалар (кыз күрендерү). Аннары кәләш кияүнең туганнарына бүләкләр (кыз бирнәсе) өләшә, тегеләре бүләк алганда подноска акча салалар. Шул ук көнне кич белән кияүнең кыз туганнары кәләшкә кияү бүләге китерәләр, шуннан соң кияү белән кәләш ялгыз калалар. Ярәшү туе белән никах туе арасында кыз ягында «кыз мунчасы», «кыз кичәсе» кебек йолалар, егет ягында һәр ике якның туган тумачаларын сыйлау мәҗлесләре үткәрелә. «Кыз кичәсе» кәләшкә чыбылдык тегүдән башлана, чәчен ике толымга үреп, кияү йортына озатырга әзерлиләр.

Ай, таш тирмән, таш тирмән,
Талдыра беләгемне.
Кырыс кайниш, авыр тормыш, тудыкайлар,
Яндыра йөрәгемне.

Энә генәм, җеп кенәм,
Калды сандык төбендә.
Уйнаганым-көлгәнем, тудыкайлар,
Калды әтием үендә.

«Тудыкайлар» дигән бу җыр Мордва республикасының Ләмбер районында язып алынган. Аны кәләш, кызлар чәчен үргән чагында, моңаеп җырлый. Кәләш, шул рәвешле, ирекле тормышы, ата-ана йорты белән саубуллаша, кайната-кайнана йортында үзен көткән авыр тормыш өчен кайгыра.

Кияү йортына китәр көн килеп җитә. Таң белән кыз табигать күренешләренә, әти-әниләренә, туганнарына, дус кызларына мөрәҗәгать итеп, елап җырлый башлый:

Әй, таң микән, таң микән,
Таң зарялары бар микән?
Таң заряларда мин еглыйм,
Миннән языклылар бар микән?

Пичкә утыннар яктыгыз,
Якты янмасын — әттегез.
Мине шул утларга салдыгыз,
Бәхетем булмасын — әттегез.

Монысы — «Таң кучат» җыры. Мондый кыз елату җырлары бик күп төрле һәм алар күп төбәкләрдә таралган.

Шундыйлардан менә тагын берсе. Нижгар мишәрләреннән язып алынган бу елау, җырдан битәр, речитатив тостә, тиз-тиз сөйләнү-такмаклауга кайтып кала.

Болдырлары биек, меналмам,
Косяклары кыек, кералмам.
Телләре ачы, үзләре начар,
Ай-һай, мин бу үдә торалмам.

Әтекәем, ызбаң саламдыр,
Салам гына түгел, сарайдыр.
Кайниш ызбасы кабыктыр,
Кабык кына түгел, тамуктыр...

«Кыз кичәсе» үткәргәннең икенче көнендә мулла чакырып, һәр ике якның да туган-тумачалары катнашында никах туе үткәрелә. Кияү ягыннан туйга сөлгеләр, аллы-гөлле тасмалар белән бизәлгән кыңгыраулы атларда гөрләтеп килеп керәләр. Туй мәҗлесендә, бер-берләрен макташып җырлашу белән бергә, үпкәле җырлар да ишетелгәли:

Кияү келәтенә кергәндә,
Келәт чукасын әлмәде;
Кәчкә-көчкә генә мал түләде,
Ярының яхшысын белмәде.

Туй азагына таба кияү егетләре белән кияү кәләшне алып китәргә киләләр. Атларда чаптырып, һай-һулап килгәндә, явыз көчләрне куркыту өчен, мылтыклардан аталар. Капка төбендә кияү кайниш тиешле малайга бүләк бирә — капка йоласы үтәлә. Кияүне кәләш янына берәр өлкән туган апа озатып куя, ә кияү егетләре кызлар янында калалар. Кызның туган йорты һәм әти-әнисе белән хушлашуы шулай ук елау җырлары белән башкарыла. Кәләшне «мәдәк» дип аталган махсус көймәле арбага утыртып алып китәләр. Шул чагында кияү егетләре төрле «Мәдәк җырлары» җырлыйлар. Пенза якларында шундый җырларның берсе «Айникәрәм» дип атала:

Айникәрәм, бу җиһанга
Ничек тудың анадин?
Син тумагансың анадин,
Җан иңгәндер һавадин.

Кара сыер кабыргасын
Каерып алып киттеләр.
Әнкәсенең бер бәбкәсен
Аерып алып киттеләр.

Кияү йортына килен булып төшкәч, кәләшнең кыз туганнары кыз бирнәсендәге әйберләр белән яшь пар яшәргә тиешле бүлмәне бизәп-җыештырып куялар. Ул зөфаф кичәсе бүлмәсе була. Икенче көнне кунакларга килен күрсәтү йоласы үтәлә, бер малай аның бөркәнчеген ача. Аннары гаилә учагына табындыру йоласы була: килен өйдәге мичне үбә, соңрак аңа су юлы күрсәтәләр, ул суга барып, су иясенә бүләк биреп кайта.

Кияү йортындагы туй, гадәттә, күңелле-шаян җырлар белән үтә. Монда инде кайгыга урын юк: яңа туганнар бер-берсе белән якыннанрак танышалар, дуслашалар, макташа һәм мактанышалар.

Безнең авылның сулары
Тулганы юк, тулмас та.
Сезнең кебек кодагыйлар
Булганы юк, булмас та.

Яки:

Ыстаканымның кыругы, әй, чылбырлы,
Чылбырлары саен чын көмеш.
Эче дә генә җимеш, тышы көмеш,
Сүәр кодагыйлар сез, имеш.

Шулай җырлашып-гөрләшеп утырганда, кемнәредер дәртләнеп, такмак әйтә-әйтә, биеп тә киткәннәр. Биегәндә, шаяртып, кәләшне бераз «чеметкәләп» тә алганнар:

Ары пәзи баулыгы, баулыгы,
Бире пәзи баулыгы, баулыгы.
Кызыгызны мактамагыз, мактамагыз,
Бигрәк керле яулыгы, яулыгы.

Шаулап туйлар үткән, көндәлек тормыш мәшәкатьләре башланган. Озакламый өметләнеп киленгә караштыра-сынаштыра торганнар. Яшь гаиләдә беренче бала туу бик зур шатлыклы вакыйга саналган, ул да һәртөрле йолалар белән билгеләп үтелгән. Казан татарларыннан аермалы буларак, мишәрләрдә ырымнарга ышану, теләк догалары уку киңрәк таралган. Бәби тугач, куанып күңел ачканнар. Бәби туйлары үткәрелгән. Бәби саклау йоласы да булган, анысына

кызлар чакырылып, алар җырлы-уенлы мәҗлесләрдә бишек җырлары җырлаганнар, ул җырларны яшь анага өйрәткәннәр. Яшь ана баласын иркәләп болай җырлый:

Әллү-бәллү ит, балам,
Карлыгачым, былбылым.
Тыңла әткән сүземне,
Йә, йом, бәгърем, күзеңне.

Гаилә, тормыш-көнкүреш йола җырлары арасында рекрут җырлары да шактый киң таралган. Солдат хезмәтенә китәсе нижгар егетенең җырында аерылу сагышы, тирән моң ята:

Бурап та гынай, бурап тай карлар да яусай,
Минем бүрекләремә сарылыр лай.
Бер карындай яткан дай туган дай сеңлем
Бунь гынамай* еглап сарылыр лай.

Комач та гынай ситса дай күлмәгемне
Патша бәйрәмнәрендә киярмен лә.
Моңап кына кучатлар кычкырганда,
Газиз әнкәм елыйдыр, диярмен.

Кеше туа, үсә, тормыш кора, гомер итә. Аннары бу фани дөньядан китеп тә бара. Татарларда, мөселман гореф-гадәтләре буенча, мәетнең җеназасы Коръән кәримнән Ясин сүрәсен уку белән, тавыш-тынсыз гына башкарыла. Мәет өстендә кычкырып еларга ярамый. Әмма мишәр татарларында мәҗүсилек чорыннан сакланып калган мәет өстендә елау күренешләре дә булган. Моның дәлиле итеп, нижгар мишәрләреннән язып алынган җыр-елауны китерергә мөмкин:

Су өстендә яфырак,
Агып барадыр ла ялтырап.
Минем туганнарым булса иде,
Шәт, булыр идем татлырак, диер.

Каберлекләр юлы карадыр,
Кара гына тузан оцып барадыр.
Йарапби, минем тудык япь-яшь кенә,
япь-яшь, тудыкай,
Кара җир астында каладыр...

Мишәр татарларының йола җырлары, шигъри эчтәлекләре ягыннан күп төрле булсалар да, көйләренең музыкаль яңгырашы бик гади, җиңел отып алына, җиңел җырлана торган булган. Артык катлаулы булмаган ул көй-җырлар озын лирик җырларга да нигез салганнар.

Озын лирик җырлар үзләренең яңгырашлары белән төп ике төркемгә бүленә: беренче — Мордва һәм Пенза төбәгендә яшәүче мишәрләрнең җырлары, икенчесе — нижгар мишәрләренеке. Мордва һәм Пенза мишәрләренең җырлары көйләре-яңгырашлары белән генә түгел, ә күп җырларның һәр ике төбәк өчен дә уртак булулары белән дә аерылып торалар. «Кузырлы чана», «Алтын кармак», «Абау, гөлкәем» һ. б. шундыйлардан. Җырларның шигъри эчтәлеге шактый бай һәм күп төрле. Авыр тормыш аһ-зарлары, читкә акча эшләргә чыгып китүчеләрнең ачы язмышы, качкын җырлары — мишәр җырларына хас мондый үткен социаль тематика казан татарлары җырларында бөтенләй очрамый диярлек. Мисалга бер үрнәк китереп үтик:

Очадыркай кик каз, әй, очадыр,
Очалмыйдыр җилләрдә, давылда.

Зариф дустым килгән, елап сүли:
Сиксән солдат килгән, ди, авылга.
Иректем анай кәбәм күрергә,
Ярамыйдыр көндезен йөрергә.

Сиксән сигез төштә яра гынам,
Лечить, әй, итә донской казагы.
Күрмәгәнгә ходай күрсәтмәсен
Хәмидулла качкынның газабын.

Ни авырдыр качкынның көннәре,
Ризыклы, әй, меңләрнең берләре...

*«Качкын җыры»ннан.*

Мондый җырларда сюжетлы тарихи эчтәлек шәйләнгәнгә күрә, кайбер галимнәр аларны бәетләр итеп карыйлар. Әмма музыкаль яңгырашлары белән ул җырлар һич тә бәет түгелләр, алар чын мәгънәсендә лирик җырлар. Сюжет-эчтәлек мишәрләрнең тарихи җырларына гына хас булмыйча, лирик мәхәббәт җырларында да еш төсмерләнә: «Олы юлкайларда өч каен», «Сәмәксәр», «Азизәкәй» һ. б. шундый җырлар бар.

Иртә белән торып тышка чыксам,
Җаныем, Азизәкәй,
Тәрәзәм төбеннән кеше узган.
Элек сәүешкәндә мин яшь идем,
Җаныем, Азизәкәй,
Әле дә сәүшер идем, көне узган.

Җаныем, Азизәкәй, ни бирием?
Җаныем, Азизәкәй,
Алып бирием Казанның пудрасын.
Әллә яр буласың, әллә дә юк,
Җаныем, Азизәкәй,
Яр булганчы җаннарны күдерәсен.

Нижгар мишәрләренең озын лирик җырлары яңгырашлары белән артык үзенчәлекле түгелләр. Шигъри эчтәлекләре белән дә алар, күбесенчә мәхәббәт җырлары булып, казан татарларының шәһәр җырларына якын торалар. Кайберләре хәтта соңгыларының аерым вариантлары гына:

Шәмшәрифкәй диган, әй, шәһәрдә
Кич ахшамсыз капкалар ябылмый.
Ага ла агым су, ага агым су,
Каршы йөзә алмыйм,
Җырламый түзалмыйм.
Үткән үмер белән калган хәтер,
Сатып алыйм дисәң дә, табылмый.
Ага ла агым су, ага агым су,
Йөзә үрдәкләр шул,
Өзелә үзәкләр.

*«Ага ла агым су» җырыннан.*

Мишәрләрнең авыл көйләре, кыска көйләре, такмаклары да казан татарлары җырларына бик охшаш яки шуларны кабатлыйлар, бары тик сүзләрендә генә мишәрчәлек чагыла. Шуңа күрә биредә без аларга аерым тукталып тормыйбыз. Бәетләр турында сөйләшүне дә башка вакытка калдырабыз.

«Безнең заманда,— дип яза музыка белгече М. Нигъмәтҗанов,— казан татарларының халык авыз иҗаты үзенең күп төрле жанрлары белән мишәрләрнең барлык буыннары арасында киң таралган һәм яшәп килә» *(НИГМЕДЗЯНОВ М. Народные песни волжских татар. М., 1982.).*

Әмма, тулаем алганда, мишәрләрнең җыр сәнгате казан татарлары җыр сәнгатеннән үзенең җирле үзенчәлекләре белән аерылып тора һәм без аны Идел буе татарларының халык иҗатында аерым бер мөстәкыйль тармак итеп карарга хаклыбыз.

**Роза ИСХАКОВА-ВАМБА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# МУСА АКЪЕГЕТ ТӨРКИЯДӘ

Милли әдәбиятыбыз тарихында тормыш юлы һәм иҗаты аеруча саран яктыртылган шәхесләр бар. Шуларның берсе — Галимҗан Ибраһимов тарафыннан «әдәбияте нәфисәбезнең беренче сандугачларыдыр» дип югары бәяләнгән, яңа заман әүвәлге татар романы «Хисаметдин менла»ны язган Муса Акъегет. Кайсы гына дәреслекне, белешмәлекне алып актарма, аның әлеге романыннан тыш бер мәкаләсе генә телгә алына, Төркиядә яшәгән 35 еллык гомере исә китапның ун юлына сыеп бетә. Хөрмәтле язучыбыз турында мәгълүматларның үтә чикләнгәнлеге, бердән, аның ватаннан еракка китеп югалуына бәйләнгән булса, икенчедән, әдәбиятыбызның үткәнен өйрәнүче гыйльми көчләрнең азлыгы, аларның чит ил архивларында һәм китапханәләрендә эзләнә алмавы, мәдәни багланышларыбызның зәгыйфьлеге аркасында да иде. Ниһаять, хәзер күп кенә тарихи шәхесләребезне киңрәк яктырту, кадерле исемнәребезне җәмәгатьчелеккә яхшырак таныту мөмкинлекләре ачыла башлады. Шул исәптән, минем дә Төркиянең кайбер галимнәре белән үзара багланышка керүем, даими рәвештә китаплар һәм вакытлы матбугат алмашып һәм хатлашып торуым Муса Акъегет тормышы һәм иҗатына беркадәр ачыклык кертү форсатын бирде — Х. З. Өлкәннең «Муса Акъегет» мәкаләсенә юлыктым.

Мәкаләнең авторы Хилми Зыя Өлкән (1901—1974), Муса Акъегет кебек үк, үзе дә заманында (1921) Истанбулның «Мөлкия» югары мәктәбен тәмамлаган, озак еллар буе төрле уку йортларында укыткан. 1940 елда Истанбул университетының фәлсәфә һәм социология профессоры дәрәҗәсен казанган, соңгы дәвердә исә Анкара университетында белем биргән. Вакытлы матбугатта күп санлы мәкалә, тәрҗемәләр бастырудан тыш, «Инсан» (1938—1943) журналын чыгаруы һәм утыздан артык китап, җөмләдән, «Почта юлы», «Ярым адәм» романнарын, фәнни тикшеренүләрен нәшер иттерүе белән дә мәгълүм ул. Аның тормышы һәм иҗаты хакында Ә. Санайның «Хилми Зыя Өлкән» (1986) дигән махсус китабы дөнья күргән. Кыскасы, Х. З. Өлкән — Төркиянең танылган һәм абруйлы галиме һәм язучысы. Шуңа күрә нәкъ менә шундый затның «Муса Акъегет» мәкаләсен язуы һәм аны үзенең «Төркиядә чагдаш дөшенчә тарихы» (Конья, 1966) исемле ике томлыгында (2— том, 343—352 бб.) бастырып чыгаруы, татар язучысының галимлегенә, аның икътисадчы буларак төплелегенә һәм зирәклегенә, Төркия мәнфәгатьләрен яклауда дөрес юлга басуына һәм кыюлык күрсәтүенә югары бәя бирүе күңелле. Х. З. Өлкән Төркиягә күчеп килгән, монда фән һәм мәдәният үсешендә, дәүләт җитәкчелегендә күренекле урын тоткан бүтән милләттәшләребезне дә белгән, хөрмәт иткән, күрәсең — аның әлеге ике томлыгында «Йосыф Акчура» (2— том, 636—649 бб.) мәкаләсе дә нәшер ителгән.

Әдәбият дәреслекләрендә электән дөнья күрә килгән мәкаләләр һәм Хилми Өлкән хезмәте җиткергән яңа мәгълүматлар нигезендә без хәзер М. Акъегет язмышы, аның эшчәнлегендәге борылыш хакында шактый ышанычлы кайбер фикерләр әйтә, фаразлар ясый алабыз.

Иң элек күңелгә килгәне, заманасына муафыйк тоелмаганлыктан, галимнәребез еллар буе дәшмәскәрәк тырышканы — Муса Акъегетнең төрек телен, төрек әдәбиятын шактый камил белүе. Әйе, ул гимназиядә урысча укыган, француз телен дә өйрәнгән, ләкин кулыбызда Европа әдәбияты белән аның кайсы телдә танышуы хакында бездә һичбер таныклык юк. Ә менә аның романы авторның шул заман төрек әдәби телен әйбәт үзләштереп һәм хәтта шуның йогынтысында, ярдәмендә иҗат ителүен ачык раслый. Бу дәвердә Европа әдәбияты төрекчәгә күпләп

тәрҗемәләнә, арада француз язучыларына аеруча өстенлек бирелә — Золя, Мопассан, Флобер, Бертуган Гонкурларның әсәрләре, башка әдипләрнең мажаралы романнары кат-кат басылып тора. Шуларның байтагы Идел-Урал буе татарлары кулына да килеп керә. 1872 елда беренче төрек романы «Тәлгать һәм Фитнәт мәхәббәте» (Шәмсетдин Сами. «Тәгашшыкы Талаат вә Фитнат») басылып чыга, әдәбият мәйданына аз гына соңрак аяк баскан Әхмәт Мидхәт исә 1873—1898 елларда 35 роман («Хәсәен фәллах», «Хәсән маллах», «Дүрдәнә ханым», «Дәмир бәй» һ. б.) нәшер иттерә. Мәгърифәтчелек фикерләре белән сугарылган бу һәм бүтән төрек язучылары (Нәмикъ Кәмал, Мәхмәт Җәлал, Халит Зыя, Әхмәт Рәсим һ. б.) әсәрләре татар укучылары да яратып укый торган рухи азыкка әйләнә.

М. Акъегетнең төрекчә өйрәнүе Мачәли авылы мәктәбендә башлангандыр, аның остазлары, танышлары арасында төрекчәне һәм төрек мәдәни хәятен белүчеләр дә булгандыр, ул юкка гына романының баш каһарманын «Госманлы җиреннән тәхсыйле голүм илә ватаны «Н»га кайтты», дип тасвирламыйдыр, дип уйларга нигез бар. Шулай ук Акъегетләр гаиләсендә И. Гаспралының «Тәрҗеман» гәзите укылып киленгәндер, Мусаның Казаннан туптуры Бакчасарайга китүе тиктомалдан, киңәш-хәбәрсез генә эшләнмәгәндер сыман тоела.

Бездә М. Акъегетнең Казаннан китүенә төп сәбәп — аның университетка керә алмавы дип күрсәтелде. Моны кире кагып булмый. Әмма, Х. Өлкәннең язуынча, аның алдынгы фикерләр белән сугарылган романын Казан кадимчеләре өнәмәгән икән. Бу бик табигый, чөнки шул заманның бөек мәгърифәтчеләре К. Насыйри, Ш. Мәрҗанинең татар башкаласындагы тормышы нинди авыр көрәшләрдә узуы безгә яхшы билгеле. Яшь язучы татарның милли пайтәхетенә аяк баскач, үзенә фикердәшләр һәм таяныч эзләп, әлбәттә, әнә шундый мәгълүм шәхесләр белән очрашырга тиеш иде. Бәлки ул шулай эшләгәндер дә, ләкин моны раслардык дәлилләргә дә без әле һаман ия түгел.

Төркиягә килгән М. Акъегетнең, инде каләм көчен уңышлы сынаган язучының, монда, күп кенә бүтән егетләребез кебек, тел-әдәбият буенча белемен тирәнәйтергә омтылмавы, ә бәлки «Мөлкия»гә керүе безгә, бер уйлаганда, үтә сәер һәм кызганыч тоела. Аның бу адымы, Мусаның иманын һәм идеалларын яхшы күзаллаганда исә, бик табигый һәм кануни санала ала.

Мәгълүм ки, төрки халыкларның үзенчәлекле бер тел һәм мәдәният, гореф-гадәтләр һәм йолалар иясе, этнографик тип буларак саклануы һәм үсүе XIX йөз ахырында сәяси бәйсезлекләрен, милли дәүләтчелекләрен югалтмаган госманлы төрекләре яшәгәндә, аларга сыенып һәм таянып гомер иткәндә генә гарантияләнә ала иде. Төрекләр көчәйсә, башка төрки кавемнәрнең дә яшәү өмете арта, алар зәгыйфьләнсә һәм юкка чыкса, татарны яки казакъны, төрекмәнне яки үзбәкне агартып кына бәладән котылу мөмкин булмаячак иде.

XIX йөз ахырында исә Көнбатыш Европа, капитализмның иң югары баскычына күтәрелеп, пар казанын электр генераторына алыштырганда, Төркия императорлыгы феодаль җитештерү ысулында кала һәм һаман артка тәгәри: натураль хуҗалык итү, кустарь һөнәрчелек, солтан һәм пашаларның мәмләкәт байлыгын әрәм-шәрәм итүе, еш кабынып торган сугышларның ил икътисадый хәлен тәмам мөшкел дәрәҗәгә төшерүе гадәти нәрсәгә әйләнә. Игенчеләрнең чамалы гына уңышы кырып-себереп талап алына, күтәрә алмаслык салымнар хезмәт ияләрен бөлдерә, ил хуҗалыгын үзгәртеп яңа нигездә корыр өчен сәрмая калдырылмый, мәмләкәт һөнәрчелеген Көнбатыш илләре күпләп китереп саткан арзанлы фабрика маллары аяктан ега. Чит ил сәүдәгәрләре Госманлы императорлыгында, солтан хөкүмәтенең булдыксыз сәясәте аркасында, аның үз сәүдәгәрләренә караганда күбрәк хокукларга ия була һәм уңайлырак шартларга куела, солтан һәм пашалар шул сәүдәгәрләр, финансчыларга зур процентлар түләү хисабына әҗәткә керә һәм бурычка бата. Икътисадый яктан зәгыйфьләнү, фән-техника* үсешендә Көнбатыш Европадан артта калу бик тиз хәрби өлкәдә дә нәтиҗәсен күрсәтә — Төркия XVIII йөз башыннан алып гел җиңелә башлый, биләмәләрен берәм-берәм җуя, Англия белән Франциянең чимал чыганагына әйләнә бара. Хәтта илнең акчасын да чит ил банклары басып бирә башлый — төрек дәүләтенең ярым колония хәленә төшүенә инде күпләрдә шик калмый. Төрки кавемнәрне тарих мәйданында саклау өчен беренче нәүбәттә Госманлы императорлыгын ныгытырга кирәк булса, соңгысын яшәтү өчен аны иң әүвәл икътисадый яктан сәламәтләндерү таләп ителә. Моның өчен инде мәгърифәтчелек эшчәнлегеннән бигрәк, хирургларча тәвәккәл эш итеп, Төркиянең экономик системасын

кискен үзгәртү сорала. Димәк, Төркиянең киләчәге тиз арада гарәпчә сәнәгать һәм финанс төзелешен җайга салу, шуны гамәлгә куярлык белгечләр әзерләүгә кайтып кала. «Яшь төрекләр» хәрәкәте, аларның ил эчендә һәм тышында барлыкка китерә башлаган «Берләшү һәм прогресс» («Иттихад вә тәрәкъкый») партиясе Госманлы империясендә конституцион идарә кертү, илне янарту, аны Англия, Франция, Русия тарафыннан басып алып, үзара бүлешүдән коткару көрәшен җәелдерә. Менә шушы шартларда Муса Акъегет үзен Төркия өчен иң кирәкле санаган икътисад өлкәсендә эшчәнлек күрсәтүгә багышлый.

Бу вакытта Госманлы империясенең алдынгы фикерле дәүләт эшлеклеләре дә мәмләкәт бәйсезлеген саклар өчен кайбер чаралар күрә башлаган була — һич югы гаскәрне көчәйтү өчен Европа казанышлары нигезендә укыта торган урта яки югары Артиллерия, Хәрби медицина мәктәпләре, инглиз телендә белем бирә торган Галатасарай лицее, Роберт колледж ачыла... «Мөлкия» мәктәбе дә әнә шундый дәрәҗәле уку йортларының берсе була. Анда дәүләт хезмәткәрләре — министрлыклар, виләят һәм каймакамлык (өяз) чиновниклары әзерләнә. Шунысы да игътибарга лаек: күп кенә танылган галимнәр, дәүләт эшлеклеләре белән бергә, күренекле шагыйрьләр һәм әдипләрдән Т. Мәнәмәнлезадә, М. Садыйк, Г. Кәмал, С. Исмаил, Ә. Тукгүз, Ә. Рәй, Ф. Озансой, М. Әриширгил, Ә. Корыйөрәк, Й. Җәмал, Ө. Ушаклы да шушы уку йортын бетерә, төрек прозасын реалистик нигездә үстерүгә, Көнбатышка табынуны мыскыллауга, урта катламнарның тискәре гадәтләрен фаш итүгә зур өлеш керткән күренекле әдип, кырыкка якын роман иҗат иткән Хөсәен Рәхми Гүрпынар да «Мөлкия» мәктәбендә белем ала. Муса Акъегет, Төркиягә килгәч, әлбәттә инде, «Мөлкия» югары мәктәбенең программасы, аның укытучылары һәм шәкертләренең кемнәр булуы белән кызыксынмый калмагандыр. Соңыннан ул югарыда саналган күренекле шәхесләрнең һәм бүтән танылган затларның кайсыларына сыйныфташ һәм һөнәрдәш, кайсыларына фикердәш һәм көрәштәш, хәтта остаз булуы да табигый. Аның «Мөлкия»не тәмамлаганнан соң Югары хәрби мәктәптә рус теленнән генә түгел, икътисадтан да белем бирергә билгеләнүе, аннары Хәрби Академиядә дә сабак укытырга чакырылуы нәкъ менә шул фаразны куәтли. Аның экономика буенча ике кисәктән гыйбарәт махсус гыйльми хезмәт бастыруы һәм Госманлы империяреньгының иң танылган икътисадчылары белән бәхәскә керүе, Европа фәне казанышларына таянып, Төркия хәлен анализлавы һәм үсешнең үз программасын тәкъдим итүе игътибарга лаек. М. Акъегет, Төркиягә килгәч, татар язучысы буларак юкка чыкса, монда киң карашлы, җитди әзерлекле икътисад галиме буларак җитешә, Европа экономик гыйлемен бөтен төркиләргә, Шәрекъ халыкларына аңлатучы фикер иясенә, Төркия икътисадын үзгәртеп кору өчен көрәшүче дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесенә әверелә. Игътибарга лаек күренеш: Й. Акчура, С. Максуди, З. Вәлиди, Ә. Курат, Х. Кошай, Г. Баттал, Р. Рәхмәти һ. б. милләттәшләребез XX йөздә Төркияне аякка бастыру эшенә җиң сызганып керешсә, аларның һәркайсы фәннең берәр тармагында хокук, тарих, тел, этнография һ. б. өлкәләрдә нигез салучы зур тикшеренүче булып танылса, Габдерәшит Ибраһим, Муса Акъегетләр шушы юлга XIX йөздә үк аяк басканнар һәм шундый ук әһәмиятле эшләр эшләгәннәр икән. Әмма төрек җәмгыятенең алдынгы фикерләрне кабул итәргә әзерлексез булуы, солтан һәм аның пашалары, кадимчел руханыйлар гына түгел, 1908 елда хакимлекне үз кулына алган «Яшь төрекләр»нең дә икътисадый карашлары дөрес нигездә формалашып җитмәве ил үсешен иң отышлы юлдан алып китәргә комачаулый. Мәмләкәт өчен гаять файдалы икътисадый программа тәкъдим иткән М. Акъегет исә, яңа хакимнәргә көндәш, хәтта зарар китерүче саналып, Истанбулдан дәрәҗәле сөргенгә сөрелә — ул ерак төбәкләрдә, хәзергечә әйткәндә, район администрациясе башлыгы вазифаларын үти. Әмма ул, нахак җәберләнүенә карамастан, шул вазифасын кайда да чыдамлык күрсәтеп, намус белән башкара, иң авыр шартларда да Төркиянең тугрылыклы ватандашы булып кала.

Хилми Өлкән язганнардан аңлашылганча, М. Акъегетнең «Әлгасрелҗәдит» журналында басылган «Европа мәдәнияте нигезенә бер караш» әсәре мәкалә түгел, аның аерым китап булып чыккан күләмле хезмәтенең бер варианты икән.

Гаяз Исхакый мөһаҗирлектә оештырган «Яңа милли юл» журналының бер санын Муса Акъегеткә багышлаган. Бу аның үзеннән алда туган әдәбиятыбызны үстерүгә күренекле өлеш керткән әдипне тануын һәм аңа югары бәя бирүен раслап тора. М. Акъегет,

3. Бигиевләрдән соң татар прозасын яңа биеклеккә күтәргән классик язучыбыз Г. Исхакыйның аларга карата әйткән фикерләре иҗтимагый әһәмияткә ия, шуңа күрә әдәбият дәреслекләребезнең яңа басмаларында ул фикерләрнең дә җәмәгатьчелеккә җиткерелүе яхшы булыр иде.

Хилми Зыя Өлкән мәкаләсендә Муса Акъегетнең туган җирен һәм туу вакытын, роман исемен һәм Мәрҗани атын күрсәтүдә кайбер ялгышлар җибәргән. Татарны «төньяк төреге», «Казан төреге» дип атау Төркиядә әле дә киң таралган. Европа исемнәрен, урысча гыйбарәне бирүдә дә кайбер төгәлсезлекләр китүе ихтимал. Әмма без кадерле язучыбыз хакында яңа мәгълүматлар туплаган Х. З. Өлкәнне, аның мәкаләсен безгә күчереп җибәргән Измир университеты доценты Явыз Акпынарны рәхмәт хисе белән искә алабыз һәм Төркиядә басылган «Муса Акъегет» мәкаләсен төрекчәдән тәрҗемәләп, сөенеч белән укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

**Тәүфикъ ӘЙДИ.**

# МУСА АКЪЕГЕТ

**(1865[1]—1923)**

Конституция елларының онытылган, әмма хөрмәткә лаек бер фикер иясе — Муса Акъегет. Ул яшәгән дәвердә Төркиядә иттихадчыларның[2] финанс министрлыгын җитәкләгән Мәхмәт Җәвитнең икътисадый карашлары хакимлек итә. Муса Акъегет Оһаннес паша һәм Җәвит икътисадына капма-каршы юнәлешне яклый һәм шуның кысасында тикшеренүләр алып бара. Җәвит беренче язмаларын «Гыйльме сәрвәт»[3] исемле фельетон төсендә Габделхәмит[4] заманында «Сәрвәтефөнүн»[5]дә бастыра. Соңыннан Поль Лерой Бьяулию һәм Чарлз Гидегә таянып, «Икътисад» китабын яза. Сакызлы Оһаннес һәм Нәмикъ Кәмалдән соңгы дәвердә урнашкан ирекле базар һәм икътисадый юл куючанлык принцибын яклый. Гомумән, классик экономика теорияләре дә (Адам Смит, Рикардо һ. б.) бу карашка нигез булачак гыйльми мәгълүматлар бирә. Әхмәт Мидхәтнең Габделхәмит заманында яклаган химаячелек карашы бу вакытта инде онытылган була.

Конституцион идарәнең, «хөррият» принцибына нигезләнеп, бу мәсләкне тотуы табигый сыман күренсә дә, асылында икътисадый яктан зәгыйфь бер мәмләкәттә ил капкаларының чит ил малына ачылуы тудырачак зарарларны санап та бетерерлек түгел иде. Моның китерәчәк бердәнбер файдасы яңа бурычлар алырга мөмкинлек ачылу иде. Ләкин дәүләт бурычының бихисап үсүе мәмләкәтнең икътисадый җәһәттән колониягә әверелүенә сәбәп булачак иде. Озак көттермәячәк бу фаҗигале хәвефләргә фәкать берәү дә әһәмият бирми иде. Иттихадчыларның мондый финанс сәясәте уздырылган елларда моңа хәтта канәгатьләнү белдерелгән шартларда хәвефле адымга каршы ризасызлык күрсәтүче бердәнбер укымышлы Муса Акъегет була.

---

[1] Хата. Дөресе — 1864.
[2] «Иттихад вә тәрәкъкый» партиясе 1908 елда ил идарәсенә килә.
[3] «Байлык гыйлеме».
[4] Габделхәмит II солтан 1876—1908 елларда тәхеттә утыра.
[5] «Фән байлыгы» (1891—1901) — гыйльми, әдәби журнал.

Акъегетзадә Муса (1865—1923) Казанда туа[1]. Идел-Ураллылар арасында танылган ике йогынтылы эшлекленең — Шәрәфетдин[2] Мәрҗани белән Каюм Насыйриның тере вакытында Муса «Хисаметдин мулла»[3] исемле романын Казанда бастырып чыгара. Язучы монда Казанның реакцион карашлы бер кешесе белән укымышлы бер егет арасындагы көрәшне сурәтли. Китап яхшы каршыланмый һәм бу хәл язучының, мәмләкәтен ташлап, белем алыр өчен Истанбулга килүенә сәбәп була. Муса Мөхәммәтҗан углы Акъегетзаденең асылы Русиядәге Пенза виләяте Чембар өязенең «алты авыл» диеп танылган даирәсендәге Кабил[4] авылыннандыр. Атасы Мөхәммәтҗан әфәнде «Давернски апека»[5] исемендәге хөкүмәт оешмасында хезмәткәр булганлыктан, заманча тәрбия бирер өчен, уллары Муса белән Хәсәнне Пенза шәһәренә китереп, урыс гимназиясендә укыта. Яшь Мусада гимназиядә белем алганда ук төрекләргә һәм Төркиягә карата мәхәббәт уяна, ул хәтта мәктәпне тәмамлаганчы ук Төркиягә китәргә тели, фәкать укуын ярты юлда өзмәсен өчен, атасы мона юл куймый. 1885[6] елда укуын бетергәч, Муса Казанга килә һәм анда «Хисаметдин мулла»ны бастыра. 1887[7] елда китабы уяткан тискәре реакция тәэсире астында Истанбулга килә. Монда ул «Мөлкия» югары мәктәбенә укырга керә. 1894 елда аны бик яхшы билгеләргә тәмамлый. Муса белән бер үк сыйныфта укыган Габделфәяз Тәүфикъ миңа бер күрешкәндә: «Сыйныфның ул — капитаны, мин — рулевое идек»,— диде.

Николай Ильминский аны искә алганда: «Акъегетзадә Истанбул медицина академиясенә кергән», ди, әмма бу — хата. «Мөлкия»не бетергәч, ул Югары хәрби мәктәптә урыс теле һәм икътисад фәне укытучылыгына тәгаенләнә. Конституцион идарәнең башлангыч дәверендә хөррият җәелүдән файдаланып, Төркиядәге әүвәлге китабы булган «Аурупа мәдәниятенең әсасенә бер назар[8]»ын, аннан соң «Икътисад яхут гыйльме сәрват»[9]ен чыгара (1918). Бу китапта ирекле базар икътисады чолтәре белән химаячелек[10] системасы арасындагы капма-каршылыкны җентекләп тикшергәннән соң, Төркия өчен химаячелек системасын кабул итүнең өстенлекләрен һәм зарурнятләрен күрсәтә. Бу фикерләрен тагын да әтрафлырак исбатлар өчен, бер матбага кора (Вәзирханында) һәм «Мәтин»[11] исемле гәзит чыгара башлый. 1910 елда бер-бер артлы ябылган гәзитләр арасында «Мәтин» дә булганлыктан, бүтән ике гәзит белән берләшеп, «Өч кардәш»кә нигез сала. Ул да ябылгач, хәрби хезмәткәр түгеллеген сылтау итеп, Муса Хәрби академия һәм Хәрбия мәктәбендәге укытуыннан да азат ителә. Башта Измир, соңрак Һама шәһәрләрендә ябык биналар комиссиясе әгъзасы һәм рәисе вазифасына билгеләнеп, Истанбулдан ераклаштырыла. Бу тәшкиләттән киткәч, көнчыгыш виләятләрдәге каймакамлыкларда[12] (Адилҗәваз, Һошап) хезмәт итә, иң ахырда, ул Чапакчур каймакамлыгында эшләгән чакта, Беренче Дөнья сугышы башлана. Урыслар Сиваска якынлаша. Муса Акъегет, хөкүмәт документларын бер чемоданга тутырып, җәяүләп поезд йөргән җиргә кадәр барып житә, әмма шул чакта тиф чирен йоктыра. Истанбулда аңа бик озак шифаханәдә дәваланырга туры килә. Сәламәтләнгәннән соң, Русиядән сатып алынган Катанов шәркыят китапханәсенә мөдир итеп тәгаенләнә. Шуннан ул пенсиягә чыга. Гомере азагында бәйсезлек сугышында Истанбулның азат ителүен күрә һәм авыру хәлендә яшьләр оештырган факеллы нәмаешларда катнаша, аннары озак та үтми вафат була (1923).

Муса Акъегет тормышын Николай Ильминский телгә ала[13]. Ул Пенза шәһәрендә Ахун мәдрәсәсендә укыган Исхаков исемле берәүнең соңыннан чукынуын,

---

[1] Муса 3.XII.1864 тә Пенза губернасы Чембар (хәзерге Белинск) шәһәрендә туа.
[2] Дөресе — Шиһабетдин.
[3] «Мулла» түгел, «менла».
[4] Бездә «Мачали» дип йөртелә.
[5] «Доверенная опека»? «Дворянская опека»?
[6] Дөресе — 1884.
[7] Дөресе — 1888.
[8] «Европа культурасы нигезенә бер караш».
[9] «Экономика яки байлык гыйлеме».
[10] Протекционизм, яклау.
[11] «Текст», «Асыл нөсхә».
[12] Өязләрдә.
[13] Ильминский мәктүпләре (А. Баттал-Таймас. Казан төрекләре. Истанбул, 1921. Шундагы чыганак саны 98, бите 308.).

урыс гимназиясендә укыган Акъегетзадәнең исә мөселманлык мәркәзе булган Истанбулга китүен аңлатып, бу хосуста кыйммәтле ике мисалны капма-каршы куеп, Муса тәкъдиренә туктала. Муса, Вәзирханындагы матбагасыннан аерылганчы, «Байлык гыйлеме» хезмәтенең икенче кисәген чыгара. Шул чакларда «Төрек йорты» һәм «Төрек дөньясы»нда да кайбер язмаларын бастыра.

Алманиядә «Яңа милли юл» исемле журнал Муса Акъегеткә бер санын багышлаган. Монда аның турында әтрафлы сүз алып барыла. Язучылар арасында башлыча Гаяз Исхакый чыгыш ясый. Мәкаләләр татарча язылган. Монда иң зур игътибар Мусаның төньяк төрек[1] әдәбиятында мөһим роль уйнаган, яңа бер буразна сызган «Хисаметдин мулла» романына бирелә һәм Истанбулдагы гомеренә бик аз тукталына. Хәлбуки безнең өчен язучы эшчәнлегенең беренче дәвере түгел, икенчесе әһәмиятлерәк.

Муса Акъегет исәбенчә, заманыбыз икътисадының иң әһәмиятле мәсьәләләре — ирекле базар һәм химаячелек. Милли байлык мәнфәгатеннән караганда, сәүдәне язмыш кочагына ташлап калдыру файдалымы, әллә аны яклау хаҗәтме? Ирекле базарчылар болай төшенә: 1) Җир йөзендәге бөтен мәмләкәтләр гомуми бер базар хәлендә. Бер җирдә туфрак, климат һәм милли характер фәлән малны җитештерүгә кулай. Икенче җирдә бүтән малны җитештерү өчен шартлар яхшырак. Һәр милләт үзе җитештерергә күнеккәнне бүтәннәрдән иң әйбәт үтәве белән аерылып тора. Хезмәт әнә шулай бүленгәндә, милләтләрнең куллану дәрәҗәсе шактый артачак. Һәр мал шулай җитештерелгәндә сыйфатлырак та, очсызрак та булачак. Халыкара сәнәгатьне үз ихтыярына ташлап, чит ил товарына зур пошлина салу һәм мәмләкәткә кертелүен тыю яки чикләү милләтләрнең төрле кабилиятләре үсешен туктата һәм малларының тагын да кыйммәтрәктән сатылуына китерә. Хәлбуки, дөнья халыклары арасында үсешүзгәреш белән берлектә эш бүленеше дә яши. Химая ысулы бу эш бүленешенең тормышка ашуына киртә була. Бу алым кайдадыр җитештерелүе тәртипкә салынмаган бер малны җитештерүгә гайрәт бирә, ләкин шул алымның кыенлыклар тудыруы һәм дөньяда гомуми байлыкның артуына киртә куюы да мөмкин. 2) Эчке сәнәгатьне яклау ысулы халыкара мөнәсәбәтләрнең киеренкеләнүенә дә сәбәп була. Химая аркасында милләтләр бер-берсе белән гаугалаша. Хәлбуки бүгенге мәдәният кешеләрнең үзара бәйләнешын ныгытып, аларны бәхетле итәргә тели. Тышкы сәүдәнең ирекле булуы кешеләрнең белемнәрен, фикерләрен һәм байлыкларын уртаклаштыруга хезмәт итә. Химая ысулында болар туктатылачак. 3) Химая ысулы ил эчендәге халыкның ватандашлар файдасына хезмәт итүен тудыра. Якланган сәнәгать тармагы чит ил малына кырык процент күләмендә пошлина түләтү белән саклanса, чит илдән мал китергән сәүдәгәрләр, ул кыйммәтне үз товарына да өстәячәк. Җирле җитештерүчеләр дә шуның аркасында товарларын тулаем кыйммәтрәктән сатыр. Бер төркем кешенең мәнфәгате өчен бөтен халыкка чыгым тагу дөрес булмас. Мәмләкәттә җитештерү чикләүсез башкарылса, җитештерүчеләр малны иң соңгы модель технология һәм кораллар кулланып, арзан бәядә чыгарырлар. Британия утраулары тәмәке игәргә уңайлы түгел. Франция күмер чыгару урынына тәмәке үстерсә, күбрәк табыш казаныр. 4) Эчке сәнәгатьне яклау ысулы бер милләтнең сәрмаясын химая кылыначак сәнәгать тармагына сарыф итүгә китерсә, шул мәмләкәтнең табигый табышлы җитештерүенә сәрмая салуны киметәчәк. Бу да бер сәнәгать тармагының алга китешенә киртә һәм илдә эш көченең кимүенә сәбәп булыр. 5) Сәнәгатькә һәм сәүдәгә ярдәмдә иске һәм аксаган сәүдә балансы ысулы яшеренгән була. Бу сәүдә балансы 16-гасырда меркантилистлар тарафыннан мәйданга чыгарылган, мәмләкәткә тыштан алтын һәм көмеш керсә, милли байлык артыр, дигән фикердән гыйбарәт. Бу ысул португаллар һәм испаннар тарафыннан колонияләргә җайлаштырылган, соңрак аларга һолландиялеләр һәм инглизләр ияргән. Болар мәмләкәттән күп мал чыгарып, аз мал алу дөрес, дигәннәр. Ләкин Адам Смит тарафыннан бу фикернең ялгышлыгы күрсәтелә.

Муса Акъегет бу дәлилләргә каршы химаячеләрнең дәлилләрен саный: А) Җир йөзендәге мәмләкәтләр гомуми бер ачык базар түгел. Кешеләрнең көткән файдасы ялгыз икътисадый файдадан гына гыйбарәт булмый. Кешеләрнең аннан өстен теләкләре һәм максатлары бар. Болар сәяси һәм милли мәнфәгатьләр белән милли гореф-гадәтләрнең саклануы кебек мәгънәви максатлардыр. Мондый теләкләр милләтләр арасында төрле дәрәҗәдә булса да, болар һәркайсында икътисади җәһәткә караганда өстенрәк. Шулай икән, милли хәятнең яшәве нәр-

---

[1] Татар.

сәне хаҗәт итсә, аны тәэмин итү зарур. Байлыкка бәйле файдалар белән милли мәнфәгатьләр бер-берсенә туры килмәгән очракта, җәмгыять өчен изгерәк саналга бу мәгънәви мәнфәгатьләр хакына матди байлыкның фида кылынуы таләп ителә. Әгәр ирекле базар милләтнең киләчәк тормышын куркыныч астына куйса, кешеләр вакытлыча химаячелекне тотуга икеләнмәс. Б) Химия ысулының милләтләр арасында суык мөнәсәбәтләргә сәбәп булуы инкарь ителмәс. Фәкать иң изге мәнфәгатькә кагылган эшләрдә бу хәл җәмәгатьчелек тарафыннан аңлы рәвештә тормышка ашырыла. Ирекле базарның сугышларны азайтуы да бик тотрыклы түгел. Англия ирекле базарны кабул иткәне хәлдә сугыш ачудан хәтта бер ел да тыелып тормады. В) Химаячелекнең әйбер бәясен арттыруына килгәнче, бу арткан бәянең күбесе җирле җитештерүчеләргә түгел, чит илнекеләргә төшә. Чөнки күп очракта якланган сәнәгать ияләре күбәеп, араларында эчке көндәшлек туа. Көндәшлекнең табигый нәтиҗәсе буларак, якланган сәнәгатьләр алга китә. Җитештерелгән малларның бәясе яклау аркасында югарырак икән, ул тора-бара төшәр һәм чит ил малларыннан да арзанаер. Бер үк вакытта үзе дә кулланучы булмаган җитештерүче юк. Шунлыктан, бары капиталист мәнфәгате өчен генә эшләгән кеше дә юк. Француз икътисадчысы Элбинең сөйләвенчә, химая аркасында малларга өстәлгән салым (пошлина) саклану бүләге төре генә. Чөнки илдә кайсыдыр малны җитештерү яклана икән, җитештерүчеләрнең күбесе аңа бу эштә булыша — страховка ясый. Бу хәлдә пошлина халык тарафыннан фабрикачыларга да йөкләнә. Г) Ярдәм алган сәнәгатьчеләр хәле һәм аны алмаган сәнәгатьләрдә сәрмаяның азаюы бары капиталы зәгыйфь мәмләкәттә генә сизелә. Сәүдәне үз ихтыярына кую, аның балансын яраксыз кагыйдә тарафдарларыңа исәпләүгә китерер. Бер мәмләкәткә кертелгән малларның микъдары читкә чыгарылган маллардан күп булуы абсолют рәвештә мәмләкәт байлыгын арттырмый. Англиядә соңгы егерме елда импорт даими рәвештә экспорттан күбрәк. Сәүдә балансы кагыйдәсе буенча, Англиянең байлыгы азаюы көтелсә, ул арта гына бара. Әгәр бер мәмләкәтнең алачагы бурычыннан күп булса, ул мәмләкәтнең байлыгы артыр, диган фикер дөрес.

Ике якның дәлилләрен санаган Акъегет, шуннан соң ике тарафны бәхәсләштерә. Әүвәл һәр кавемнең мәгълүм бер тармакта сәләте булуы әйтелми, ди, чөнки бу ысул буенча, бер кавемнең шахтер, икенчесенең игенче, өченчесенең — фабрика эшчесе булуы кирәк. Хәлбуки мондый халыкара эш бүленешен сәнәгать тарихы расламый. Җир йөзендә һичбер кавем билгеле бер эшне генә башкаруда ныгып калмаган. Һәр мәмләкәт бер-бер артлы әллә ничә шөгыль: аучылык, көтүчелек, игенчелек дәверләрен кичергәннән соң, безнең көннәрдә фабрикачылык белән игенчелек аралашкан шәкелгә кергән. Фабрикачылык игенчелекне кысрыклап юк итми. Бер мәмләкәтнең зур фабрикачылык сәнәгатен үстерүе игенчелек белән берлектә фабрикалар эшләтүе ул. Халыкларның бу дәверләрне кичергәннән соң, берсенең бары игенчелеккә, бүтәненең фабрикачылыкка гына бирелүе сәнәгатьнең алга китү канунына туры килми. Бер кавемнең игенче булып кына калуы да индустриаль үсешкә ярашмый. Ирекле базарчаларның теләге гамәлгә ашу өчен берничә мәмләкәтнең җитештерү куәтләре булуы кирәк. Хәлбуки җир йөзендә тиң куәтле ике кавем икътисад тарихында күренми. Ирекле базар челтәрендә куәтлесе зәгыйфьне изә. Эчке базар куәтле як карамагына күчә. Аграр бер мәмләкәт, сәнәгатен якламаса, игенчелек дәверендә калып яши алырмы? Ирекле базар шартларында мондый мәмләкәт халкы малны арзан бәягә тыштан сатып ала алмасмы? Муса Акъегет уенча, икътисад тарихы берсе аграр, икенчесе индустриаль булган ике мәмләкәтнең беренчесе икенчесенә икътисадый бәйле булуын күрсәтә. Ягъни байлык кулга төшерү җәһәтеннән бәйсез булмас. Аграр Ирландия индустриаль Англиягә бәйле. Капиталист инглизләр Ирландиянең бөртекле игенен арзан бәядән сатып ала, Ирландия бәрәңгесен һәм бодаен югары бәядән алырга теләми, механик станокларда ясалган авыл хуҗалыгы машиналарын исә ирландияләргә югары бәядән саталар. Инглизләр сәнәгать әйберләрен Ирландия чималына караганда кыйммәтрәк тәкъдим иткәнлектән, ирландияләрнең игенчелектә алга китүе кайда — ул әле түбән дә тәгәрәячәк. Һиндстан да Англиянең сәяси колониясе булудан элгәре икътисадый яктан шундый ук сурәттә бәйле иде. Бер мәмләкәтнең игенчелек шөгыльендә генә калмавы өчен: 1) Мәгарифнең җәелүе; 2) Сәнәгать мәктәпләренең ачылуы; 3) Транспорт челтәренең юлга салынуы; 4) Сәнәгатьнең һәм сәүдәнең яклануы һәм уңайлы шартларда үстерелүе кирәк. Башлангыч дәвердә кирәкле тармакны химая

кылуны күз уңында тотмыйча гына үз куәтле сәнәгатен булдыруга ирешкән бер генә мәмләкәт тә юк. Йөз ел әүвәл һәм аннан элегрәк Англия дә химая ысулы куллануы билгеле. Бүген ирекле базарчы булуларына карамастан, хәтта алкоголь житештерүне дә юлга салалар. Тыштан килгән малларга салынган пошлинаның илдә житештерелгән шундый ук маллардан алынган салымнан азлыгы жирле сәнәгатьнең түбән тәгәрәвенә сәбәп була. Эчке базарда жирле мал чит илнеке белән көндәшлек итә алмый һәм сәхнәдән төшү мөшкеллегендә кала.

Химаячелек халыкара хезмәт бүленешенә каршы килми. Чынлыкта табигать үзенчәлекләре үзеннән-үзе күпмедер хезмәт бүленешенә этәрә. Җылы-суык, югары-түбән, коры жир-диңгез аерымлыклары теге яки бу ил эшчәнлегенең үзенчәлеген барлыкка китерми калмый. Шунлыктан химаяне җайга салу халыкара хезмәт бүленешен юкка чыгармаячак. Бизмәнләп кулланылачак яклау чит ил малларына дәүләт капкаларын тулаем ябу түгел ул. Мөстәкыйль мәмләкәттә мәгълүм чималга бай сәнәгать тармагының аякка басуы өчен башлангыч дәвердә булышу бу тармакны буа торган чит ил көндәшенә каршы чара күрү дигән сүз. Акыл белән гамәлгә ашырылачак бу яклау нибары биш-ун еллык вакытлы бер чара.

Химаячелекнең гыйльми нигезе нәрсә? Акъегет аны түбәндәгечә саный: А) Җәмгыять мохтаж сәнәгатьне алга җибәрү зарур. Б) Катнаш индустриаль дәвернең өлешләре булган игенчелек, сәүдә һәм куәтле сәнәгатьне эченә алган житештерү даирәләре корылмыйча, житештерүнең тулаем үсеше мөмкин түгел. В) Алда искәртелгән сәбәпләр аркасында жир йөзендә мәңгелек тынычлык саклануы мөмкин булмаганлыктан, җәмгыять ирексездән имин яшәве өчен зарури сәнәгатьне (корал ясау һ. б.) барлыкка китерәчәк. Җитештерү даирәсенең төзелешен алдынгы дәүләтләрдә ачык күрәбез. Ул авыл хуҗалыгы, кул эше, сәнгать, станоклы зур индустриядән гыйбарәт. Даирәдә фабрикалар булган жир — мәркәз. Аграр сектор мәркәз тарафыннан кысрыклана. Халык тыгыз урнашкан мәркәз тирәлегеннән ашамлык ала. Шәһәрләрдә — фабрикаларда ясалган әйберләр, өлешчә, ашлама да товар төсендә әйләнә-тирәгә китә. Химик Лиебик, уңышын биргәндә, туфракның уңдырышлылыгын югалтуын белдерде. Карей борынгы Латин Америкасы кыйтгасы, Мексика тигезлеге халкының, бары игенче генә булуы аркасында, вакыт узу белән уңдырышсызга әйләнгән туфракта фәкыйрьлеккә төшүләрен әйтә. Фәкать бер төрле житештерү даирәсендә генә мондый кыенлык калкып чыга. Терлекчелек исә игенчелекне тулыландыра, алар икесе бергә сәнәгатьне тукландыра. Бер житештерү даирәсе: 1) Зур сәнәгатьне коручылар; 2) Сәүдәгәр; 3) Игенче; 4) Эшче булып, бер-беренә бәйле дүрт катламнан гыйбарәт. Фәкать шундый бер даирә мөкәммәл бер икътисадый организм санала. Мәмләкәт монда тасвирланган әнә шундый күп кенә даирәләрдән корыла. Болар тупламаның да бер мәркәзе була. Мисалга, Англиядә бөтен житештерү даирәләренең мәркәзе — Лондон. Бер-берен табигый рәвештә тулыландырган мондый житештерү даирәләреннән гыйбарәт икътисадый бер организм булган җәмгыятьнең мәдәни үсеш хәлендә булачагы акыл һәм тәҗрибә аша аңлашыла. Француз икътисадчысы Евгене Даире, чит илләргә күп микъдарда чимал тире экспортлаучы Ла Платаның, һичбер фабрикасы булмаганлыктан, сәнәгать товарларын Европадан китертүен, шуңа күрә икътисадый кризистан чыга алмавын белдерә. Химаячелекнең гыйльми нигезе дә шул: җәмгыять, кеше кебек, катлаулы бер организм. Кеше төрле әгъзалардан гыйбарәт булган кебек, җәмгыятьтә икътисадый әгъзалар берлегеннән тора. Кешедә мускул көче — хәрәкәтләнүгә, күзе — күрүгә, борыны ис тоюга хезмәт иткән шикелле, икътисадның да шундый рухтагы төрле әгъзалары бар.

Ирекле базар мәктәбенең тамыры физиократларның рационализмында. Бу сукмакны ачкан Куеснай мәгърифәтче бер фикер иясе һәм рационалист иде. Шунлыктан икътисадый күренешләрне акыл белән тикшерү һәм аны бөтен гореф-гадәтләрдән, киләнәкләр[1], йола-күнекмәләрдән, тиешле кануннардан арындыру кирәк. Моның өчен бу ысулны кулланучылар Франциядә бик күп оешмаларны егарга керештеләр. Эштә чикләрне аермау һәм вакыйгаларны үз агымына кую өчен Франция һәм Англиянең кустарь һөнәрчелегеннән арыну кирәк иде. Чөнки һөнәрчелек кагыйдә-уставлары соңыннан төзелгән, акыллы нигезгә таянмаган иде. Әмма рационалистлар тагын да ераграк житә. Заманында акылга сыешлы һәм файдалы булган кустарь һөнәрчелек соңрак иҗтимагый

[1] Традицияләр

куәтләрне алга җибәрүдә киртәгә әйләнә. Муса Акъегет, химаячелек фикерләрен яклаганда, ул елларның танылган француз икътисадчысы Поль Каувес белән алман икътисадчысы Листкә таяна. Ләкин Лист бер мәмләкәтнең саф индустриаль булуы бүтән мәмләкәтләргә икътисад җәһәтеннән хакимлек итүен барлыкка китерәчәк, ди. Акъегет бу фикергә кушылмый, фәкать индустриаль булуның кыенлыклары бар, төрле сәбәптән бер өлеш фабрикалар туктап калса, аның эшчеләре нишләр, ди. Бу ноктада Каувесның фикерләре аны бик канәгатьләндерә. Көнбатыш мәмләкәтләрдә химаячелек баскычын узмаган милләт юк. Икътисадый яктан артта калган җәмгыятьләр өчен исә бу ысул аеруча зарури. Төркия әлегә бу юлга басмаса да, пошлина күләмен бер кадәр арттырып, безне сөендерде, ди.

Акъегет Әхмәт Мидхәттән дә тәвәккәлрәк чыгыш ясый һәм тагын да көчлерәк дәлилләр китерә. Химаячелекне очраклы рәвештә генә якламый. Карашының гыйльми сәбәпләрен күрсәтә. Аңа каршы Җәвит һәм Хөсәен Җаһит гыйльми дәлилләр белән каршы чыкмый, Акъегет аңлатканны белмәмешкә генә салышалар. Укытучылыктан алынгач һәм гәзите ябылгач, Акъегет тынып кала һәм Госманлы императорлыгы бурычлары, аның ачык базар системасы белән берлектә упкынга егыла. Төркия Җөмһүрияте бары 1930 елда гына икътисадый хәяткә яңа тәртип кертер өчен эш башлап җибәрә, химаячелек һәм чикләү (монополия кертү) гамәлләренә керешә. Без бүген дә шул ук юлдан атлыйбыз. Менә ни өчен бу юлга беренче булып аяк баскан каһарманыбыз Акъегетнең юлбашчылыгын хөрмәт белән искә алу бүген бик урынлы булыр.

**Хилми ЗЫЯ ӨЛКӘН.**

Китап күзәтү

# ТАТАР ТАРИХЫ БУЕНЧА ЯҢА ДӘРЕСЛЕК

Егерменче гасырга кергәч татар халкының тарихы буенча күп кенә хезмәтләр дөнья күрде. Аларның бер өлешен милләтнең үз вәкилләре, аның мәнфәгатен яклаган галимнәр язды. Икенче бер өлеше исә урысның гуманистик позициядә, колониаль-империячелек карашларыннан өстен торган галимнәре тарафыннан һәм өченче өлеше инде коньюнктур заказларга ялланып эшли торган кәсепчеләр тарафыннан иҗат ителде.

Татарның этник тарихы өлкәсендә эшләүче галим нинди булырга тиеш соң? Әлбәттә, ул беренче чиратта шушы тема буенча специальләшкән, язма чыганакларны яхшы белүче, аларга тәнкыйди караш методикасын үзләштергән, коньюнктур бурычлардан арынып, татарның тарихи фаҗигаларын аңлап эш итүче, белгечлеге буенча тарихчы булырга тиеш.

Бездә Газиз Гобәйдуллин, Евгений Чернышев, Михаил Худяков, Морад Рәмзи, Һади Атласов, Мөхәммәт Сәфәргалиев кебек әзерлекле тарихчылар булган. Аларның хезмәтләре әле бүген дә искермәгән. Бу очракта чит илдә яшәгән татар тарихчыларын искә алып булмый, чөнки аларның хезмәтләре татар өчен түгел, фән өчен, аеруча чит илләрдәге фәнни даирәгә генә хезмәт иттеләр. Нигъмәт Курат, Зәки Вәлиди, Габделбари Батталларның хезмәтләренең тәэсире 1917 елдан соң 1990 елларга кадәр татар өчен нульгә бәрабәр иде. Алардан бары Г. Баттал язган тарих турында гына сүгеп язып килделәр.

Соңгы елларда бездә күпләр «тарих» яза башлады. Әмма аларның күбесе татарның этник һәм сәяси тарихы буенча берәр хезмәт күрсәткән адәмнәр түгел, төп белемнәре буенча бу темадан бик ерак торган кешеләр. Әйтергә кирәк, аларның җиңел генә язылган хезмәтләре татар халкына бик зур әхлакый зыян китерде: милләткә вәсвәсә салынды, аны үз этник атамасыннан, тарихыннан баш тартырга чакыручылар пәйда булды. Шөкер, татар арасында аек акыллы кешеләр табылды, провокаторларга тиешле җавап бирелде. Кызганыч ки, әле татарны болгар «ясарга» йөргән диваналар бу хәлдә сабак алып, үзләренә нәтиҗә ясамадылар, һаман үзләренең коткы эшләрен дәвам итәләр. Ф. Нуретдинов кебек, фәндә беркем булмаган кешеләр тузга язмаган «Родиноведение» исемле дәреслек китапларын язып, аны иллешәр меңлек тираж белән бастыралар. Бу китаптагы фикерләр буенча яшь буынны тәрбияли башласаң, киләчәктә бездән бөтен дөньяның укымышлы халкы бот чабып көләчәк.

Мондый көлкемәләр туа торганда, ярый әле, дөрес тарихыбыз язылган китаплар да дөньяга чыгып куйгалый! Менә шундый хезмәтләрдән тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдиновның 1995 елда «Мәгариф» нәшриятында «История татарского народа и Татарстана» исемле хезмәтенең беренче кисәге дөнья күрде. Равил Фәхретдинов — бөтен гомерен Идел буе төрки тарихын өйрәнүгә багышлаган галим. Ул, башкалар кебек, картайганчы угро-фин тарихына хезмәт итеп, соңыннан гына төрки, үзебезнең тарихка күчмәде. Без аны Болгар дәүләте археологиясенә һәм тарихына караган хезмәтләре аша хәзерлекле археолог һәм тарихчы буларак беләбез. Әлбәттә, ул галим булып формалашкан дәвердә, эскәнҗәдәй куелган кысалар, аңа тулы колач белән эшләргә мөмкинлек бирмәделәр. Шуңа да карамастан, аның торгынлык дәверендә язылып басылган тарихи хезмәтләре дә татарның олы тарихының бер кисәге буларак, әле дә кыйммәтләрен югалтмадылар.

Тоталитар система идеологиясе җимерелгәч, иҗади эшләргә чикләүләр юкка чыкты. Шушы мөмкинлек нигезендә, кыска гына вакыт эчендә

галимнең югарыда исеме аталган дәреслек китабы дөнья күрде.

Бу хезмәттә татар халкының этник тарихын «турыдан-туры болгарлардан гына» башлау, башка этник төркемнәрне субстрат дип карау, тенденциоз концепциядән чыгып хәл итү юк инде. Югыйсә, моңа кадәр язган совет тарихчылары татар халкын бүлгәләп, «Казан татарлары» дигән термин уйлап чыгарып, аларны болгарларның турыдан-туры дәвамчылары дигән фикер белән эш итә башлаганнар иде. Әйе, болгарларның бер өлеше, шөбһәсез, татарга кушылып киткән. Ләкин алар субстрат компонент булып катнашканнар. Шулай ук аларның чуаш, чирмеш, ар, урыс халыкларына субстрат буларак кушылу факты да тарих өчен сер түгел.

Инде китапка күзәтүне беренче бүлектән үк башлыйк.

Беренче бүлектә хәзерге Идел-Урал буйлары, шул исәптән Татарстан җирләренең моннан 80—100 мең еллар элек үк кеше тарафыннан үзләштерелгән булганлыгы тасвирлана. Тарихның бу дәвере «таш гасыры» дип атала. Безнең эрага кадәр 3—2 мең еллар әүвәл бронза гасыры дәвере башлана. Безнең эрага кадәр VIII—III гасырлар Урта Идел буенда тимер куллану дәвере дип санала.

Китапның икенче бүлеге бүгенге Евразиядәге иң борынгы төркиләр һәм төрек кабиләләргә багышлана.

Дәреслекнең авторы Урта Иделдә иң борынгы төркиләр итеп һуннарны саный. Аның бу фикере тарихи археологик материал белән ныгытыла. Һуннарга бәйле булган иң әһәмиятле археологик истәлек Татарстанның Аксубай төбәге Сүлчә елгасы буендагы «Кыз тавы»нда табылды. Бу табылдык ике ритуал җиз казаннан гыйбарәт иде. Казаннарның табылу тарихы да рецензия авторына бик ачык мәгълүм. Монда кайбер Казан археологларыныкы кебек фактларны бозу яки бозып аңлату кебек тенденциозлык юк. Һуннарның ритуал казаннары Татарстанның Ык буенда һәм күрше Сембер өлкәсендә дә табылуы мәгълүм. Шулай ук Менделеев шәһәреннән ерак булмаган Турай каберлеге дә һуннардан калган истәлек дип фараз ителә. Равил Фәхретдиновның Татарстандагы җирләрдә һуннар яшәве хакындагы фикере гидронимия чыганаклары белән дә раслана. Сон, Сөн гидронимнары һуннар этнонимы булып тора. Филология фәннәре докторы Ф. Гарипова Урта Идел гидронимиясенә багышланган хезмәтендә һуннар теле белән бәйле булган күп атамалар китерә[1].

Яңа дәреслеккә татар этник тарихына бәйләнешле һун дәверен кертү кирәк һәм мөһим. Һуннарның татар тарихыннан аерылмаганлыгы тарихчылардан Газиз Гобәйдуллин, Зәки Вәлиди, Габделбари Баттал һәм археолог Альфред Халиков, тел галиме Мирфатих Зәкиев хезмәтләрендә дә күрсәтелә. Югыйсә, һун темасы тарихчы Хәйри Гыймади хезмәтләрендә телгә дә алынмады. Һуннарның төркилегән, аларның тарихын яңа чыганаклар белән искә алып эш итү бик мөһим. Ләкин тарих Көнчыгыш Европада һуннарга кадәр үк төрки телле скифлар булу турындагы хезмәтләрне дә белә. Әмма биредә аларның Урта Идел буенда булуларына киңрәк тукталу өчен тарихчы һәм археолог Равил Фәхретдиновка үтә сак фикер йөртү юл бирмәгәндер.

Татарстанда дистә еллар буена археологларның барлык көчләре диярлек нигездә Болгар һәм Биләр шәһәрлекләрен казуга тотылды. Башка археологик истәлекләр нигездә разведка ясау өчен генә өйрәнелделәр. Һуннардан соң Идел-Урал буйларында тарих сәхнәсенә менгән төркиләр, аварлар, болгарлар, хазарлар турында мәгълүматлар китапка нигезләп кертелгәннәр. Автор аларга кагылышлы сәхифәләрне Византия, Сирия, Әрмән чыганакларына нигезләнеп яза. Шулай ук бу бүлектә төркиләр, каңлылар, кыпчаклар хакындагы кыскача тарихи информацияләрнең татар этник тарихына кагылышы булуында шөбһә юк.

Китап-дәреслекнең өченче бүлеге татар халкы бабалары тарафыннан төзелгән беренче дәүләтләр тарихына багышлана. Әлбәттә, беренче урында Төрек каганаты тора. Каганатны төзүчеләр арасында борынгы төрки телле татарлар да була. Равил Фәхретдинов Төрек каганлыгын төрки-татарлар төзегән беренче дәүләт дип саный. Аның бу фикере чыганаклар белән яраша һәм башка галимнәрнең хезмәтләренә каршы чыгып язылган очраклы фикер түгел.

Төрек каганатының варисы булып күтәрелгән Кыймак каганлыгының татар кабиләләре белән бәйләнгән булуын хезмәт авторы нигезле, ышанычлы чыганаклар белән дәлилли. Хазар каганлыгы, Азов диңгезе буенда Бөек Болгар дәүләтләре тарихларына багышланган сәхифәләр дә ышанычлы чыганакларга таянып, тәфсилләп язылганнар.

---

[1] Гарипова Ф. Г. Исследования по гидронимии Татарстана. М., 1991, 126—129 бб.

Дәреслекнең дүртенче бүлеге Идел буендагы Болгар әмирлеге тарихына багышланган. Бай археологик материал һәм язма чыганакларга таянып, галим тарафыннан дәүләтнең сәяси тарихына, диненә, хуҗалыгы, биләгән мәйданы, шәһәрләре һ. б. турында тәфсилле мәгълүмат бирелә. Ләкин бу бүлектә мөһим һәм принципиаль бер факт бар. Аңа бер-ике сүз белән тукталып үтү мөһим булыр. Равил Фәхретдинов Идел буендагы Болгар дәүләтен беренче оештыра башлаучы кеше «Алмас» исеме дип саный. Гарәп дипломаты Ибн Фадлан язмасында бу исем Алмыш дип бирелгән. «Алмас» дип борынгы шәхеснең исемен әйтү, филологик хатага китерә. Алмыш исеме үзе генә дә тарихи чыганак, аның угыз кабиләсеннән чыккан икәнлеген күрсәтүче, яки билдерүче факт булып хезмәт итә. Шулай ук 61 биттә китерелгән карта төгәл хронологик дәверен күрсәтүне сорап тора. Гомумән, Болгар дәүләтенә багышланган бүлек төзек кенә язылган.

Бишенче бүлек Алтын Урда тарихына багышлана. Бу тема турында озак еллар буе татар галимнәренә сүз әйтү тыелган иде. Татар тарихчыларыннан М. Сәфәргалиев, С. Закиров, М. Госмановлар нindидер ысуллар һәм тәвәккәллек белән Урданың тарихына багышланган гыйльми әсәрләр язып чыгара алдылар. Тоталитар империя шартларында андый теманы күтәреп чыгу зур батырлык сорый иде. Равил Фәхретдинов дәреслегендә Алтын Урда дәверенә зур урын бирелгән.

Бездә әлегә хәтле татарларны монголлардан килеп чыккан халык дип ышанучыларны, урысны гына түгел, бәлки, татарның үз арасыннан да табып була. Автор төпле тарихи чыганакларга таянып татар кабиләләренең төркиләр икәнлеген раслый. Кытай тарихчылары татар кабиләләрен күнбатыш төркиләре дип санаганнар. Тарихчы Ф. Рәшидетдин (1247—1318) дә татарларның төркилеген инкарь итми. Татарларның Европага килеп чыгуларын басып алу максатыннан дип санаган күп тарихчылар бар. Ләкин бит татарлар үзләренең бабалары төзегән һун һәм төрки каганатлар җирләрен генә берләштерәләр. Сугышларсыз гына кайсы халыкның берләшкәнен күрсәтергә мөмкин? Урысларны канга батырып Иван Грозный берләштерде, немецләрне Бисмарк, гарәпләрне Мөхәммәд пәйгамбәр, итальяннарны Джузеппа Гарибальди (һ. б.) берләштерде. Татарлар Җүҗи олысын төзеп, ягъни Алтын Урданы, куәтле төрки дәүләт барлыкка китерделәр. Тәре йөртүче католик рыцарьлары тарафыннан яулап алыну алдында калган, бер-берсе белән дошманлык утында янган урыс князьлекләрен, нигездә, татарлар коткарып калды. Алтын Урда белән урыс князьлекләре арасында хәрби-сәяси берлек барлыкка килгән.

Китапка Алтын Урдада күпсанлы шәһәрләр булу (150 чамасы) һәм чит илләр белән киң сәүдә баруы бәян ителә. Алтын Урданың гаскәр төзелеше турында, матди мәдәнияте казанышлары, сәнгате, әдәбияты турындагы бүлекчәләр Алтын Урда татарларының зур мәдәни казанышларга ия булуларын раслыйлар.

Китапның бер бүлекчәсе Болгар олысының Алтын Урда канаты астындагы хәленә багышлана. Дәреслек авторы: 1361 елда Булат Тимер бик Болгар олысын аерып алырга маташты дип яза (149 б.). Хәлбуки Булат Тимер Болгарга олыс бигe буларак куелып, 1361—1366 елларда идарә итә. Ул 1361 елда бөтен Идел буен үз кулына ала һәм ушкуйникларның юлбасарлыгына чик куя. Тарихта Булат Тимер Нурган әмир улының мәрхүм Җанибәк хан исеменнән 1366 елда Болгарда һәм шул елларда Гөлстан шәһәрендә акча суктырганлыгы языла[1]. Булат Тимернең атасы — Нурган Әмир. Алтын Урдадагы дүрт бикләр бигенең берсе була, ул хан була алмаган[2]. Димәк, аның улының да хан булырга хокукы булмаган. Шунлыктан Болгарда ул үзенең бикләр биге (олыс биге) вазифасын башкарган. Урыс елъязмаларында аны бәйсез идарәче дип атамыйлар. Шунлыктан аны совет тарихчылары тарафыннан уйлап чыгарылган Болгар олысын аерып алырга йөрүе турындагы легенданың нигезе юк. Булат Тимер Нуган улы — ханнар кардәше булган. Ихтимал, ул Үзбәк ханның кызы Сөенбикә белән Нугудай (Нуган?) никахыннан туган булса кирәк.

Алтын Урдада XIV гасырның икенче яртысында «берәр олысны аерып чыгарып, аерым дәүләт төзергә омтылу» турындагы тезис тәнкыйтькә мохтаҗ. Олысларда утырган угланнар, мирзалар үз урыннарын Сарайда властька килү өчен булган трамплин итеп кенә карыйлар. Аның соңгы мисалы

[1] Сафаргалиев М. Г. Распад Золотой Орды. — Саранск, 1960. — Б. Б. 119; Мухамадиев А. Г. Булгаро-татарская монетная система XII—XV вв. — М.: «Наука», 1983. — Б. 151.
[2] Сафаргалиев М. Г. Распад... — Б. 119.

Кырым ханлыгы тарихында күренә. Кырым ханнары бөтен тарих буенча Сарай мирасына дәгъва белән яшәгәннәр һәм шундый сәясәт уздырганнар.

Равил Фәхретдинов Алтын Урдага Аксак Тимер һөҗүме хакында да беркадәр тукталып үтә. Автор әлеге җиһангирның Болгар олысының Көньяк читләренә кадәр генә кергән дип фараз итсә дә, монда мәсьәлә хәл ителеп бетмәгән. Җиңүчеләрнең Болгар, Биләр кебек мәгълүм шәһәрләрне тынычлыкта калдырып китүләре икеле. XVII—XVIII гасыр татар әдәби-публицистик әсәрләре Аксак Тимернең Болгар, Биләр шәһәрләрен алып җимерүе хакында сөйлиләр.

Алтын Урда мәдәнияте белән бәйле Иске Казан шәһәрлеген өйрәнү нәтиҗәләре күрсәтелгән бүлекчәгә дә кирәкле һәм бай сәхифәләр теркәлгән. Бүгенге Болгар шәһәрендә сакланып калган архитектура истәлекләренең барсы да Алтын Урда татар архитектурасына (XIV гасыр) нисбәтле булуы да дәреслекләрдә ачык әйтелә (153 б.)

Хезмәтнең алтынчы бүлеге Казан ханлыгына багышлана. Авторның Казан ханлыгы тарихына бәйле булган чыганакларга, аерым алганда урыс әдәбияты ядкаре «Казанская история» (яки «Сказание о царстве Казанском») китабына тәнкыйди фикерләре әһәмиятле һәм башкалар өчен дә гыйбрәтле. Бүлектә Казан ханлыгының төп халкы татарлар икәнлеге раслана. Аның составында болгар дигән халык юк (180 б.).

Равил Фәхретдинов үзенең хезмәтендә Казан ханлыгының хуҗалыгына, иҗтимагый төзелешенә, һөнәрчелегенә, шәһәрләр төзелешенә, сәнгатенә, дәүләт төзелешенә, хәрби хәленә, сәяси һәм яулап алыну тарихына багышланган бай мәгълүматлар китерә.

Башка татар ханлыклары тарихына, аларның сәнгатенә багышланган бүлекчә дә бик мөһим һәм кирәкле сәхифәләрнең берседер.

Бу дәреслек шактый бай тарихи иллюстрацияләр белән бизәлгән. Аларның абсолют күпчелеге бер рәссамның да фантазиясе түгел, ә оригинальдән алынган фотодокументлар. Алар арасында татарның дәүләт билгеләре булган таҗлар, кораллар, ювелир әйберләре, савыт-саба, ташка, металлга, кәгазьгә руник һәм гарәп графикасында язылган ядкарьләр, архитектура һәйкәлләре һ. б. сурәтләр бар. Шулай ук археологик истәлекләрнең автор төзегән карталары хезмәтне баеталар. Рәсемнәрнең төсле үрнәкләре дә булу, дәреслекнең кызыклылыгын, тәэсир көчен арттыра. Хезмәттә автор хикәяләвенә кушымта итеп еш кына тарихи документлардан өзекләр китерелүе дә урынлы. Кушымта рәвешендә бирелгән кыскача хронологик җәдвәл үзләренең кирәклеге ягыннан бәхәс уятмыйлар. Гомумән, китап тарих дәреслекләре язу тәҗрибәсенең бай традициясеннән файдаланып эшләнгән.

Әлбәттә, дәреслектә кайбер төгәлсезлекләр дә күренгәли. Мәсәлән, «Нәсыйхәт әс-салихин» әсәрен болгар әдәбияты истәлеге итеп күрсәтү. Ләкин алар бу зур хезмәттә бик кечкенә урын билиләр. Киләсе басмаларда төзәтелер дип ышанасы килә.

Равил Фәхретдиновның хезмәте татар халкының тарихын белеп, аның бер бөтен халык һәм татар икәнлеген тоеп язылган. Югыйсә, бездә укымышлы кешеләр арасында да татарлыкларына иманнары какшап, төрлечә шуны тудырып сафсата сатучылар күренә башлады. Бу хезмәтнең чыгуы — татарның үз тарихына йөз белән борыла башлавы билгесе.

Киләчәктә «История татарского народа и Татарстана» китабының тагын да камилләштерелгән басмалары чыгар һәм алар тоталитар система идеологиясе изүе астында бердәмлеге җимерелгән халыкның үз-үзенә ышанычын арттыруга, ата-бабаларына хөрмәт белән карарга өйрәтүдә хезмәт итәр.

Бу хезмәт Татарстан һәм татар мәктәпләре өчен әлегә камил булган иң яхшы һәм бердәнбер дәреслек булып саналырга лаек.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# САТИРА БАТЫРЫ

Хәзерге татар язучысы ирекле-ме, түгелме?

Әйе, бер караганда ул, чыннан да, ирекле шикелле. Тулаем Рәсәйдәге сыман хәзер бездә дә үзең ни теләсәң шуны язарга мөмкин кебек. Бастыру өчен дә матбугат шактый иркенәйде, газета-журналларның саны артты.

Ләкин болар — беренче карашка күзгә ташлана торган тышкы факторлар. Ә соң эчкәрәк кереп, ныклабрак уйлаганда эшләр ничегрәк тора?

Иң башта «үзең теләгәнне язу» дигәнгә тукталыйк әле. Безнең бүгенге татар язучысының теләк-омтылышлары нинди соң? Ә гомумән, дүрт гасыр буена коллыкта һәм изелүдә яшәгән зат нинди була алсын соң инде ул?! Аның бүгенге рухи халәте дә ата-бабаларыныкыннан әлләни нык аерылмый әле. Бүген дә «курку» дигән хис гаять күп кешеләр өчен хәлиткеч дәрәҗәдә мөһим булып кала бирә. Әнә шул хис идарә иткәнгә күрә тормыш-көнкүрешләре дә тар кысада һәм колларча бара, уйлары һәм хис-кичерешләре дә әнә шул тар мөхиттән ерак китә алмый. Көнен һәм төнен баш булган курку хисе уйларын да тышаулый, тезгенли, билгеле... Шулай булгач, хәзерге «үзең теләгәнне язу» дигән нәрсә дә озак еллар буе зоопаркта яшәгән филнең ирекка чыккач та бер урында гына таптанып торуына тиң.

Инде хәзер «матбугатның иркенәюе» дигәнне аңларга тырышыйк. Әйе, Аллага шөкер, соңгы елларда басмалар саны шактый артты. Ләкин шуның артыннан ук биредә дә ике зур «дошман» пәйда булды. Бердән, басмалар бөтенләй диярлек каләм хакын түләми башлады — иҗатчы өчен матди кызыксыну бетте. Ә икенчедән, безнең бөтен басмалар да диярлек хөкүмәт акчасына яшәгәнлектән, үзеннән-үзе диярлек югарыда утырган чиновникларга бәйлелек килеп туа.

Менә боларның барысын да күздән кичерсәң, хәзерге татар язучысына иҗат ирегенең һәм басылу мөмкинлегенең бик тә аз калуын күрербез. Һәммәсен бергә кушып уйласаң, совет чорыннан әлләни алга китеш тә юктыр әле, бәлки?!

Әнә шуна күрә бүген безнең иҗат кешеләре арасында чын-чыннан ирекле булган, шуның белән иҗатта зур үзенчәлеккә ирешә алган әдипләребез күп түгел. Сирәк, бик сирәк алар!

Фәнзаман Баттал — әнә шул сирәкләр арасында да күзгә бәрелеп, үз иҗатына игътибарны әллә каян үк тартып торган иҗатчы.

Элегрәк аны шигырьләр язган, диләр... Үзгәртеп кору башлангач матбугатта аның ялкынлы-ялкынлы мәкаләләре дә байтак кына булып алды. Һәр очракта аның белән килешмәсәк тә, ул язмалар тиз онытылмый иделәр. Күпләрдә ризасызлык, каршы хисләр тудыра иде кайберләре. Минемчә, алар Фәнзаман Батталның үзе өчен дә иҗаттагы төп юнәлеш түгел иде, шикелле.

Бу иҗатчының иң төп юнәлеше — юмор һәм сатира. Әле аның да «сатира» дигәне әйбәтрәк бирелә авторга. Моңа кадәр басыла килгән язмаларын һәм китапларын янәшә куеп, чагыштыра-чагыштыра уйланганда, ирексездән, әнә шундый уйга килеп чыгасың.

Берничә ел элек Фәнзаман Батталның «Сакалыңа ут капса» исемле сатира-юмор җыентыгы басылып чыкты һәм бик тиз арада кибет киштәләрендә күренми дә башлады. Әлеге китап хакында матбугатта да, шулай ук аның каләмдәшләре арасында да тик җылы сүзләр генә ишетергә туры килде.

Инде менә 1995 елда бу авторның «Бака да бата» дигән кыска хикәяләр китабы дөнья күрде. Шуңа күрә бу уңайдан безгә сатирик иҗаты турында җентекләбрәк сөйләшергә, уйлашырга җай бар.

«Бака да бата» (исеме генә ни тора!) китабын кулга алып, аның эчендәге сатирик һәм юмористик хикәяләрне (әле аларны автор шулай ук бик үзенчә итеп «хи-хикәяләр» дип атаган) укый башлагач, Фәнзаман Батталның дөньясын, бу мөхитнең үзенә генә хас хикмәтләрен тагын да күбрәк күрәсең. Китапны ачып җибәргән беренче ике әсәр болай дип аталган: «Азгын ирне ничек үтерергә?» һәм «Иптәш Сталин булсамы?» Җыентыкны кулына алган кеше мондый исемле әсәрләрне күргәч, ничек инде укымыйча калсын, ди? Хәзер, безнең чорда, телевидение белән китап арасында гаять зур көрәш, тартыш бара. Телевидение бүгенге кешегә сәгать саен кызыклыдан-кызыклырак тапшырулар тәкъдим итеп тора. Ул кешене хәзер тулаем яулап алып килә. Безнең замандашның телевизор карамый торган вакыты бик аз. Хәзер әнә шундый бик аз вакыт эчендә дә үзен укыта алырдай әсәрләр кирәк. Ә кызыклы булу исә әсәрләрнең исемнәреннән үк башлана.

Беренче хикәянең тәүге юлларында ук автор аз да түгел, күп тә түгел, менә болай дип белдерә: «Бик дөрес әйтәләр — азгын ирне, һичшиксез, үтерергә кирәк! Хатынына бер генә мәртәбә хыянәт иткән булса да, аның дөньяда яшәргә хакы юк». Әнә шулай кителмәгән, без һич уйламаган киңәш-тәкъдимнәрне тезә генә сатирик: азгын ирне тиз генә үлеп котылмаслык итеп, акрын-акрын үтерергә кирәк! «Монысы нәрсә икән тагын?» дип аптырап каласың да, әсәрдән җавабын да табасың: тәмле ашата-ашата, өс-баш киемнәрен юа-юа, чиста итеп карап йөретә-йөретә — ир-атны әнә шулай итеп озак яшәтә-яшәтә «газаплау» ята икән бу хәйләнең төбендә! Фәнзаман Баттал хәзерге хатыннарга шундый киңәш бирә. Һәм сатирик буларак ул күп яктан ота, үз дигәненә ирешә.

Аннан соңгы хикәядә язучының иҗади үзенчәлеге аеруча калку булып чагыла. Ул әсәрнең иң беренче җөмләсе менә нинди: «Каяле, энем, тагын бер төреп җибәрик әле синекен!» Шулай дип сүз башлаган абзый үзенең әңгәмәдәшенә иптәш Сталин белән әшнә булуы турында бик тә мавыктыргыч итеп «борчак сибә». Имештер аны Мәскәү заводында кәчигәр булып эшләгәндә Сталин үзе чакырып алып, йомыш кушкан!

Ярый, эчтәлеге калып торсын, без биредә Фәнзаман Батталның сатирик буларак үзенчәлеген табарга тырышыйк. Аның иҗади үзенчәлекләре нәрсәдә аеруча ачык күренә соң?

Авторның сатира угы түбәнгә таба гына түгел, югарыга таба да шундый ук кыюлык белән һәм шундый ук осталыкта оча. СССР һәм КПСС та, Сталин һәм Хрущев та, Ельцин һәм башкалар да эләгәләр сатирикның «агулы» теленә. Бүген байтак әдипләр һаман алны-артны карап кына язганда (коммунистлар хакимияткә кайтса дигән куркудан) һәм баш саклауны иҗатта да төп кагыйдә итеп алганда, Ф. Батталның мондый иҗади кыюлыгы зур хуплауга лаек.

Алай гына да түгел: бүгенге заман тудырган бушбугазлык та китапта матур чагылыш таба. «Алланың кашка тәкәсе» дигән хикәядәге Иргали, мәсәлән, дөньяның иң зур кешеләрен сүгә, аларны хурлап газеталарга хатлар яза, алар басылып чыккач Иргали «батыр, курыкмый» дигән дан ала. Тик менә үзенең директоры янында ул — иң мескен кеше икән. «Директор турында яз, имеш... Син нәрсә?! Әллә башыма тай типкән дип белдеңме?»

Әнә шулай итеп, безнең чор тудырган күп персонажлар килеп керә сатирикның китабына. Хөкүмәт кулындагы оешма һәм предприятиеләрдә тир түгүче адәм балалары тамак хакына бүген нинди генә түбәнлекләргә бармый да, иҗатчыларга юмор һәм сатираның мөмкинлекләрен ничек кенә арттырмыйлар! Курыкмыйча язучы һәм күнеле тар булмаган мөхәррир генә табылмасын!

Фәнзаман Баттал язган вакытта укучыга тәэсир итүнең бик күп төрле ысулларыннан актив файдалана. Сүз сөрешендәге һич тә уйланмаган, кителмәгән борылышлар дисеңме, өр-яңа гыйбарәләр һәм сүзтезмәләр дисеңме — болар барысы да әсәрләрдә бик оста кулланыла. Шул ук «Иптәш Сталин булсамы?» дигән хикәяне генә алсак та, «сакаллы бәрәңге», «тел белән торна мамыгы җәю», «сыер дагалау», «тилегә думбыра каккандай» һәм башка үткен гыйбарәләр тулып ята! «Миңдәлә базарыннан алган кирза итегемне салидул белән майлап» дигән бер тезмә үзе генә дә ни тора!

Ә Сталинны менә ничек итеп сөйләтә оста сатирик: «Сезнең хакта заводской гәҗиттән укып беләм мин, иптәш Сәмигуллин. Партритыгызга да озак карап утырдым». «Ал, ал, — ди бу миңа төребкәсен. Шикләнмә, мин чирле түгел, бырачлар карап кына торалар». «Аптыраш инде, малай, — ди. Үзе бик монсу итеп елмая, мәрхүм...»

Әйе, Фәнзаман Баттал иҗатта заманча эш итүе белән алдыра: ул кыска яза, әсәрнең сюжетын үтә дә динамик итеп төзи, җөмләләрдә укучыга нык тәэсир ясый алырдай, аның колагын торгызырдай һәм әнә шул юл белән уйландырырдай сүзләр-гыйбарәләр кулланыла. Аның әсәрләрен укыганда үзеңне кино экраны янында «безнең тормыш» дигән сатирик фильм карап утыргандай хис итәсең.

Арадан тагын бер хикәягә — «Никахлы мафия» дип исемләнгәненә — күз салыйк. «Көпә-көндез хатынны урладылар... Эштән кайтсам, юк теге. Ике-өч сәгать сыраханә ларегы төбендә чират торып кайтсам, тагы юк. Йокларга яттым — һаман юк...»

Әсәр әнә шулай алып кереп китә үзенә. Менә бу беренче юллар үзләре үк инде оста сатирикның уй-фикер буразнасына төшерә дә куя: «урладылар» дигән сүзнең мәгънәсе белән «сыра ларегы янында чират тору», «йокларга яту»ларның мәгънәсе кара-каршы килеп, маңгайга-маңгай бәрелешә дә, уйда ирексездән ачы итеп көлүнең беренче дулкыннарын кузгата... Сарказм бе-

лән көлүнең куәтле дулкыннарын тудыра!

Аннан ары килгән күренешләр исә беренче туган әлеге дулкыннарны яңадан-яна биеклеккә күтәрә бара: төнен бик тә тыныч (!) йоклаган бу абзагыз янына иртән рэкетчы килеп, урланган хатынны кире кайтару шарты белән, аның өчен ирдән акча сорый. Шул вакытта инде бу абзагыз уйлый — «Яле, исәпләп карыйк: ничә сум тора икән минем хатын?.. Тәк-тәк... Йөзеге 500 сум, алкасы 200... Ну, күлмәге-мазары 300 сумдыр тагын, туктале, 1000 сумга гына җыела түгелме соң? Ә бу дивана (ягъни рэкетчы) биш мең сорап тора». Әнә шуларны җәһәт кенә уйлап өлгергән абзагыз рэкетчыга да болай ярып сала:

«— Махмырга биш тәңкә бирсәң, тагын биш хатын табып җибәрәм үзеңә!»

Көтелмәгән, беркем дә уйламаган җавап бит, ә!

Гомумән, сатирик автор мондый көтелмәгән ысуллары белән рэкетчыларны гына түгел, әсәр укучыларының да башларын әйләндерә яза. Ул оста күз буучы шикелле, тыгыз мәгънәле күренеш-эпизодларны күз алдында бик тә җитез рәвештә уйнатып кына тора. Рэкетчылар бу абзагызның явыз хатыныннан ничек котылырга белми азапланганда (чөнки хатын кулына автомат, авызына пычак кабып, туфля очы белән шартлаткыч кнопкасына басарга җыенып аларның котларын ала!) абзагыз килә дә мондый сүзләр генә әйтә:

«— Давай, юләр сатма монда! Тамак ачты, кайтып ашарга пешер! — Хатыным җебеде дә төште. Авызындагы кинжалын төкереп ташлагач елыйелый:

— Автоматымны кулдан ычкындырмыйм, Мысыргали,— ди».

Сатирик хикәянең бер персонажы авызыннан әйтелгән менә шушы сүзләр үзләрендәге психологик ачкыч белән, ярсыган хатын-кызны тиз генә җебетеп алырдай көчкә ия булулары белән әсәрне язган автор файдасына безнең күңелдә зур-зур «очколар» яздыра. Тулаем әсәр өчен дә «5»ле билгесе куймыйча булдыра алмыйбыз без аңа.

Әйе, Фәнзаман Баттал әсәргә бик кыю тотына һәм хикәяләүне ныклы кул белән, ахыргача оста итеп алып бара ала. Ә вакыт-вакыт шундый четерекле урыннар килеп чыга — автор өчен борчылып, икеләнеп-шикләнеп тә каласың. Мисал өчен «Изге эш» хикәясендә укучы күңелендә шундыйрак бер психологик шок булып ала:

«— Дөньяда иң изге нәрсә — басу! — диде Хәтмулла, кул аркасы белән баш түбәсен ышкый-ышкый...»

Ташка басылып чыккан китапта мондый сүзләрне укыган татар кешесенең хәлен чамалыйсыздыр. Аның уеннан ниләр генә узмый, бу әсәр авторына карата нинди генә сүзләр әйтелəм-әйтеләм дип тормый шул мизгелдә тел очында... Әмма Ф. Баттал психологик трюклар ясый-ясый, тәки судан коры килеш килеп чыга ала бит! Чөнки ул әлеге четерекле теманы менә болай итеп төгәлли белә: «— Әйтик, игеннәр үсә торган басуны үзеңнең дә күргәнең бар. Ипекәй бит ул, юл-ләр, ипекәй!...»

Менә шушындый азакны укыгач — кем юләргә кала инде? Әлбәттә, без — автор турында әчтән генә әллә нинди «бозык» уйлар уйлап өлгергән кеше — җүләргә кала! Сатирикның зур сәләткә ия булуына менә дигән бер мисал бу психологик трюк. Шуңа охшашрак хәлне алда сүз барган хикәядә дә искә алган идек.

Әле алай гына да түгел: хикәя башында ук безнең башны әйләндереп алу һәм үзебезне үк көлкегә калдыру белән генә дә канәгатьләнми автор, ул хәйләкәр төлке сыман, эз чуалтып алга таба чаба һәм безне уйламаган-көтмәгән җирдән «ялган акча басу» дигән ачы, зәһәр көлү төбәгенә алып чыга. Хәзерге акчаның мескенлегеннән әчләрне тотарлык итеп көлдерә ул. Ленин башы урынына Хәлим Җәләл һәм Равил Шәрәфи, Батулла башларын куеп акча басучылар турында искиткеч мәзәк итеп сөйли. Акча басучылар өенә милиция дә килеп керә. Тик алар... азык талоны басучыларны эзли икән, акча басучыга исе дә китми хәзерге милициянең! Вәт заманнар! — диеп, көлә-көлә саубуллашасың сатирикның бу әсәре белән дә.

Әнә шулай итеп, китап бүгенге тормыш күренешләреннән рәхәтләндереп көлдерә. Хәер, бик үк рәхәтләнеп көлү түгелдер бу. Яшь аралаш көлүдер бу! Җаның сыкрый-сыкрый, бәгырең телгәләнә-телгәләнә, әрниәрни көлүдер бу... Чөнки бу китапка кергән бөтен хикәяләрне укыган чагында безнең күңел төбендә һаман бер уй, бер тойгы талпынып тора. «Их, нигә соң без шундый!» — дигән ачыну катыш борчылу тойгысы ул. Көлү дигәнебез дә кешедән түгел, ә еш кына үзебездән һәм үзебез ишеләрдән көлү булып чыга анда. «Тормышыбыз шулай булгач, нишлисең инде» — диярге туры килә, ахыр чиктә, тынычлану өчен...

Сүз барган китап турында тулы мәгълүмат булсын дисәк, шунысын да әйтми ярамас: биредә татарның хәзерге зыялылары хакында да кыска гына мәзәкләр кертелгән. Соңгы вакытта бездә бу жанр матур гына булып җанланып китте. Элегрәк Батулла шундый язмалар бастыра иде, Шамил Маннаповның газеталарда чыккан мәзәкләре милләтнең бүгенге тормышына матур-матур бизәк булып чигелеп бара. Бу китаптагы кыска хикәяләре белән Фәнзаман Баттал да әдәби-мәдәни мөхитнең үзенчәлекле елъязмасына үз өлешен кертергә булган.

Соңгы елларда әдәбиятның хәлләре бик тә кыенлашканы һәммәбезгә мәгълүм. Әмма, шуңа да карамастан, татар әдәбияты һаман үз укучыларын сөендерүен дәвам итә. Фәнзаман Батталның менә бу яңа җыентыгы да безне куандыра торган китаплар рәтендә. Безгә әнә шундый гадел язучылар, чын күренешләрне тәэсирле итеп ачып салган әсәрләр бик тә кирәк. Намуслы һәм тырыш татарның тормышында кычкыра-кычкыра көләрдәй хәлләр бихисап күп ул! Бүгенге сатира безгә көлә-көлә яшәвебезне әзме-күпме төзәтергә булыша. Фәнзаман Батталише сатира батырлары тагын берничә генә булса да табылсын иде!

**Мансур ВӘЛИ.**

# ИЛ ЙӨРӘГЕНДӘ ТАМЫРЛАНСЫН

Җир-ана йөрәге күпне саклый. Ата-бабаларыбызның: «Тел астында тел бар, җир астында юл бар»,— дигән мәкале дә шуңа бәйләнгәндер. Әйе, тел астында да тел бар. Һәм тел артында да тел бар. Хәтта Җир астындагы юлларда да... тел бар. Чөнки аларда — тарих сәхифәләре. Ә сәхифәләрдә исә — халык язмышы, гасырлардан-гасырларга энҗе бөртегедәй җыелып килгән күңел байлыгы, халыкның рухи дөньясын чагылдыручы аңы-акылы. Җир астындагы юллар да, тел артындагы телләр дә күмелеп каламы? Тарих тузаннары каплыймы аларны? Иске юлны — яңа юл, иске телне яңа тел алыштырамы?

Әйе, телне без яшь тал чыбыгыдай бөгәргә, корыган агач урынына сындырырга, имгәтеп ташларга тырышабыз. Ә ул тәкәббер, горур, гаярь. Ул безгә баш ими — үз кануннары белән яши бирә.

Болгарлар — безнең борынгы ата-бабаларыбыз. Аларның да ата-бабалары булган бит. Ул ата-бабаларның да ата-бабалары бар. Ничек сөйләште икән алар? Телнең күңел көзгесе, халык көзгесе, ил көзгесе булуын аңлаганнармы? Моны тарих сәхифәләренә язып калдырганнармы? Кайда алар? Их, укырга иде... Юк шул. Юк! Әдәби тел тарихын Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан башлыйбыз (XIII йөз). Ә аңа чаклы? Булмаганмы? Булган. Ләкин тарих тузаннары күмгән. Исәр җирләр, туздырыр ул тузаннарны. Шулай итеп, юл астындагы юллар, тел артындагы телләр ачылыр, бәлки. Галимнәр халкыбызга бик борынгы кавем-кагъбәләребезнең тел-ләгать гәүһәрен, яшәү рәвеше өлгесен, рухи дөнья серләрен бүләк итәр.

Бу җәһәттән бүген күп кенә фәнни хезмәтләрне күрсәтеп була. Әдәби телебез, гәрчә ерак тарихтан булмаса да, бөтенләй үк өйрәнелмәгән түгел. С. Күкләшев, К. Насыйри, Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, Л. Җәләй, М. Зәкиев, Х. Курбатов, Ф. Сафиуллина...— тагын да бик күп галимнәр әлеге чишмә башыннан киң һәм тирән диңгезгә йөзеп чыгарга тырышты һәм тырыша. Әмма бу өлкәдә армый-талмый, өзлексез, җиң сызганып, мәсьәләнең асылына чын мәгънәсендә төшенеп эшләүче тел галиме — филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры Вахит Хаков. Моңа чаклы аның күп кенә китаплары дөнья күрде. Менә аларның кайберләре генә: «Тел һәм стиль мәсьәләләре» (1961), «Татар әдәби теле тарихыннан очерклар» (1965), «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» (1977), «Татар язучыларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү» (1984), «Татар әдәби теленең совет чорында үсеше (20—30 нчы еллар)» (1985) һ. б. һ. б.

Вахит Хаковның «Татар әдәби теле тарихы» исемле соңгы хезмәте Казан дәүләт университеты нәшриятында 1993 елда дөнья күрде. Күләме 18 табак.

Бездә фонетика, лексика, морфология, синтаксис, диалектология, стилистика, тарихи грамматика буенча төрле дәрәҗәдә хезмәтләр язылды. Ә менә әдәби тел тарихи буенча студентлар өчен дәреслекнең шулай соң басылуында, минемчә, берничә сәбәп бар. Бердән, бу фән башкаларга караганда соңрак укытыла башлады. Аннан соң аның колачы бик киң — барлык тел тармакларын үз эченә ала. Башта ул кыскача гына «Тел тарихы» дип йөртелә иде. Аннан икегә бүленде: «Тарихи грамматика», «Әдәби тел тарихы». Аларны «игезәк» дип атарга да мөмкин. Берберсенә бик якын. Вакыт-вакыт үзара керешеп тә китәләр. Ләкин игезәкләр дә кайсы як беләндер аерыла ич. Болар да шулай. Тарихи лексика, тарихи фонетика, тарихи морфология, тарихи синтаксис бар. Болар «Тарихи грамматика» кысасына сыеп бетә. Әдәби тел тарихи стильләр системасыннан да гыйбарәт. Белинский әйткәнчә, стилистика — грамматиканың югары «баскычы». Димәк, стилистикага керешкәнче тел гыйлеменең барлык тармакларын фәнни нигездә эшкәртү мотлак. Бер кеше җилкәсенә ул шактый авыр йөк булып төшә. Безнең шартларда аны башкарып чыгу мөмкин дә түгел. Сәбәпсез җил дә исми, агач яфрагы да селкенми, дигәндәй, бу хезмәтнең шулай соң чыгу сәбәбе берникадәр аңлашылды булса кирәк.

Әдәби тел тарихы буенча шөгыльләнүчегә лексика, фонетика, морфология, диалектология, синтаксис, стилистика, тарихи грамматика фәннәрен камил белү генә дә җитми. Бу фән башка төрки телләр әдәби теленә дә чагыштырылып өйрәнелә. Алар исә — утызга якын. Шуларның һәммәсен белү лазым. Үз халкыңның һәм әнә шул төрки телле егермедән артык халык тарихын җитди белү дә шарт. Шунсыз бу фәнне укыту яки аның турында хезмәт язу юкәдән чикләвек эзләү кебек кенә булырга мөмкин.

Мәгълүм ки, унтугызынчы йөздә «Татар теле грамматика»сын күбрәк руслар язган. Ә алар рус телендәге бәрәр грамматик категория татар телендә табылмаса, аны «ярлы» дип исәпләгәннәр. Ләкин бит татар телендәге тартым категориясе рус телендә дә, инглиз телендә дә юк. Әмма без бер дә аларны «ярлы» тел димибез.

Төрки телләрнең байлыгын исбат итү белән унберенче йөз филологы Мәхмүт Кашгари шөгыльләнгән. Унтугызынчы йөздә исә бу изге эшкә Каюм Насыйри җиң сызганып керешә. Димәк, «татар әдәби теле тарихын» укытучыга кардәш телләрне, ерак кардәш телләрне генә түгел, ә бәлки кардәш булмаган телләрне дә белү кирәк. «Башка телне белмәгән кешенең үз теле турында төшенчәсе булмый»,— ди Гёте. «Күп телләр белү — бер йозакка күп ачкыч ярату дигән сүз» (Вольтер) һәм «Теге яки бу халыкның гореф-гадәтен белү өчен башта аның телен өйрәнү» (Пифагор) дигән сүзләр дә бар.

Профессор В. Х. Хаковның бу хезмәтен укып чыккач, әнә шулар һәм башкалар хакында да уйланырга туры килде. Авторның шундый югары таләпләрне нигез итеп алуы шатландырды.

Әдәби тел тарихы чорларга бүлеп өйрәнелә. Автор бу мәсьәләне дә игътибар үзәгенә ала. Моның өчен ул бүлек тәгаенләнә. Беренче бүлектә татар әдәби теле тарихының гыйльми нигезләре карала. Анда «әдәби тел тарихы» фәне турында төшенчә бирелеп, әдәби тел тарихы һәм җәмгыять тарихы арасында мөнәсәбәт, әдәби телнең язма һәм сөйләм төрләре, әдәби тел һәм стильләр, төрки телләрнең һәм татар әдәби теленең үсешен чорларга бүлеп өйрәнү мәсьәләләре тикшерелә. Икенче бүлек: «Идел буе төрки язма теле һәм иске татар әдәби теленең барлыкка килү һәм үсеш чоры» (X гасыр — XIII гасырның беренче яртысы). Бирелә борынгы һәм иске татар әдәби теленең барлыкка килүе өчен төп шартлар, татар әдәби теле һәм этногенез мәсьәләләре, борынгы язма әдәби телне һәм җанлы сөйләм үзенчәлекләрен чагылдыруда глоссарийларның роле, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы һәм аның тел үзенчәлекләре яктыртыла. Өченче бүлек: Алтын Урда хакимияте чорында татар әдәби теле» (XIII гасырның икенче яртысы — XV гасырның беренче чирегe).

Әдәби тел тарихын стильләр тарихыннан аерып карау — җирнең сыйфатын гумусны исәпкә алмый билгеләү кебек булыр иде. Чөнки стиль (өслүб) әдәби телнең теге яки бу чорда ни дәрәҗәдә торышын, үткәнен, киләчәген билгеләүгә ярдәм итә. Болгар чорында, мәсәлән, поэтик стиль өстенлек ала. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының сәнгатьчә эшләнешен, андагы тел-сурәтләү чараларын тикшерми торып, ул чактагы әдәби тел торышын билгели алмыйбыз. Вахит Хаков бу мәсьәләгә дә даими игътибар итә. Шуңа күрә икенче бүлектә «Кыйссаи Йосыф» әсәренең те-

лен тикшерү — табигый күренеш. Дөрес, аның теле турында төрле караш бар. Ул, имеш, борынгы госманлы төрекләр әсәре (Карл Броккельман); аның теле, имеш, борынгы сәлҗүк теленә якын (Баскаков) һ. б. Әлбәттә, аларны да инкарь итеп булмый. Әсәр катнаш телдә язылган. Шулай да, лингвистик анализ ясап карасаң, үзәктә бүгенге әдәби телебезнең тамырлары ятканлыкка ышанасың. Моны сүзлек хәзинәсе, авазлар төрлеге, грамматик чаралар, фигыль формалары, мәкальәйтемнәр, сурәтләү чаралары раслый. Алар: «Без борынгы орлыктан тамырланып шытып чыктык, киләчәк зур әдәби тел дөньясы өчен кәүсәләнеп, боталар җибәрербез, яфрак ярырбыз — афәтләрдән саклагыз безне»,— дип кычкырып тора кебек. Вахит әфәнде, чыннан да, ул әсәрдәге тел чаралары аша шул чор әдәби теленең торышын оста күрсәтә алган.

Казан ханлыгы чорында (XV гасырның утызынчы елларыннан — XVI гасыр уртасына кадәр) исә, матур әдәбият стиле үсү белән бергә, башка стильләр «канатлана» башлый. Шуны искә алып, автор дүртенче бүлектә бик хаклы рәвештә фәнни стиль, рәсми канцелярия һәм дипломатия теле турында мәгълүмат бирә. Чыннан да, шул чордагы фәнни стильчәрәк язылган төрле тарихи язмалар, юл язмалары — сәяхәтнамәләр, әдәби әсәрләр телендә фонетик, морфологик, лексик һ. б. яктан охшашлыклар зур. Автор раславынча, аларның бөтенесе «уптым илаһи» шул чор әдәби телен күз алдына китерүгә ярдәм итә.

Телне тудыручы, иҗат итүче, үстерүче, камилләштерүче — халык. Шуңа күрә әдәби телне икегә бүлеп карау гадәте дә бар: сөйләмә әдәби тел, язма әдәби тел. Язма әдәби тел барлыкка килгәнче сөйләмә әдәби телне халык үзе эшкәрткән. Ә инде язма әдәби тел, гәрчә үзәктә үз телебез гәүһәр-чылбырлары сузылса да, ул әле Казан ханлыгы чорында да, аннан соң да шактый «чуар» була. Шулай да әдәби тел нормалары, әлеге үзәк гәүһәр-чылбырга бәйләнә-бәйләнә, акрынлап ныгый бара. Бишенче бүлектә нәкъ менә шушы мәсьәлә карала да. Инде менә безгә өч стиль үзенчәлегенә тукталу вакыты җитте. Югары стиль (гарәп-фарсы сүзләре күплек), түбән стиль (гади сөйләм), урта стиль (катнашлык) Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый, Утыз Имән һ. б. сүз сәнгате осталарының әсәрләрендә «канат кагып» килде. Аңа карата — һәр шагыйрьнең үз карашы. Ә без телгә алган шагыйрьләр күбрәк югары стильгә табынды. Өч стильнең фәнни нигезләрен ачыклау исә Аристотельдән үк килә. Аннары Күкләшев шөгыльләнә. Ничек кенә булмасын, ул әдәби телнең үткәнен, теге яки бу чорда торышын билгеләүгә нык ярдәм итә. Ә инде милли әдәби тел чорына якынлашкан саен алар бер-берсенә керешә бара. Аннан урта стиль өстенлек ала. Шуңа күрә Вахит әфәнде бишенче бүлектә татар әдәби теле тарихына өч стиль системасын махсус тикшерүне кирәк тапкан.

Хезмәтнең алтынчы бүлегендә татар әдәби телендә фонетик нормалар үсешенә анализ ясала. Авазлар! Диңгез су тамчыларыннан барлыкка килгән кебек, тел диңгезе дә аваз-хәреф гәүһәрләреннән тора. Һәр гәүһәр — чал тарих көзгесе. Берсен генә алып карасаң да, бик борынгы ыруг, кавем-кагъвә, кабилә туганлыкларын, алар арасында булган тел аерымлыкларын һәм бүгенге әдәби телебездәге бу «гәүһәрләрне» аера белмәү каршылыкларын аңларга ярдәм итә.

Әйе, хәл ителмәгән мәсьәләләр бик күп. Төрлечә язабыз: егәрле-җегәрле, егет-җегет, аз-әз, акрын-әкрен, яткыр-яткыз, кидер-кигез һ. б. Кайсы дөрес? Моны ачыклау өчен һәр аваз-гәүһәрнең ерак үткәндәге тарихын белергә кирәк. Й-җ авазларын гына алыйк. М. Кашгари әйтүенчә, угызлар һәм кыпчаклар сүз башындагы «й»не «җ»гә әйләндерә. Й-ның җ-гә күчеше үзбәк теленең кыпчак сөйләшендә очрый. Шулай да ул барлык кыпчак телләре өчен характерлы түгел. Бу хакта күп галимнәрнең каршылыклы фикерләре бар. Чөнки аны ачыклау өчен борынгы Орхон-Енисей язмаларын да, башка төрки телләрнең авазлар системасын да белү таләп ителә. Профессор Хаков тикшерүне нәкъ шул юнәлештә алып бара да. Ә инде хәзерге вакытта җ-нең өстенлек ала баруы сөйләү телендә аеруча нык күзәтелә. Башкортстан татарлары да хәтта «җыл», «җегәрле», «җегет», «җылады» дип «Ярып сала». Бу аларда бик матур яңгырый. Колакны назлаган кебек. Әлбәттә, урыны-урыны белән «й»ләштерү дә көчле. «Тел артында тел бар» дигәнне «аваз артында аваз бар», «сүз артында сүз бар» дип тә әйтеп була. Алар ярыша. Мәйдандагы көрәшче ише генә түгелдер әле.

Шулай итеп, һәр аваз — хәрефтә, һәр сүздә, һәр грамматик чарада (кушымчаларда) телебезнең зур тарихы чагыла. Аның шулай икәнлеген җиденче («Татар әдәби теленең лексик нормалары»), сигезенче («Әдәби телдә грамматик (морфологик) нормалар-

ның тарихи үсеше») бүлек турында фикер йөрткәндә дә күрәбез.

XIX гасырга килеп җиткәч, авторның әдәби тел һәм матур әдәбият теле (тугызынчы бүлек) үсешенә махсус тукталуы да бик урынлы. Чөнки бу инде — милли әдәби тел формалашып килгән чор. «Әдәби тел», «әдәби әсәрләр теле», «язучылар теле» бер үк төшенчә кебек тоелса да алар бер-берсеннән аерыла. XX йөз башында (унынчы бүлек), милли әдәби тел формалашкач, аның тирәсендә җитди каршылыклар барлыкка килә. Ул хәтта вакыт-вакыт сыйнфый характер ала. Мәгълүм ки, тел өлкәсендәге демократик юнәлеш җиңеп чыга. Монда Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һ. б. сүз сәнгате осталарының, галимнәрнең эшчәнлеге шифасы зур була.

Без сүз алып барган хезмәткә кереш сүздә болай диелә:

«Китапта татар тел гыйлеменең бер тармагы булган «Татар әдәби теле тарихы» фәненең катлаулы мәсьәләләре яктыртыла.

Борынгы язулы татар әдәби теленең үсеше Идел буенда төзелгән дәүләтләрдәге (Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы) телләр белән тыгыз бәйләнештә карала. Аннан соңгы дәверләрдә татар әдәби теленең нормалары урнашуы, әдәби телнең стильләр белән тыгыз бәйләнеше тикшерелә, әдәби телне эшкәртүдә әдипләр, укымышлыларның тоткан урыны күрсәтелә.

Студентлар, югары уку йортлары һәм мәктәп укытучылары, фән хезмәткәрләре һәм татар халкының тарихы, язма мирасы белән кызыксынучы киң катлам укучылар өчен».

Бу сүзләрдә хезмәтнең теоретик һәм практик әһәмияте ачыклана. Соңгы вакытта милли тел язмышы өчен зур көрәш башланганны искә алсак, хезмәтнең нык актуальлеге тагын да арта. Хәзер телебезнең үткәне, бүгенгесе, киләчәк язмышына аң-акыл белән генә түгел, зур хис-тойгы, йөрәк сыкрану аша караучылар сафы һаман ишәя. Халык арасына чыксаң, галим икәнлегеңне белеп алсалар, тел турында һич көтелмәгән төрле-төрле сорау биреп гаҗәпләндерәләр. Гаҗәпләнәсең дә, шатланасың да. Үз баласы кебек якын күреп үстергән теленә беркемнең дә битараф булмавын аңлап, куанасың. Чөнки бу тел аның күңеленә, йөрәгенә, бөтен тән күзәнәкләренә ананың бишек җыры-моңы аша сеңгән бит. «Әттә», «әннә» дигән сүзләр белән теле ачылган. Тукай әйтмешли, ул шушы туган тел аркылы дөньяның күп нәрсәләрен танып белгән. Бу телдә ерак ата-бабаларыбызның көрәш каны, данлыклы үткән олы юлы, аналарыбызның илаһилыгы, яшәвебезнең рухы, милләтебезнең горурлыгы барлыкны аңлый халык.

Дөрес, телнең тамырына кат-кат балта белән чапканнар. Әмма өзеп чыгара, тураклый алмаганнар. Өзелгән, киселгән урыны булса, ул еллар үтә-үтә йәнә төзәлеп, үсеп киткән. Бу телне гарәп сүзләре дулкыны да (кайбер галимнәрнең исәпләвенчә, егерменче йөз башына чаклы булган әдәби әсәрләрдә гарәп алынмалары 80 процентка җитә), рус лексикасы ташкыны да күмеп китә алмады, Иван юньсезнең дә теше үтмәде.

Ни гаҗәп, соңгы вакытта рус һәм гарәп сүзләре телебезгә Колорадо коңгызы урынына ябырыла башлады. Туган телебезнең рухы, моңы, җаны-каны югалып бара. Журналистлар тел белән аеруча нык шаяра. Ә менә әдәби тел тарихын белгән кеше һәр авазга, һәр кушымчага, һәр сүзгә бик сак килергә, аның эчке хосусиятен, асыл сыйфатын аңлап эш итәргә тырыша. Шул яктан караганда да, профессор Хаков хезмәтенең файдасы зур булу — бәхәссез.

Хәзер һәр милләтнең әдәби тел тарихы турындагы хезмәтләре еш басыла. Русларда аны санап чыгу да кыен. «Башкорт әдәби тел тарихы» исә башкорт телендә дә, рус телендә дә чыкты. В. Хаков, бәлки, бу хакта да уйланыр. Бу — бер. Икенчедән, шундый зур күләмле хезмәт нибары 1000 тираж белән чыгарылган. Аны халыкка тарату турында уйласаң кашыкка чеметеп он салу кебек кенә булачак... Мондый хезмәтне Татарстан китап нәшрияты аша зур тираж белән чыгарып, бөтен халык массасына сибелерлек итәргә кирәк иде.

Бу китапны укып чыккач, телебезнең бүгенге көнгә чаклы нинди урау, авыр, сикәлтәле, бормалы юлларны үтүенә сокланасың да, гаҗәпләнәсең дә, аптырыйсың да. Әллә ничә чәчәк җыелмасыннан ясалган букетка чагыштырасы килә аны. Ләкин букет тарала да, чәчәкләр барлык кыйтгаларга сибелә. Безнең телебез чәчәкләре үз илебез йөрәгендә тамырлансын иде!

**Суфиян ПОВАРИСОВ,**
филология фәннәре докторы,
профессор.

## Кәшфи Басыйров

(1906—1943)

Татар әдәбияты Ватан сугышы кырларында үзенең байтак каһарман әдипләрен югалтты. Чәчәк кебек гомерләрен күкрәп торган ир уртасы чагында сугыш өзгән әдипләребез арасында исеме бөтен кыйтгаларга танылган герой-шагыйрь Муса Җәлил булган кебек (аның тууына 90 ел тулуны без февраль аенда билгеләп үткән идек), әдәбиятыбызда тыйнак кына үз хезмәтен башкарган бүтән шәхесләребез дә бар. Шуларның берсе — Кәшфи Басыйров.

Кәшфи Басыйровның тууына быел 90 ел тулды. Ул (тулы исеме-аты — Кашшаф Хәбир улы Басыйров) 1906 елның 17 апрелендә Башкортстандагы күп санлы татар авылларының берсендә — Мәтәүбашта дөньяга килә. Бәләбәй шәһәрендә урыс-татар мәктәбендә (1917—1921), аннары Бәләбәй педтехникумында (1922—1927) белем ала. Алты елга якын Башкортстан (Дүртөйледә), Татарстан (Кукмарада) авылларында һәм Казанда мөгаллимлек итә. 1934 елны Таттосиздатка эшкә килеп, 1942 елның башына кадәр — сугышка алынганчы, шунда эшли. Аннары сугышка китә һәм бер ел дигәндә, 1943 елның 16 гыйнварында батырларча һәлак була.

К. Басыйров — кызыклы, үзенчәлекле хикәяче. Аның хикәяләре 1925 елдан башлап матбугатта күренә килә. Әмма аерым җыентыгы — «Танышлар» (Сайланма әсәрләр) — бары тик 1958 елда, үзе һәлак булганнан соң унбиш ел үткәч кенә нәшер ителә.

Урыс телен камил белүче әдип буларак, К. Басыйров үзенең кыска гомере эчендә Рәсәйнең бик күп классик язучылары әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. Татар укучысы аның тәрҗемәсендә М. Лермонтов, Н. Гоголь, А. Чехов, В. Короленко, А. Серафимович, К. Паустовский, В. Катаев һ. б. язучыларның әсәрләрен йотлыгып укый.

Казанның Бауман урамындагы Матбугат йортының бишенче катында Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучыларына мемориаль-истәлек тактасы куелды. Ул мәрмәр тактада Кәшфи Басыйров исеме дә бар.

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНА — ХАЛЫК ЫШАНЫЧЫ

24 мартта Җөмһүриятебездә Татарстан Республикасы Президентын сайлау үткәрелде. ТР Үзәк сайлау комиссиясеннән алынган мәгълүматларга караганда, тавыш бирүдә исемлеккә теркәлгән гражданнарның 77,9 проценты сайлауда катнашкан. Аларның 97,2 проценты Президентлыкка кандидатны яклап тавыш биргән. Шулай итеп, Минтимер Шәрип улы Шәймиев икенче тапкыр Татарстан Республикасы Президенты итеп сайланды. Шул уңайдан аңа дөньяның күп кенә илләре җитәкчеләреннән котлаулар килде.

## КОЛШӘРИФ МӘЧЕТЕНӘ НИГЕЗ САЛЫНДЫ

21 февральдә Казан Кремле тыюлыгында яңа салынасы Колшәриф мәчетенең нигез ташын кую тантанасы булды. Аны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин ачып җибәрде. ТР Президенты М. Шәймиев тантанага килүчеләрне әлеге тарихи вакыйга уңаеннан котлады.

Тантанада шулай ук Татарстан мөфтие Габдулла хәзрәт, Әҗем һәм Борнай мәчетләре имам-хатыйплары Габдерәүф һәм Зөфәр хәзрәтләр, Самара мөфтие Вәгыйз хәзрәт, Казан Кремле тыюлыгы директоры И. Вахитов чыгыш ясады.

Мәчетнең нигез ташын кую вакыйгасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев, халык депутатлары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Яңа мәчет салу фондына Татарстан Президенты шәхсән үзеннән 5 миллион сум акча кертте.

## ИСТАНБУЛДА — ТАТАР КИТАПЛАРЫ

Г. Тукайның тууына 110 ел тулу уңаеннан, Истанбулның Сөләймания мәчетендә татар китаплары күргәзмәсе ачылды. Аны Татарстан Республикасының Дәүләт Советы, Татарстан китап нәшрияты, «Татурос» уртак ширкәте һәм Төрки халыклар мәдәниятен өйрәнү фонды оештырган иде. Күргәзмә соңгы 75 елда Татарстанда китап басу сәнгатенең үсешен чагылдыра. Шул уңайдан бередә, яңа гына нәшер ителгән китаплар белән бергә, утызынчы елларда латин шрифты белән дөнья күргән басмалар да урын алган. «Татар поэзиясе антологиясе» күргәзмәгә килүчеләр арасында аеруча зур кызыксыну уятты.

Сугыш елларында һәм соңгы вакытларда нәшер ителгән, шулай ук Татарстан тарихына кагылышлы китаплар Төркиядә бөтенләйгә калачак. Аларны «Татурос» ширкәте Сөләймания мәчетенең мәдәни үзәгенә бүләк итә.

## ТАТАРСТАН — БАШКОРТСТАН: ЭЛЕМТӘЛӘР НЫГЫЙ

Моннан ике ел элек Башкортстан газета-журнал редакцияләре баш мөхәррирләре, Татарстанда булып, республикабыз журналистлары белән очрашып, ике матбугат министрлыгы арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелгән иде. 13—15 март көннәрендә Татарстан һәм Башкортстан матбугат органнарының җитәкчеләре Башкортстанның Яңавыл шәһәрендә очраштылар. Бу юлы әлеге очрашу ике тугандаш республиканың хөкүмәт җитәкчелеге дәрәҗәсендә үтте. Кунаклар делегациясенә ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, ә хуҗалар делегациясенә Башкортстан Премьер-министры урынбасары Х. Ишморатов җитәкчелек итте.

Республикабызда чыгучы төрле газета-журналларның баш мөхәррирләре, Башкортстандагы каләмдәшләре белән якыннан аралашып, үзара тәҗрибә уртаклаштылар. Соңыннан Башкортстан һәм Татарстанның Мәгълүмат һәм матбугат министрлары И. Әхмәтҗанов һәм Г. Хисамов үзара хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куйдылар.

* * *

27 мартта Казанда, Матбугат йортында, Башкортстанның Ишембай каласыннан — Зәки Вәлиди исемендәге башкорт гимназиясеннән килгән бер төркем мөгаллимнәр һәм аларның шәкертләре белән очрашу булды. Кунаклар алдында «Сабантуй» газетасы, «Ялкын» журналының баш мөхәррирләре Л. Гыймадиева, Э. Закирова, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррирләре Р. Гатауллин, Ш. Мостафин һ. б.лар чыгыш ясадылар. Башкортстанда туып-үскән күренекле язучы — Татарстанның халык шагыйре И. Юзеевның чыгышы тыңлаучыларда аеруча зур кызыксыну уятты.

## ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ

27—30 мартта Казанда «Милли мәктәпләр үсеше» дигән темага халыкара конференция булып үтте. Аны Татарстан һәм Россия мәгариф министрлыклары ЮНЕСКО

белән берлектә үткәрде. Конференция эшендә АКШ, Финляндия, Төркия, Румыния, Австрия, Украина, Казагыстан, Беларусь, Молдова һ. б. илләрнең күренекле вәкилләре бүгенге шартларда милли мәгарифне үстерү проблемалары буенча фикер алыштылар.

### МӘСКӘҮДӘ — ТАТАРЧА ГАЗЕТА

Мәскәү дәүләт университетының журналистика факультетында «Яңа сүз» дигән газета чыга башлады. Аның баш мөхәррире — Татарстанның Азнакай районы кызы Надия Грона. Газетаның редколлегиясенә Мәскәүдә яшәүче аеруча күренекле милләттәшләребез кертелгән.

«Яңа сүз»нең беренче-икенче саннарында татар халкының мәшһүр уллары Гаяз Исхакый һәм Муса Җәлилгә багышланган махсус сәхифәләр урын алган, татар дөньясыннан төрле кызыклы хәбәрләр урнаштырылган, шәригать кануннары бирелгән.

## *ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ*

### ТӨРКИЯ ЯЗУЧЫЛАРЫ КОРЫЛТАЕНДА

Соңгы елларда төрки халыклар арасында рухи өлкәдә үзара элемтәләр һәм хезмәттәшлеккә омтылыш аеруча нык сизелә. Март башында Анкарада Төркия язучыларының 9 нчы корылтаенда бу аеруча ачык күренде. Бирегә бу илнең барлык төбәкләреннән генә түгел, бәлки байтак башка төрки җөмһүриятләрдән дә каләм әһелләре җыелган иде. Аның эшендә Казагыстан, Үзбәкстан, Әзербәйҗан, Кыргызстан, элекке Югославиянең Македония, Косово республикаларыннан һәм башка илләрдән делегацияләр катнашты. Төркия башкаласына Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев һәм тәнкыйтьче Фоат Галимуллин чакырылган иде. Безнең делегациянең чыгышы әдәби форумда катнашучыларда зур кызыксыну уятты, анда татар сүз сәнгатенең бүгенге торышына тирән анализ ясалды.

3 мартта Төркиянең Конья шәһәрендә төрки җөмһүриятләр язучылар оешмаларының конференциясе булды, кардәш халыкларның әдәбиятларын үстерүне тәэмин итү, аларның үзара хезмәттәшлеген җайга салу юллары билгеләнде.

### ОСТАХАНӘЛӘРДӘ

И. Юзеев җитәкләгән «Шигърият остаханәсе» үз эшчәнлеген көннән-көн ныграк җәелдерә. Остаханә утырышларын хәзер төрле аудиторияләрдә үткәрү матур бер гадәткә әверелде. Мәсәлән, Казанның М. Горький исемендәге музеенда атаклы милләттәшебез Бакый Урманченың туууына 99 ел тулуга багышлап үткәрелгән кичәдә (бирелдә рәссам-сынчының «Хатын-кыз портретлары» дигән күргәзмәсе дә оештырылган иде) И. Юзеев, Р. Гаташ, А. Миңһаҗева һәм остаханәгә йөрүче яшь авторларның мәхәббәт турындагы шигырьләре яңгырады. Кичәдә Татарстан Дәүләт Советының комиссия рәисе — шагыйрь Р. Миңнуллин һәм ТР Мәдәният министры урынбасары М. Низамиев та катнашты һәм чыгыш ясады.

* * *

«Шигърият остаханәсе»нең чираттагы бер утырышы Казан дәүләт педагогия университетының яшь иҗатчылары Чулпан Зариф, Гүзәл Галиева, Гөлүсә Закирова, Рәмзия Сабирҗанова шигырьләрен тикшерүгә багышланды. Уңышлы дип табылган әсәрләр «Ватаным Татарстан» газетасына тәкъдим ителде.

* * *

«Балалар әдәбияты остаханәсе» (җитәкчесе — Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиев), «Шигърият остаханәсе» белән берлектә, танылган фольклорчы-галим һәм шагыйрь Рәшит Ягъфәров иҗаты турында зур сөйләшү үткәрде. Фикер алышуларда Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Миңнуллин, М. Фәйзуллина, Р. Рахмани, Г. Гыйльманов, Л. Гыймадиева, Р. Зәйдулла, Р. Мулланурова, Л. Лерон һ. б. катнаштылар. Р. Ягъфәров иҗатына уңай бәя бирелеп, ул бертавыштан Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим ителде.

## *ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР*

### РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Әлмәт хакимияте олуг талант иясе — күренекле прозаик, Бөек Ватан сугышы ветераны Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия булдырды. Ул һәр елны, шушы төбәктә яшәп, замандашларыбызның матур образларын иҗат иткән язучыларга, рәссамнарга, композиторларга, күренекле әдәбият-сәнгать әһелләренә биреләчәк.

1995 ел йомгаклары буенча Р. Төхфәтуллин исемендәге премиягә шагыйрь Нур Әхмәдиев, публицистик язмалары өчен Әлмәт шәһәре прокуроры Флер Баһаветдинов, музыка һәм театр сәнгате өлкәсендә композитор Разим Вәлиуллин (Лениногорск) һәм артистка Дилбәр Әбүнәгыймова (Әлмәт татар дәүләт драма театры) лаек булды.

### РАВИЛ ФӘХРЕТДИНОВКА — ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК ПРЕМИЯСЕ

Моннан өч ел элек Бөгелмә җәмәгатьчелеге «Мәгърифәтче» премиясе булдырган иде. Беренче елны ул районның танылган мөгаллимнәре — телебезнең гаярь сакчылары Дания Солтанова белән Рәүф Ибраһимовка бирелде. Былтыр әлеге премия күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Халимгә тапшырылды.

Быел исә әлеге бүләккә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан күренекле тарихчы-археолог галимебез, Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты Равил Фәхретдинов лаек дип табылды. Аңа 2 миллион сумлык премияне мәшһүр мәгърифәтче Һади Атласиның

улы — танылган нефтьче Угыз Атласи һәм күренекле журналист-публицист Дамир Асылов тапшырды.

### ЮБИЛЕЙЛАР, ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

12 мартта «Казан» милли-мәдәни үзәгендә, «Алтынчәч», «Качкын», «Түләк», «Илдар» операларының, «Сабантуй» симфониясенең һ. б. бик күп музыкаль әсәрләрнең авторы, танылган татар композиторы Н. Җиһановның тууына 85 ел тулу уңаеннан, әдәби-музыкаль кичә булды. Анда композиторның әсәрләрен Р. Ибраһимов, Х. Бигичев, В. Ганиева, М. Сиражетдинов, Л. Маслова кебек җырчылар һәм музыкантлар башкарды.

* * *

Фронтовик-язучы, дистәләгән китаплар авторы Геннадий Паушкинның тууына 75 ел тулу уңаеннан, Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Анда әдипне Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, каләмдәшләре Р. Кутуй, М. Зарецкий, Н. Орешина, Д. Вәлиев котладылар. Шагыйрьләр О. Лададная, Р. Кожевникова, Л. Газизова, Н. Ахунова яңа шигырьләрен укыдылар.

* * *

12 мартта ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге һәм Мөслим районы хакимияте Мөслимдәге мәдәният йортында танылган әдип һәм драматург Фоат Садриевның тууына — 55, иҗат эшчәнлегенә 30 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе үткәрделәр. Әлмәт төбәге язучылары җитәкчесе Р. Вәлиуллин, Мөслим районы хакимияте башлыгы Р. Шәрипов, Түбән Камадагы якташлар җәмгыятеннән Ф. Абдуллин һ. б. юбилярның адресына котлау сүзләрен җиткерделәр, бүләкләр тапшырдылар.

Юбилей кичәсендә Ф. Садриевның «Безнең авыл кызлары» пьесасы буенча Әлмәт драма театры коллективы куйган спектакле күрсәтелде.

* * *

28 мартта Казандагы Театр әһелләре йортында танылган шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Роберт Әхмәтҗановның иҗат кичәсе булып үтте. Анда шагыйрьне якташлары, каләмдәшләре Р. Мөхәммәдиев, Р. Фәйзуллин, танылган сәнгать осталары У. Әлмиев, Ф. Сөләйманова, Р. Сәхәбиев, Г. Ильясов, В. Гыйззәтуллина, Р. Миндияр, А. Арсланов, Р. Шәрәфи, Х. Җәләлов һ. б. кайнар котладылар, яңа иҗади уңышлар теләделәр.

## *СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНДА*

### ТЕАТРЛАР БӘЙРӘМЕ

20—27 март көннәрендә Казанда К. Тинчурин исемендәге IV республика театр фестивале узды. Башкалабыз театрларында барлыгы 12 профессиональ коллективның һәм Уфадан «Нур» татар дәүләт театрының яңа спектакльләре күрсәтелде. Фестиваль 27 мартта, Халыкара театр көнендә Актерлар йортында бүләкләү тантанасы белән тәмамланды. Бүләкләнүчеләр арасында язучы Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») әсәрен сәхнәләштергән Яшьләр театры коллективы (директоры һәм режиссеры — Фәрит Хәбибуллин) да бар.

### МУЗЫКА ФЕСТИВАЛЕ

22—27 март көннәрендә Казан, Чаллы шәһәрләрендә «Аурупа — Азия» дигән II халыкара музыка фестивале булып үтте. Аны Татарстан композиторлар берлеге оештырган иде. Бирегә музыка әһелләре дөньяның төрле илләреннән килде.

### «ТАҢБАТЫР» — КИНО БАЗАРЫНДА

16 мартта Мәскәүдә Россия һәм чит ил кинокомпанияләре катнашында чираттагы кино-базар ачылды. Татарстан Республикасы киносы бирегә үзенең беренче иҗат җимешен — татар халык әкиятләре мотивлары нигезендә эшләнгән «Таңбатыр» мультфильмын тәкъдим итте. Фильмның режиссеры — Г. Сәйфетдинов, рәссамы — И. Маханова. Көйләрне исә композитор А. Монасыйпов язган.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Президенты Указы нигезендә, музыка сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисткасы — музыка уен коралларында уйнаучы **Лариса Владимировна Масловага** «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Габдулла Тукайга Яңа Кырлай авылында куелган һәйкәл.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Мин Тукайга киләм.** Төзүчесе Г. БӘЙРӘМОВА. Шигырьләр. Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1996 ел. 248 бит. Тиражы — 3000 данә.

Моннан нәкъ 20 ел элек «Тукайга чәчәкләр» дип исемләнгән китап чыккан иде. Аңа татар һәм бүтән халык әдәбияты вәкилләре — шагыйрьләре, әдипләре, философ-зыялыларының бөек Тукайга багышланган шигырьләре, фикер-уйлары теркәлгән иде. «Мин Тукайга киләм» җыентыгын алда әйтелгән китапның дәвамы дип әйтеп була. Аерма шул: бу җыентыкка фәкать шагыйрьләрнең шигырьләре тупланган. Анда Бабич, Сүнчәләй, Гафури кебек Тукай замандашларының да, безнең чор классиклары Х. Туфан, С. Хәким, М. Кәрим кебек өлкәннәрнең дә, бүгенге әдипләребез Г. Афзал, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт һ. б. да шигырьләре тупланган. Китап Тукайның 110 еллык юбилее уңае белән нәшер ителгән.

**Юл догалары** (Коръән сүрәләре). Төзүчесе һәм мөхәррире — Равил РАХМАН. Рәссамы — Дамир Җәләлетдин. Сувенир басма. Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1995 ел. 96 бит. Тиражы — 20000 данә.



Кеше һәрвакыт юлда-хәрәкәттә, язмышы каршысында билгесезлек эчендә яши. Шуңа күрә дә, күрәсең, хәер-фатихасыз, Юл догасыз үзеңне тыныч һәм бәхетле итеп тою мөмкин түгелдер. Әлеге китапчык укучыларыбызның әнә шушы олы ихтыяҗын исәпкә алып чыгарылган. Аны ата-анаң, якыннарың, кардәшләреңнең ак теләкләрен чагылдырган символ-талисман итеп тә, төрле бәла-казалардан саклаучы изге бөти-амулет буларак та кабул итәргә мөмкин.

Китапның беренче бүлеге нәкъ әнә шундый — мөселманнар тормышында тылсымлы-изге хасиятләре белән зур роль уйнаган Коръән сүрәләреннән тора да. Китапның алдагы бүлекләре дә гамәли ихтыяҗларны күз алдында тотып төзелгән. Икенче бүлек, әйтик, биш вакыт намаз догаларын үз эченә алуы белән игътибарга лаек. Өченче бүлек исә юл догаларын берләштерә.

Китап уч төбенә сыярлык форматта яхшы итеп бизәлеп чыгарылган.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)